

# казан утлары

4
АПРЕЛЬ-1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**4**

АПРЕЛЬ
1970

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## Бу санда:

Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу турында коммунистлар һәм эшчеләр партияләре киңәшмәсе мөрәҗәгате . . . . . . . . . . 3

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга карата Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты тезисларыннан . . . . . . . . 5

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Н. ДӘҮЛИ. Ленин турыкда уйлар. Шигырь. . 7
С. БАТТАЛ. Безне саклаган. Шигырь. . . . . 8
З. НУРИ. Йөрәккә якын җырләрдә. Шигырьләр. 9
М. ЛЬВОВ. Якташ. Шигырь . . . . . . . . . 14
С. КАЛЯЕВ. Ленинны җырлыйм. Шигырь. . . 15
Э. РОМЕРО. Ленин. Шигырь. . . . . . . 16
Э. КАРРЕРА ГЕРРА. Эшче иртәсе. Шигырь . 16
Б. МОЛОКУ. Ильичка. Шигырь. . . . . . 17
Ленин матбугатта. . . . . . . . . . . . . . 18
Н. К. КРУПСКАЯ. Ильичка нинди әдәби әсәрләр ошый иде. . . . . . . . . . . . . 19
Л. РАДИЩЕВ. Бер кечкенә эш. Хикәя. . . . 22

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

Э. КАСЫЙМОВ. Сорбонна профессоры. Повесть. . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Р. ГАТАУЛЛИН. Зур темага эскизлар. Шигырь. . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Р. МИНГАЛИМОВ. Минем дәүләт. Поэма. . 72
И. ЙОСЫПОВ. Тукайга. Шигырь. . . . . . 78
И. НУРУЛЛИН. Хәсрәт бакчасы. Хикәя. . . 79
Г. МӨХӘММӘТШИН. Йөрәктәге эзләр. Повесть. . . . . . . . . . . . . . . . . 93

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. МОСТАФИН. Минем горурлыгым. . . . 122

ЛЕНИН ДОКУМЕНТЛАРЫ ЭЗЕННӘН

А. КОСТИН, И. МОРАТОВ, А. МӨСЛИМОВ. Киң фарватерга чыкканда. . . . . 129
А. ХӘРӘВИЕВ. Ягулык фронтында. . . . . 132
Ф. ӘСЫЙРОВ. «Ленинга хат җибәрик!». . 134

**И. НИЗАМОВ.** «Сагындым мин Иделне!». . 138

**М. ХӘСӘНОВ.** Ленин тәгълиматы һәм татар халкының иҗтимагый-политик фикер тарихын өйрәнү мәсьәләләре. . . . . . . . . 142

**С. САБИРОВ.** Ул көннәрдә. . . . . . . 152

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

**М. ЗАРИПОВ, Г. АХУНОВ.** Тормыш китабы. 158
**С. ШАКИР.** Онытылмас хатирә. . . . . . . 163

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

**А. МӨСЛИМОВ.** Ильич үрнәгендә. . . . . 168
**С. ЧЕРВОННАЯ.** Куанычлы күренеш. . . . . 171

ЗУР БӘЙРӘМГӘ ЯҢА КИТАПЛАР

Безнең лениниана . . . . . . . . . . . . 177

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**З. СӘЙДӘШЕВА.** Татар халкының революцион җырлары. . . . . . . . . . . . . 180

Безнең сафка. . . . . . . . . . . . . . 185

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

**Р. ФӘИЗОВ.** Соңгы батыр. Хикәя. . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . 189

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 30/I-1970 ел. Басарга кул куелды 17/III-1970 ел. ПФ 00132. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 88646 экз. Заказ С-61. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1970 ел.

# ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУ ТУРЫНДА КОММУНИСТЛАР һӘМ ЭШЧЕЛӘР ПАРТИЯЛӘРЕ КИҢӘШМӘСЕ МӨРӘҖӘГАТЕ

*В. И. Ленинның туууна 100 ел тулу юбилее алдыннан коммунистлар һәм эшчеләр партияләре киңәшмәсе үзенең фикерләрен революцион эпохабызның мәңгелек даһиена юнәлдерә.*

*Ленин исеме Бөек Октябрь җиңүенең, дөньяның социаль йөзен тамырдан үзгәрткән, кешелек дөньясының социализмга һәм коммунизмга таба борылуын күрсәткән гаять зур революцион эшләрнең символына әверелде.*

*Ленин — Маркс һәм Энгельс иҗат иткән фәнне: диалектик материализмны, политик экономияне, социалистик революция һәм коммунистик җәмгыять төзү теориясен һәр яклап үстергән күренекле фикер иясе.*

*Ленин — большевиклар партиясен — яңа типтагы беренче пролетар партияне төзүче, дөньяда беренче җиңеп чыккан социалистик революциянең җитәкчесе, тарихта беренче пролетариат дәүләтенә, совет социалистик демократиясенә нигез салучы.*

*Ленин — империализмга һәм реакциягә каршы какшамас көрәшче, уртак сыйнфый дошманга каршы бәрелешләрдә хезмәт ияләренең барлык отрядларының хәрәкәт бердәмлеген саклап калган көрәшче; эзлекле интернационалист, халыклар арасында тигезлек, тынычлык һәм дуслык өчен көрәшче, расизмның һәм шовинизмның һәртөрле күренешләрен ачу белән гаепләүче; барлык изелгән милләтләрнең дусы, колониализмга каршы, халыкларның бәйсезлеге һәм азатлыгы өчен, аларның үз язмышларын үзләре билгеләү хокукы өчен көрәшнең җиңүле юлын ачкан кеше.*

*Халыкара эшчеләр сыйныфының танылган юлбашчысы Ленин пролетариатта дөньякүләм-тарихи миссияне — капитализмны бәреп төшерү һәм җәмгыятьне социалистик үзгәртеп кору миссиясен үтәргә сәләтле алдынгы көчне күрде. Ул эшчеләр сыйныфының крестьяннар белән союзы турында тәгълимат эшләде. Эшчеләр хәрәкәтенең бердәмлеген саклап, Ленин барлык формалардагы оппортунизмга килешмәүчән булды.*

*Ленинизм тәэсирендә коммунистларның эшчеләр сыйныфына, халыкка, социализм эшенә чын күңелдән бирелгән буыннары үсте. Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге, аның революционер, иптәш, кеше буларак югары сыйфатлары бөтен дөньяда миллионнарча революцион көрәшчеләргә һәрвакыт рухландыргыч үрнәк булып хезмәт итәләр.*

*Ленинизм байрагы астында күпчелек илләрдә революцион хәрәкәт яңа дәрәҗәгә күтәрелде. Коммунистик партияләр төзелде һәм ныгыды, халыкара коммунистик хәрәкәт чын-чыннан бөтен дөнья күләмендәге, хәзерге заманның иң йогынтылы политик көченә әверелде.*

*Бөтен дөнья социализмының, эшчеләр һәм милли азатлык хәрәкәтенең бөтен тәҗрибәсе марксизм-ленинизм тәгълиматының халыкара әһәмиятен раслады. Байтак илләрдә социалистик революциянең җиңүе, бөтендөнья социализм системасының барлыкка килүе, капитал илләрендә эшчеләр хәрәкәтенең казанышлары, элекке колонияләр һәм ярымколонияләр халыкларының мөстәкыйль иҗтимагый-политик эшчәнлек мәйданына чыгуы, антиимпериалистик көрәшнең тиңдәшсез күтәрелеше — болар барысы да хәзерге эпоханың төп ихтыяҗларын чагылдыра торган ленинизмның тарихи дөреслеген исбат итәләр.*

*Бүген без тулы нигез белән Ленин тәгълиматы турында марксизмны характерлаганда ул үзе әйткән сүзләрне үк әйтәбез: бу тәгълимат көчле, чөнки ул дөрес. Марксизм-ленинизм теориясе, аны конкрет шартларда иҗади куллану бөтендөнья революцион хәрәкәтенең теләсә кайда эш итүче барлык отрядлары алдына килеп баса торган сорауларга фәнни җаваплар эшләргә мөмкинлек бирәләр.*

*Бөек интернациональ тәгълимат булган марксизм-ленинизмга тугрылык — коммунистик хәрәкәтнең киләчәктәге уңышларының залогы.*

*Һәртөрле дошманнарга каршы көрәштә марксизм-ленинизмның, пролетар интернационализмның революцион принципларын нык яклауны, аларны тайпылышсыз тормышка ашыруны, марксизм-ленинизм теориясен даими үстерүне, аны сыйнфый көрәшнең һәм социалистик җәмгыять төзүнең хәзерге тәҗрибәсе нигезендә баетуны коммунистлар үзләренең бурычлары дип саныйлар. Коммунистлар ленинизмның иҗади рухына һәрвакыт турылыклы булырлар.*

*Якынлашып килүче Ленин юбилее — бөтен дөнья күләмендә әһәмиятле тарихи дата. Коммунистлар һәм эшчеләр партияләре бу датаны үзләренең революцион эшчәнлеген активлаштыру шартларында каршылыйлар һәм аны массалар арасында политик һәм идеология эшен көчәйтү белән, үз сафларын киңәйтү һәм ныгыту белән билгеләп үтәрләр. Алар хезмәт ияләренең революцион энергиясен империализмга каршы, социализмның якты идеаллары өчен көрәшкә туплауга бөтен көчләрен бирәләр.*

*Коммунистлар һәм эшчеләр партияләренең халыкара киңәшмәсендә катнашучылар, бөек Ленинның тууына 100 ел тулуны лаеклы билгеләп үтәргә чакырып, барлык коммунистларга, җәмгыятьне социалистик үзгәртеп кору өчен барлык көрәшчеләргә, прогресс һәм тынычлык ягында торучы барлык кешеләргә мөрәҗәгать итәләр. Ленин хезмәтләрен өйрәнегез! Аларда сез реакциягә һәм изүгә каршы, социализм һәм тынычлык өчен көрәшкә бетмәс-төкәнмәс рухлану чыганагы табарсыз. Алар белән танышу яшь буынга эпохабызның революцион перспективаларын ачыграк күрергә ярдәм итәр. Ленинизм казанышларын, социалистик илләрнең, коммунистик партияләрнең, барлык революцион көчләрнең уңышларын киңрәк пропагандалагыз!*

*Барлык илләрнең хезмәт ияләре, бөтен дөнья халыклары!*

*Ленин идеалларының тантанасы хакына сезне эшчеләр сыйныфының тынычлык, демократия, милли бәйсезлек һәм социализм өчен бөек һәм изге көрәшенә актив кушылырга чакырабыз!*

*Дөньяны революцион яңарту өчен көрәштә ленинизм байрагын югарырак күтәрик!*

*Яшәсен ленинизм!*

17 июнь, 1969 ел. Мәскәү.

# ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУГА КАРАТА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ КОММУНИСТЛАР ПАРТИЯСЕ ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ТЕЗИСЛАРЫННАН

*...Социализмның бурычы, диде Ленин, культураның барлык казанышларын хезмәт ияләре интересларына хезмәт итүгә куюдан гыйбарәт. Политик властьның эшчеләр сыйныфы кулына күчүе белән фән, техника, сәнгать казанышлары бөтен халык байлыгына әверелә, кешелек талантын эксплуатация чарасына яки средствосына әверелдерү мөмкинлеге тәмам бетерелә.*

*Ленинның культура революциясе программасы революцион теориягә һәм практикага кертелгән әһәмиятле өлеш булды. Аның төп эчтәлеге: халык мәгарифен күтәрү — хезмәт ияләренең иң киң массаларын политикага, белемнәргә, эстетик кыйммәтләргә тарту өчен барлык шартларны тудыру; фәнни социалистик идеологияне җәелдерү һәм аның принципларына халыкның бөтен рухи тормышын оештыру; буржуаз карашларны һәм гореф-гадәтләрне җиңү.*

*Хәзер СССР халкының өчтән бер өлешеннән артыграгы югары һәм урта белемле, гомуми урта белем бирүгә күчү тормышка ашырыла. Халык хуҗалыгы һәм культураның барлык тармакларында 820 меңнән артык фән работнигы эшли. Эшчеләрнең, крестьяннарның, хезмәткәрләрнең өзлексез күтәрелә барган эш квалификациясе гаять зур иҗтимагый байлык булып тора.*

*Партия социалистик җәмгыятьтә рухи иҗатны һәрвакыт гомумпартия, гомумпролетар эшнең аерылгысыз өлеше дип карады. Ленинчыл принциплар — әдәбият һәм сәнгатьнең партиялелеге һәм халыкчанлыгы принциплары художество интеллигенциясенең иң яхшы көчләрен Совет властеның идея-политик платформасында туплауның нигезе булды. Талантка, иҗади эзләнүгә игътибарлы караш рухи эшчәнлеккә ленинчыл караштa идея-политик позицияләрнең принципиальлеге, әхлак-эстетика таләпләренең төгәллеге белән бергә кушыла. Ленин антисоциалистик идеяләрне, үзе атаганча, «әдәбият белән пәрдәләү» дигән нәрсәгә, модалы фраза ярдәмендә реакцион карашлар сөйрәп кертүгә, эчтәлекнең фәкыйрьлеген формалистик боргаланулар белән яшерергә маташуларга килешмәүчән булды, художество әсәрләренә бәя бирүдә гадиләштерүгә һәм субъективизмга каршы чыкты.*

*Социалистик культура — кешелекнең рухи үсешендә дөнья-күләм тарихи адым...*

*...Ленин коммунизмның рухи алшартларын булдыруда, яңа кеше тәрбияләүдә әдәбиятка һәм сәнгатькә мөһим урын бирде. Коммунизм төзүче җәмгыять әдәбиятның һәм сәнгатьнең барлык формалардагы художество иҗатының чәчәк атуы белән тирәнтен кызыксына. Аларның җәмгыять каршындагы кыйммәте югары художество осталыгы, идея ягыннан компромиссызлыгы һәм коммунистик идеалларны раслауда партияле ялкынлылык белән билгеләнә...*

*...Ленинның мәңгелек идеяләре һәм эшләре, аның тормышының бөек батырлыгы совет кешеләре өчен, бөтен дөнья хезмәт ияләре өчен бетмәс-төкәнмәс рухлану һәм оптимизм чыганагы булып тора.*

*Ленинның якты даһилыгы революцион көрәш һәм иҗади төзелеш юлын балкыта.*

*Ленинча яшәү һәм көрәшү — бөтен көчеңне, белемеңне, энергияңне җир йөзендә иң гуманлы һәм гадел эшкә — хезмәт ияләрен изелүдән һәм эксплуатациядән тулысынча азат итү өчен, коммунистик идеалларның җиңүе өчен, кешелекнең иң яхшы киләчәге өчен көрәшкә бирү дигән сүз.*

*Ленин эшен дәвам иттереп, совет халкы тырыш хезмәт белән җәмгыять байлыгын арттыра, социалистик демократияне, фәнне һәм культураны үстерә, социалистик Ватанның оборона куәтен ныгыту турында армый-талмый кайгырта, кешегә лаек булырлык яңа тормыш төзи.*

*Ленин эшен дәвам иттереп, совет халкы Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә үз сафларын тагын да тыгызрак туплый. СССР халыкларының туганлыгын һәм дуслыгын ныгыта.*

*Ленин эшен дәвам иттереп, совет халкы социалистик илләр халыклары белән, халыкара эшчеләр сыйныфы белән, демократия һәм милли азатлык өчен, нык тынычлык, демократия һәм социализм өчен, марксизм-ленинизм идеяләренең тантанасы өчен көрәшчеләр белән интернациональ бердәмлекне ныгыта.*

*Владимир Ильич Ленинның идеяләре коммунистларның эшчәнлегендә, эшчеләр сыйныфының һәм барлык хезмәт ияләренең көрәшендә, социализмның һәм коммунизмның омтылышлы үсешендә, кешелек дөньясының җиңелмәслек социаль прогрессында гәүдәләнә.*

*Ленинның исеме һәм эше мәңге яшәр!*




# *ЛЕНИН—*
# *БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

## Нәби Дәүли

### Ленин турында уйлар

Ленин,—
үле түгел,
тере,—
Тере кеше йөрәгендә.
Бу планета,—
Аның ватаны.
Туса да ул —
Идел буенда.
Халыкларның
яши илләрендә,
өйләрендә,
яши телләрендә,
тормышында,
яши уенда.

Ленин, —
таштан куйган
һәйкәл түгел,
Тимердән койган
монумент түгел.
Алар нәрсә? —
салкын гранит,
һәм соры металл.
Ленин,—
җир кешесе,
җирнең хезмәтчесе,
һәм җир ана,—
үзе пьедестал.

Ленин,—
әкият түгел,
истәлек түгел,

укырга кичен
эч пошканда,
тыныч төннәрдә.
Ленин, —
өмет кешегә
җирдә,
күктә,
туктаусыз,
куркусыз барырга
Бәхетле,
киләчәк көннәргә.

Мактанма,
эшлә син,
Сөйләнмә,
яшә син.
Бул гади,—
тимерче,
төзүче.
Бул шагыйрь,
министр,
бул кырда игенче.
Нәкъ шулай булганда,
илеңне,
халкыңны
яратып торганда,
Син хаклы әйтергә:
Мин кеше!
Ленинчы!

## Салих Баттал

### Безне саклаган

Бала өчен кискен көрәшләрдә
Корбан була ата-аналар:
«Үзебез һәлак булсак булыйк,— диләр,—
Яшәсеннәр безнең балалар...»
Бөтен гомере һәм көрәше белән
Даһиларча безне яклаган
Ленин
Капланнарның пулясыннан
тәне белән безне саклаган.

Зәки Нури

# ЙӨРӘККӘ ЯКЫН ҖИРЛӘРДӘ

*Шигъри этюдлар*

## Җыр белән яңа очрашу

«Ниһаять, сөргеннен
очына чыгылды!» —
Диеп ул, бер көнне
иркенләп сулады.
Хушыгыз, камышлар,
хушыгыз, танышлар!
Хушыгыз, болыннар
һәм Үшнә буйлары!

...Казанда театр.
Куялар опера.
Володя Ульянов
балконда утыра.
Янында — Дмитрий,
икәүләп тыңлыйлар.
Оркестр ду килә,
авазлар тынмыйлар.
Сәхнәдә — тылсымлы
чишмә бар шикелле:
Әнә ул, ярсынып,
таш ярга сикерде,
Әнә ул, уйнаклап,
бөтерелә юлында,
Әнә ул чәчәккә
әйләнә болында.
Бервакыт аңарга
ермаклар кушыла,—
Яңа көй башлый ул
сөенеп шушыңа.
Әнә ул, борылып,
кирегә агыла...
Һәр тыны, һәр моңы
йөрәккә кагыла.
Афиша белдерә:

«Кардинал кызы» дип.
Сәхнәдә кем җырлый?
зур тормыш үзе бит!
Уйлана Володя:
тормыш ул — кичереш,
Тормыш ул — ашкыну,
ярсу һәм сикереш.
Тормыш ул үзе дә
агыла җыр булып —
Кайчакта чигенеп,
кайчакта ыргылып...

Иделдә бурлаклар
ыңгырашын ишеттем,
Моң-зарлы Аппакай
көйләре исемдә.
Көр тавыш яшенләп
күкрәми ничектер,—
Күрәсең, буылган
агымы хисең дә.

Әйе шул, әйе, җыр,
минор күп синдә дә,
Мажорның колачы
бүгенгә тар әле...
Залимнар утыра
синең киң иңдә дә,
Синең дә богаулар
өзәсең бар әле!
Ә бүген — рәхмәт, дус!
Мин бүген бик шатмын,
Үзе бер бәхет ул —
очрашу җыр белән.
Күзаллый күңелем
шушындый бер чакны:
Аваздаш булыр җыр
өр-яңа чор белән!

Казан

## Шушь елгасы буенда

Иделемнән кайнар сәлам алып
Килдем, Себер, синең Шушена.
«Россиянең үткән чоры белән
Киләчәге монда кушыла».

Беләм, Себер, шулай дигәнсең син,
Килеп төшкәч Ленин бу якка.
Аның кулы тигәндер дип уйлыйм
Биредә мин һәрбер куакка.

Кочкандыр ул Шушьның һәр дулкынын,
Һәр сукмакта эзе бар кебек.
Себер хәтле бу Себер дә аның
Киң колачы өчен тар кебек.

Ә ул язган, ул уйлаган чакта
Тынганнардыр шаулы бураннар.
Көтә аны монда, күптән көтә
Яңартылган иске урамнар.

Ул Россия «Капитал»ын яза,
Үстерә ул Маркс гыйлемен.
Капитализм! «Үсеш» дигән сүздән
Килеп чыга синең үлемең.

Көн-төн утыра кайчак бүленмичә,
Артык түгел бер дә ашыгу.
Сембер. Казан. Самар. Петербург...—
Юлның әле бары башы бу.

Ә ял дисә — торды, чыкты китте...
Кауарый күле, Торна тавы бар.
Шугалагы Шушьның көзге кебек,
Карурманның әйбәт авы бар.

...Шушь буйлары. Шул һаваны сулап,
Шул юлларны таптап йөргән ул.
Бу як ерак... ләкин һәр урында
Якын булып төшкә кергән ул.

Иделемә кайнар сәлам алып
Китәм, Себер, синең Шушеннан.
Россиянең үткән көне белән
Киләчәге шунда кушылган.

Шушенское

## Тауларга менү

Польшаның үз Альп тавы бар,
Исеме аның — Татр.
Ул монда җырлар герое,
Ул монда Алып-батыр.

Бу тауда биек түбәләр
Ап-ак эшләпә кигән...
Тауларда йөрүне Ленин
«Акробатика» дигән.

Үрләрдән үргә менгән ул
Бар көчен аямыйча,
Кулында таяк булса да,
Таякка таянмыйча.

Янында — поляк дуслары,
Таянган шуларга ул.
Я ташка ышкылып үтә,
Я тия суларга юл...

И рәхәт! Башны болытка
Тидереп йөреп була.
Биеккәрәк менгән саен
Күбрәкне күреп була!

Күренә моннан Россия
Күгендә кара болыт —
Патшалар намусы төсле
Караңгы-кара булып.

Күренә узасы юллар,
Юлларның — киртәләре.
Барып җитәсе көннәрнең
Кояшлы иртәләре...

Алмыйча күңел күзләрен
Шул якты көннән Ленин,
Ераккарак карар өчен
Тауларга менгән Ленин.

Закопане

## Диңгез Күзе

Кара диңгез бик еракта үзе.
Ә Татрда бар бер зәңгәр күзе:
Тау төбеннән күккә карап тора,
Диңгезне һәм үзен яраттыра!
Нәни генә бер күз, кысык кына,—
Биек ярлар аны кысып тора.
Тып-тын ята ташлар арасында.
Серле моң бар аның карашында.
Күпләр килә аны күрер өчен,
Төрле телдә сәлам бирер өчен.
Күреп тора шуның һәммәсен ул!
Ә бер көнне Ленин шәүләсен ул
Чагылдырды якты күзгесендә —
Күзгедән дә якты күзге көндә.
Әллә ялга, әллә ауга менде? —
Ул көнне дә Ленин тауга менде.
Карап торды күлгә исе китеп,
Нәкъ Россия күзе төсе итеп.
Алар икәү: дусты-юлдашы бар,
Күз алмыйча карый ул да шуңар.
Бу күлнең ул ерак чорын белә,
Легендасын — язмыш җырын белә.

...Бу җирләрдә, имеш, диңгез булган,
Җил юк чакта өсте тигез булган.
Ә давылда шаулап ярсыган ул,
Үз киңлеген гүя тарсынган ул.

Бу таулар да, кыя ташлы яр да —
Су төбендә яткан бар да, бар да...
Ә бер чакны Дингез кучеп китә.
Мәгълүм түгел — кайчан, ничек китә.
Күчеп китә бүтән тау ягына,
Ә биредә бер күз пәйда була.
Калдырган ди аны Дингез үзе,
Шуңа күрә исеме: Дингез Күзе.
Бу тауларны көн дә күрсен өчен,
Шуннан көн дә хәбәр бирсен өчен
Калдырган ди. Ахры, теләмәгән
Китәргә ул тәүге биләмәдән.
Юллар яшерен... маяк тезелмәгән...
Аралары ләкин өзелмәгән.
Үзе киткән, ләкин эзе калган —
Туган якны күрер Күзе калган...

Ачкан өчен ана Дингез Күзен
Ленин хуплый поляк дусның сүзен.
Аннары ул чыга юл өстенә.
Тагын аска, тагын күл өстенә
Тагын кат-кат карап куйгач кына,
Әрле-бирле атлап уйга чума...
Шунда туып нинди зирәк уйлар,
Кичте икән нинди ерак юллар?
Күз алдына әллә китердеме
Сине, Идел? Әллә Питерneме?
Бәлки, сүзнең яшерен эзләрен ул,
Дусларының яшен-күзләрен ул
Уйлагандыр? Туган якта алар...
Торалар бит бар да сакта алар!
Хәбәр кылә, сүзләр йөреп тора,—
Күзләр, димәк, яхшы күреп тора.
Әйе, шуны, шуны уйлагандыр,
Россиягә сәлам юллагандыр:
«Хәтерләтеп дингез күзләрен сез,
Яктырыгыз, таныш күзләрем, сез!
Беләм, кыен, беләм, еллар авыр...
Ләкин инде тиздән кубар давыл.
Дингез шаулар нәфрәт җилебездән
Һәм Азатлык туар илебездә!..»

* * *

Шулай булды, әйе, бар да шулай!
Шул ук Татр. Тауда кар да шулай
Ята һаман. Шул ук Дингез Күзе...
Бүтән ләкин тормыш-дингез үзе!
Агыла тормыш Ленин сызган юлдан —
Россияннар җиңеп узган юлдан.

Поронин

**Михаил Львов.**
Мәскәү шагыйре

## Якташ

...«Бу авазда калмык та һәм татар да
Йөрәгенә якын якны ишетер».

...«Кешеләрнең галәм күләм
Дуслыклары хакына...»

СЕРГЕЙ ЕСЕНИН.

Ленин Казанга килгән! — дип,
Ленин Казанны сөйгән!—дип,
Ленин Казанда булган!—дип,
Ленин Казанда торган!—
дип,—

Уйласам да, әйтсәм дә мин
Зур шатлык били күңелне.
Ленинның якташы булу
Үзе мең бәхет түгелме!

Казанда күпне белгән ул,
Киң колач белән эш иткән.
Русча сөйләшкән чакларда
Татарчаны да ишеткән.

Юк, чиркәүгә чакырмаган,
Ә фән кырын тирән сөргән.
Богаулар ничек өзеләсен
Күңел күзе белән күргән.

Узып заман йөрешеннән,
Казан буйлап атлаган ул.
«Мин, көрәш,— синеке!» диген
Антын шунда ятлаган ул.

Карашы яшендәй үткен,
Бераз кысык аның күзе —
Нәкъ безгә хас күздән гүя
Нидер алган аның йөзе.

Зур һәм горур бәхет санап
Аны искә ала Казан,
Чөнки безгә якташ иткән
Аны безнең кала — Казан!

Сембер каласында туды —
Ул — семберлеләр якташы,
Шушь бозларында шуды —
Ул — себерлеләр якташы.

Иң якын якташ дип аны
Саный бөтен иделләр,
Парижлылар үз итәләр:
«Бездә торган иде!» — диләр.

Ленин — Җир якташы, чөнки
Җирдә кара көнне җиңде...
Ә хәзер ул вымпел булып
Венерага менде инде!

Ленин — Җир улы, җирнең ул
Бик күп авыр юлын үтте.
Ә хәзер аны зур галәм
Үлемсез бер улы итте.

Галәмдә дә Ленин юлын
Ачык күрәм һәм таныйм мин.
Ләкин аны җирдә барыбер
Үз якташым дип саныйм мин.

Уйласам да, әйтсәм дә мин
Зур шатлык били күңелне.
Ленинның якташы булу
Үзе мең бәхет түгелме! —

Ленин Казанга килгән бит!
Ленин Казанны сөйгән бит!
Ленин Казанда булган бит!
Ленин Казанда торган бит!

**Санджи Каляев.**
Калмык халык шагыйре

## Ленинны җырлыйм

Сөйлиләр:
Дала бөркете,
Тик бер булса да елга,
Омтыла, ди, канатланган
Оясына кайтырга.

Мин дә шуның күк:
Язмышым
Шулай куша миңа да —
Кайтам беренче җырларым
Канатланганояма.

Ленин!
Шушы исем белән
Илһамланды уйларым.
Башланды шул исем белән
Минем шигъри юлларым.

Ерак авыр елларда да
Мин сыгылып төшмәдем.
Яшәдем Ленин әйткәнчә,
Ул кушканча эшләдем.

Тугрысын әйтте, Лениннан
Үрнәк алып, йөрәгем.
Аз гына булса да аңа
Охшарга гел теләдем.

— Язамсың аның турында,—
Дисәләр,— син тагын да?
— Эх, туган! — диярмен
фәкать
Мин моңа җавабымда,—

Язмасам — нинди шагыйрь
мин?!
Эштә һәм көрәштә гел
Ленинны җырлыйм.
Ленинны
Җырламый мөмкин түгел!

Ышан, дус:
Ленинны җырлап
Башланды тормыш юлым.
Һәм аның турында булыр
Бу юлда соңгы җырым!..

ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәсе

## Эльвио Ромеро.

Испан шагыйре

# Ленин

Яшел имән кебек камил кеше,
очар коштай алга омтылышлы,
ул, елмаеп, ерак максатына,
көнчыгышка карап басып тора.
Елмаюы гади һәм хикмәтле.
Тыңлап тора: еракларданд әнә,
җир астыннан шаулап күтәрелә
әче шәраб төсле алсу иртә.
Кем иде ул —
чатыкы түгел идемени караңгы-шомлы төннәрдә?
Кем иде ул —
икмәк түгел идемени ябык-ярлы өстәлләрдә?
Кем иде ул —
сусын түгел идемени кипкән чакта иреннәргә?
Хыялланды
камчылар чыжламый торган җир турында,
кан һәм яралардан каушап калмый торган
Ир турында,
кырларда чәчәкләр-гөлләр уятырдай
Җил турында.
Очкынлы сандал, чүкечләр җыры яңгырар
Ил турында,
ерак, якын йолдызларны
тарту һәм туплау турында,
Туган илне яктыртучы
яңа, яшь утлар турында,
күмәк чәчә, ура торган
хезмәтчән куллар турында...
Кем иде ул? —
Шатлык, канат булды бит ул бөек дауда!
Һәлакәткә таба барган бу упкында,
бу җиһанда!

**НУРИ АРСЛАНОВ** тәрҗемәсе

## Эмилиу Каррера Герра.

Бразилия шагыйре

# Эшче иртәсе

Күк —
Киерелгән җилкән күк.
Җан өшеткеч салкын таң.
Тротуар өстендә —
Сәләмә томан.

Буш кафега керәм.
Авызда —
Беренче сигарет.
Тәңгә ял бирәм,
Йокысыз төнне

Күзләрдән куып чыгарып.
Кашык житез йөри,
Кулда соңгы сынык,
Соңгы сынык — тик бер кабым.
Ә иртәгә
Каеш кысыла төшәр тагын.
Ләкин төшенкелеккә урын юк.
Әнә —
Беренче гудок.
Житез генә сикереп торам,
Кочагына ала шау-шулы урам.
Автобуска чират.
Кеше боткасы.
Мин дә килеп кысылам...
Һөжүмнең һич юк туктасы.
Башкалар белән бергә
Мин дә һөжүмдә —
Автобуска керергә.
Башны югары тотып,
Карыйм фабрика капкасына.
Станоклар чинап ябыша күк
Һәр эшченең якасына.
Эш, эш, эш...
Темп төшмәскә тиеш.
Бирелә мине көтәләр,
Мин үз кеше бирелә.
Чын күңелдән сөйләшү кирәкме?
Нәрсәне аңлатып бирергә?
Һәр нәрсәгә яңача карыйм,
Яңа уйлар бораулый миемне.
Әйе, мин — яңа кеше.
Чөнки
Укый башладым Ленинны.

МАРС ШАБАЕВ тәрҗемәсе

## Бендели Молоку.

Нигерия шагыйре

### Ильичка

Кешелек акылы
Көчле һәм чиксез,
Даһилар исеме —
Халык телендә.
Әмма синнән дә
Яктырак йолдыз
Янмаган әле
Галәм күгендә.

Телибез синең
Исәннәр белән
Гомер-гомергә
Бергә булуыңны.
Без башкарачак
Барча эшләрне
Үз күзең белән
Күреп торуыңны.

Син — көрәшләрдә
Җиңелмәс байрак,
Коллык чылбырын
Син башлап өздең.
Батмаска чыккан
Кояшыбыз син,
Иң ышанычлы
Дустыбыз безнең.

Үлмәс исемең
Нурларын сирпеп,
Мәңге җемелдәр
Мәрмәр ташында.
Пирамидалар,
Зур потханәләр
Югалып кала
Синең каршыңда.

Көрәшчеләрнең
Илһамчысы син,
Изелгәннәрнең
Тугры юлдашы.
Юк, алла түгел,
Пәйгамбәр түгел —
Бөек һәм гади,
Зирәк юлбашчы.

Миллионнарның
Таудай кайгысын
Үз иңнәрендә
Күтәреп үттең.
Халык диңгезен
Бердәм кузгатып,
Изелгәннәрне
Ирекле иттең.

Сафлар башында
Атлыйсың һаман
Зур җиңүләргә
Безне чакырып.
Дөнья инелә
Җәелә бара
Син бүләк иткән
Бөек яктылык.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәржемәсе

# ЛЕНИН МАТБУГАТТА

*Бөтенсоюз китап палатасы хезмәткәрләре һәм «Китап» нәшрияты В. И. Ленинның 100 еллык юбилее уңае белән «Ленин матбугатта» исемле статистик җыентык чыгарды. Бу җыентык СССРда һәм чит илләрдә басылган В. И. Ленин әсәрләре һәм В. И. Ленинга багышланган китаплар турындагы беренче фәнни-белешмә басма.*

*Җыентыкка кертелгән һәр факт һәм һәрбер сан В. И. Ленин әсәрләренең киң катлам халык арасында зур популярлык казанганлыгын бик ачык күрсәтә. В. И. Ленин әсәрләре Совет власте елларында безнең илдә генә дә төрле телләрдә (барлыгы 100 телдә) 10096 тапкыр басылып 348,9 миллион данә тираж белән чыккан. Ә чит илләрдә 1897 елдан алып 1968 елга кадәр Ленин хезмәтләре 48 илдә, 51 телдә, 4079 тапкыр басылган.*

*Бөек Октябрь Ленин хезмәтләрен халыкка җиткерү өчен киң юл ачты. Җыентыкка кертелгән мәгълүматлар моны бик ачык раслый. Мәсәлән, 1894 елдан 1917 елга кадәр безнең илдә Ленин хезмәтләре нибары 212 генә тапкыр һәм 574 мең данә тираж белән генә басылган булса, Бөек Октябрьдан соң ул хезмәтләрнең тиражы да, басмалары да бик нык артты. Бары тик 1968 елда гына да аның әсәрләре 184 тапкыр 8,2 миллион данә тираж белән чыкты. 1920—1968 елларда В. И. Ленинның Сайланма җыентыкларының 1284 томы басылды, ә ул томнарның гомуми тиражы — 82,9 миллион данә.*

*Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: коммунистик хәрәкәт мәсьәләләре теориясен, стратегиясен һәм тактикасын, яңа җәмгыять төзү проблемаларын яктыртуга багышланган Ленин хезмәтләренең уникидесе безнең илдә 100 тапкырдан да артыграк басылып чыккан. Аның классик хезмәтләреннән — «Яшьләр союзының бурычлары» — 450 кат, «Дәүләт һәм революция»се — 217, «Совет властеның чираттагы бурычлары» — 149, «Бер адым алга, ике адым артка»сы — 123, «Апрель тезислары» 106 тапкыр басылган. В. И. Ленинның югарыда әйтелгән хезмәтләре һәм башка әсәрләр чит илләрдә дә бик күп мәртәбәләр һәм зур-зур тиражлар белән басылып чыкты. Әйтик, «Дәүләт һәм революция» хезмәте 37 илдә 196 тапкыр, «Империализм — капитализмның югары стадиясе» 30 илдә 156 тапкыр, «Нәрсә эшләргә?»се 29 илдә 76 тапкыр басылган.*

*Әлеге җыентыкта союздаш һәм автономияле республикаларда басылган В. И. Ленин хезмәтләре турында да кызыклы мәгълүматлар китерелгән. Мәсәлән, революциягә кадәрле укый-яза белүчеләр саны бик аз булган Үзбәкстан, Төркмәнстан, Казагыстан, Таҗикстан һәм Кыргызстан республикаларында Совет власте елларында чыгарылган Ленин хезмәтләренең тиражлары миллионнар белән исәпләнә.*

*«Ленин матбугатта» исемле җыентыкның Владимир Ильич Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге хакындагы китапларга һәм брошюраларга багышланган бүлеге дә бик кызыклы. Бу бүлектә урнаштырылган мәгълүматлардан күренгәнчә, 1918—1968 еллар эчендә безнең илдә генә дә Ленинның тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган 7919 китап һәм брошюра басылып чыгып, аларның гомуми тиражы 240,9 миллион данәгә җиткән. Ул басмаларның 5417 се иҗтимагый-политик китаплар һәм брошюралар, 675 е художестволы әсәрләр, 1220 се балалар өчен язылган әсәрләр һәм 200 дән артыграгы библиографик материаллар.*

Н. К. Крупская

# ИЛЬИЧКА НИНДИ ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘР ОШЫЙ ИДЕ[1]

Беренче мәртәбә Владимир Ильич белән таныштырган иптәш миңа: Ильич ул укымышлы кеше, гыйльми китаплар гына укый, үз гомерендә бер генә роман да укыганы юк, шигырьләрне беркайчан да укымый,— диган иде. Мин гаҗәпкә калдым. Мин үзем яшьлектә барлык классикларны укып чыккан идем. Лермонтовны бөтенләе белән диярлек яттан беләм һ. б. Чернышевский, Л. Толстой, Успенский кебек язучылар минем тормышка әһәмиятле бер нәрсә булып кергәннәр иде. Менә шуларның барысы белән дә аның бөтенләй кызыксынмавы миңа бик сәер тоелды.

Аннары эштә мин Ильичны якыннан белдем, аның кешеләрне ничек бәяләвен күрдем, аның тормышны, кешеләрне ничек җентекләп өйрәнүен күзәттем — һәм күбрәк белгән саен Ильичның кешеләр турындагы китапларны кулына алмый торган кеше түгеллегенә ышандым.

Ләкин ул чактагы тормыш шундый иде: безгә ничектер ул темага сөйләшергә туры килмәде. Соңрак, Себердә, мин Ильичның классикларны миннән ким укымаган булуын, мәсәлән, Тургеневны укыган гына түгел, кат-кат укып чыккан булуын белдем. Мин Себергә үзем белән Пушкин, Лермонтов, Некрасов китапларын алып килгән идем, Владимир Ильич аларны үзенең кровате янына Гегель әсәрләре белән янәшә куйды, кичләрен кат-кат укый торган булды. Барыннан да бигрәк ул Пушкинны ярата иде. Ләкин ул әсәрне бер форма ягыннан гына бәяләми иде. Мәсәлән, ул, әдәби яктан бик үк югары булмаган һәм форма ягыннан шактый беркатлы булуына карамастан, Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» романын ярата иде. Мин аның бу романны нинди зур игътибар белән укуына һәм бу романдагы иң нечкә үзенчәлекләрне билгеләвенә гаҗәпләнә идем. Хәер, ул Чернышевскийны бөтенләе белән ярата, аның Себердәге альбомында бу язучының ике рәсеме булып, аларның берсенә Ильич кулы белән язучының туган һәм үлгән елы язылган иде. Ильичның альбомында тагын Эмиль Золяның, ә руслардан Герценның һәм Писаревның рәсемнәре бар иде. Үз вакытында Владимир Ильич Писаревны яратып укыган. Хәтеремдә, Себердә немец телендә Гетенең «Фауст»ы һәм Гейненың шигырьләр китабы да бар иде.

Себердән кайтышлый, Мәскәүдә Владимир Ильич бер тапкыр театрга барды, «Извозчик Геншель»ны карады һәм соңыннан пьесаның аңа бик ошавын сөйләде.

Мюнхенда Ильичка ошаган китаплардан Гергардның «Әнием янында» романын һәм Поленцның «Крестьян» диган китабын хәтерлим.

Аннары, соңрак, икенче эмиграция вакытында, Парижда Ильич Виктор Гюгоның 48 елгы революциягә багышланган, үз вакытында сөргендә язылып, Франциягә яшерен рәвештә кертелгән «Җәза» диган шигырьләрен рәхәтләнеп укый иде. Бу шигырьләрдә ниндидер самими кабарынкылык күп, шулай да аларда революцион омтылыш

[1] Берникадәр кыскартып бирелә.

кәчле иде. Ильич эшче кварталларда бөтен нәрсә турында — исерек крестьяннарның депутатлар палатасына узгынчы бер агитаторны сайлаулары турында, балалар тәрбияләү турында, эшсезлек һ. б. турында җырлаучы революцион шансонеткаларны тыңлау өчен төрле кафеларга һәм шәһәр чите театрларына бик теләп йөри иде. Ильичка бигрәк тә Монтегюс ошый иде. Коммунар улы Монтегюс эшче бистәләренең яраткан кешесе иде. Дөрес, аның үзе уйлап чыгарган, һәрвакыт тормыш буяуларына бай булган җырларында билгеле бер идеология юк, аның кәравы аларда эчкерсез мавыгу күп иде. Ильич аның стачкага катнашучыларга атудан баш тарткан 17 нче полкка сәламен еш кына үзе көйләп йөри иде. «Сәлам, сәлам, сезгә, 17 нче полк солдатлары». Бервакыт руслар мәҗлесендә Ильич Монтегюс белән сөйләшеп китте... Кайчак шулай була бит: аз таныш кешеләр вагонда очрашалар да, вагон тәгәрмәчләренең тыкылдавын тыңлый-тыңлый, иң якын нәрсә турында, бүтән вакытта сүз катасылары булмаган нәрсә турында сөйләшеп китәләр, аннары аерылышалар һәм бүтән бер генә тапкыр да очрашмыйлар. Монда да шулай булды...

Безнең өйгә бер-ике сәгатькә җыештыручы француз хатыны килеп йөри иде. Бер вакыт Ильич аның җырлавын ишетте. Бу Эльзас җыры иде. Ильич җыештыручыдан аның кабат җырлавын һәм сүзләрен әйтүен үтенде һәм соңрак аны үзе дә еш кына җырлый торган булды. Ул җыр мондый сүзләр белән тәмамлана иде.

«Сез Эльзас һәм Лотарингияне алдыгыз, ләкин сезгә үч итеп, без французлар булып калабыз; сез безнең кырларны немецлаштыра аласыз, ләкин менә безнең йөрәк — бервакытта да сезнеке булмаячак!»

Бу 1909 елда — реакция вакытында булды, партия тар-мар ителгән, ләкин революцион рух сындырылмаган иде. Һәм бу җыр Ильичның эчке халәте белән аваздаш иде. Җырның соңгы сүзләре аның җырлавында ничек җиңүле яңгыравын үзе тыңлаган кеше генә әйтә алыр.

Эмиграциянең бу авыр елларында,— ул турыда Ильич һәрвакыт ниндидер гарьләнү белән сөйли иде (инде Россиягә кайткач та әле, ул әлек күп тапкырлар әйткән: «Нигә соң без ул чакта Женевадан Парижга күчеп киттек?» дигән сүзләрен ничектер тагын бер кабатлады) — Монтегюс белән сөйләшкәндә дә, Эльзас җырын җиңүле кыяфәт белән җырлап йөргәндә дә, йокысыз төннәрендә йотлыгып Верхарнны (Эмиль Верхарн — 1855—1916 елларда яшәгән Бельгия шагыйре) укыганда да гел хыяллана иде.

Аннары, соңрак, сугыш вакытында, Владимир Ильич Барбюсның «Ут» дигән китабы белән мавыкты, аны бик игътибар белән укыды. Бу китап та аның ул чактагы рухи халәте белән аваздаш иде.

Без театрга сирәк йөри идек. Кайчак шулай барабыз, ләкин пьесаның юк-бар нәрсә турында булуы яисә уендагы ясалмалык һәрвакыт аның нервасына тия иде. Гадәттә, барабыз да беренче пәрдәдән соң ук кайтып китәбез. Иптәшләр бездән көләләр: «Юкка акча әрәм итәсез»,— диләр иде.

Ләкин бервакыт Ильич азакка кадәр утырды. Бу хәл 1915 елның ахырында иде булса кирәк. Берлинда Л. Толстойның «Тере мәет» дигән пьесасын куйганнар иде. Спектакль немец телендә куелса да, князьне уйнаган актер рус кешесе иде, ул Л. Толстойның төп фикерен җиткерә алды. Ильич уенны бирелеп һәм дулкынланып карады.

Менә без, ниһаять, Россиядә. Яңа сәнгать Ильичка ят булып, аңлашылмый торган булып тоелды. Бервакыт Кремльдә безне кызылармеецлар өчен оештырылган концертка чакырдылар. Ильичны алдагы рәткә алып барып утырттылар. Артистка Гзовская, Ильичның өстенә үк килгәндәй итеп, Маяковскийның шигырен укыды: «Безнең аллабыз — йөгерү, йөрәгебез безнең — барабан». Ә Ильич, көтелмәгән бу хәлдән каушап, аптырашка калып утырды. Һәм, Гзовскаядан соң, Чеховның «Усал ниятле кеше» хикәясен укырга ниндидер артист чыккач, җиңел сулап куйды.

Көннәрнең берендә Ильич яшьләрнең коммуна булып ничек яшәүләрен күрергә теләде. Без... Вхутемаска[1] Варя Арманд янына барырга булдык. Бу хәл 1921 елда Кропоткинны күмгән көнне иде булса кирәк. Ачлык өл булуга карамастан, яшьләрдә энтузиазм зур иде. Алар коммунада коры такта өстендә диярлек йоклыйлар, ашар-

[1] Бөтенроссия художниклар оешмасы ул вакытта шулай исемләнгән.

ларына юк. «Аның каравы бездә ярма бар»,— диде безгә дежур торучы көләч йөзле коммуна члены вхутемасчы. Ильичка алар шул ярмадан тозсыз булса да бик һәйбәт итеп ботка пешереп ашаттылар. Ильич яшьләргә, үзен камап алган яшь художникларның көләч йөзләренә карап торды да аларның шатлыгы аның да йөзендә чагылгандай тоелды. Алар аңа үзләренең гади генә рәсемнәрен күрсәттеләр, ул рәсемнәрнең мәгънәсен аңлаттылар, аны сораулар белән күмделәр. Ул көлде, җавап бирүдән читләшергә тырышты, сорауларга сорау белән җавап бирде: «Нәрсәләр укыйсыз? Пушкинны укыйсызмы?», «О, юк,— дип ычкындырды кайсыдыр,— ул буржуй булган бит. Без Маяковскийны укыйбыз». Ильич елмайды. «Минемчә, Пушкин яхшырак», диде ул. Шуннан соң Ильич Маяковскийга карата бераз йомшарды. Ул исем телгә алынганда, аның хәтеренә тормыш дәрте һәм шатлык белән тулы, Совет власте өчен үләргә дә әзер торучы, үзләренең уйларын аңлатып бирү өчен заман телендә сүз таба алмаучы һәм бу сүзләрне Маяковскийның аңлаешсыз шигырьләрендә эзләүче Вхутемас яшьләре килә иде. Соңрак Ильич бюрократизмнан көлгән шигыре өчен Маяковскийны мактады да. Үз заманындагы әсәрләр арасыннан, хәтерләвемчә, Илья Эренбургның сугышны тасвирлаган романы ошаган иде. «Беләсеңме, бу — Илья Лохматый (Эренбургның кушаматы) яхшы чыккан» дип тантана белән әйтте ул.

Без берничә тапкыр Художество театрына бардык. Бервакыт «Туфан»ны карадык. Ильичка ифрат ошады. Аның икенче көнне үк тагын театрга барасы килде. Горькийның «Тормыш төбендә»сә куела иде. Лондон съездында дуслашканнан соң, Ильич Алексей Максимовичны кеше буларак та, художник буларак та ярата, художник буларак, Горький күп нәрсәне бер сүздән үк аңлый ала дип саный иде. Ул Горький белән ачыктан-ачык сөйләшә иде. Шуңа күрә, билгеле, Горький әсәрләре куелуга ул аерата таләпчән карый иде. Постановканың артык «театрча» булуы Ильичның ачуын китерде. «Тормыш төбе»ннән соң ул театрга йөрүен озак вакытка ташлады. Тагын бер тапкыр без аның белән Чеховның «Ваня абзый»сына бардык. Бу спектакль аңа ошады. Һәм, ниһаять, соңгы тапкыр театрга 1922 елда Диккенсның «Мич башындагы чикерткә»сенә бардык. Беренче пәрдәдән соң Ильич күңелсезләнде, Диккенсның мещанлык сентиментальлеге аның нервасына тия башлады, ә уенчык ясаучы картның сукыр кыз белән сөйләшүе башлангач, Ильич түзмәде, пәрдә бетмәс борын чыгып китте.

Ильич гомеренең соңгы айлары. Аның кушуы буенча, мин аңа, гадәттә кичләрен, әдәби китаплар укыдым. Щедринны укыйм, Горькийның «Минем университетларым»ын укыйм. Болардан тыш ул шигырьләр, аеруча, Демьян Бедный шигырьләрен тыңларга ярата иде. Аңа Демьянның сатирик шигырьләреннән тыш пафос белән язылганнары да ошый иде.

Кайчак шулай аңа шигырь укыйсың, ә ул батып баручы кояшка тәрәзә аша уйчан гына карап тора. Демьян Бедныйның «Беркайчан да, беркайчан да коммунарлар кол булмас», диган сүзләр белән тәмамланган шигырен хәтерлим.

Үзең укыйсың, ә үзең гүя Ильичка ант сүзләрен кабатлыйсың: «Беркайчан да, беркайчан да революциянең бер генә казанышын да бирмәбез»...

Үлүенә ике көн калганда, мин аңа, кич белән, Джек Лондонның «Тормышка мәхәббәт» диган хикәясен,— ул әле хәзер дә аның бүлмәсендә өстәл өстендә ята,— укыдым. Бик тә көчле әсәр. Ачтан үләргә җитешкән бер авыру кеше аяк басылмаган карлы дала аша зур елга пристанена таба юл тота. Ул хәлсезләнә, ул инде атлый да алмый, шуыша гына, ә аның белән янәшә шундый ук ачтан үләр хәлдәге бүре шуыша, алар арасында көрәш башлана, кеше җиңеп чыга,— ул ярым үле, ярым акылсыз хәлендә теләгән җиренә барып җитә. Ильичка бу хикәя гаҗәеп ошады. Икенче көнне ул Лондонның хикәяләрен тагын укуымны сорады. Ләкин Джек Лондон иҗатында көчле әйберләр зәгыйфь әсәрләр белән аралаша. Моннан соңгы хикәя бөтенләй икенче типта — буржуаз мораль белән сугарылган иде: ниндидер бер капитан ашлык төялгән корабльнең хуҗасына бу ашлыкны әйбәт бәягә сатарга вәгъдә бирә. Сүзендә тору өчен ул үзенең тормышын корбан итә. Ильич көлеп җибәрде, кул селтәде.

Шуннан соң миңа аның өчен укырга туры килмәде...

Леонид Радищев

# БЕР КЕЧКЕНӘ ЭШ

хикәя



Спасс манарасына терәп салынган агач будка эчендә иптәш Ивановка озак көтәргә туры килмәде. Дежурный аның кәгазьләрен карады да телефон トткасын әйләндерергә кереште. Аннары трубкага һәр сүзен аерым-аерым кычкырып иптәш Ивановның Казаннан, иптәш Милютиннан, доклад белән килгәнлеген әйтте. Барысы да бик гади, гадәттәгечә, шул ук вакытта искитмәле иде. Менә хәзер, шушы минутларда, Кремльдә, башка меңнәрчә мәсьәләләр белән бергә, тагын бер мәсьәләнең: Халык Комиссарлары Советы председателенең иптәш А. В. Ивановны кайчан кабул итәчәге хәл кылынуын күз алдына китерү ничектер кыен иде.

...Иптәш Иванов күптән түгел генә — ике ай элек кенә — Мәскәүдә, азык-төлек Халык Комиссариатында эшли иде. Аннары аны, Казанда туып-үскән кеше дип, Казан губерна азык-төлек комиссариатына күчерделәр. Ул Мәскәүдән киткәндә көз иде, ә хәзер иртә килгән кыш зур шәһәрне бөтенләй биләп алган. Түбәләргә кат-кат булып кар яткан, хәрәкәтсез ак дулкыннарны хәтерләтеп, бульварларны каплап киткән. Тирән кар ерып ясалган траншеялар буйлап, авыр гүелдәп, сирәкмирәк кенә трамвайлар йөри.

Иптәш Иванов кар каплаган урамнар буйлап акрын гына атлады. Кичке алтыга кадәр әле шактый вакыт бар, һәм ул үзенең Мәскәүдә кечкенә генә тагын бер эше булуын исенә төшерде. Бу эш шуннан гыйбарәт иде: көзен, Мәскәүдән киткәндә, ул үзенең барлы-юклы малмөлкәте салынган чемоданын багаж белән җибәрү өчен биреп калдырган иде — ни әйтсәң дә, сулыш алгысыз дәрәҗәдәге тыгыз вагоннарда буш кул белән йөрү әйбәтрәк.

Поезд Казанга килеп җиткәч, ниндидер сәбәпләр аркасында, багажның килмәгәнлеге билгеле булды. Бу сәбәпләрне ачыкларга иптәш Ивановның һич тә вакыты булмады. Бер-ике мәртәбә станциягә барып килде, әмма багаж һаман килмәгән иде. Менә хәзер, буш вакыттан

файдаланып, ул Мәскәүнең Казан вокзалына барып килергә, чемоданның кая югалганын урында ачыкларга уйлады.

Гренадерларча мыек җибәргән агай— багаж кабул итеп алучы (теге вакытта да чемоданны ул алып калган иде) — бик ачулы кыяфәт белән аның гозерен тыңлады да:

— Квитанция номерын язып алыйк. Тикшерербез,— диде.

— Кайчан тикшерерсез әле сез,— диде иптәш Иванов, дулкынланып.— Күпме көтәргә мөмкин! Ә миңа чемодан бик кирәк!

— Менә хәзер барлык эшләремне ташладым да, ди, синең чемоданны эзләргә киттем, ди! Беләсеңме, ул нинди мәшәкатьле эш? Тау актарырга кирәк аның өчен! Аңладыңмы?

Иптәш Иванов кинәт кенә борылды да, бозланып каткан платформа буйлап, вокзалга юнәлде.

Вокзал эчендә тәмәке төтене шул кадәр куе, түшәм дә күренерлек түгел иде. Поезд көтүчеләр кайда урын тапкан — шунда утыралар, йоклыйлар. Кыршылып беткән җиз тоткалы ишек төбеннән — вокзал начальнигы бүлмәсеннән — озын чират сузылган.

Ни булса, шул булыр дип, иптәш Иванов ишек янындагы хатын-кызларга: «Хатын-кыз иптәшләр, минем багажга тапшырылган чемодан юкка чыкты. Инде ике ай көтәм, бүген китәргә кирәк, начальстводан шуны сорыйсы иде»,— дип мөрәҗәгать итте.

Иптәш Иванов һич тә көтмәгән иде: хатын-кызлар аның хәленә керделәр. Менә ул бүлмә ишеген ачты. Зур өстәл артында тимер юлчылар фуражкасы һәм шинель кигән, якасын күтәргән кеше утыра иде. Ул бик бирелеп ниндидер белешмәләр актара. Иптәш Иванов бер урында таптанып торды да йөткереп куйды. Әлбәттә, эш башында утыручы кеше сине күреп тә, күрмәмешкә салынып, бүтән эш белән шөгыльләнә икән, үзеңне әйбәт хис итмисең инде.

— Нәрсә кирәк? — дип сорады начальник, башын күтәрмичә генә.— Сөйләгез, мин чукрак түгел!

Сөйләгәннәрне тыңлагач, ул кыска гына итеп:

— Багаж кассасында гаризагызны калдырыгыз. Эзенә төшәрләр,— диде.

Иптәш Иванов беравык дәшми генә начальникның фуражкасына карап тор-

●

Радио,
Радио,
Радиолар.
Җир шарын сүзләр болыты
чорнады.
Электроннар,
Болытлар барсы да
Җырлады:
Ленин!
Ленин!
Ленин!
Ленин!

Баррикадаларда,
Сарайларны җимергәндә,
Бомбалар,
Утлар эчендә,
Төрмәләрдә,
Шахталарда
Син идең безнең белән,
Канлы кырларда сугышканда,
Синең шәүләң һаман
Безгә ак юллар сызып торды
Азатлыкка табан!
Безне коллыктан азат иткән
Бөек юлбашчыбыз,
Безгә иркенле сарай төзгән
Беренче ташчыбыз
. . . . . . . . . . . .
Без, —
Бөтен дөнья, —
Урамда:
Франция,
Испания,
Дания,
Германия...
Анда ораторлар сөйли,
Монда пионерлар:
— Ул үлмәде,
Ленин мәңге бар!
Ленин — без ул!
Ә без?
— Бөтен дөнья!
— Без бар!
Без миллионнар,
Көчле ленинчылар!
. . . . . . . . . . .

Ул үлмәде.
Җир шары өстендә Ленин
Шәүләсе көн-төн йөри.
Уң кулында канлы байрак,
Сул белән
Куркыныч илларны алга өстери.
Ул, кояш нуры кебек нурлар сибеп,
Төрмәләр, подвал, заводларга керә,
Я коточкыч байрагын тотккан килеш,
Ул кинәт килеп чыга зур
Парламентлар өстенә!..

ҺАДИ ТАКТАШ

1924

ды да: «М-да-а! — диде, эченнән генә.— Монда чемоданыңны гына түгел, башыңны югалтырсың!» Аннары сәгатенә күзен төшерде һәм куркып калды: вакыт бик аз калган! Күз ачып йомганчы, барысы да — багаж кабул итүче дә, начальник та, чемодан да онытылды. Ул йөгерә-атлый, кар өемнәренә абына-абына Кремльгә ашыкты. Караңгы төшкән иде инде, бары тик Кремль өстендә генә — тәрәзәләрдән балкыган яктылыктандыр инде — күк йөзе беркадәр яктырып тора сыман иде...

Аскы каттагы сак. Өске каттагы сак. Менә Халык Комиссарлары Советы коридоры. Аның яныннан кулына телеграф лентасы тоткан, аякларына солдат обмоткасы чорнаган бер кеше узып китте. Алгы бүлмәдәге хатын-кыз иптәш Ивановны ачык чырай белән каршы алды, исәнләште, аннары сәгатькә (алты туларга чирек сәгать бар иде әле), дәфтәренә карап алды да:

— Сез Казаннан, Александр Васильевич Ивановмы? — дип сорады.— Мин хәзер сезнең килүегезне әйтермен.

Иптәш Ивановның йөрәге, текә тауга менгәндәге кебек, бик еш тибәргә тотынды. Ул биредә бердәнбер кеше. Димәк, нәкъ сәгать алтыда бары тик аны гына көткәннәр, бу вакытта башка беркемгә дә килергә әйтелмәгән. Һәм ул азык-төлек Халык Комиссариаты коллегиясе члены Милютин белән булган әңгәмәсен хәтерләде. Иптәш Милютин аңа бик тиз генә Ленинга доклад илтергә һәм Халык Комиссарлары Советы председателе бирәчәк сорауларга җавапка әзерләнеп торырга кушкан иде.

Яшь хезмәткәренең дулкынлануын күргәч, Милютин:

— Минемчә, Владимир Ильич янында үзен уңайсыз хис итүче кешенең дөньяда булуы мөмкин түгел,— дигән иде.— Моңа сез үзегез дә ышанырсыз. Ләкин, зинһар дим, Ленинга ялганны сөйли күрмәгез, дөреслекне яшермәгез. Бик озакка, ә бәлки бөтенләйгә аның ышанычын югалтырсыз. Тагын шунысы: Ленин, әгәр вакытын билгели икән, беркайчан да беркемне дә көттерми, шулай ук бүтәннәрнең дә соңга калуын кичерми. Ул моны җинаять дип саный. Хәзер инде сез Ленин белән очрашырга әзер, дип уйлыйм.

Һәм Милютин елмаеп аның кулын кысты...

— Сез Владимир Ильич янына керә аласыз!

Иптәш Иванов кесәсеннән калын конверт тартып чыгарды һәм, ишекне ачып, бусага аша бүлмәгә узды. Ленин, аңа каршы килеп, кулын сузды:

— Казаннанмы? Иптәш Милютиннанмы? Рәхим итегез, утырыгыз. Озак килдегезме? Дүрт көнгә якын! Үзегезне ничек хис итәсез?

— Бик яхшы хис итәм, Владимир Ильич.— Аңа кинәт кенә җиңел булып китте һәм җавап сүзләре дә үзеннән үзе чыкты.— Юлда да әйбәт булды...

Ленин: «Аңлыйм, аңлыйм, бүтәнчә җавап бирәсезме соң сез»,— дигәндәй, беленер-беленмәс кенә елмаеп куйды, аннары конвертны алып ачты. Аның уң кулында әйбәт итеп очланган карандаш иде. Ул бик бирелеп, һәр юлдан тирән мәгънә эзләгәндәй, укырга кереште. Өстәлдә акрын гына телефон шалтырады, лампочка кабынды. Ленин трубканы алды һәм кыска гына итеп: «Әйе, һичшиксез! Вакытын әйтермен!» — диде дә, тагын бүлдерә күрмәсеннәр дигәндәй, шундук кабат кәгазь өстенә иелде. Карандаш белән нindидер билгеләр куйды.

— Ә хәзер минем сезгә сорауларым бар,— диде Ленин, башын күтәреп һәм урындыгын якынгарак шуыштырды.

Аның кыска һәм төгәл сорауларына каршы күп сөйләргә мөмкин түгел иде. Җавапларны тыңлаганда, ул бөтен гәүдәсе белән әңгәмәдәшенә омтылды. Ивановка бу вакытта аның биек маңгае эчендә фикер хәрәкәте күренгәндәй тоелды. Иптәш Ивановның моңа кадәр әле бервакытта да үзен зур дәүләт эшенә Ленин белән бергә катнашучы кеше итеп сизгәне юк иде.

— Әйе, икмәкле Казан ачыга,— диде Владимир Ильич акрын гына һәм аркасын үреп ясалган утыргычның артына терәде.— Казанны коткарырга кирәк! — Ул лампаны бер читкәрәк этәрде дә беравык күзен кысыбрак уйланып утырды. Лампа уты аның битен бер яктан гына яктыртканлыктан, йөзендә арыганлык эзләре аермачык беленеп тора иде. Ләкин шундук, күз-ачып йомганчы, аның йөзе җанланып китте, күзләренә очкын кабынгандай булды.

— Александр Васильевич, ә сез үзегез тумышыгыз белән кайдан?

— Туган җирем минем — Казан, Владимир Ильич.

— Шулай дип уйлаган идем. Казандагы хәлләрне сез бик яхшы беләсез. Сезне туган якларыгызга күчереп яхшы эшләгәннәр... Ә Мәскәү ничек?

— Мәскәү ул һәрвакытта да әйбәт! — дип елмайды иптәш Иванов һәм үзе дә сизмәстән өстәп куйды: — Ләкин минем минем чемодан белән мәшәкатьләнергә бер дә теләми. Аны көз көне, Казанга киткәндә тапшырып калдырган идем, һаман кайдадыр ята.

Монда керер алдыннан иптәш Ивановка Халык Комиссарлары Советы председателе белән менә шулай сөйләшү дә мөмкин булуын әйтсәләр, ул һич нигек тә ышанмас иде. Ә хәзер бу сөйләшү шул кадәр гади һәм табигый чыкты, Ленин үзе дә бик кызыксынып сорап куйды:

— Ә бу турыда Мәскәү — Казан тимер юлы хезмәткәрләре ни диләр соң?

— Вак-төяк нәрсә лә ул! — дияргә ашыкты иптәш Иванов.— Кечкенә эш. Табарлар, беркая да китмәс!

Ленин, күзен кыса төшеп, аңа карап куйды.

— Һм, һм... Шулай! Ә Казанга кайчан кайтып китәсез?

— Бүген үк, Владимир Ильич. Төн уртасында товар-пассажир поезды вагъдә итәләр. Шуңа утырып.

Тарих бик күп олуг даһиларны белә. Күп зур җаннар адәм балаларын авыр коллыктан коткару өмете белән кузгалган көрәшләргә командирлык кылдылар, ләкин дин, тел, җир, мәмләкәт, гореф-гадәт аермасына карамастан, бөтен дөнья мәзлумнарының һәммәсенең йөрәгенә бер дәрәҗәдә якын, бер дәрәҗә үк кадерле, үзенеке булу — тик Ленинга насыйп булды...

Ленин — революция корабының капитаны, пролетариат гаскәренең командиры, капитализмга каршы көрәшнең юлбашчысы гына түгел, Ленин эшче-крестьянның кайгы-шатлыгын уртаклашкан, авыр көрәшләрне масса белән кулга-кул бергә кичергән, хезмәт әһеленең тормышы, җыеү-җыелүе эчендә бергә булган якын, кадерле дусты һәм иптәшедер дә.

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ. «Татарстан» газетасы. 1920 ел. 24 һәм 27 январь саннары.

Ленин иптәш буржуазный тормышны җимерүнең юлбашчысы булса, ул пролетариат тормышы, яңа бәхет, якты коммунизм тормышы төзү, торгызуның да юлбашчысыдыр.

ФАТИХ ӘМИРХАН. Ленин иптәш — төзү, яңартып кору символы. «Социалистик Татарстан» газетасы. 1966 ел. 6 январь.

Һәрбер мәсьәләдә булган кебек, Ленин иптәш, милләтләр мәсьәләсендә дә нык практически карап, партия Программасы төзегән гамәли якны гына игътибарга ала һәм шуларга бинаан милләтләр турында мөхакәмә йөртә.

Берәр халыкның ихтыяҗын үтәргә барган вәкилләр, мәркәзгә килгәч, иң әүвәл аңарга мөрәҗәгать итәләр һәм аның тарафыннан үз теләкләренең үтәлүенә ярдәм күрәләр.

ШАМИЛ УСМАНОВ. Ленин иптәш һәм милләтләр азатлыгы. «Кызыл Армия» газетасы. 1920 ел. 22 апрель.

Ленин бер милләтнең сәгадәте янсә бер дәүләтнең зураюы өчен генә көрәшүче революционер түгел. Ленин бәйнәлмилал сәгадәт, бөтен инсаниятнең рәфгате өчен көрәшүче бөек революционер. Шуңа күрә иптәш Ленин бөтен халыкларның тарихында аерым шәрәфле урын тотарга тиеш.

...Шәрыктагы иптәшләрнең Ленин иптәшнең инсаннар сәгадәте өчен сызган юлын һәрвакыт хәтерләрендә тотарлар дип өмет итәбез.

ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ. Ленин (Владимир Ильич Ульянов). «Кызыл шәрык» журналы. 1920 ел. 3—4 саннар.

Ленин башын селкеп куйды. Нәкъ шундый җавап ишетергә теләгәне аның күренеп тора иде. Ул каләм алып блокнот битенә нәрсәдер язарга керешге.

Иптәш Иванов сәгатькә күз салды. Ярты сәгатьтән аз гына артыграк вакыт узып киткән, ә бу минутларның һәрберсе аның өчен никадәр кыйммәтле!

Ленин язып бетерде дә өстәл яныннан торды, иптәш Ивановка ябыштырылган конверт сузылды.

— Кайту белән үк хатны Милютинга тапшыруыгызны сорыйм. Ә монысы менә сезгә.— Һәм ул иптәш Ивановка урталай бөкләнгән кәгазь бирде.— Хәерле юл телим...

...Бу кәгазь кисәген иптәш Иванов кырык елдан артык саклады. Әлбәттә, ул белә иде: Ленинның бу язмасы музейда урын алырга тиеш. Шулай да Октябрь революциясе юлбашчысы белән очрашу истәлеге булган бу кәгазь кисәгеннән аерылуны бик кыен кичергән кешенең хисләренә каршы килеп буламы соң?

Менә күптән түгел генә Казан дәүләт музеенда Ленин исеме белән бәйле башка әйберләр янына тагын бер кәгазь куелды. Вакыт үтүдән саргайган бу кәгазь кисәгенә Ленин кулы белән:

«Мәскәү — Казан тимер юлы станциясе. Бу кәгазь иясе Казан губернасы азык-төлек комиссариаты хезмәткәре Александр Васильевич Ивановның әйберләрен күчерү өчен чара күрүегезне сорыйм. СНК предс. В. Ульянов (Ленин)»,— дип язылган.

**МАЛИК ХӘМИТОВ** тәрҗемәсе.

Эдуард Касыймов

# СОРБОННА ПРОФЕССОРЫ

ПОВЕСТЬ

Без — «классиклар». Ачыклап әйтсәм, тарих-филология факультетының классик филология бүлеге студентлары. Асыл максатыбыз — борынгы классик дөньяны, ягъни борынгы Греция һәм Рим дөньясын, аның телен һәм әдәбиятын өйрәнү, белү. Киләчәктә, исән-аман яшәсәк һәм укысак, шунын белгечләре булып чыгарга тиешбез. Димәк, үзебезнең факультетта гына түгел, бөтен университет буйлап безне, авыз тутырып һәм күкләргә чөеп, «классиклар» дип атап йөртүләре тикмәгә генә түгел...

Инде айдан артык укыйбыз. Расписаниедә борынгы грек теле дә бар. Ләкин аны укытырга кеше юк. Дөрес, югарырак курсларда грек телен дә җиренә җиткереп, бик шәпләп өйрәнеп яталар ятуын, әмма аларның укытучысы, үзе дә коеп куйган грекка охшаган тап-такыр башлы доцент Фирстов: «Эшем болай да муеннан, сәламәтлегем дә бик какшады, бүтән кеше табыгыз» дип, безгә керүдән баш тарткан, ди...

Грек теле урынына латин керә. Монысы аның расписаниедә болай да атнага дүрт көн, ягъни сигез сәгать куелган, ә инде грек теленә билгеләнгән дәресләрне дә кушып җибәрсәң, көн саенга китә, ягъни атнага унике сәгатькә тула.

Укытучыбыз Чернявский Семен Яковлевич — бәләкәй, чандыр гәүдәле карт, әллә беренче, әллә икенче көнендә үк, борыны өстенә алтын кысалы пенснэсын ныгытып куйгач, озын нәзек бармагын һавага чөеп:

— Сез уку елы азагына инде Цицерон нотыкларын укып аңларлык дәрәҗәдә булырга тиешле! — диде.

Латин әле икенче курста да укытылачак иде, шуңа күрә без:

— Бу елны ук андый дәрәҗәгә житәрлек булгач, икенче елыбызда нишләрбез икән? — дидек.

— Икенче елгыздамы? Латинны су урынына эчәрсез...— диде ул, юка иреннәрен җәеп. Аннары янәдән бармагын түшәмгә төбәде дә гайрәтле бер тавыш белән өстәп куйды:

— Курыкмагыз: гутта кават ләпидэм нон ви, сэд сэпо кадэндо!

Без әле латин телендәге мәкальләрне аңларлык баскычка күтәрелмәгән идек, шунлыктан укытучыбыз бармагы белән түшәмгә ябыштырып куйган әлеге девизын русчага күчереп аңлатып та бирде:

— Тамчы ташны көче белән түгел, еш тамуы белән тишә...

Арадан беребез, борынын тартып кына:

— Латинны ул хәтле әйбәт белүнең нигә кирәге бар? Ул телдә хәзер беркем дә сөйләшми, үлгән-беткән тел бит ул,— дип, барыбызга да уртак шөбһәне белдерде.

— О тэмпора, о морэс![1] — дип кулын маңгаена куйды Чернявский.— Үлгән, имеш... Соң сез, акыллы башлар, латин телендә ничәмә мең томнар язылганлыгын, никадәр хәзинә барлыгын аз гына да чамаламыйсызмыни? Ул телдә хәзер инде сөйләшмәсәләр дә, мәңге үлмәячәк латин! Шәпләп өйрәнегез генә — галим булырсыз! Ярый, һәммәгез дә зур галим булмады, ди. Ләкин медицина институтларында һәм училищеларында латин телен укытучылар аз кирәкмени?

Аннары ул кафедра артыннан чыкты да, барыбызны да кочагына сыйдырырга теләгәндәй, кулларын киң җәеп, каршыбызга басты һәм ягымлы-йомшак иттереп:

— Мин сезгә, кызларым-егетләрем, ышанам: җиңәчәкбез без латинны! Башларыбыз чатнап ярылса ярылыр, әмма ләкин җәйгә чыгуга без Цицерон, Лукреций, Вергилий әсәрләрен чатырдатып укый алачакбыз! — диде. Шундук тагы, тавышын калынайтып, имән бармагын янәдән һавага чөйде:

— Бүредән курыккан урманга бармас, ди!

Укытучыбыз әнә шулай гайрәт чәчкәндә, нишлисең, безгә, волэнсноленс[2] дигәндәй, ике куллап латинга ябышырга туры килде. Ничәмәничә еллар укытып, тәмам шомарып-остарып беткән укытучыбыз дәрестә утлар уйната. Группада без егерме биш студент. Ул бер үзе. Ләкин ул бер дәрестә, ягъни туксан минут эчендә, безнең һәркайсыбызны берәр тапкыр гына түгел, икешәр, хәтта өчәр-дүртәр тапкыр аягүрә бастырып, сүз төрләндертеп, җөмлә тикшертеп яисә текст укытып алырга өлгерә. Кочагы-кочагы белән өйгә бирелгән эшләрне әйтсәң дә юк. Гүя дөньяның кендеге шул латинга килеп терәлгән, гүя бу тормышның яме дә, тәме дә шуңарда гына...

Октябрь урталары булгандыр, ахры, бер көнне Чернявский безнең аудиториягә керде дә, маңгай җыерчыкларын тирәнәйтеп, моңсу бер тавыш белән яңа хәбәр әйтте:

— Расписание буенча иртәгә сездә грек теле булырга тиеш бит? Латин булмаячак, борынгы грек теле үзе башланачак...

Без, ни куанырга, ни кайгырырга белмәстән:

— Кем керә? — дип сорадык.

— Кергәч күрерсез, танышырсыз. Бик тә зур кеше,— диде коры гына һәм пенснэсын ныгытып куйды да, безнең чыш-пышны басу өчен, карандашы белән кафедра тактасына шакылдатып алды.

Безнең группада үткен һәм чая кызлар җитәрлек, шул көнне үк кемнәрдәндер сорашып-белеп алдылар:

— Борынгы грек телен безгә бер карт профессор укытачак икән. Парижның үзеннән килгән, ди...

Без, егетләр, коры кибәккә генә алданырдай чыпчыклар түгел:

— Грек телен укытыр өчен Париж хәтле Париждан килеп йөрерләр, ди... Суган әкияте,— дидек.

— Деканатта белмичә әйтмәсләр!

Менә икенче көн дә килде. Грек теле сәгате дә җитте. Көтәбез. Барыбыз да диярлек аудитория ишеге төбендә, коридорда.

---

[1] О заманалар, о гадәтләр!..
[2] Ирекле-ирексез.

Бездән еракта, коридор борылышында, ниһаять, берәү күренде. Бер кулында таяк, икенчесендә — портфель. Өстендә соргылт костюм, башы ап-ак... Ләкин ул бик тә экрен, ничектер ян беләнрәк вак-вак атлап килә иде.

Коридор бушап калды: без урыннарыбызга сибелештек.

Ачык калдырылган ишектә иң әүвәл сары күн портфель һәм таяк, аннары ап-ак башлы картыбыз үзе күренде. Тукталып калды, чал кашлары астындагы зәңгәр күзләре белән безгә карады. Аннары нигәдер тотлыгып-каушап, карлыкканрак тавыш белән исәнләште.

Без барыбыз бердән:

— Исәнмесез! — диюгә, ул тагын да каушый төшеп:

— Борынгы грек теле сездә булырга тиешме? Мин ялгышмадыммы? — дип сорады.

— Юк, ялгышмадыгыз. Без сезне көтә идек, профессор,— дидек.

Вак-вак басып түргә үтте. Ләкин, Чернявский кебек, кафедра артына кереп басмады, каршыбызга, өстәл артына килеп утырды. Кулларын шәп күннән эшләнгән портфелена куйды. Озын нәзек бармаклары, бигрәк тә сул кулының бармаклары, сизелерлек булып калтырый иде аның... Менә ул күпереп торган чал мыегын селкетеп, сәер генә иттереп елмаеп куйды.

— Шулай итеп, кадерлеләрем, мин сезгә борынгы грек телен укытачакмын,— диде. Аның тавышы да тамак төбеннән ничектер сынып-өзелеп чыга иде.— Әйе, иң башта танышып алыйк әле. Фамилиям минем, кадерлеләрем, Одинцов булыр, исемем Петр, этиемнең исеме Дмитрий иде... Димәк ки, авырсынмасагыз, Петр Дмитриевич диярсез...

Аудиториягә килеп кергән профессор кадәр профессорның менә болай каушап-тотлыгып калуын безнең беренче күрүебез иде!.. Соңыннан гына белдек: бу ак башлы карт профессорның Советлар илендә совет студентлары янына дәрескә керүе үз гомерендә беренче тапкыр булган икән...

Безнең арадан чая кыз Нинель Данкевич чытлыкланып:

— Ә сез, Петр Дмитриевич, чынлап та Парижның үзеннән килдегезмени? — дип сорап куйды.

— Әйе, Париждан... Ярый, монысы хакында соңыннан,— диде профессор һәм группаның исемлеген бирүебезне үтенде.

Старостабыз Роза Мөхәммәтьярова нәкъ аның каршысында, алдагы өстәл артында утыра иде. Ул, журналның тиешле битен ачып, профессорга сузды. Теге рәхмәт әйтеп елмайды да куен кесәсеннән калын кара кысалы зур күзлеген алып киде. Һәммәбезне берәм-берәм бастырып, тотынды танышырга... Ләкин аның исемлекне укуы әкәмәт сәер иде:

— Мадмуазель Әминова... Мсье Вахитов... Мадмуазель Данкевич... Мсье Кәримов... Мадмуазель Тазаровская...

Болай дип, фамилиябезгә чуар бант тагып, безгә монарчы беркемнең дә, беркайчан да эндәшкәне юк иде. Кинәт кенә без «мадмуазельләр» һәм «мсьелар» булып куйдык...

* * *

Беренче курста гына әле без. Группабызда, әйткәнемчә, төп-төгәл егерме биш кеше. Әмма шуларның тик өчәве генә университетка кергән чакларында гаризаларын классик филология бүлегенә дип атап язган. Калганнары факультетның тарих, рус филологиясе һәм логика-психология бүлекләренә керергә теләп тә конкурстан үтү өчен тиешле балны туплый алмаган халык. Аларны, үзләреннән ризалык алып, нигәдер бөтенләй буш торган шушы «классиклар» бүлегенә тыкканнар...

Әлеге өчнең берсе — Чәчкә Әминова. Чистайдан иде ул. Озын кара толымлы, киң битле һәм зур коңгырт күзле бу кызның тырышлыгына искитәрлек иде: бер генә дәрескә дә ныклап, җиренә җиткереп әзерләнмичә килмәс. Җитмәсә, күңеле дә киң, йомшак. Аның шушы сыйфатларыннан группабыздагы бик күпләр, аерата без — егетләр, бик оста файдаланадыр идек: кызның төн йокыларын качырып әзерләгән нәрсәләрне, бигрәк тә латин һәм француз телләреннән өйгә бирелгән эшләрне, без бик иплән күчереп кенә куябыз... Икенчесе — Соня Тазаровская. Монысы төп Казанныкы. Төз, зифа буйлы бу яһүд кызы бик тә ыспай һәм матур киенеп йөрер иде. Ул да ярыйсы гына тырыш һәм актив. Ләкин аның кызылга буялган озын тырнаклы бармаклары арасыннан күн тышлы калын дәфтәрне суырып алулары, ай-яй, кыен була торган иде.

«Классиклар» бүлегенә үзе теләп кергәннәрнең өченчесе — мин... Чәчкә Әминова белән Соня Тазаровскаяны борынгы грек һәм рим дөньясы ни сәбәптән кызыксындыргандыр, белмим, әмма минем шушы бүлеккә керүем үзенә күрә хәйләгә корылган иде. Бу хакта чак кына аңлатып китмичә ярамастыр.

Мин урта мәктәпне тәмамлауга, меңләгән яшьтәшләрем кебек үк: «Кая керергә, кем булырга?» — дигән уй белән башымны катырдым. Математикадан әкәмәт шәп барган идем мин. Бергә укыган бер дусыма ияреп, Свердловскиның политехнический институтына китәргәме, әллә Казан университетының физматына керергәме? — иң әүвәл шушындый уй-теләк белән яндым. Ләкин күңелне кытыклаган икенче бер нәрсә дә бар иде: мин урта мәктәптә укыганда ук шигырьдер, вак хикәядер языштыргалый идем, хәтта өч пәрдәлек комедия сыман нәрсә язып, аны Казанга да җибәргән идем. Әлбәттә, комедияне кире кайтардылар: бер язучы абый аны, зәңгәр карандаш белән хәтәр сызгалап, бөтенләй юкка чыгарып ташлаган иде. Ләкин ул абый әлеге пьеса дәфтәре эченә салган бәләкәй генә хат кисәгенә: «Бик каты тырышсаң, Рифгать энекәш, синнән ни дә булса килеп чыгар, өмет бөтенләй үк юк түгел синдә», дип тә язган иде. Димәк, өмет бар... Күкрәктә бураннар уйнатып купкан миңә шул өмет математика фәненә булган мәхәббәтемне күңелнең кайсыдыр аулак почмагына кысрыклап та куйды. Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге барлыгын ишеткән идем инде: анда, имеш, миндәй языштыргалаган кешегә оҗмах ук булмаса да, бик тә кулай, ди... Ләкин бәреп керә алырмынмы? Хикмәт шунда: мин җиденчене татар мәктәбендә бетергән булсам да, калган классларны рус урта мәктәбендә тәмамладым. Татар әдәбиятын әйбәт белмим диярлек. Әтегендә татар теленнән дә, әдәбиятыннан да имтихан бирәсе. Җитмәсә тагы, нәкъ миңә шул фәннәрдән иләмсез каты сорыйлар, ди...

Безнең каладан университетның тарих-филология факультетында укучы өч егет бар иде. Шулар җәйге каникулга кайткач, минем исәпниятне ишетүгә, иптәшләрчә үтә якынлык белән:

— Тотасың да безнең факультетның теләсә кайсы бүлегенә керәсең. Конкурстан үтеп, эләгә генә күр... Анда инде, укый башлагач, икенче бүлеккә күчүе чүпкә дә тормый,— дип киңәш бирделәр.

Ләкин гаризаны кайсы бүлеккә язарга?

Шулай каңгырап йөргән көннәрнең берендә, Вятка ярында ук утырган бер авылдан минем дусларга килгән карт укытучы Никольский белән очраштым. Сорашты-нитте бу һәм, минем ни турында баш ватуымны белгәч, чалара төшкән калын сакалын сыйпаштыра-сыйпаштыра:

— О, кер син анда, улым... Казан университеты үзенең классик филологиясе белән гомерлек дан казанды да инде! Күңелең дөрес сизенгән, мәңге үкенмәссең,— диде.

Ул үзе дә кайчандыр, әле герман сугышына кадәр үк, шул бүлектә

укыган икән, ләкин ниндидер яшерен эшләре өчен «классиклар» арасыннан сөрелгән булган...

Әни белән дә киңәш тоттым. Ул куанды гына.

— Бик әйбәт булыр, улым. Анда бит Ленин үзе укыган,— диде.

Мин университетның физматына кердем ни дә, классик филология бүлегенә кердем ни — әнигә барыбер иде.

Китте гаризам...

Конкурста җиңеп, укырга дип килсәм — «классик» булырга теләүчеләр өч бөртек кенә булып чыкты. Ләкин мин, өметемне җуймыйча, өлкән курсларда укучы якташ студентларның киңәшен исемдә тотып, бер-ике атна укыгач ук татар теле һәм әдәбияты бүлегенең ишеген шакып карарга булдым. Әмма кафедра мөдире Рабига Афзаловна, минем теләкне ишеткәч, алай җәелеп китмәде, кара кашларын сәер иттереп селкеткәләп кенә куйды. Аз-маз языштыруым хакында әйтүнең дә файдасы тимәде.

— Андыйлар күп бездә: ике студентның берсе... Фән белән ныклап кызыксынсаң иде син, энем,— диде ул.— Аннан соң, беренче курстагы группа тупланып беткән шул инде безнең, хәтта артык кешеләр дә йөри әле... Булмастыр,— диде.

Деканатка да кереп ялындым. Анда да:

— Кая керәсеңне башта уйлыйлар аны. Юк артыннан йөрмә, кергән җирендә җин сызганып укы! — дип кырт кистеләр.

Ул заманда тарих-филология факультеты университетның төп бинасында, иң югарыгы катта урнашкан иде. Ләкин безнең классик филология бүлегенең үз аудиториясе белән татар теле һәм әдәбияты кабинеты беренче катта иде.

Тәнәфесләрдә мин татар бүлегендә укучы студентларны бик еш күрә торган идем. Алар юк-бар турында сөйләшмиләр, һаман да шигырь, хикәя турында сүз куерталар, кайчакларда кайнарланып-чәчрәп бәхәсләшеп тә алгалыйлар. Алар үзләренең иҗат түгәрәкләренә йөриләр һәм ходаның һәр бирмеш атнасында диярлек «Әдәби сүз» исемендә, җәйсәң колач җитмәслек озынлыкта галәмәт кызыклы стена газетасы чыгаралар. Аларда бүгенге тормыш кайный. Кызыгам да, көнләшәм дә...

* * *

Борынгы грек теленнән шактый гына шүрләп куйган булсак та, профессор Одинцов безнең өчен алай куркыныч кеше булып чыкмады.

Дәрескә беренче кергән көнендә үк профессорыбыз, исемлекне тикшереп бетергәч, тамагын кыргалап алды да, уңайсызлана төшеп кенә:

— Миңа үз гомеремдә бик күп төрле телләрне өйрәнергә туры килде, ләкин моңа кадәр минем бер генә телне дә укытып караганым булмады,— дип куйды.

Әлеге дә баягы чая кыз Нинель Данкевич пумала бөдрәсен яхшы ат кебек як-якка чайкатып алды да, форсаттан файдаланып:

— Ә сез, Петр Дмитриевич, Парижда нинди фән укыткан идегез? — дип сорады.

— Сорбоннадамы? Мин ни... тарих укыткан идем. Асылда Россия дәүләте тарихын...

— Ә нишләп безнең университетта да шуны укытмыйсыз?

Менә бит тыела белмәс тел: тапты сорашыр нәрсә!

«Смена» журналында басылган ниндидер шахмат мәсьәләсен тикшереп утырган Леонид Хотин Нинельнең терсәгенә кагылып, ачулы йөз белән:

— Аптыратма кешене! Син аның каян килгәнлеген онытма. Тоттырдылар, ди, сиңа монда буржуа галименә тарих фәнен, җүләр,— дип пышылдады.

Профессор, әлбәттә, Леонидның пышылдавын ишетмәде. Әмма аның какча саргылт йөзенә кинәт сыек кызыллык йөгерде, һәм ул, сынык тавыш белән:

— Мин бит, мин... Сезнең үзегездә дә менә дигән галимнәр бар икән, алар миннән бик күпкә яшь тә әле,— диде. Үзе көлгәндәй булды, ә үзенең зәңгәр күзләрендә ниндидер уйчан чаткылар күренде. Аннары ул өстәл артыннан авыр гына кузгалды.— Ярар, бу хакта сөйләшмик әле... Безне бит, кадерлеләрем, борынгы грек теле көтә. Башлыйк әле үзен, зарыктырмыйк!

Яңы белән вак-вак атлап кара такта янына килде һәм кулына акбур алды.

Борынгы грек әлифбасын өйрәнергә керештек.

Профессорның озын нәзек һәм көчсез бармаклары арасына кысылган акбуры кара тактада авырлык белән генә йөри, аңардан идәнгә вак кыйпылчыклар коелып төшә иде. Әйе, аңарга такта янында басып торуы да читен, калтыранган көчсез бармаклары белән язуы да кыен иде. Үзе яза, үзе ара-тирә безнең якка күз ташлап, ягымлы елмаеп кына, грек хәрефләренең атамаларын әйтеп бара.

— Сезгә гимназиядә укыган чагыгызда грек теле кермәгән булса да, сез математика, физика фәннәреннән бу хәрефләрнең байтагын беләсез инде, шулаймы, кадерлеләрем? — ди.— Тик, зинһар, дәфтәрләрегезгә менә минем кебек кәкре-бөкре иттереп язмагыз инде, матуррак булсын... Гимназиядә укыганда минем үземнең каллиграфиям әйбәт иде, ә хәзер, күрәсез, таракан йөргәннән дә болайрак чыга, ди.

Әлбәттә, без борынгы грек хәрефләренең шактыен танып белә идек инде: альфа, омега, ипсилон, игрэк, зэтта, пи... Монысына исебез китмәде: яңалык түгел. Ләкин бит профессорыбыз һаман да әүвәлге белән хәзергене бутый: без укыган совет урта мәктәбен «гимназия» ди. Сәер тоелды. Кызлар пырхылдашып алды.

Ул арада профессорыбыз грек әлифбасыннан унлап хәрефне язып аңлаткач, талчыккан кулын селкеткәләп торды да кинәт кенә:

— Ах, онытканмын икән... күрсәтим әле үзегезгә! — дип, кире өстәл янына килеп утырды.

Без башларыбызны калкытып, сагаеп калдык. Ә профессор күн портфеленнән бер китап тартып чыгарды.

— Менә сезгә, кадерлеләрем, бик шәп бүләк әзерләгәннәр! — диде ул, янә аягүрә күтәрелеп.— Борынгы грек теленең дәреслеге булыр бу! Өр-яңа: менә типография буявы кипмәгән дә әле.

Кайберәүләр күңелсезләнеп тел шартлатып куйды: китап кечерәк мендәр калынлыгы иде. Әмма Петр Дмитриевич кызларның тел чәпелдәтүен үзенчә юрады, ахры, йөзендә шатлыклы нурлар балкыды:

— Әйе, һәйбәт дәреслек! Без укыган чакта мондый дәреслек төшебезгә дә кермәс иде, мондыйны әлегә кадәр бер генә илнең дә дөньяга чыгарганы юк.

Куанычыннан микән, профессорыбыз титул битен ачалмый азапланды. Дәфтәренә грек хәрефләрен язу урынына профессорның төрле рәвештәге сурәтен төшереп маташкан Вил Вахитов, моңсу гына:

— Шундый калын китапның бәясе дә шактыйдыр әле,— дип кыстырды.

Профессор һаман да балкуын киметмичә:

— Шалкан бәясе: нибары егерме ике сум! — дигәч, Вил авызын учы белән каплады да, ыңгырашкандай иттереп:

— Миңа ике көн туенырлык акча икән, минем ише плебей аны пристаньда ярты көн йөк бушатып табарга тиешле,— диде.

— Әйе, шалкан бәһасе,— дип, тантаналы сүзен дәвам иттерде профессор Одинцов.— Әмма бу китапны сезгә сатып алырга туры килмәс, кадерлеләрем: университет дәүләттән үзе сатып алган инде аны... Ди-

мәк ки, сез бөтенләй бушлай файдаланачаксыз! Сез, мадмуазель Мөхәммәтьярова, бу китапны кабинеттан тиеш хәтлесен алып, исемлек буенча таратырсыз. Иренмәсәгез, бүген үк, яме!

Старостабыз Роза Мөхәммәтьярова, ризалык белдереп, башын түбән иде.

Ниһаять, Петр Дмитриевич китапның титул битен ачты:

— Менә авторы: профессор Соболевский. Иренмәгән, тырышкан, картлач! Әйе, белә идем мин аны, яшь чакта, әле Берлин университетында укып йөргәндә үк танышып алган идем. Белемгә җегәрле күренгән иде ул вакытта ук.

Түземсез Нинель Данкевичка тагы да:

— Ә сез, Петр Дмитриевич, Берлин университетында укыдыгызмыни? — дип сорап куярга җай чыкты.

— Петербург университетын тәмамлагач, Берлин университетына барып кергән идем шул... Ярый, мадмуазель, алары хакында сөйләшмик әле, сүземне читкә бормасагыз иде,— диде Петр Дмитриевич, чая кызыбызга үпкәләгән сыман рәвештәрәк чал башын селкеп. Кулындагы калын китапка янә сөйкемле карашын төбәде дә, тавышын күтәрә төште: — Искитмәле! Совет иле коточкыч сугыш афәтеннән әле генә котылып, җиңеп чыккан, әле яралары да төзәлмәгән, ә үзендә нинди китаплар чыгып ята. Борынгы Элладаны өйрәнүчеләргә моннан да һәйбәт бүләк булмас. Дөньяң таң калыр... Аңлыйсызмы сез шуны, кадерлеләрем?!

Янымда утырган Леонид терсәге белән янтыгыма төртте.

— Исе китте шул китапка. Тәмам мәдхия укый. Югыйсә, бездә ул китаптан мең өлеш кызыклырак та, әһәмиятлерәк тә нәрсәләр аз эшләнми бит. Тапты! — диде ул, иреннәрен бөрештереп, һәм, ирексездән, ахры, сызгырып ук җибәрде.

Аның ни әйткәне профессорга барып җитмәде, билгеле, әмма сызгырып алуы тегене сискәндерде: йөзендә балкыган елмаюы кисәк катып калды.

— Сез нидер әйттегез кебек, мсье? — дип төбәлде ул Леонидка.— Мин әйткәннәргә риза түгелме әллә сез?

Леонидым торып басты.

— Юк, профессор, мин риза... Ләкин минем бер генә дә сез әйткән борынгы эллиннар дөньясына чумып каласым килми шул.

— Ничек? Ничек?

— Мин үзебезнең Россия тарихы буенча белгеч булырга теләр идем. Шулай булгач, борынгы грек телен өйрәндем ни дә, өйрәнмәдем ни...

Профессорыбыз тотлыгып калды, ике кулының да нәзек бармакларын бергә кушылдырды да аларны аера алмыйча торды.

Менә, ниһаять, аның чал мыек тирәсе хәрәкәткә килде.

— Әһе, егетләребезнең берсе грек теленә каршы, димәк... Ә сез, мсье?

Леонид Хотинның күңелендәгене һич куркусыз ярып әйтә белүенә бик канәгать булып, иренен җәеп утырган Вил Вахитовка торып басарга туры килде. Башкортстанның Бәләбәй каласыннан килгән кара күзле, каракучкыл ябык йөзле бу егет тә конкурста тарих бүлегенә үтә алмаганнардан иде. Ул да, ап-ак тешләрен елтыратып, һич каушамыйча Леонид әйткәнне сүзгә-сүз диярлек кабатлагач, профессорыбыз, тамагын кыргалап, миңа ишарәләде. Ә мин ни әйтим? Тоттым да әлеге дулкынгаияреп, кырлы-мырлы кыланмыйча, әмма карашымны тәрәзә ягына күчереп, иреннәрем арасыннан сытып чыгардым:

— Минем исәп татар әдәбияты бүлегенә керү иде, профессор. Ә борынгы грек телен анда өйрәнмиләр. Кирәк түгел, күрәсең...

Петр Дмитриевичнын сөмсере тәмам коелды. Аудитория тынып калды. Тәрәзә пыяласында бер зур чебен генә безелдәп, тынлыкны игәүли иде.

Группада без дүрт егет идек, калганы кызлар. Шул уңайдан профессор әле исемлекне барлаган чакта ук:

— О, мсьелар, сезне кызлар уч төпләрендә утыртып, өф-өф итеп кенә йөртәчәк икән,— дип шаяртып та алган иде. Дүртенчебез Миша Черепанов. Без, бер-бер артлы торып, профессорга җавап биргән чакта, ул башын кыңгырайтып, учы белән колагына таянган хәлдә, мыштым гына утыра бирде. Профессор, нишләптер кызларга кагылмыйча, Миша ягына күз салды һәм, шыпыртлап кына диярлек:

— Ә сез, мсье Черепанов, бу хакта ничек уйлыйсыз? — дип сорады.

Кара син: фамилиясен дә отып калган бит моның!

Миша Черепанов бездән өч-дүрт яшькә олырак. Менә ул күгелҗемкара кителенең чабуын тартып, күкрәгеннән киерә төште дә:

— Мине рус филологиясе кызыксындырган иде. Әмма мин болай уйлыйм, профессор: теләсә нинди телне өйрәнеп белү, гәрчә ул тел күптән үлгән булса да, гыйльми эштә беркайчан да зыян итмәслеге көн кебек ачык,— диде.

Кыландырыбрак әйтсә дә, шәп чиертте бу безнең борынга!

Профессорның кырыс йөзенә җан керде, чал кашын сикертеп куйды:

— Хак сүзләр! — диде ул һәм Мишага төбәлде.— Ә сез, мсье, каян килдегез, гимназияне кайда тәмамладыгыз?

— Мин ни... Казагыстаннан. Кандагач дигән тимер юл станциясеннән,— диде Миша. Кинәт аның тавышы сыныбрак китте, уңайсызланып, уч төбенә йөткергәләгәч кенә, егетебез әйтә куйды: — Мин ни... урта мәктәпне тәмамламадым. Мин тимер юлчылар техникумын тәмамлаган идем, аннан ике ел буена үзебезнең станциядә техник булып эшләдем.

Болары хакында группада мин генә белә идем. Күпләр хәйран калып, тел чәпелдәтте.

Ә профессор җылы карашын һаман Миша Черепановтан алмыйча:

— Россиядә беренче паровозны уйлап чыгарган атаклы мастер нәселеннәнме әллә сез, мсье Черепанов? — дип сорады.

— Юк, профессор... Хәер, кем белә анысын! — дип көлемсерәде Миша.

Арттарак утырган кызлардан кайсыдыр:

— Үзе паровоз техникы, үзе тел өйрәнәм дип җенләнгән! — дип җибәрде.

— Көлмәгез, мадмуазель. Паровоз инде күптән уйлап табылган, хәзер юлларда электровозлар да чабып йөри. Хикмәт шунда: мсье Черепановтан менә дигән филолог чыгуы бик тә ихтимал.

Тирән канәгатьләнү белдереп, Мишага утырырга кул изәгәч, профессор аудитория буйлап күз йөртергә кереште. Ул борынгы грек әлифбасы хакында бөтенләй онытты шикелле. Хәер, аңа бай рухлы эллиннар язмасын өйрәтә башлаганчы, безнең ул телгә мөнәсәбәтебезне ачыклау әһәмиятлерәк иде, ахрысы...

Тәнәфескә чыгарга звонок шалтырады. Петр Дмитриевич капылт кына, аерым исемнәрне атамыйча гына, кызларга мөрәҗәгать итте:

— Кадерлеләрем, сезнең арада да чит телне өйрәнүгә каршылар бармы, әллә...

Кызларның күбесе авызын ерды:

— Без каршы түгел, без риза...

Профессорыбызның кулына бер бәйләм хуш исле матур чәчәкләр тоттырдылармыни! Бер мизгел кабынып, балкып торгачтын, килеп кергәндәгечә вак-вак атлап, ишеккә табан юнәлде. Ләкин ишек төбенә җиткәч борылды да, дустанә елмайган хәлендә, безгә бармак янады:

— Ә сез, мсьелар, борынгы греклар телен барыбер аз-маз булса да өйрәнмичә калмассыз...

Аның артыннан ишек ябылуга, аудиториядәге барлык кыз без өч мескенгә ябырылды. Аерата старостабыз Роза Мөхәммәтьярова зәһәрләнде:

— Профессор кешене беренче көнендә үк алай кәефсезләндерергә ярыймыни!

— Кыюлар, имеш! Оятыгыз юк.

Без кул гына селтәдек:

— Юк инде, кадерле «мадмуазельләр», без сезнең кебек ике йөзләнеп кылана алмыйбыз. Күңелебездәгене ярып салабыз!

Сүз көрәштерү ызгыш-талашка әверелеп китәр идеме, әйтүе кыен. Әмма шул чакны Миша Черепанов, гадәтенчә үтә акыллы кыяфәт белән, без кызган башларның өстенә бер чиләк салкын су сипкәндәй иттереп:

— Чәйнәшмәгез дим! Профессор бөтенләй теге Чернявский кебек түгел икән, аның белән яшәргә була икән... Куанышыгыз! — диде.

Барыбыз да Миша белән килештек.

* * *

Ят телне өйрәнү — майлы ботка ашау түгел. Моны һәркем белә. Ә бит безгә бер генә тел кирәмени? Латин, француз һәм борынгы грек телләрен өйрәнәбез. Икенче семестрда тагын борынгы славян теле дә өстәләчәк, ди... Зиһенгә ничек сыйдырмак кирәк? Җилкәләребездә берәр генә баш утыра лабаса безнең!.. Француз теле ярый инде, исән-сау яшәгән кешеләр теле. Аны белсәң, файдадан бүтән, зыяны булмас. Әйтик, алай-болай Франциягә, Парижга барып чыгу язмышыңда язылган булса, аптырап, йөдәп йөрмисең. Ә инде Ромен Роллан, Анатоль Франс яисә Анри Барбюс кебек олы язучыларның гүзәл әсәрләрен оригиналда укып, чиксез ләззәтләргә бирелү үзе генә ни тора! Ә бит тегеләр бөтенләй үлгән телләр. Миша Черепанов шикелле тел галиме булырга яисә борынгы заман сукмакларыннан гына атлаучы тарихчы булырга җыенсаң, ул телләрне дә белү, әлбәттә, ярап куяр иде. Ләкин бит мине ул сукмаклар кызыктырмый. Алай да, шушы «классиклар» бүлегенә килеп капкач һәм уку программасында алар барысы да булганлыктан, нишлисең, өйрәнмичә чараң юк. Тәртәгә тибеп кенә әллә ни кырып булмаячагы көн кебек ачык иде.

...Төн уртасы авышкандыр инде. Бүлмәдәшләрем күптән инде мәрткә китеп, борын сызгырта. Тулай торак тынып калган. Төннәрен еш кына шулай йокы калдырып уйланып ятам мин. Күңелгә әллә ниләр килә. Иң әүвәл һаман да шул әлеге дә баягы латин белән саташам. Берәр сүз исемә килеп төшә дә, шуны төрләндереп, әвәләп-нитеп азапланам. Аңа французныкылар ялганып китә. Грек теле исә әллә кайда читтә кала, күңелне чак кына да бимазаламый. Әкренләп мин әлеге ят сүзләрне һәм тәгъбирләрне, киемгә сырышкан тигәнәкне йолкыгандай иттереп, читкә сыпырып ыргытам. Зиһендәге бушлыкны бүтән нәрсәләр басып ала башлый...

Шулай икән, дим, гуманитар вузларда күп нәрсә бик борынгы заманнардан башланып китә икән, дим, безнең бүлектә бигрәк тә... Борынгы җәмгыятьләрнең җилләр әллә кайчан туздырган һавасын сулап яшәве җиңел түгел, күңелне әллә нинди юшкын — архив тузаннары басып алгандай тоела. Һәм моны син лекцияләрдә утырган чакта түгел, бәлки өеңә тынычка кайткач кына аермачык сизәсең. Хикмәт, бәлкем, шунда булгандыр: нәкъ менә шул борынгы грек һәм Рим җәмгыятьләре турында лекторыбыз доцент Шофман искитмәле оста итеп

сөйли. Үзе бернигә карамый-нитми, кулын пиджагының күкрәк турысына куя да йомшак һәм саф тавышы белән тотына, мин сиңа әйтим, бер җепкә мәрҗәннәр тезәргә! Сихерләнгәндәй, суларга да онытып, авызына текәләсең дә утырасың... Бер-ике атна үтүгә үк безнең группадагы кызлар юантык гәүдәле доцент Шофманга муеннан гашыйк булдылар дисәм, ялгышмамдыр...

Аннан тагы антик әдәбият курсын укучы Савельева. Бусы Ленинград университетының безнеке шикелле үк «классик» бүлеген тәмамлап килгән. Ябыграк йөзле, нәзек озын муенлы бу кыз борынгы дөньяның Гомер, Эсхил, Эврипид, Софокл кебек титаннары хакында гаҗәеп матур һәм тылсымлы сөйләве белән безнең бик күбебезнең күңеленә шифалы, саф орлыклар сала белде. Ә бит үзе бик яшь иде, әле беренче елын гына укыта иде...

Шул җәһәттән күз алдыма тагы өлкән укытучы Тузов килеп баса. Логика укыта ул. Пиджагының бер җиңсәсе буш: кулын сугышта өздереп кайткан. Каршыбызга менеп баса да сау сыңар кулының биш бармагы белән көрәнсу-соргылт чәчен алдан артка таба сыпырып җибәрә һәм тираннән, күкрәк төбеннән менгән калын тавышы белән безнең күңелләрне дә, акылны да бергә үреп, сөйләргә керешә бер заман... Уйландыра, сискәндерә, шаккатмалы гади мисаллары белән әллә нинди катлаулы уй-фикер тезмәләрен дә яшен чаткысында яктыртып куйгандай итә. Кайчакны без актлар залының тәрәзә пыялалары зеңгелдәрлек иттереп, шаркылдап көлеп тә җибәргәлибез... Моның лекцияләренә бер без генә түгел, университетның бүтән факультетларыннан да, хәтта башка институтлардан да килеп йөрүчеләр булгалый.

Әйе, бөтен хикмәт лекторның осталыгында, күрәсең...

Әнә шулай төн уртасында һәркайсын берәм-берәм күз алдымнан кичерәм мин. Бүлмәдәшләрем гырлап йоклый бирә, югарыда төнге һаваны ярып, гүелдәп самолетлар узгалый, якындагы чокыр буйлата безнең тулай торак бинасын дерелдәтеп һәм яман кычкыртып поезд үткәли, ә мин һаман үз уемда...

Миша Черепанов... Тулай торакта аңа урын чыкмаган. Университет подвалында берәүләрдә яши. Алар ике студент ярыйсы гына хакка озынча тар бер бүлмәне билиләр. Ә барын да үзләренә кайгыртасы — безнең тулай торактагы уңайлыклардан мәхрүм... Алай да Миша бик канәгать шикелле: «Миңа лекциягә сезнең кебек янып-пешеп чабасы юк, китапханә дә минем борын төбемдә генә...» — ди. Бар гомерен шул гыйльми китапханәдә уздыра диярлек. Тын алса да, кайбер кичләрне университетның кыллы оркестрында уйнаганда гына ала торгандыр. Фән дип үлмәсә ярый инде... «Минә кем турында шигырь язсаң, зыян итмәс иде...» — дим...

Вил Вахитов... Бу юка, җиңел гәүдәле кара малайның хәле хөрти: керү имтиханында бер фәннән, рус әдәбиятыннан, ахрысы, «өчле» алган, шул сәбәпле теләгән группасына эләгү түгел, хәтта стипендиядән дә мәхрүм калган. Әтисе сугышта хәбәрсез югалган икән. Бәләбәйдәге әнисе янында моның тагын икеме-өчме энесе белән сеңелесе бар, ди, ярдәмгә өмет итәрлеге юк. Әтисенең абыйсы гына аз-маз җибәргәләп тора икән. Аннары, бәхетенә, Казанның үзенә килеп, төзүче булып йөргән бер авылдаш түтәен очраткан. Кай кичләрдә шул түтәй янына баргалый. Әмма төп кереме пристаньда яисә тимер юлда йөк бушатудан була. Аңа ияреп, бер-ике тапкыр мин дә бардым. Ял көнендә, билгеле. Ярап куйды. Үзебезгә тукланырга яртышар капчык бәрәңгесенә хәтле күтәреп алып кайттык... Хәле әнә шулай бик тә алама булса да, Вилның һичнәрсәгә исе китми иде. Гүя ул университет идәннәрен беренче елын гына таптамый. «Шул бердәнбер өчле генә хәрап итте башымны. Алай да барыбер үземнекен итәрмен, тарихчылар группасына күчми калмам!» — дип гайрәт чәчә. Борынгы телләргә төкерми дә...

Әйе, үз казанына килеп эләкмәгән егет. Ә мин үз казанымда кайныймы соң? Кем булып пешеп чыгармын икән? Ярый ла файдага булса...

Күңелнең йолкынмыйча хәле юк. Колак төбендә карт төлке Чернявский сүзләре янгырагандай була: «Күңел хәсрәт һәм шатлыклар өчен, ә баш уйлар өчен яралган», дип сөйләнергә ярата ул. Шулайдыр. Нишлисең, әлеге картыбыз әйтмешли, һомо сапиенс[1] шул без...

* * *

Старостабыз Роза Мөхәммәтьярова группабызда иң олылардан: аңа егерме биш-егерме алты яшьләр булгандыр инде. Озын буйлы, кипкәнрәк тыгыз битле, кыска киселгән сумала чәчле. Ул армиядә хезмәт итеп, фронтта булып кайткан. Деканатта һәр группага староста итеп, фронтта булып, дөньяның утын да, суын да кичкән адәмнәрне куялар. Тикмәгә түгел, билгеле... Бүтән группаларда өсләреннән гимнастерка яисә кительләрен салмаган үтә җитди кыяфәтле фронтовик егетләр журналны култык асларына кыстырып йөртсә, бездә Роза йөртә, чөнки бездә егетләрдән сугышта булган кеше берәү дә юк.

Розабыз карап торырга ипле генә күренсә дә, тәртип дигәндә үлә инде. Алай-болай лекциягә килмәсәң яки дәрескә соңга калып килсәң, сәбәбен сорашып җелегенне суыра һәм синең аһ-ваһыңа тамчы да ышанмыйча, авырудан бүтән теләсә нинди сәбәпне дә чүпкә санап, журнал битенә тиешле билгесен утыртып куя. Ә дәресләр бетүгә бик тә пөхтәләп язган рапортын деканатка кертеп тапшыра. Я кемнең инде бер-ике тапкыр дәрес калдырганы өчен генә деканатка чакыртылып, тиргәләсе килсен, ди? Күбрәккә китсә, стипендиянә куркыныч туу ихтимал, диләр, бит... Без әле беренче курста гына, шомармаган, студент хәйләләренә өйрәнеп җитмәгән, шунлыктан Розаның артык кырыслыгын шулай кирәктер, шулай тиешледер дип табабыз.

Ләкин Вил Вахитов алай уйламый. Рәттән берничә тапкыр дәрес калдырганнан соң, бер мәлне юньләп тә, үпкәләп һәм ачуланып та Розаны журналга билге куймаска күндерә алмагач, егетебез, чыгырыннан чыгып, өстәлгә йодрык сукты:

— Син нәрсә! Мине уйнап йөри дип беләсенме әллә? Сезнең кебек стипендия алмыйм бит мин, плебей бит мин. Укыр өчен иң әүвәл яшәргә кирәк бит әле. Тимер юл тупигында утын бушаттым — акчасы кирәк, белдеңме!

Розабыз бәбәкләрен генә агартты:

— Менә интересно! Кемнән рөхсәт сорадың? Стипендия алмагач та...

Без дә бу хәлгә катнашып китеп, Вилны яклагач, Розабыз чигенә төште тагы:

— Ярар, бу юлы рапортка язмам. Ә башка көннәрдә штубы... как штык!

Дәрес калдыру мәсьәләсе бер хәл әле: монда старостаны деканат кыса — сизәбез. Ләкин менә кайбер лекцияләр вакытында үз эшең белән шөгыльләнергә керешсәң, яисә берәр дәрестә иркенәебрәк китеп, темага бик үк карамаган, тегенди-мондый сораулар бирергә тотынсаң да, Розаның кашы-күзе җимерелә, кайчакны бармак сырты белән өстәлгә текелдәтеп алырга да тартынып тормый: янәсе, җиттеме сезгә, юкмы... Аның бу кыланышлары Чәчкә Әминова шикелле һәр дәресне бары-югы белән йотарга утыручы юашрак һәм карусызрак җаннарга хуш килсә дә — без егетләрне әйтмим дә — кызларның күбесе:

— Ярар, студент демократиясен кысмасана,— дип, тегеңәргә караңгы чырай күрсәтә иде.

[1] Акыл иясе кеше...

Борынгы грек теле укытучысы профессор Одинцовның дәресләрне шактый таркау алып барганлыгы өченме, әллә аның күңел йомшаклыгы әллә каян кычкырып торгангамы, старостабыз аның тән һәм җан сакчысы сыманрак кылана башлады: имеш, юк белән карт кешенең башын катырмагыз, тикмәгә йөдәтмәгез... Ләкин укытучының йомшак ягын бер сизеп алгач, күңел кытыклануын алай ансат кына басып буламыни? Җитмәсә, группанда Нинель Данкевич шикеллерәк, йөгәнсезрәк кызларың берничәләп тә булса?..

Профессорыбыз аудиториягә кереп, дәресне башлап җибәргәнче, ун-унбиш минутлап вакытын, төрле сораулар яудырып, җилгә очырабыз. Ул үзе моны сизми дә кебек: без кузгаткан дулкыннарда һич киреләнмичә, шулай тиешледер дип, ахры, иңле генә йөзә башлый.

Сорауны гадәттә әлеге шул Нинель Данкевич бирә. Бер мәлне ул:

— Сез, Петр Дмитриевич, бик күп телләрне беләсез, ахрысы. Ачыклабрак әйтегезче: нинди телләрне? Ничек өйрәнә алдыгыз аларны? — дип сорады.

Монысын да укытучыбыз җавапсыз калдырмады. Ләкин артык вакланмыйча:

— Миңамы? Миңа, кадерлеләрем, роман һәм герман телләрен дә, славян телләрен дә, менә бу грек белән латиның да өйрәнергә туры килде,— диде.

Безгә гомуми тел белеменнән дә лекцияләр укыла иде, шунлыктан без әлеге группаларга никадәр телләр кергәнлеген аермачык белә идек инде. Хәйран калдык: каршыбызда иягенә таянып һәм чак кына көлемсерәп, җанлы полиглот үзе утыра икән ләбаса!..

Әмма ул үзенә, аның язмышына кагылышлы сорау ишетү белән үк, кинәт айнып киткәндәй, капылт кына утырган җиреннән кузгала башлый:

— Ай, шаяннар, күпме вакытны алдыгыз... Зарыктырмыйк, башлыйк әле борынгы грек телебезне,— ди.

Ә тәнәфескә звонок яңгырау белән Одинцов, гүя без янәдән сораулар яудыра башларбыз дип курыкканга күрә, тизрәк аудиториядән чыгып киту ягын карый. Кәкре башлы таягына таянган хәлдә, яны беләнрәк вак-вак атлап, ул әллә кая түгел, озын коридор буйлап ректор кабинетына таба юл тота. Өс киемнәре дә шунда аның... Безнең группадагы үткен күзләрнең әйтүенә караганда, ул анда ректор кабинетының алгы бүлмәсендә киң диванга җәйрап утыра да инде олыгаюга таба барган секретарь апа белән ни турындадыр күңелле генә әңгәмә башлап җибәрә. Кайчакларда, бушрак вакытына туры килсә, хәл белешергә-нитәргә ректорның үзе янына да кергәли, ахрысы... Ә звонок шалтырап, профессорыбыз әйләнеп килгәләгәнче, тәнәфескә өстәлеп, тагы ярыйсы гына вакыт үтә, буфетта һич ашыкмыйча рәхәтләнеп тамак ялгап алабыз...

Ләкин ике-өч атна үтүгә безнең чая кызларыбыз аның бу юлына киртә куйдылар. Хикмәт шунда: грек теленнән соң ук, ялганып киткәндәй, безгә француз теле керә. Расписаниедә шулай. Ә француз теле укытучысы өйгә эшләрне латин телендәгедән чак кына да аз бирми — өлгер генә... Нинель кебегрәк кызларыбыз, профессор Одинцов тәнәфескә чыгып китәр өчен урыныннан купмас борын ук, француз теле дәресләген ачкан көенчә, моның янына килеп баса башламасыннармы бер заман! Басалар да, язгы күгәрченнәр шикелле гөрләшеп:

— Петр Дмитриевич, менә бу төшен генә аңламадык... менә монысын гына төшендереп бирегезче, пожалуйста! — дип ябышалар.

Нишләсен, кызларның назлы һәм иркәле гөрелтесенә буйсынса да буйсына, буйсынмаса да буйсына профессорыбыз. Бер-ике «төш»не аңлаттыру гына түгел, бер тотынгач, ярыйсы гына озын текстларны да тәрҗемә иттерәбез үзенә...

Ә старостабыз Розаның моңа бик тә эче поша: ярамаган эш бит, чал чәчле профессорны гөнаһка тартабыз. Ул үзе өйгә биремнәрне әйбәт кенә эшләп килә һәм француз теле укытучысыннан шелтә ишетми диярлек. Эче пошып кына калмый, без егетләрнең беләгеннән чеметкәләп, ә кызларның нәзек билләренә төрткәләп:

— Җиттеме сезгә, юкмы? Кешегә тын алырга бирегез, ярамый бит! — дип, безнең артта пышылдап-ысылдап йөри.

Эх бу староста, ирек бирсәләр, группада бөтенләй хәрби тәртип урнаштырыр иде бугай!..

Әмма озакламый старостабызның кырыслыгы челпәрәмә килеп җимерелде һәм ул безгә бөтенләй көтелмәгән ягы белән ачылып китте. Монысы да аның шул ук грек теле дәресендә булды.

Ул көнне Роза Мөхәммәтьярова дәрескә өч-дүрт яшьләрендәге тулы битле зур кара күзле елгыр гына бер малайны ияртеп килде. Берәр апасыныкы яисә күршеләренекедер дип уйлаган идек. Түгел икән. Розаның хәлен якыннанрак белгән бер-ике кыз минутында безгә төшендереп бирде: үз малае икән... Менә сиңа мә: безнең, кияүгә чыкмыйча, кияү назын белмичә, картаеп бара инде бу дип йөргән усал кызыбыз күптән инде хатын кеше икән, ана икән. Җитмәсә, бу җан кисәккәен әллә каян түгел, ут эченнән, сугышның үзеннән үк йөрәк астына салып алып кайткан, ди. Тегендә, фронт җирендә, кырыс-усалланып әллә ни кыра алмаган, кем алдындадыр чигенеп, туарылып куйган икән дә... Без егетләрнең авызы шундук кыйшайды.

Ә малаен университетка дәрескә алып килүенең хикмәте шунда ди: моңа кадәр бу түгәрәк битне әбисе карап тәрбияләп торган икән, әмма алдагы кичне аңарчы ук авырый башлаган карчыкны, хәле яман төс алгач, «ашыгыч ярдәм» белән больницага илтеп салганнар икән.

Малайның исеме әкәмәт сәер иде: Одер.

Беренче сәгатендә әйбәт кенә утырды ул. Профессорыбыз да, баштарак сәерсенеп һәм гаҗәпсенеп калган булса да, андый-мондый сүз кузгатмады, тик:

— Кем алмасы бу? — дип сорап, белешеп алды. Аннары малайга ягымлы тел шартлатып, шаярта куйды: — Бигрәк акыллы икәнсең, безнең борынгы грек телен шушы яшеңнән үк өйрәнергә теләгәнсең икән.

Бу юлы үзебез дә профессорны юк-бар сораулар белән аптыратмадык. Шунлыктан ул турыдан-туры грек теленә керешеп китте. Әмма аның сөйкемле, җылы карашы һаман да әлеге йомры җанга таба тартыла да куя иде. Малай үзе дә, әнисе тоттырган карандаш һәм кәгазь битен бер читкә этеп, нәни кулы белән яңагына таянган килеш, күзләрен зур ачып, профессорга төбәлеп утыра бирде. Каршысындагы сакалсыз, әмма кардай ап-ак чәчле һәм кабарынкы ак мыеклы «кыш бабай»ны яратты, ахры, нарасый...

Ләкин дәреснең икенче сәгатендә хәл бөтенләй үзгәрде. Малаебыз әллә безгә күнегеп бетте, әллә тәнәфестә озын коридор буйлата чабып, шукланып йөрүләрен тагын да дәвам иттерәсе килде, һәрхәлдә, ни генә булса да, дәрескә ул бик тә теләмичә керде һәм, бер ара вакыт үтүгә, кыбырсый башлады. Егетебезнең «йомышы» килеп терәлгән иде, ахрысы... Әнисенә кузгалырга урын калдырмыйча, малайны аудиториядән Чәчкә Әминова алып чыгып китте.

Алар артыннан ишек ябылуга, Одинцов кулындагы калын дәреслекне бер кырыйга куйды да күзлеген салды, көлемсерәде:

— Чая малай икән, молодец!.. Әйтегезче, мадам Мөхәммәтьярова, улыгыз әтисенә охшаган, ахрысы, әйе?

— Әйе,— диде Роза, чак кына кызарына төшеп.

— Ә кем соң аның әтисе... Гафу итегез, мадам.

— Әтисе... ни... Астраханьнан иде ул. Укытучы. Ә сугышта өлкән лейтенант...

— Үзегез каян?

— Төп Казанныкы мин.

— О, сез алайса ике зур каланы бер төенгә бәйләгәнсез икән. Әтуегыз кайда үтте? Казандамы, әллә егет каласындамы?

— Безнең туй, профессор, фронтта булды. Бөтен рота белән ясаган иделәр...— дип чак ишетерлек итеп җавап кайтарды Роза.

— Фронтта? Кара син әl Гаҗәп тә хәл... Малаегызның исеме дә гаҗәеп... Кем куШты, әтисеме?

— Юк... Мине, йөкле булгач, сугыштан иртәрәк кайтардылар. Мин... ни... ни...— Розабызның кысык иреннәре арасыннан без күнекмәгән бөтенләй икенче тавыш, әллә нинди сынык, нәүмиз авазлар чыга башлады. Менә аның күз төпләрендә бөрчек-бөрчек яшь күренде, һәм алар аның бите буйлап түбәнгә тәгәрәделәр.— Мин монда бәбәйләп чыгуыма, аның хәбәрен китерделәр. Ирем... ирем Одер елгасын кичкәндә һәлак булган икән... Улымның исемен аның ядкаре... аның хәтере өчен, мин үзем...

Розабыз өстәлгә капланды. Одинцовның йөзен кара болыт басты. Тавышы сыкранып, өзгәләнеп чыкты:

— Гафу итегез, мадам... Мин белмәдем. Авырткан җирегезгә кагылганмын икән... Гафу итегез, зинһар, мин картлачны...

Картыбыз бер мизгел баскан җирендә кузгала алмыйча торгач, өстәлләр арасына керә башлады. Яшь хатынны, янына басып, юатмакчы булды, ахрысы... Ләкин шул мәлне ишектә Чәчкә Әминова белән Одер күренде. Профессорыбыз, кире борылып, тәрәзә янына китте. Арты белән басты. Күрсәтмәскә тырышса да, имән бармагын күз төпләренә тидереп алганлыгын аермачык сиздек. Аудитория тып-тын иде. Шул тынлыкта Одерның әнисе колагына нидер пышылдаганы ишетелде. Розабыз башын күтәрде. Ләкин ул без белгән әүвәлге староста Роза кебек иде инде. Кырыс елмайды...

Дәрес бетүгә профессор ялварулы бер тавыш белән Розага мөрәҗәгать итте:

— Мадам Мөхәммәтьярова... Сез кичерегез инде... Сезгә бер үтенечем бар иде: улыгызны мин үзебезгә алып чыгыйм әле! Ул монда сезгә комачау гына итә бит. Ә безнең квартира монда гына, гыйльми китапханә артындагы флигельнең икенче катында гына, тиз табарсыз... Карчыгым да нәниләрне өзелеп ярата минем... Ризамы сез?

Роза утырган җиреннән олыгаеп күтәрелде. Башын селекте.

— Юк, Петр Дмитриевич, бирә алмам шул. Мин аны детсадка урнаштыру артыннан йөриячәкмен... Менә тагы ике сәгатьтән соң, француз теле дәресен уздыргач та, врачка бармакчы идем. Гаеп итмәгез,— диде ул моңсу гына.

— Нинди гаеп булсын, ди? Тик аңарчы да вакыт шактый бит әле. Сабыегыз да кинәнер генә иде. Безнең дә бит шушындыйрак оныгыбыз булырга торган иде, тик... язмаган икән...— Профессор кинәт тавышына көррәк, ягымлырак рәвеш биреп, турыдан-туры Одерның үзенә эндәште: — Улым, карале, барасыңмы безгә? Мин сиңа шундый да кызыклы, шундый да көлкеле китап-журналлар күрсәтер идем, аннары бергәләп уйнар да идек, ә! Барасыңмы безгә улым?

Малаебызның түгәрәк бите куанычлы җәелеп китте:

— Барам!

Без артларыннан карап калдык: озын коридор буйлап икәү генә киттеләр. Бер якта аю малае шикелле итеп киендерелгән малай аватүнә атлый, икенче якта чак кына бөкрәя төшкән профессор картыбыз яны белән тырыйк-тырыйк баса, ә урталарында ике кулга эленгән шәп күнле портфель селкенә иде...

* * *

Француз теленнән эшләребез сизелерлек булып алга таба тәгәрәде. Укытучыбыз Ксения Гавриловна, илле тирәләрендәге юантык кына апа, бик тә канәгать. Хәзер ул элгәреге кебек тырт-пырт кабынып китми, ыңгыр-шыңгыр зарланырга да тотынмый. Рәхәт хисләр кичерәсен алдан ук сизенгәндәй елмаеп килеп керә, елмаеп, бер җай белән, дәресне әпле генә алып бара. Ник дисәң, өй эшләре тиешенчә хатасыз-нисез диярлек бәрыбыз тарафыннан да үтәлгән була, бирелгән текстны теләсә кайсыбыз шартлатып тәрҗемә итеп чыга ала. Ишетүебезчә, Ксения Гавриловна безнең курстагы бүтән группаларга кергәч:

— Әнә «классик»лардан үрнәк алыгыз, ичмасам, анда өйгә бирелгән эшне үтәмичә килгән студент булмас, ничә тел өйрәнсәләр дә, җан аямый тырышалар,— диебрәк макташтыра, ди.

Алай түбәләребез түшәмгә тиярлек иттереп чөймәсә дә, үзебезгә дә җылы-җылы сүзләрне ычкындыргалый иде. Без канәгатьләнеп елмаешабыз гына. Сиздермибез. «Деканат, расписаниегә сезгә кадәр грек телен куеп, әкәмәт шәп иткән, ә без ул дәрестә гел грек телен генә өйрәнмибез...» дип, аңа алга таба тәгәрәвебезнең төп сәбәпләреннән берсен ачып салмассың бит инде.

Гадәттә Ксения Гавриловна аудиториягә ут капкандай ашыгып, кабаланып килеп керә һәм, урындыкка җәйрәп урнашкач, бер ара тын алып утыра. Бу юлы да ул шулай бер ара сулышын җайлап һәм тулы йөзенә кулы белән һава җилпеп утырды да, күк букчасыннан китапдәфтәрләрен чыгарганчы, мөлаем бер караш белән безгә күз йөртеп алды:

— Әлерәк кенә сезнең профессорыгыз Одинцовны очраттым мин. Нигәдер бүген кыяфәте талчыкканрак сыман күренде. Шулай да, исәнләшкәндә, елмайды үзе,— дип хәбәр итте апабыз.— Ничек соң, мөнәсәбәтләрегез әйбәтме, картны охшаттыгызмы, рәнҗетмисезме?

— Без бик тату яшибез, кая ул рәнҗетүләр,— диештек барыбыз бер авыздан диярлек.— Бездә полный демократия!

— О, демократия дисез! Тик ул демократия дигәнегез үтә бер яклы, тик сезнең файдага гына булмаса, шәп инде... Сез аның бик тә олы, бик тә зур кеше икәнлеген беләсезме соң?

— Беләбез.

— Ә сез аның сәламәтлеге ни өчен шулай бик нык зәгыйфьләнеп калганлыгын да беләсезме? Аннары ни сәбәптән безнең Казанга килеп чыкканлыгын да әйтteләрме, әллә үзе сөйләп бирдеме?

Тукта, бу апаның теле кычытып тора түгелме соң? Әнә күрәсу күзләрендә дә ниндидер сәер чаткылар чагылып китте ләбаса... Ксения Гавриловнаның ире доцент Ширяев безнең классик филология бүлегенең мөдире, димәк ки, бу апа безнең карт профессор хакында иреннән ни дә булса кызыклы нәрсә ишетеп алган... Сагаеп калдык һәм шундук:

— Белмибез... Сөйләгәне юк,— диештек төрле яктан.

— Шулаймы? — дип, юан гәүдәсен боргалап алды Ксения Гавриловна.— Алайса, сезгә үзем ишеткән хәтлесен генә булса да аңлатып бирмичә ярамастыр... Петр Дмитриевич сугышка хәтле, үзе ак эмигрант булса да, политикадан читтә торган. Никадәр генә тегеләр яклар кысып нитеп карамаса да... Гел үз фәненә чумган да утырган, дөнья аңа әллә бар, әллә юк дигәндәй...

Шул чакны Леонид Хотин аны, кыбырсыкланып:

— Ә ни өчен ул ак эмиграциягә киткән, әйтә алмыйсызмы? Үзеннән соравы ничектер уңайсыз,— дип бүлдерде.

Ксения Гавриловна сүзгә кысылганлыгына ризасызлык белгертеп, каш җимереп безнең егет ягына карап куйды.

— Ансы миңа да караңгырак... Революция культураны җимерә, Россияне упкынга тәгәрәтә дигән уйдырмага ияргән, ахрысы, ул да... Ярый, ни булса да булган, эмиграциягә киткән бу. Әйткәнемчә, эмигрантлар коткысына бирелү, төрле компанияләргә катнашу түгел, шуларга үзенчә ризасызлыгын күрсәтеп, фәнгә чумган... Тарих фәненә. Ачыклап әйтсәк, Россия тарихына, аның да бигрәге культура тарихына... Моның өчен бик күп, бик күп телләрне өйрәнгән, булган материалларны оригиналда уку, белү, чагыштырып өйрәнү өчендер, билгеле. Тора-бара Одинцов зур галим булып өлгергән, зур-зур хезмәтләр бастырып чыгарган. Рус, француз, тагын бүтән телләрдә... Сорбоннада укыткан. Әйткәнемчә, политикада катнашырга теләмәгән. Әмма ләкин, егетләрем-кызларым, сезгә мәгълүмдер ки: кеше политикадан читләшсә дә, политика кешедән читләшми бит ул, бүрәнәме, әллә йомычка гынамы син, елга тулып ташып аккан чагында, бөтерә дә дулкыннарында тирбәлдереп агызып алып китә... Менә бервакыт Францияне, Парижны фашистлар басып ала. Анда инде, үзегезгә мәгълүм, җәбер-золым, ату-кисүләр, бөтен бер илне аяк астында таптау... Үз туган иле түгел, шулай да Одинцов гамьсез генә күзәтеп тора алмый. Антифашистлар хәрәкәтенә катнашып китә. Политика дигәннәре моны җиңә. Әлбәттә, дошманга сиздермичә, астыртын гына көрәшчеләргә төрлечә ярдәм итешә, бигрәк тә материаль яктан. Ул да түгел, фашистлар Германиясе безнең Советлар иленә сугыш башлап җибәрә... Бу нишли?

Апабыз соравын куйды куюын, әмма аңа җавап бирергә ашыкмады, әле сөйләгәннәре безгә ничегрәк тәэсир итте икән дип, ахры, бер мәл аудиториядә утырганнарның сулышын тыңлап торды. Ә без сулышларны кыскан идек...

— Юк, башта берни дә эшләми, эшли дә алмый. Ачы сыкранудан бүтәнне белми... Ә немецлар моның исеме дөньяга таралган зур галим икәнлеген яхшы аңлыйлар. Үз якларына борып, аңардан файдаланырга ниятлиләр. Монда инде политиканың бөтенләй икенче төрлесе, яманы бөтереп алмакчы була моны... Ләкин фашистлар аны буйсындыра алмый. Ни хәтле җәберләсәләр дә, профессор бирешми. Шуннан соң аны, тәмам эштән чыгарып, концлагерьга илтеп ташлыйлар...

Шул чакны мин:

— Ә фашистлар аңардан кайда, ничек файдаланмакчы булганнар соң? — дип сорашмыйча булдыра алмадым.

— Аңарданмы? Ничекме? Юк, ул кадәресен мин белә алмадым әле,— дип җилкә тартты Ксения Гавриловна һәм, уфтанып, сүзне икенчеләйгә борды:

— Аның семьясына да җиңел булмый. Хатынын, Элизабет ханымны, бәлкем күргәнегез дә бардыр? Минем яшьләрдә ул, ә чәчләре — Ксения Гавриловна бераз тузгый төшкән, бер бөртек тә энҗесе күренмәгән куе көрән чәч өеменә орынып алды,— ә чәчләре бүген иртән яуган кар шикелле...

Бер почмактан Нинель Данкевичның тавышы ишетелде:

— Ә ни өчен профессор безнең Казанга кайтырга исәп иткән? Мәскәү ише зуррак калага түгел?

— Иреккә чыгарылгач, Франциядәге төрле больницаларда, курортларда дәваланган ул. Аннары, сәламәтлеге бераз рәтләнә төшкәч, безнең Париждагы илчелеккә мөрәҗәгать иткән. Туган иленә кайтуны сорап... Әлбәттә, аңа Мәскәү яисә Ленинград ише шәһәрләрдә дә урын табылыр иде, әмма профессор Мәскәүгә кайту белән: «Миңа Идел буенда утырган берәр тынычрак кала булса икән», дип үтенгән. Моңа Казан университетын тәкъдим иткәннәр. Профессор шатланып риза булган...

Бу хәлләрне без болай ук белми идек һәм укытучы апабызның шушы сөйләгәннәренә бик тә канәгать булдык. Ә ул, бүтән сүз өстәмичә, аудиториядәге тынлыкны уйчан-боек бер кыяфәт белән тагын бераз тыңлап торды да юан бүксәле букчасыннан дәреслеген-мазарын ала-ала болай диде:

— Әйе, профессорыгыз зур галим генә түгел, олы җанлы кеше дә ул. Сез инде аның күңелен күрә белегез. Ә укытучыга студентлары сабакларын әйбәт укыса, иң әйбәт бүләк шул... Аңладыгызмы?

Ләкин соңгы сүзе яңалык түгел иде: укый башлаганнан бирле укытучыларның колакны тондырып бетергән нәрсәсе иде...

Арабыздан кайсыдыр кыз ярым пышылдап:

— Аңладык,— дип куйды.

* * *

Бер дә бер көнне миңа профессор Одинцовның хатыны Элизабет ханымны болай күреп калу гына түгел, хәтта танышып, бераз сөйләшеп алырга да җай чыкты. Бу хәл мин һич көтмәгәндә булды.

Беренче дәрестә үк профессорның без өч егетне: «Чамалагыз аны, мсьелар, мин сезгә борынгы грек телен өйрәтмичә калдырмам!» — дип кисәтүе үзенчә бер рәвештә тормышка аша барды. Һәр дәрестә диярлек ул, яңа материалны аңлатырга керешкән чагында, мине яисә Леонид Хотинны такта янына чакырып чыгара да:

— Сез барыбер дәфтәрегезгә дә юньләп язмыйсыз, китаптан да күзәтеп бармыйсыз, ичмаса, менә шушында кара такта янында зиһенегезгә азмы-күпме сеңеп калыр,— дип, аерым сүз яисә тулы җөмлә әйтеп, тактага яздырта.

Үзенә такта янында басып торуы кыен аңа.

Баштарак Вил Вахитовны да борчый торган иде, ләкин бу егетебез еш кына дәрескә кермичә кала, керсә дә, киреләнә яки укытучы кушканга бик тә иренеп кенә буйсына иде. Ә без икәү күнегеп беттек.

Менә бу юлы да Одинцовның карашы миңа төбәлде:

— Мсье... иптәш Кәримов...

Ул шулай, буталып булса да, акренләп «иптәш» сүзенә ияләшеп килә иде инде.

Мин фамилиямне ишетүгә үк, аны-моны уйламастан, кара такта янына чыгып бастым. Кулыма акбур алдым. Ә ул кесәләрен капшаштырып, эзләнеп утырган җирендә, баш селкеп, көлемсерәде.

— Юк, мин сезгә тактага җөмлә яздыру өчен дәшмәгән идем. Мин ни... күзлегемне өйдә онытып калдырганмын. Сез, авырсынмыйча гына безгә кереп, күзлегемне алып чыга алмас идегезме? Минем квартирам монда гына бит... Табарсызмы, мсье? — диде.

— Әлбәттә, табармын... Бер аягым монда, икенчесе тегендә булыр, профессор,— дидем.

Чыгып йөгердем.

Менә ул аулактарак утырган ике катлы борынгы йорт. «Бу текә, бормалы баскычтан профессорга менеп йөрүләре, ай-яй, җиңел түгелдер», дия-дия икенче катка күтәрелдем. Иплән кенә ишекләрен шакыдым. Эчтән нәзек-йомшак бер аваз яңгырагач, ачып кердем. Кердем дә гайрәт белән исәнләштем. Каршымда мадам Элизабет үзе басып тора иде, әлбәттә... Юкарак кына гәүдәле, вак җыерчыклар сырлый башлаган, әмма чибәрлеген җуймаган түгәрәк йөзле. Тик җилкәсенә дулкындулкын булып төшкән чәчләре генә көмеш энҗеләр сыман... Мин исәнләштем дә ишек төбендә катып калдым. Ә ул каршымда басып торган җирендә кисәк балкып китеп елмайды һәм чуар алъяпкычының ике як итәген бармак очлары белән генә эләктереп:

— Бонжур, мсье! — дип, салмак кына рәвештә реверанс ясады.

Өнсез калдым... Бу хәлдә ни кылырга миңа! Кинәт зиһенем яктырып киткәндәй булды һәм мин, әле генә исәнләшкәнемне онытып, үзем дә:

— Бонжур, мадам Элизабет! — дип, гомеремдә беренче тапкыр, әмма һич тиешсезгә, тез сындырып куйдым.

Авызын кулы белән каплады бу... Көлде? Ә мин колакларымның уттай янганлыгын тоеп, һәм бөтенләй каушап:

— Петр Дмитриевич... ни... күзлек дигән иде... ул аны онытып калдырган,— диебрәк, тотлыга-тотлыга йомышымны аңлатып бирдем.

— О,— дип кулларын күкрәгенә кушырды мадам Елизабет,— аның шулай инде: һаман берәр нәрсәсен оныта... Ә сез хафаланмагыз, мсье, хәзер табарбыз аны... Узыгыз, утырыгыз менә монда... Утырыгыз, мсье!

Түгәрәк өстәл янындагы борынгы стильдә ясалган ялтыравык буяулы утыргычны болай табарак күчереп куйды. Мин таптангалап алдым. Ләкин ул зәңгәр күзләре белән мөлаем карап, йомшак кына иттереп янә бер әйткәч, утырмыйча чарам калмады.

Квартиралары ике бүлмәле икән. Гап-гади, профессор кадәр профессор өчен ярлырак җиһазлы иде. Мөгаен, шәбрәк, зиннәтлерәк нәрсәләрен тегендә калдырганнардыр... Түр бүлмәнең ачык ишегеннән яшел абажурлы лампа куелган язу өстәле күренә, аның кырыйларына калын-калын китаплар өелеп куелган иде... Кызык, нинди китаплар икән ул, бирегә, Казанга килгәч, көннәрен ни белән шөгыльләнеп уздыра икән профессорыбыз? Ничектер моңарчы бу хакта безнең сораганыбыз да булмады шикелле...

Алгы бүлмәләре ишек төбеннән сулга таба тоташ стена ягына ширма белән бүленеп алынган: кухня сыман нәрсәләре, ахры. Мин карангалаган арада мадам Элизабет:

— Чак кына сабыр итегез, мсье,— дип, түр бүлмәләренә кереп китте.

Бераздан чыкты, аккош канат каккандай, кулларын селкеп:

— Юк бит. Кая гына куйды икән? — диде.

Аның тавышы калтыранып чыккандай булды. Ә русчасы әйбәт икән, акценты йомшак, сизелми диярлек... Менә ул тагын кереп китте, тагын чыкты... Гәүдәгә бик тә җиңел икән. Тегеннән караштыра, моннан эзләштерә күзлекне. Аптыраганнан, ахры, бит урталарына алсу төс йөгерде.

Кинәт ул, комод тартмасын актаруыннан тукталып, ике кулы белән дә башын кочты һәм:

— Һи, хафаланмагыз, мсье: картым инде тапкандыр! — дип көлеп куйды.— Исемә төште: күзлекне шушы кулларым белән мин аның портфеленә тыгып куйган идем ич!!

Мин чак кына сызгырып җибәрмәдем.

Саубуллашып чыгып киткән чагымда, мадам Элизабет, янәдән матур иттереп, реверанс ясап алды.

Бу минем аларга беренче тапкыр аяк басуым иде, ләкин ул соңгысы булмаган икән...

Шушы хәлдән соң, берәр атна үтте микән, юк микән, бер көнне кичкырын гыйльми китапханәнең уку залында китап караштырып утырам. Партия тарихыннан семинарга хәзерләнүем. Аның укытучысы да дуамал каты сорый, аннан да бигрәк дәрестә әллә никадәр кызлар алдында абруйны җибәрәсе килми... Шулай онытылып, китапта язылган бер бик әһәмиятле фикерне дәфтәремә күчереп утырган чагымда, кайсыдыр, арттан килеп, колак яфрагыма чиртте. Башны борып, күз салсам, Миша Черепанов. Авызын ерган килеш, ишеккә табан ым какты, әйдә, бераз тын алып керик әле.

Чыктык. Ләкин, баскычтан түбәнгә төшеп, мин тәмәке тартучылар бүлмәсенең ишек тоткасына ябышуга, Миша:

— Тукта, Рифгать, анда кермичә тор әле, никотин порциясе белән агуланырга өлгерерсең әле,— дип, минем икенче кулдан әләктереп алды.

— Ә ни тагы?

— Тукта дим... Беләсеңме, нәрсә: миңа мадам Элизабет бер китап ышандырган иде. Мин аңа бүген кичке алтыда керергә вәгъдә биргән идем.

— Ничек, син аның белән танышырга да өлгердеңмени әле?

— Болай гына, бик тә очраклы төстә...

Миша бер-ике сүздә аңлатып та бирде. Кичә ул китапханәнең абонемент бүлегендә профессор Одинцовка тап булган. Теге үзенә бик күп китап сайлап куйган икән, Миша аңа шуларны өенә алып керергә булышкан.

— Алайса, әйтим инде: мадам Элизабет миңа француз теленнән «разговорник» вәгъдә итте. Үзең беләсең, бик кирәкле нәрсә бит ул безгә. Ә аны бүтән җирдән табасың да юк... Мадам Элизабет вәгъдәсендә торыр микән, әйдә бергәләп керик әле!

— Ул бит сиңа вәгъдә иткән, миңа түгел,— дидем мин, кырт кисеп.— Аннан, профессор янына керүе уңайсыз да...

— Профессормы? Ул хакта син миннән сора! Профессор ул кичке биштә тамагына ашый да монда, гыйльми китапханәгә, кереп бата. Китап актара-нитә... Мадам Элизабет кереп алмыйча торып, чыга да белми... Профессор өйдә юк дим, әйдә!

Күндем тагы.

Миша, күршедә генә торганлыктан, китапханәгә җиңелчәдән генә кереп йөри. Мин дә ес-башыма киеп тормадым: профессор яшәгән флигель янәшәдә генә ләбаса...

Кердек. Мадам Элизабет безне үтә мөлаем йөз белән һәм, гадәтенә сеңгәнчә, реверанс ясап каршы алды. Бу юлы мин, әлбәттә, сынатмадым: башымны чак кына ия төшеп, көр һәм нык тавыш белән исәнләшә белдем.

Профессор чынлап та өйдә юк икән. Мадам Элизабет, урындыкларын кучергәли-кучергәли, безне түргәрәк үтәргә дәшә башлады. Нишлисең, уздык, утырыштык. Хуҗа хатын, миңа караганда үзен ничектер иркенрәк тота белгән иптәшемә төбәп:

— Мин сезгә ышандырган китапны табып куйдым инде, мсье Мишель,— диде һәм үзе икенче бүлмәләренә кереп китте.

Ләкин ул аннан французча сөйләшергә өйрәтүче китапны түгел, бәлки калын гына бер альбом күтәреп чыкты.

— Сезнең вакытыгыз ул кадәр кысан түгелдер бит, мсье? Менә минем туган илем белән таныша торыгыз... Ә мин хәзер...

Альбомны тез өстенә алып, ашыкмыйча гына битләргә керештек. Мадам Элизабет ширма артына кереп югалды. Озакламый анда нидер чатыр-чытыр кыза башлады, борынга тәмле май исе килеп керде.

Альбомда без күрмәгән, тик ишетеп кенә белгән ерак бер илнең гаҗәеп күренешләре... Мадам Элизабет, кухнядагы эшен калдырып, кайберләрен безгә аңлатып та биргәләде. Күренешләрнең хәтергә нык сеңеп калырдайлары да байтак иде. Арада берсе безнең игътибарны аерата җәлеп итте... Диңгез уртасында тузып, ертылып беткән иске «кәпәч» кебек бәләкәй генә утрау калкып тора. Кырыйларын, текә һәм куркыныч кыялар өстеннән, биек таш койма әйләндереп алган. Урталыкта калын стеналы, тәрәзәсез-ишексез корылмалар, манаралар — дәһшәтле крепость...

— Иф замогы бу. Марсельдән ерак түгел... Гасырлар буена Франция корольләренең иң куркыныч дошманнарын, зинданга ябып, черетү урыны булган,— дип төшендерде мадам Элизабет һәм безнең икебезгә

дә күз йөртеп алды.— Сез «Граф Монте-Кристо» дигән романны беләсезме, укыганыгыз бармы?

— Белмәскә... Безнең мәктәптә ул китап укый-укый чүпрәккә калып беткән иде,— дип елмайдым мин.

— Александр Дюма үзенең герое моряк Эдмон Дантесны менә шушы зинданга ябып куя да инде... Соңыннан, беләсездер, ул кыю, батыр кеше бу тәмуг оясыннан котылу юлын да таба... Аннары инде атаклы граф Монте-Кристога әверелә...

Зәңгәр диңгез уртасында карасу-соры төстә калкып утырган бу куркыныч «кәпәч»нең ни икәнен аңлагач ук, бөтен тән буйлап салкын йөгерде...

Ары киттек... Тагын бер сурәт. Эре-эре ташлардан салынган калын стена. Аңарда ташка чокып-уеп төшерелгән кырыс һәм кыю йөзләр. Бераз алга таба чыгарып ясалган мәрмәр сын. Озын итәкле күлмәк кигән хатын-кыз сыны. Ул ярым шәрә күкрәген хәтәр киергән дә, кулларын як-якка киң җәеп, кыю йөзле адәмнәрне гәүдәсе белән капларга омтыла сыман...

— Монысы Марианна[1]... Үзенең коммунар улларын дошманнан саклап калмакчы... Атаклы скульптор Поль Моро-Вотье һәйкәле. Пер — Лашез зиратында версальчылар соңгы коммунарларны аткан стена артындагы бер скверга куелган ул.

Юк, бу альбомга табигатьнең гүзәл, искитмәле күренешләре генә түгел, канлы, дәһшәтле тарих үзе дә тупланган икән. Яңа битне ачкан саен, тарихның без ишетеп белгән яисә бөтенләй белмәгән сәхифәсе кырыс буяуларда күтәрелеп-калкып чыга иде.

Ул арада мадам Элизабет табынга әзерләргә дә өлгергән икән инде. Безне:

— Куеп торыгыз, мсье... Ни бары белән сыйлыйм әле үзегезне. Рәхим итегез! — дип өстәл янына дәшә башлады.

— Юк, рәхмәт, мадам Элизабет... Без әле күптән түгел генә ашаган идек,— дип каршы торып азапландык. Югыйсә, мин үзем, баядан ук инде ширма артыннан килгән тәмле искә кытыкланып, авызымда төкерегемне йотып утыра идем.

— Тәмләп кенә карагыз, дим... Зинһар!

Бүтән әмәлебез юк. Утырдык. Табында куырылган күкәй. Уртада олырак һәм бизәклерәк тәлинкәдә һәйбәтләп пешерелгән вак-вак белен өелгән тагы...

Миша кыюрак кылана. Ә мин тартыныбрак. Бер ялмап алырдай ризыкны вак-вак иттереп кенә кабам. Чәнечке сул кулымда, пычак уңында... Парижның үзеннән килгән бу апа каршында сынатырга ярамас, дим. Дөньяда әдәп-нәзакәт дигән нәрсәнең барлыгы кинәт исемә төшеп, җәфалый башлады лабаса!..

Ә ул, хуҗа ханым үзе, өстәл почмагындарак, кул өстенә кул салып утырган көенчә, без ашаган уңайга җаен китереп кенә, тегесен-монысын сораштыра. Минем әнинең балалар бакчасында тәрбияче икәнлеген ишеткәч, мадамның болай да сөйкемле йөзе бөтенләй нурга күмелде.

— О, бигрәк тә изге эштә икән, мсье! Кайчандыр мин үзем дә педагог идем.

Мишада эшем юк, үзем һаман да сынатырга ярамас, дим. Куырган тәбәнең дә, беленнең дә тел очына салып кына йотарлык кисәкләрен капмыйча калдырдым; булды, янәсе, булды, туклandык... Алдыбызга җыйнак кына бокалларда сөтле кофе да китереп куйган иде. Әллә ни кайнар да түгел, җитмәсә тагы, шундый тәмле дә! Монысын соңгы тамчысына хәтле йотып бетергәнемне сизми дә калдым, каһәр. Ни күз

[1] Французлар үзләренең республикаларын гадәттә «Марианна» дип, хатын-кыз исеме белән атап йөртәләр.

салыйм, Миша да шул ук халәттә... Ә мадам Элизабет, без авызыбызны ачып рәхмәт әйтергә өлгергәнче, үзе:

— Мерси, мсье... егет икәнсез! — диде, елмаеп, һәм кофены тагын салып китермәкче булды, әмма без, икебез бердән, мең рәхмәт әйтеп, баш тарттык.

Кунак ашар да качар, ди... Ләкин без качарга ашыкмадык. Кулыбызда тагын теге яшькелт хәтфә тышлы калын альбом. Янябызда мадам Элизабет үзе дә утыра. Альбомның бер битендә тукталып калдык. Рәсемнән безгә, тигез ак тешләрен елтыратып, чибәр йөзле, таза гына гәүдәле бер егет карап тора иде. Өстендә спортсменнарның җәйге җиңел киеме. Үзе, бер аягын велосипед педаленә куеп, уң кулы белән рульга таянган. Менә ул җәһәт кенә атланыр да карт юкәләр арасыннан сузылган аллея буйлап җилдәй элдертеп китәр кебек...

— Улыбыз Жак...

— Сезнең улыгыз да бармыни? Кайда ул?

— Бар иде...— Мадам Элизабетның тавышы кинәт киселгәндәй өзелеп калды, тик бераздан соң гына кипкән иреннәре тибрәлде.— Хәзер юк инде: фашистлар кулында һәлак булды... Әле өйләнергә дә өлгермәгән иде...

Миша белән мин бер-беребезгә карашып алдык. Аларның уллары хакында безнең арада берәү дә белми иде әле, хәтта француз теле укытучысы Ксения Гавриловна да бу турыда берни әйтмәгән иде.

— Ә ни өчен? Әллә Петр Дмитриевич аркасындамы? — дип сорадым мин.— Аны бит фашистлар тынычта калдырмаганнар, аңа ни хәтле җәфалар күрсәткәннәр... Безгә шулай дигәннәр иде...

— Анысы шулай. Тик улыбыз әтисенә кадәр үк инде антифашистларга кушылган иде. Аннары яшерен эшкә күчте... Оккупантларга тынгылык бирмәделәр алар. Тауларга партизаннарга киткәнен ишеттек бервакыт... Шунда, Гренобль каласына разведкага барган җирендә, бер хыянәтче аркасында, гестапо тырнагына эләккән улыбыз...

Бәхете һәм шатлыгы ташып торган көләч егетнең сурәтенә текәлгән килеш, бер мизгелгә тын калдык.

Миша авыр сулап куйды һәм:

— Ә Петр Дмитриевичны ни сәбәпле концлагерьга ябып куялар соң? Ни нәрсә эшли ул аларга? — дип, башын күтәреп, хуҗа апаның йөзенә карады.

Мондый сорауны мин үзем дә бирмәкче идем: Ксения Гавриловна нәкъ менә шул хакта аныклый алмаган бит.

— Юк, киресенчә, мсье: бер ни эшләмәде... Болар минем картым белән күптәннән кызыксына иде. Танылган галим ич... Үз якларына аударырга маташалар. Оккупантларның коменданты бер-ике тапкыр икебезне дә зур банкетларына чакырды, бүләкләр җибәртеп карады. Улыбызның партизан отрядларында аларга каршы сугышып йөрүен дә белмәмешкә салындылар хәтта... Әмма озакламый беленде: бөтенесе дә хәйлә икән...

Мадам Элизабетка теге заманның яман көннәренә кире әйләнеп кайтуы җиңел булмагандыр, әлбәттә, ләкин шулай да, тавышы вакыт-вакыт өзгәләнеп куйгаласа да, ул фашистларның мәкерле хәйләсе турында сөйли алды.

...Кырык икенче елның май аенда була бу хәл. Бер дә бер көнне Париж коменданты әйтә профессор Одинцовка: «Сезне Геббельс әфәнде үзенә чакыра, кичекмәстән барырга кирәк», ди... Шул көнне үк, комфортабельле зур самолетка утыртып, алып китәләр Берлинга, Геббельсның үзенә. Кунак итеп, янәсе... Анда моның алдына дөньяда булмаган шәраплар куялар, татлы телләнеп, күкләргә чөеп мактыйлар үзен. Шуннан соң, тагын самолетка утыртып очырталар фронтка, Ленинград тирәсенә... Ә Ленинград камауда, Ленинград халкы әҗәл

белән якалаша... Менә шунда гына ачыла инде дошманның хәйләсе. «Син, диләр, атаклы галим, рус кешесе, ак эмигрант, син, давай, ватандашларыңа эндәшеп, радиодан һәйбәтләп чыгыш ясa әле! Күңелләренә, җаннарына үтәрлек булсын — безгә каршы торып азапланмасыннар!» — диләр... Ягъни кулындагы асылташны дошман бер ялтыратып алмакчы була. Ә бу ялтырамый: «Мин Ватаныма хыянәт итә алмыйм», ди. Тәмле телләнеп үгетләп тә карыйлар: «Без әйткәнгә күнсәң, без сине Россия академиясенең президенты итәр идек» дип, юхаланалар хәтта... Юк, буйсынмый! Шуннан соң яман куркытуга-янауга күчәләр, стенага териләр үзен... Юк, бирешми профессор! Аннары ни? Караңгы зиндан базлары, концлагерьлар...

— Картымны шулай җәберләгән вакытта, улымның да гестапо тырнагына эләгүен ишеттем... Анда инде үземне дә ирекә озак тотмадылар. Үземнең туган илем туфрагындагы Шатобриан концлагерена илтеп яптылар. Ярый әле дуслар булышты. Ул җәһәннәмнән котылуыма әле дә ышанып бетә алмыйм...

— Фашист этләре кайда да бер инде алар...

Мин Элизабет ханымның җилкәсенә дулкын-дулкын булып төшкән чал чәчләренә күз салдым. Күңелемне соклану һәм горурлану хисе биләп алды: «Әнә нинди кешеләр икән безнең профессор да, аның хатыны мадам Элизабет та...»

Хәтфә тышлы калын альбомны тагын да караштырырга безнең күңел ятмый иде инде, Миша аны әкрен генә ябып куйды...

* * *

Тора-бара әллә старостабыз Роза Мөхәммәтьярова йомшый төште, әллә без үзебез әкренләп шомарып, үткенләнеп киттек, ни генә булса да, без күңелебезгә бик үк ошамаган кайбер лекцияләрдән киткәли башладык. Әлбәттә, дәрестә тик үз группаң гына булганда, моны уйларга да ярамый иде, лекция бөтен бер курска укылган сәгатьләрдә, ягъни аудитория халык белән тулган чакларда гына алдын-артын уйламыйча шылу мөмкин иде. Старостабыз кайвакытны сизмичә генә дә кала торган иде.

Бер көнне шулай азаккы лекциядән тайдым да, инде хәзер нишләргә, буфетка гына кереп, тамак ялгап алыргамы, әллә ашханәгә китеп, корсакны тутырып чыгаргамы дип баш ватып, озын коридор буенча эленке-салынкы гына барам. Шулай барганда, ни күрим, коридорның теге башыннан бирe таба профессор Одинцов килә. Ул көнне аның дәресе юк иде, ә дәресе булмаганда, ул, университетка кереп, тиктомалга буталып йөрмәс иде. «Ни йомышы төшеп, болай да сырхаулы аякларын җәфалап йөри инде бу карт», дип уйладым мин...

Якынлаштык. Гадәтенчә, ягымлы балкып елмайды. Мин дә шулай. Дустанә кыяфәт һәм көр тавыш белән исәнләшкәч, мин ипле генә үтеп китмәкче булдым. Ләкин ул:

— Мсье... иптәш Кәримов. Бер генә минутка сабыр итегез әле,— дип мине туктатты.— Сез бик ашыкмыйсызмы? Лекциягә керәсегез юкмы?

— Ашыкмыйм. Лекциягә дә керәсем юк...— Профессорга: «Әле генә лекциядән шылдым», дип әйтмәссең бит инде.— Ә нигә, Петр Дмитриевич?

Картым кәкре башлы таягын беләгенә элеп куйды, йөзендәге елмаюы чал мыегы эченә сеңде, карашында да бер төсле инәлү күренде сыман...

— Мин менә тегендә вестибюльдә үк чишенгән дә идем... Сез, иптәш Кәримов, Ленинның музей бүлмәсен беләсезме? Мин менә шул бүлмәне карап чыгарга ниятләп кергән идем.

Университетка эләгеп, укулар башланган шәпкә үк инде мин Ленин бүлмәсендә булып чыккан идем, аннан соң да бер-ике мәртәбә кергәләгән идем.

— Ник белмәскә, беләм, әлбәттә... Менә монда икенче катта гына ул, профессор,— дидем мин, ашыгып.— География факультетына менгән чагында... Элгәре анда юридик факультет булган, диләр.

— Әйе, әйе... килгәч тә мине анда бер алып кергәннәр иде инде. Ә сез, мсье, мине шунда озатып куярга иренмәс идегезме?

— Нишләп ирениим, ди! Тик Ленин бүлмәсе бикледер әле. Хәер, аның ачкычы марксизм-ленинизм кабинетындагы лаборантка кулында гына. Аңардан алып ачуы бер минутлык эш, профессор.

— Тик, зинһар, вакытыгыз булса гына, иптәш Кәримов.

Мин профессорны бер ягыннан култыклап алдым. Ашыкмыйча, жай-жай гына икенче катка мендек.

Ләкин марксизм-ленинизм кабинетының лаборанткасы, ак чырайлы татар апасы, безгә ачкычны тоттыру гына түгел, хәтта музей бүлмәсенә кереп, үзенә күрә гид сыман, Володя Ульяновның яшьлек еллары хакында сөйләп-аңлатып бирергә дә теләге барлыгын сиздерде. Күрәсең, бу апа да каршысында көләч елмаеп, баш иеп торган картның кемлеген һәм каян килгәнлеген аермачык белгәндер.

Әмма профессорыбыз:

— Хафаланмасагыз иде, мадам. Владимир Ильичның биографиясе белән танышлыгым бар минем. Без үз жаебыз белән ашыкмыйча гына карыйк инде, зинһар,— дип үтенде.

Лаборантка апа, ризалыгын белгертеп, ияк какты.

Кердек.

Анда булган кеше белә: әллә ни зур булмаган жыйнак кына гаподи аудитория ул. Тәрәзәләре ишек алды ягына, бакчага карый. Стеналардагы пыяла рамнарга төрле экспонатлар беркетелгән. Арада зур рәссамнар төшергән сурәтләрнең әйбәт күчермәләре дә бар. Кай урыннарга күргәзмә әсбаплары бәләкәй-бәләкәй пыялалы өстәлләргә дә куелган. Бер кырыйда яшь Ульяновның уйчан, акыллы кыяфәтен гәүдәләндергән пөхтә таш сын. Урталыкта нык һәм шома имәннән эшләнгән кыйгач такталы озынча тар өстәлләр тезелеп китә. Алар аудиториянең ярты өлешен диярлек алып торалар. Кайчандыр, бик күп дистә еллар элгәре, аларга утырышып, студентлар лекцияләр тыңлагандыр. Ә хәзер аларга беркем дә утырмый. Ярамый. Музей әйбере. Озын һәм ерак гомерләргә сакланырга тиешле.

Петр Дмитриевич музей-аудиториянең урта бер төшенә баскан көенчә, каян һәм ничек башларга белмичә, бераз вакыт уйчан житдилектә тын гына баш боргалап торды.

— Менә шушы аудиториядә инде ул күбрәк булган,— дидем мин, пышылдап кына.

— Беләм, мсье...

Ул да пышылдап кына әйтте. Ләкин, пышылдап кына әйтсә дә, тавышы тамак төбеннән калтыранып чыкканлыгын аермачык сиздем. Монда сүз сөйләшү кирәкми. Монда, ничә керсәң дә, күңелне якты һәм кайнар хисләр өермәсе бөтереп ала. Акылның да, жанның да, әнә шул сәер һәм рәхәт дулкыннарда тирбәлгән хәлдә, япа-ялгызга гына үзара серләшәсе, киңәшәсе килә. Изге урын, изге һава...

Карыйбыз, күздән кичерәбез. Юк, монда барын да йөрәк һәм күңел аша кичерәсең. Ничә керсәң дә, шулай...

Профессорның гәүдәсе әле бөгелә, әле турая. Ара-тирә киң һәм тирән сулыш алганы ишетелгәли...

Бер заман, ни күз салыйм, профессорым, тәрәзә янына барган да, тын гына басып тора. Тәрәзә пыялаларын юка челтәрле бәс каплаган. Шәрәләнгән агач ботаклары артында анатомия театрының һәм гыйль-

ми китапханәнең тонык-ак биналары күренә... Тышта буранлый, ахры: һавада кар тәңкәләре бөтерелә... Теге заманнарда студент Владимир Ульянов та һавада йомшак һәм нәфис кар бөртекләре уйнавын күзәткәндер, мөгаен... Ни уйга батты икән профессор?

Аудиториянең кыйгач такталы озын һәм тар өстәленә таянган хәлендә, бер ноктага озак кына текәлеп торгач, Петр Дмитриевич шул ук калтыраулы пышылдау белән:

— Мсье Кәримов, минем әле актлар залына да кереп чыгасым бар. Бер уңайдан, авырсынмасагыз, сез миңа аны да күрсәтсәгез иде,— дип үтенде.

— Рәхим итегез, профессор. Монда, янәшәдә генә ул,— дип, баскан җиремнән куптым.

Безнең бәхеткә, актлар залының ишеге ачык һәм ул буп-буш иде. Көч саен диярлек без берәр лекцияне шушында тыңлыйбыз. Зур һәм иркен зал. Хәзер тып-тын. Тик безнең аяк астыбызда шома паркет кына шыгырдап алды. Стеналарда калын бизәкле алтынсу овальрамнарда университетта укыган һәм эшләгән бөек галимнәр, бөек әдипләр. Профессорым бер карауга ук аларны таныды һәм шыпыртлап кына исемнәрен әйтә башлады: Лобачевский, Бутлеров, Зинин, Аксаков, Толстой... һәркайсының карашы безгә төбәлгән иде...

Ә түрдә, кызыл комач ябылган зур өстәл һәм трибуна артындагы стенада, бөек юлбашчы үзе... Янында чәйле стакан. Киң маңгаена таянып, тирән уйга чумган. Чираттагы ялкынлы чыгышына әзерләнүе, ахры. Әллә тагын бер даһи хезмәтен язып утыруымы?..

— Менә шушы залда инде, Петр Дмитриевич... Мең сигез йөз сиксән җиденче елның дүртенче декабрендә... Студентларның бунтына дәрт-ялкын бирүчеләрнең алгы сафында була ул Владимир Ульянов...

— Әйе, мсье... Мин гимназиягә кергән елны булган икән...

Залның аргы башына бардык. Инде ераграктан түр стенадагы сөекле һәм даһи кешенең олы рәсеменә төбәлгән килеш, залдагы тынлыкны, юк, йөрәгебез тибешен тыңлап тордык...

Аннары музей бүлмәгә кире әйләнеп кайттык.

Петр Дмитриевич, һичкемгә рөхсәт ителмәсә дә, әлеге озынча өстәлләрнең берсе артына кереп утырды. Кулларын кушырып, кыйгач такта өстенә салды, гүя ул менә хәзер кемнеңдер гаять кызыклы һәм әһәмиятле лекциясен тыңларга җыенган иде. Башын күтәреп миңа карады:

— Бераз тын алыйм әле. Аякларым да...— Аның күз карашында монарчы мин күрмәгән монсу уйчанлык чагылгандай булды.— Сез ашыгасыз бугай. Хәзер китсәгез дә була, мсье... Бүлмәне бикләргә үзем әйтермен. Минем әле марксизм кабинетында китап карыйсым, китап сайлыйсым да бар... Рәхмәт сезгә, иптәш Кәримов. Ә мин калыйм әле...

Аның ни теләгәнен күз карашыннан да, тавышыннан да аңлавы кыен түгел иде.

Әлбәттә, ул бу изге бүлмәдә аяклары арганлыктан гына япа-ялгызы утырып калмагандыр...

* * *

Кышкы сессия якынлашты. Әкренләп имтиханнарга әзерләнеп маташабыз һәм җиң сызганып зачетлар биреп йөрибез. Ничек тә стипендиядән төшеп каласы килми.

Кышын латин теленнән имтихан да, зачет та юк иде. Ләкин безнең ут борчабыз Семен Яковлевич:

— Коллоквиум уздырырбыз, ансыз ярамый,— дип белдерде. «Коллоквиум» дигәнне тәрҗемә итсәң, безнеңчә «аңгәмә» дигәнгәрәк туры

килә. Ләкин бу нәрсәкәй үзенең катылыгы белән кайберәүләрнең зачетларын да егып сала. Ике айлап укыганнан соң, бер дәрестә уздырып караган иде инде ул аны.

Монысында укытучыбыз коллоквиумны, зачет алырга җыенган һәр укытучы шикелле үк, көнен-сәгатен алдан ук әйтеп, кичке уңайга билгеләде.

Ярый, килдек, җыелдык. Әмма ул бүтән укытучылар кебек һәркайсыбыздан аерым-аерым сорашып азапланмый, сорауларны бөтен аудиториягә куя да ваклап-ваклап кына йолкырга керешә. Төптән каера, усал һәм нечкәләп вәзенли...

Менә шушы коллоквиумда инде безнең Башкортстаннан килгән кара егетебез Вил Вахитов белән кызыклы да, күңелсез дә вакыйга булып алды. Вилның борынгы телләргә исе китмирәк йөргәнлеген әйткән идем инде. Шул сәбәпле Чернявский аны бер генә тапкыр әрләмәгәндер. Хәер, Вилны латин теленә бөтенләй кул селтәгән иде дисәм дә гадел булмас. Аның латинга карашы бик тә үзенчә иде: «Миңа грамматикасы-чурты ни пычагыма аның. Латинның тапкыр сүзләрен, әйтемнәрен-фәләнен шәпләп отып калсам, миңа бик житкән. Боларның кайчан да бер кирәк булып чыгуы бар»,— ди иде, һәм, безнең күбебезне шаккатырып, әллә никадәр мәкальне өйрәнеп өлгергән иде. Ул кайбер дус-ишләренең һәм башка группа студентларының күзләренә тузан җибәреп, борынгы римлыларның энҗе бөртекләрен борчак урынына гына сиптерә иде.

Менә, ниһаять, аңарчы бер почмакта кеше җилкәсе артына посып, мыштым гына утырган Вилыбызга да чират җитте. Семен Яковлевич аны бик җилле генә урыныннан куптарды да артык кыен булмаган сүзне әйтеп, шуны төрле килешләрдә төрләндереп чыгарга кушты.

— Ягез, тыңлыйм сезне, хөрмәтле иптәш.

Баш һәм иялек килешләрне Вил шартлатып әйтеп бирде. Аннары:

— Дативус... аккузативус... зингулярис...— дип тотлыга башлады, гүя әлеге сүзнең койрыгы теш арасына кысылып калган иде. Бер ара шулай әле безгә караштыргалап, әле укытучыга күз атып торгач, Вил гамьсез генә җиң эченә көлеп куйды: — Юк, белмим икән...

Чернявский кулындагы журнал белән шап иттереп өстәлгә сукты һәм, читлеккә ябылган каплан шикелле, гайрәт күрсәтеп, арлы-бирле йөренеп алды. Аның күзләре генә түгел, алтын кысалы пенснэсы ук нәфрәтләнеп яна сыман иде.

— Сез нәрсә, укырга килдегезме, әллә җил куып йөрергәме? Оятыгыз кайда? Иптәшләрегез җимертеп җавап биреп торганда, сез... сез... Юк, сез ата ялкау гына түгел... сез... сез... үтә җиңел холыклы, үтә юньсез бер кеше. Аңлыйсызмы, үтә юньсез?!

Вил җилкәләрен тарткалап, баскан җирендә таптангалап алды. Аннары, кара-кучкыл йөзенә тагы да вәемсызрак чалымнар чыгарып, кинәт бер сулыш белән:

— Гомо сум эт ниһил гуманис а мэ алиэнум путо[1], Семен Яковлевич! — дип ярып салмасынмы!

Чернявский баскан җирендә катып калды, аның озын борынлы йөзе бер кызарды, бер агарынды, һәм укытучыбыз бәләкәй гәүдәсе белән лап иттереп урындыкка утырды да күзләрен түшәмгә төбәде. Гүя ул югарыдан ярдәм көтә иде...

— Сез юри шулай... алдан ук өйрәнеп килгәнсез... мәсхәрә итәр өчен... Ни хәтле еллар укытып, ишетмәгәнеңне ишет!

Аның сулыш алуы авыр һәм еш-еш иде. Ниһаять, тынычлана төште, ахрысы, кулын җәеп өстәлгә салды:

[1] Мин кеше һәм миңа кешенең бер генә нәрсәсе дә ят түгел.

— Моннан болай мин сезне, иптәшкәй, укыта алмыйм, дәресемә керергә дә рөхсәт юк сезгә... Деканатта әйтәчәкмен. Ә сез...— Семен Яковлевич барыбызга да усал иттереп күз йөртеп чыкты да старостабыз Роза Мөхәммәтьяровага төбәлде: — Сез дә моны бу килеш калдырырга тиешле түгел. Яман гадәт чүп үләне шикелле ул, вакытында йолкып атмасаң, бөтен иген кырыңны басып китүе ихтимал. Борынгы римлылар да бик яхшы белгән моны...

Роза кырыс чырай белән баш какты:

— Әйе, Семен Яковлевич. Без аны группа җыелышына куярбыз.

Комсоргыбыз Лида Спирина да:

— Бүтән тырай тибеп йөрмәслек итәрбез! — дип куәт өстәде.

Чернявский, Вил ягына күз салып та тормастан, горур катылык аша кулы белән ишеккә таба күрсәтте:

— Бездән үзегезне азат итегез, иптәш Вахитов!

Моңсу тынлыкта кара егетебез әллә бик нык каушаганга, әллә юрамалый кыланып, ава-түнә аудиториядән чыгып китте...

Коллоквиумда бүтәннәребез андый хәлгә төшмәде. Ни хәтле авыр булса да, сыйрат күперен кичтек. Коллоквиум бетүгә, комсоргыбыз Лида Спирина, Чернявский да ишетерлек иттереп:

— Егетләр дим, кызлар дим, онытмагыз: иртәгә лекцияләр беткәч тә комсомол җыелышы! Вил Вахитовны җилләтеп алырбыз,— дип хәбәр салды.

Коридор буйлап атлаган чагында Леонид Хотин, як-ягына карангалап алды да:

— Вилны тикшергәндә, таякның бер башы безнең муен тамырга да төшүе ихтимал. Без дә бит латин белән грек теленнән песи яларлык кына тырышабыз... Җыелышта Вилны яклап, тегеләргә отпор бирмичә ярамас,— диде.

— Әлбәттә,— дидем мин, көрсенеп.

Икенче көнне Вил дәрескә килмәде. Үзе күзгә күренмәсә дә, иртәнге якта ук аның исемен шактый әвәләдек. Очкылык тотып интеккәндер мескен. Аннары беравыкка онытып тордык.

Ләкин борынгы грек теле дәресендә Вилның исеме һич уйламаганда янә калкып чыкты һәм уртага куелып, тикшерүгә дучар ителде. Монысында профессор Одинцов сәбәпче булды.

Яңа теманы башлап, яңа сүзләрне аңлатырга тотынгач, ул бер сүзгә төртелеп калды да мыек астыннан гына көлемсерәп:

— Петрос ул... петрос, кадерлеләрем, грекча «кыя» дигән сүз. Петр исеме дә, күрүегезчә, кыядан алынган,— диде.

— Димәк, сез, профессор, «кыя»... Ә этиегезнең исеме Дмитрий ни нәрсәне аңлата? — дип сорады Нинель Данкевич.

Шуннан соң профессорыбыз рус исемнәренең этимологиясен аңлатырга тотынды. Шактый озынга китте ул исемнәр: Дмитрий, Георгий, Григорий, Виктор, Виталий, Юрий, Александр, Алексей, Аркадий, Анатолий... Әлбәттә, аларның барысы да борынгы греклардан килмәгән, бүтән телләрдән алынганнары да байтак икән. Бәлкем, тагын да озынгарак китәр иде, әмма профессорыбыз кинәт:

— Ярар, артык тирәнгә китмик, кадерлеләрем,— дип кул селтәде һәм барыбызны да хәйран калдырып, өстәп әйтте.— Шунысын истә тотыгыз: «а» хәрефенә башланган исемнәр генә түгел, гомумән «а»дан башланган бик-бик сирәк сүз генә без русның чын үз сүзе булыр. Телнең үз хикмәтләре бар аның!

Безне шулай бер ара авыз ачтырып тотканнан соң да, профессор грек теленә таба кискен борылыш ясый алмыйча:

— Анысы шулай... Тик, кадерлеләрем, үзем дә аптырадым әле: мин югында безнең Россиядә... Советлар Союзында диюем, өр-яңа әллә

никадәр исемнәр туган лэбаса! — дип гаҗәпсенү белдерде.— Мин үзем күбесенең асыл мәгънәсен аңлап та бетермим.

— Нишләп? Күбесенең мәгънәсе кычкырып тора бит аларның, профессор! — диде барыбыздан да өлгер Нинель Данкевич һәм тезеп, аңлатып та китте: — Әйтик, Люция — «революция» сүзенең койрыгы. Октябринаны аңлатып торасы да юк. Ә КИМ «Коммунистический Интернационал Молодежи» дигән сүз...

Одинцов чал мыегының очларын бөтергәләп куйды:

— Ә Вил дигән исем ни аңлата, мадмуазель? Сезнең группагызда бар бит ул. Тик егетебез үзе генә нишләптер күренми әле. Әллә мин ишетмәгән төрек-татар исемеме?

— Вилмы? — дип сәер тавыш белән кычкырып куйды арадан бер кызыбыз.

— Әйе.

Муеныбыз сузылды да калды: менә сиңа мә! Шул матур исемнең дә асыл мәгънәсен белмәсен әле кеше!

— Вил ул Владимир Ильич Ленинның инициалларыннан ясалган исем, Петр Дмитриевич,— дип аңлатты, гадәтенчә, үтә белдекле кыяфәт белән Миша Черепанов.

Бу юлы инде профессорыбызның муены сузылды:

— Шулаймыни! Ә мин тагы... Исем үзе матур да, килешле дә... Заманча! — Аннары профессорыбыз безгә чал башын кыек салып карады: — Тик ни, кадерлеләрем, сезнең группадагы иптәш Вахитовның исеме җисеменә туры киләме соң?

Көлемсерәдек. Старостабызның калку күкрәге бер менде, бер төште:

— Эх, туры килсәче! Килми шул, профессор.

Һәм Роза Мөхәммәтьярова кичә коллоквиумда булган хәлне профессорга сөйләде дә бирде.

— Кара син, ә! Дәресен белмәве җитмәгән, вакытында тыела да алмаган икән егетебез... Шулай инде, әле борынгы эллиннар ук: «Гэ глотта поллакис айзия экстрас», дип кисәткән бит...— Без мәкальнең мәгънәсен аңлап бетермәгәнгә күрә, профессор аны шундук русчага күчереп төшендерде.— «Тел еш кына бәхетсезлекләргә китерә», дигәннәр алар...

— Әйе, җыелышта без аның тетмәсен тетәчәкбез,— диде комсоргыбыз, борынгы мәкальнең дөреслеген раслагандай катгыйлык белән.

Шул мәлне минем янда утырган Леонид Хотин чәчрәп купты:

— Сез нәрсә! Һаман Вил да Вил дип авыз суларын корытасыз... Ярый, коллоквиумда абынды, ди, латинны юньләп өйрәнми, ди... Әмма, аның каравы, партия тарихы семинарында кем иң актив? Шул ук Вил түгелме? Күбебез авыз ачып утырганда, кем куелган сорауны, бик шәпләп, төбеннән үк әләктереп, аңлатып, сөйләп бирә? Ничә тапкыр иң авыр моментларда коткарып калды, ә? Тарихчы булырга җыена ул — бөтен хикмәт шунда!.. Әнә, ишетмәгән булсагыз, ишетегез, гел дәресләреннән качып, кайчакларны тарихчыларның спецсеминарына барып кысыла, кичләрен түгәрәкләренә дә йөри...

— Чынлап та тарих белән бөтенләй җенләнгән ул,— дип кыстырды Нинель Данкевич, Леонидка көләч йөз белән ым кагып.

Нинель белән Вил арасында без әле бик үк сизеп өлгермәгән җепләр сузылып, ялганып бара иде сыман. Вилның волейболчылар секциясенә язылуы да нәкъ менә Нинельнең шунда йөрүе һәм иң шәп, иң җитез уйнаучылардан саналуы аркасында булгандыр әле. Бик тә урынлы кыстырды Нинель!

Петр Дмитриевичның кыяфәте үзгәрде:

— Тарих белән җенләнгән, дисезме?

— Әйе, профессор! — дип кычкырып куйдым мин.

— Димәк ки, бөтенләй төшеп калганнардан түгел икән. Димәк ки кая кунарга белмичә, җир белән күк арасында очып йөрүче кошлардан түгел икән лә ул егетебез. Дөресе, кунарга урын да сайлаган... Бәлкем куна да алыр әле. Тик ни, зинһар, кадерлеләрем, җыелышыгызда артык кызып китеп, канатларына зыян китермәсәгез иде сез ул кара бөркетегезнең...

Профессор, шулай дип, безгә гадәтенчә мыегын селкетеп кенә ым какты да каршысында онытылып яткан грек теле дәреслегенең кирәкле битен эзләргә кереште.

— Нечево яклашырга монда. Вилны барыбер утлы табага басты-рып кыздырмыйча калмыйбыз. Бүтәннәргә дә сабак булыр, ичмаса,— дип мыгырданды Лида Спирина, Леонид белән минем якка күз атып.

Без шулай азгын егетебезне комсомол җыелышында кыздырыргамы-кыздырмаскамы, кыздырсак, ни рәвештәрәк итәргә, дип баш ваткан чагында, алдына киртә булып килеп баскан әлеге ямьсез нәрсәне Вил үз куәте белән бәреп еккан булып чыкты.

Соңгы лекциягә керер алдыннан гына килде бу. Кара-кучкыл йөзен-дә хәсрәтнең эзе дә юк. Киресенчә, кара күзләрендә очкыннар уйный. Зур залга таба атлаган җиреннән туктаттым да тәрәзә янына өстерә-дем. Мин группадагы хәлне аңлатырга керешкән генә идем, Вилым, тигез ак тешләрен елтыратып, көлеп җибәрде:

— Тикшермичә торсыннар! Мин Лида Спиринаның авызын томала-дым инде. Ник дисәң, китәм мин сездән... Аллаһы әкбәр!

— Ничек китәсең? Кая китәсең?

— Тарихчылар группасына күчәм...

Коридордан, алынкы-салынкы атлап, безгә СССР тарихы курсын укучы профессор Пискарев килә иде инде.

Аудиториягә кереп урнашкач, Вил авызын учы белән каплап, ба-шыннан кичергәнне аңлатырга тотынды.

Төн йокысы качкан икән моның. Иөрәге әрнеп, уйлана-нитә торгач, «шул каһәр суккан латин аркасында гына кеше алдында хур булып ятмассың монда, зурга китсә, университеттан куылуың да бар... Беткән баш беткән, муен калса, җиткән!» — дип, таң тишегендә гариза язарга утырган. Ректор исеменә... Барын да тутырган кәгазь битенә. Тарихны өзелеп яратуын әйтү генәме, хәтта этисенең сугышта хәбәрсез югалуы хакында да кыстырган... Ә көндез, җаен китереп, барып кергән ректор кабинетына...

— Беләсең бит ректорның әйбәтлеген. Өмет тик шуңа гына иде,— диде Вил, кайнар сулышын минем яңакка өреп. Аның авызы минем колакта булса, үз колагын профессор Пискарев авызына таба каратып куйган иде.

— Беләм,— дидем.

— Шуннан?

— Барып керсәм, йөрәгем жу итте: анда үзебезнең профессор уты-ра... Одинцов! Дәрестән чыккан шәйгә кергән, күрәсең. Тез асларым йомшап китте. Инде кире дә борылмакчы идем, ректор кул изәде. Ә ул, безнең профессор, минем бәхеткә утыра икән. Ректор гаризамны укып, бер-ике сорау биргәч, Петр Дмитриевич: «Моңардан барыбер юньле филолог чыкмаячак, мсье. Аны тарих белән җенләнгән, диләр» дип, сүз кыстырып куймасынмы! Йөрәгем уч төбенә кысылган мәче баласы кебек калтыранып типкән җирендә кинәт эреде дә китте!.. Аннарымы? Ректор деканат белән кафедрага шалтыратып, сөйләшеп алды да: «Ярар»,— диде...

Вилым, шатлыклы көлемсерәгән килеш, уфтанып куйды тагы:

— Тикмәгә канына тоз салып, рәнҗеткәләгәнмен икән профессоры-бызны... Гафу үтенмичә ярамас. Аңардан да, Чернявскийдан да...— диде һәм минем кабыргага төртте.— Син дә йоклап ятма монда!

Шигырь-хикәя язамын, татар бүлегенә күчерсәгез, җан аямый укыр идем, дип кер... Ятып калганчы, атып кал!

Күнелем бер мизгелгә иләсләнеп, омсынып куйгандай булды. Ләкин шундук зиһенемне авыр уй басып алды: «Булмас, барып чыкмастыр... Мин анда керүгә, ярдәм кулы сузар өчен, профессор Одинцов һаман да утырып тормас бит».

Башкорт егете Вил Вахитовта булган тәвәккәллек миндә юк иде шул...

Беренче курста бер генә нәрсә дә ансат кына бирелми. Кышкы сессия әллә ни озын һәм катлаулы булмаса да, шактый җегәрне суырды. Авырлыгыннан бигрәк, куркудандыр, мөгаен...

Өйгә, үзебезнең Вятка буена, кайтып, әни янында югалган хәлне яңартып килдем. Килгән көннең кичендә үк туп-туры Миша Черепановны күрергә киттем. «Кышкы каникулда үзенең подвалында сөрсенеп ятты микән, әллә аңа да шәпләп ял итәргә берәр җай чыкты микән?» дип кызыксынып барган идем. Ул, кайтыр юлы шактый ерак булганга, Казанда торып калган иде.

Барып кердем. Тар, кысан бүлмәдәге ике койканың берсенә сузылып яткан да укуга чумган. Сикереп торды. Күрештек. Әле ул ялгыз гына икән. Бүлмәдәше, Пензадан килгән астроном егет, каникулга киткән җиреннән әле күренми, ди. Мин:

— Әйдә, куеп җибәр тизрәк чәеңне! Әйбәтләп сыйлыйм әле үзеңне! — дип, кулымдагы газета төргәген өстәлгә куеп, таратып җибәрдем. Анда каклаган каз боты һәм әни юлга дип салган пешкән әйберләр иде — студент өчен бары да тансык нәрсәләр...

Мишаның күзләре шундук майланды.

Тәмле кайнар чәй янында мин моңардан тегесен-монысын сораштырам.

— Нишләп сөрсеп ятыйм, ди! Минем дә ял менә дигән булды,— диде ул, каклаган каз ботын бик тәмләп чәйнәгән шәйгә.— Көндезләрен Казанка буенда чаңгыда йөрдем, ике-өч тапкыр Аккош күленә барып, исергәнче нарат урманы һавасын сулап кайттым.

— Ярый, бик шәп. Ә кичләрен нишләп яттың? Менә болай китап кимерепме? — дип текәлдем мин.

— Һе, әйттең сүз! Көн саен театрга йөрдем.

— Кесә төбеңне, алайса, беткәнче такырайткансың икән. Яниләр карадың, ниләр тыңладың соң? Мактан! Тагын опера яисә балеттыр әле. Әллә берәр җирдән симфоник оркестр килгән идеме?

Миша музыка хакына җанын сатарга әзер кеше. Кыллы оркестрга да тикмәгә генә язылмады. Декабрь азакларында сессия житеп, студентларның кайнар көннәре булуына да карамастан, ул Куйбышевтан килгән симфоник оркестрның (ул чакта Казанның үзендә юк иде әле) бер генә концертын да калдырмаган иде диярлек.

Егетем җавап бирергә ашыкмады. Ниһаять, чәйнисен чәйнәп йоткач, авыз тирәсен газета кисәге белән сөртештереп:

— Ни карадык, ни тыңладык, дисеңме? — дип вәкарь белән сузып җибәрде.— Без Петр Дмитриевич белән...

— Нәрсә, профессор Одинцов белән йөрдегезмени?

— Әйе. Кай кичне безгә мадам Элизабет та ияргәләде. Операны да, балетны да калдырмадык. Әкәмәт театрал кеше икән безнең профессор! Житмәсә, күршеләр генә бит без... Эх, беләсеңме, сезнең «Алтынчәч» операсы белән «Шүрәле» балетын да үлеп яратты ул. Мин дә...

Калай бокалдагы чәйне өрмичә, абайламыйча каптыммы, авызым пеште.

— Галәмәт шул. Дөньяда бер,— дидем мин.— Ә Зур театрга бармадыгызмыни?

— Бармадык. Анда бит тау астына, Бауманга төшәсе. Профессорга кыен анда баруы. Без һаман да бер җиргә — татар театрына йөрдек.

Ул заманда опера һәм балет театры да спектакльләрен Татар академия театрында куя, үз йортына аерылып чыкмаган иде әле.

— Эх, җен алгыры, килеп җитмәдең! Өченче көн генә әле без татар театрында, беләсеңме нәрсә карадык? «Хуҗа Насретдинны!»

Халыкның дуамалланып театрга йөргән чагы: анда Хәлил Әбҗәлилев Хуҗаны уйный иде. Авызымнан бер генә аваз чыкты:

— Соң?

— Әкәмәт көлке икән. Петр Дмитриевич әйтә: «Моңа кадәр бик күп телләрне өйрәнгән идем, ләкин төрки телләрне өйрәнмәвемә үкенәм. Ичмаса, барын да аңлап көләр идем», ди... Алай да күп җирен аңлады шикелле. Аннары кеше көлгәндә, аңлап бетермәсәң дә, түзеп булмый икән. Колакта әле дә чыңлап тора... Эх, килеп җитмәдең, янибызда тәрҗемә итеп утырган булыр идең!

— Җәл шул,— дидем һәм борын яфракларын сызгыртып еш-еш сулап куйдым.— Монда сөрсегән һаваңны иснәп утырганчы, әйдә, урамга чыгабызмы әллә?

— Ярар, чыгарбыз...— Миша кисәк минем иңбашка шапылдатып куңдырып алды.— Ә син көнләшмә, яме!

Көнләшмәссең монда!..

*
* *

Тулай торакта без бер бүлмәдә биш студент яшибез. Төрлебез төрле милләттән.

Кичләрен, лекциядән кайтып, тамак туйдыргач, мәж киләбез. Гадәттә шаулатып домино сугабыз.

Чуваш егете Антон белән минем якташ Вятка егете Герман физматта укыйлар. Боларның өйгә биремнәре чиксез күп була, әллә ниткән мәсьәләләр чишеп, әллә нинди формулалар өстендә баш ватып утыралар. Алар еш кына без куптарган шау-шуга чыдый алмыйча өченче каттагы уку залына менеп югалалар. Буш чаклары булганда да, безнең шикелле уч төпләре кызарып-бүртенеп чыкканчы домино сугып азапланмыйлар, бер-ике мәртәбә «кәҗә» калгач ук, койкага менеп кунаклыйлар да шахматка ябышалар.

Домино чирен безгә Васил йоктырды. Төз гәүдәле, чүмәләдәй күпереп торган сумала чәчле егет. Дөрес, ул үзе генә әллә ни кыра алмаган да булыр иде: безнең күрше бүлмәдә генә аның дусты Идрис яши тагы. Менә шулар кара-каршы утырып тотынсалар, чыда гына: башың «кәҗәдән» чыкмый...

Бер көнне Васил домино уйнап утырганда тәрәзәгә күз салган иде, кинәт, муенын сузган көенчә:

— Оһо, карагызчы, кем ул, ни ул?! — дип кычкырып куйды.

Урамнан кәз-кәз атлап барган берәр чибәррәк кызны күрсә, шулай ул: барыбызны да урыннарыбыздан кубарып, тәрәзәгә сыландыра һәм теге чибәр кызыкайның аяк-сыннарын, атлау рәвешләрен бик тәмләп тикшерергә тотына. Кайчакларда без аның белән бик үк килешеп бетмибез һәм теге кызыйның шәплеге турында кайнарланып сүз көрәштерә башлыйбыз...

Ә бу юлы, юк, урамда кыз затыннан берәү дә күренми иде.

— Ә мин кыз дидеммени? Әнә «Победа»га кара син, кем килгән аңарда? Синең профессорың түгелме соң, Рифгать? — диде Васил.

Күрче, чынлап та бит: ректорның соры «Победа»сы янында башына каракүл бүрек кигән, кулына таягын тоткан безнең профессор Одинцов үзе басып тора лабаса! Аның янәшәсендә Миша Черепанов — өстендә кышын да, җәен дә кия торган нечкә билле кара шинеле... Менә Миша

профессорны култыклап алды, һәм алар әкренләп болай таба кузгалдылар.

— Шундый пычрак көнне дә иренмәгән, ә? — дип ахылдады Герман.— Ни йомышы төште икән?

Моннан бер-ике ай элгәре үк әле профессорның: «Вакыт табып, бер барып кайтам әле сезгә... Үземнең студентларымның кайда, ничек торганын үз күзем белән күрәсем килә», дигән сүзләре капыл гына исемә төште һәм:

— Ярар, телегезгә салынмагыз! Безнең бүлмәгә сугылмыйча калмас, давай, ач тизрәк форточканы, ач ишекне — җилләтик! Тотыныгыз ятьрәк җыештырырга! — дип команда бирдем.

Идрис үз бүлмәсенә шылды. Безнекеләр, санкомиссия йөрү хәбәрен ишеткәннән дә болайрак җитезлек белән урыннарыннан кубып, бүлмәне рәткә китерергә тотындылар.

Мин үзем тегеләрнең каршыларына чаптым.

Профессор, гадәтенчә елмаеп һәм тәмле телләнеп, вахтер абзый белән сөйләшкән арада, мин Мишаның колагына:

— Иң әүвәл икенче катка кызлар янына меник. Бездә эт баш, сыер аяк әле,— дип пышылдарга өлгердем.

Миша хәлне бер сүздән аңлап алды. Профессор үзе дә каршы килмәде:

— Әйе, дөрес булыр... Соныннан югарыдан түбәнгә төшүе ансатрак ул,— диде, ләкин үзен култыклаттырмады.

Мендек.

Икенче катта безнең группадан Чәчкә Эминова белән комсоргыбыз Лида Спирина яши иде. Икесе дә бер бүлмәдә. Шакыдык, кердек. Әмма безнең кызлар өйдә түгел икән. Бүлмәдә саргылт түгәрәк йөзле чех кызы Марина гына япа-ялгызы өстәл артында нидер язып утыра иде. Туган иленә хат иде, ахрысы...

Кызый капылт кына урыныннан купты, бер кулы белән халат изүен каплагандай итте, сөйкемле йөзенә куе кызыллык йөгерде.

Профессор, бүлмәнең пөхтәлегенә сокланыпмы, әллә яшь кенә бер кызның самими гадилектә тотлыгып, кызарынып калуына гаҗәпсенепме, кулына бүреген тоткан көенчә баш селкеп торудан бүтәнне белмәде. Безнең Чәчкә белән Лида хакында сорашуыбызга Марина:

— Алар кайтмадылар әле. Белмим, гыйльми китапханәдә утыралар микән, әллә кинода микән,— дип җавап кайтарды.

Кызның сузыбрак һәм каушабрак әйтелгән сүзләрендә акцент аермачык сизелде, һәм профессор шундук:

— Ә сез, мадмуазель, каян килдегез соң? — дип сорады.

— Прагадан.

— О, Прагадан? Сез чех кызымыни әле! — дип сузып җибәрде Петр Дмитриевич һәм Миша белән мин аңламаган телдә кызу-кызу нидер такылдарга кереште.

Кыз да иркен сулыш белән көлеп куйды. Кая монда тотлыгып торулар! Теле телгә йокмый, үзе бертуктаусыз елмая, кай арада пырхылдап та ала. Без генә берни аңламыйча авыз ачып торабыз...

Марина утырырга ни кыстаса да, утырмадык. Профессор инде без белгән телдә:

— Мин әле бер иркенләбрәк килермен... Җирләр кипкәч, кояш җылытып, елмая башлагач, яме, мадмуазель! Бүлмәдәшләрегез белән бергәләп саф һавада тегесен-монысын сөйләшеп йөрербез, сабыр итик,— диде.

Коридорга чыккач, профессор уйчан бер кыяфәттә баш чайкап, безгә пышылдады:

— Заманасында без чит илләргә гыйлем эзләп барыр идек, ә хәзер...

Тулай торакта безнең группадан тагын өч-дүрт кыз яши иде. Ләкин

алары дүртенче катта иделәр. Петр Дмитриевич анда менәргә авырсынды:

— Мин бит әле болай гына, уйламаганда гына килеп чыктым. Ректордан да автомобилен бер генә сәгатькә сораган идем. Әйдәгез, үзегезгә генә кереп чыгыйк,— диде.

Кире беренче катка төштек. Бездә дә инде тулы тәртип диярлек. Әлбәттә, кызлар бүлмәседәй ялт итми, шулай да һава саф, урын-җирләр ярыйсы гына пөхтә җыештырылган, хәтта китап этажеркасындагы тузан да сөртелгән иде.

Доминодан җилләр искән: өстәл артында Антон белән Герман шахмат уенына чумган, ә Васил исә бер кырыйда аяк бөкләп утырган да, няген югары чөеп, үтә акыллы кыяфәт белән кулындагы китапка төртелгән. Изге бер ишан яисә алланың кашка тәкәсе диярсең үзен! Кулында, әлбәттә, әллә ни түгел, тетелеп бетә язган бер брошюра...

Без килеп керүгә, өчесе дә, җил куптаргандай, җәһәт кенә урынннарыннан кузгалды. Кунакларны күз ачып йомганчы чишендердек.

Профессор узарга да, утырырга да ашыкмады, бер ара бүлмәгә күз йөртеп алды, этажеркадагы китапларны кузгаткалап карады һәм:

— Әйбәт яшисез икән...— диде. Аннары, янәшәсендә үрә катып торган Мишага ым какты.— Әйдәгез әле, Мишель, егетләрнең шахмат уйнавын карап карыйк әле: бездән шәбрәк уйныйлар микән, юк микән?

Мишаның профессор квартирасында бер-ике кичне шахмат уйнап уздырганлыгы хакында миңа әйткәне бар иде. Өстәлнең түр башына үтеп, егетләр куйган урындыкларга утырыштылар һәм, авызларына май капкандай, тынып калдылар.

Ул арада Васил кухняга чыгып керде дә шыпыртлап кына:

— Ботка пешеп җитте. Нишләргә? Әллә ниме, сыйлыйбызмы? — дип сорады.

— Шәп булыр. Китер тизрәк! Ә мин хәзер табак белән кашыкларны ялтыратып керәм,— дип пышылдадым мин аңа.

Мин олы калай табак белән кашыкларны ялтыратып керүемә Петр Дмитриевич бүлмәдәшләремнән кайбер нәрсәләрне сорашырга өлгергән икән инде, үпкә белдергәндәй иттереп миңа:

— Моңарчы әйтми дә йөрдегез, мсье... иптәш Кәримов: сезнең монда полный интернационал икән ләбаса! — диде.

— Әйе шул,— дидем мин.

Профессор имән бармагын чал мыегы өстеннән уздырды:

— Эх, яшь чагым түгел: рәхәтләнеп сезнең арага кысылыр идем. Сезнең интернациональ бригадагызда шәт миңа да урын табылыр иде бит, ә?

— Әлбәттә, профессор! Сез менә хәзер дә безнең арада ич! — дип баш калкытты чуваш Антон.

— Чынлап та, ә! Без сезне староста итеп сайлап куяр идек. Юкса ул почетлы дәрәҗәне менә Рифгать иптәшкәйнең бөтенләй күтәреп йөрисе дә килми... Ә үзегезгә кыл да кыймылдаттырмас идек,— дип күтәреп алды Васил һәм тузгыган чәче арасына биш бармагын да тыгып куйды.— Ант итәм, профессор: кыерсыттырмас идем!

Профессорыбыз рәхәтләнеп көлде. Күз төпләренә хәтта яшь бөртекләре бәреп чыкты һәм ул:

— Эх, яшьлек, мәңге кояшлы яшьлек! — дия-дия, бездән һич тартынмыйча, кулъяулыгын күзләренә тидергәләп алды.

Шахматны читкә куярга туры килде. Өстәлгә табын әзерләдек. Уртада калай табакта дөге боткасы хуш исле бу бөркеп утыра, ботка уртасында Антон салган зур гына атлан май кисәге эреп күл ясаган, ян-якларда алюмин кашыклар тезелгән...

Профессор болай әдәп өчен генә баш тартып кыланды булса кирәк, без төрле яклап кыстарга тотынгач:

— Ярый-ярый, кадерлеләрем, үземнең дә тамак төбем кытыкланып китте әле,— дигән булып табын янына килеп утырды.— Минем, кадерлеләрем, үз гомеремдә бик күп төрле ризыклар ашаганым булды, әмма ярлы студент чагында тамакка эләккәненнән дә тәмлесе булмагандыр... Ә сезнең боткагыз ай-яй ла икән!

Монысы инде безнең салпы якка салам кыстыру иде.

Кашыгыбызга аз-азлап кына эләктерәбез дә, май күленә чумдырып алгач, авызга китерәбез. Ашыкмыйча, өреп-өреп кенә кабабыз. Электр плиткасында чәй кайнарга тора. Ботка ашаганда — коммуна без, ә чәйне, билгеле, калай кружкаларга бүлеп салырбыз. Әлегә кашыклар бик салмак йөри. Кашыктагы майлы боткага кушып, шаян һәм күңелле сүзләрне йотып җибәргәлибез. Кай арада авызыбыздан пырхылдашып күгәрченнәр очып чыккандай була...

Ниһаять, профессор бармак аркасы белән мыек тирәсен сыпыргалап куйды.

— Тату да, дус та яшисез икән — куандырдыгыз... Рәхмәт! — диде ул һәм барыбызга да мөлаем күз йөртеп чыкты.— Димәк ки, үзара ачуланышулар, кыерсытышулар бөтенләй булмый да икән...

— Нишләп, булгалый,— диде Герман коры һәм житди рәвештә.

Профессорның кыяфәте үзгәреп китте:

— Ничек, мсье?

— Минә Антон миңа һаман да мат куя, ә мин булдыра алмыйм әле,— дип аңлатты Герман, чак кына да көлмичә, һәм кашыгы белән Василга төртеп күрсәтте.— Ә менә бу әфәнде әнә теге мескеннәрне доминода туктаусыз «кәҗә» калдыра...

— Ха-ха! Андый гына кыерсытулар! — дип көлеп куйды профессор. Ул Германның сүзләреннән чынлап та житдирәк бер нәрсә көткән иде, күрәсең.

Васил утырган җирендә түземсезләнеп кымшангалады да, чүмәлә башын янтайтып, профессорга төбәлде:

— Сезне, профессор, Парижддан килгән, диләр. Әйтегезче, зинһар, анда сез укыткан Сорбоннада студентлар домино сугып яталармы-юкмы? Менә болар ышанмый.

— Әлбәттә,— дип баш какты профессор.— Домино гынамы? Карта уйнауны да читкә какмыйлар. Тик шунсы гына бар, кадерлем: кайберәүләр уйный-уйный да, ахырдан диплом алуга ирешәме-юкмы, ләкин тәмам кәҗә булып чыгып китә...

Янә көлеш яңгырады. Мин Василга күз кыстым, ләкин ул, кем бакчасына таш ыргытылганын аңламаган кыяфәттә, авызын гына турсайтты.

Профессор белән Миша Черепановны без барыбыз бергә кубып, шаулашып озатып җибәрдек. Аннан соң, кире кердек тә, тәмле дөге боткасының төбенә кадәр төшү өчен, җылытырга плиткага куйдык. Менә шул чакны Васил, шыңшыгандай иттереп:

— Бүтәннәр, ичмаса, лекция-мазар укырга килә янсә акыллы киңәшләр биреп китә,— диде.— Ә бу нигә килгән? Морале тагы: күп уйнасаң, тәмам кәҗә тәкәсе буласың, имеш...

Кем бакчасына таш атканнарын аңламаган булып кыланган иде янәсе! Әмма бу җәһәттә бүлмәдәшләремнән нигәдер көлеп җибәрүче булмады.

Койкасына сузылып ятарга өлгергән Антон да:

— Чынлап та мондый шыксыз көнне ни йомыш белән килгән ул, син беләсеңдер бит, Рифгать? — дип миңа кадалды.

Боларны егып салырлык үткенрәк, тапкыррак җавап эзләп, мин колак артымны кашырга керештем. Әмма Герман өлгеррәк булып чыкты: ул даһиларча гап-гади иттереп:

— Просто безнең интернациональ ботканы тәмләп карарга килгән, шул гына! — дип куйды.

* * *

Өстәл уртасында сирень һәм шомырт чәчәкләре хуш исләр бөркеп утыра.

Нурлы, чәчәкле җәй башы килеп җитте.

Чокыр-чакырлардагы яшел чирәмлектә кояшта кызынабыз. Кай арада йөгереп кенә Казанкада су коенып кайткалыйбыз. Кичке якта тулай торак тирәсендәге бушлыкларда ау-һаулашып волейбол сугулар кыза. Әнгер-меңгер куеруга икенче, хәтта дүртенче катларның төбенә тикле ачып куелган тәрәзәләре аша бүлмәләргә су тутырылган кәгазь пакетлар ыргытып йөрибез. Таныш һәм таныш булмаган кызлар чыр-чу куптара...

Күңелдә кырыкмаса кырык төрле хисләр өермәсе котырынган, йөрәкне шатлык яшеннәре телгәләгән чак...

Алай да асыл шөгылебезне онытмыйбыз. Зачетлар тапшырырга да, имтиханнарга әзерләнергә дә иң күп вакыт табыла.

Зачет һәм имтиханнарны бүтән фәннәрдән ничек тапшыруыбыз хакында сөйләп тормыйм — алары болай ярыйсы гына шома үтте, әмма борынгы грек теле белән булган кызыклы хәл күңелгә мәңге сеңеп калды...

Баштарак без грек теленнән зачет кына булыр дип йөргән идек. Ләкин җәйге сессиягә бер-ике ай гына калып килгәндә, әллә программаны үзгәрттеләр, әллә электән үк шулай булган, профессорыбыз бер көнне:

— Мин сезгә ялгыш әйткәнмен икән. Шушы елны ук сездә имтихан икән лә, кадерлеләрем,— дип белдерде.

Ышанасыбыз килмәде. Ләкин кафедра мөдиребез доцент Шкляев та:

— Әйе, имтихан булачак,— дип раслагач, чәчләребез үрә торды.

Программа буенча без шактый артка калып, өстерәлеп кенә бара идек. Мондый хәл килеп чыккач, профессорыбыз көченнән килгәнчә дәресләрне тыгызлый, кыса төште. Укытучыны интектереп, чүп-чар турында сорашулар, ләчтит сатулар җилгә очты. Аңарчы алынкы-салынкы гына йөреп, кердeле-чыктылы белемне кара такта янында гына алырга тырышкан Леонид Хотин белән миңа да җиңне сызганырга туры килде. Бүтәннәр инде әллә кайчан зиһененә сеңдергәнне без әнә кайчан гына ныклап өйрәнергә ябыштык. Бөтенләй үк сәләтсез түгел икәнбез: тырыша торгач, шактый ук үзләштерә башладык.

Бервакыт стенага имтиханнар расписаниесен элеп куйдылар. Анда, ни күрик, грек теленнән имтиханны иң азакка, июньнең егерме бишләре тирәсенә билгеләгәннәр. Имтиханны ничек тапшыру турында әле уйлаган юк, «Ай-һай, сузганнар икән», диештек.

Шунда башка бер уй төште, дөресе, ул уйны иң әүвәл Леонид кузгатты:

— Әйдәгез, егетләр, тотабыз да грек телен иң башта, вакытыннан элек тапшырабыз,— диде.

Бу шәп фикерне мин шундук күтәреп алдым. Миша киреләнде. Әмма аңа:

— Соң үзең әти сырхаулап ята, дисең, өеңә дүрт-биш көн иртәрәк кайтып төшсәң, зыян итәрмени? — дигәч:

— Әйе шул... Иртәрәк кайтсам, үзебезнең тимер юл станциясендә әүвәлге эшемә кереп, бераз эшләп алырга да булыр иде,— дип килеште тагы.

Башта без кызларга әйтмәскә уйлаган идек. Ник дисәң, яз башларында гына безнең группада «Мәхәббәт һәм дуслык» дигән диспут

булып, анда бик кайнарланып чәнчешкән идек, һәм кызларның бер ишесе без-егетләргә, гөрбиян ахмаклар сез диебрәк, түбәнсетеп һәм борын чөеп йөрерләр иде. Шулай да, без капчыкта ятмас, беленер дип, планыбызны әйттек. Ләкин алар:

— Беренче имтихан партия тарихыннан. Грек телен бирәбез дип, аңардан тәгәрәп калыйкмы? Ярый ла сезнең партия тарихыннан хәлегез ал да гөл,— дип баш тарттылар.

Ансы хак: партия тарихы безне тамчы да өркетми. Семинар дәресләрендә без, өч егет, иң активлардан саналабыз, чыгып сөйләмәгән көнебез булмагандыр да. Шунлыктан безгә зачетны да бер сүз сорамыйнитми генә куеп чыгардылар.

Ярый, хәерлегә... Ләкин грек теленнән имтиханны алдан тапшырырга рөхсәт алу өчен нинди сылтау-хәйлә уйлап табарга? Бу яктан Леонид Хотинның зиһен казаны галәмәт шәп кайный, шундук пешереп чыгарды:

— Кавказга туристик походка барырга җыенабыз, дибез. Ә нигә? Минем анда барырга чынлап та исәп юк түгел,— диде ул, сүзне шактый коры тотып.

Очраттык профессорны. Ләкин ул ияген угалап икеләнеп калды.

— Мин каршы түгел түгелен... Тик югарыда ни диярләр икән? Имтиханнар режимын бозарга теләрләрме? Ярар, мин иртәгә сорауларны ничек тә язып бетерергә тырышырмын, танышырсыз,— диде ул, ниһаять, безгә хәл кертеп.

Өчебез исеменнән бер гариза язып, деканатка мендек. Леонид Хотин юмакай бер төс белән:

— Профессор риза. Без дә бик әйбәт әзерләндек инде,— дип ышандыргач, декан гариза читенә шытырдатып рөхсәт язып куйды. Тик чыгып киткәндә генә кырыс тавыш белән:

— Карагыз аны, кабат-кабат тапшырып йөрерлек булмасын! — дип ныклап кисәтте. Монысы шома үтте.

* * *

Аудиториядә өчәү профессорны көтеп утырабыз. Ул менә-менә килеп керергә тиеш.

Әзерләнүен шәп кенә әзерләндек. Миша безнең яшерен эшкә чынлап та катнашмады: ул егерме биш билетның барысына да бертигез дәрәҗәдә әзерләнде. Төн йокыларын качырып, күпме көч-җегәр сарыф иткәндер — үзе генә белә... Ә безнең, Леонид Хотин белән минем, эшләр көйлерәк: без нибары үзебез сайлап алган ун билетка гына җаваплар эзләп баш ваттык. Хәтергә дә ярыйсы гына сеңдердек шикелле. Инде алай-болай үзеңне йомшаграк сизеп, икеле-микеле хәлгә юлыксаң, рәхим ит: кесәләрдә шпаргалка...

Шулай да, нигәдер җан тыныч түгел. Күңелнең кайсыдыр почмагын тикмәгә генә тычкан кимермәгән икән...

Көтә торгач, бервакыт ишек ачылып китте һәм аннан... иң әүвәл доцент Фирстов күренде, аның артыннан, яны белән кереп, профессор Одинцов калыкты.

Тез аслары шундук йомшарып китте. Леонид Хотин да, муенын алга сузган килеш, күзләрен челт-мелт йомгалады... Бу ни хәл бу? Ни пычагыма безгә доцент Фирстов? Имтиханнар расписаниесендә грек теленнән дә, бүтәннәреннән дә бернинди дә ассистент күрсәтелмәгән ләбаса... Профессорның совет студентларыннан беренче тапкыр сынау алуы — әллә үзенә ышанмадылар микән? Бәлкем, профессор үзе үтенгәндер...

Доцент Фирстов урындыкка утырды да тураеп катты. Мәрмәр таштан ясалган борынгы грек статуясы шикелле...

Өстәлгә билетларын тараткан чагында профессорның бармаклары калтырады. Тавышы да коры һәм ят тоелды:

— Рәхим итегез... иптәшләр!

Безнең исә бармаклар түгел, җаннарыбыз калтырый иде.

Тик үзебез сайлаган, үзебез белгән билетлар кулга эләгеп, өстәл артында бер мәл утыргач кына хәл керде. Леонид Хотин миңа күз кысты: янәсе, әлегә майлагандай... Ә Миша Черепановның колак яфраклары уттай яна. «Намуслы, имеш. Безгә катышмыйча кыланган булды, ахмак» дип, мин аны күңелемнән кызганып та куйдым.

Түземе җитмәде, ахры, иң әүвәл Леонид Хотин чыкты. Белгәнлеге әллә каян күренеп тора: авызында яшен уйната. Грек телен түгел, рус телендәге кагыйдәне аңлата кебек. Бер сүзне тәрләндергәндә генә буталды, алай да тиз ермачлап чыга белде. Аннары бирелгән текстны тәрҗемә иткәндә тупас кына хата ясап куйды. Шул ашыгуы аркасында, билгеле...

Доцент Фирстов әллә абайламыйча да калды микән: өстәмә сорау бирү түгел, сынын да селкетмәде. Котылды егетебез, авызын колагына тикле ерып, чыгып китте.

Миша купты. Аның йөзе-кыяфәте агарынган кебек тоелды һәм мин: «Абынмагае бу», дип уйлап, аның өчен куркынып та алдым. Юк, кыш буе күз чекрәйтеп, өйрәнеп ятсын да абынсын, ди, кеше! Миша авызыннан очкыннар чәчрәтмәде, югалып та калмады: тыныч һәм үз-үзенә ышанган ныклы бер тавыш белән, кабаланмыйча, буталмыйча тезеп алып китте. Күңелдән белә, язган кәгазь битенә күз салмый да диярлек...

Доцент Фирстов, ниһаять, уянды булса кирәк: муенын чак кына бора төшеп, Мишага бер-ике өстәмә сорау бирде. Мин сулышымны кыстым: сораулар шактый ук авыр кебек тоелды миңа. Ләкин Миша, безнең уңган егетебез, җавапны чатнатты да куйды!

Инде миңа чират. Чыгып бастым. Шәп белгән кеше артыннан җавап бирүе ифрат читен. «Эх, Мишаны алга уздырып харап булдым», дип үкендем. Шулай да үземне кулга алырга тырыштым... Нигә куркырга, билетны беләм бит! Бәлкем, өстәмә сорау бирмәсләр дә әле.

Ярыйсы гына шома китте. Каушау югалды — иң әһәмиятлесе шул! Тавышның ныклыгыннан ук әйбәт белгәнлекне сизсеннәр!

Доцент Фирстовның кырыс иреннәре дә чак кына хәрәкәтләнеп, елмайгандай булды: канәгать сыман. Ә профессор Одинцовның нурлы елмаюын әйтәсе дә юк — үз кешебез...

Инде котылдым дигәндә генә...

Икенче сорауга тәрҗемә дә ялганып китә. Болай бик шәп ерып чыктым шикелле. Ләкин мин иркен сулап куярга өлгермәдем, доцент Фирстов:

— Гафу итегез... Сез менә бу сүзне дөрес тәрҗемә иттегезме? — дип, бармагын текстка төртте.— Сүзнең нинди төре бу?

— Фигыль.

— Дөрес... Фигыльнең нинди формасы? Кайсы заман?

Борынгы грек телендә фигыльнең заман формалары унҗиде төрле. Без шуларның яртысына гына җиттек бугай...

— Перфектум... Плюсквамперфектум... Аористус...— дип мин, ни әйткәнемне үзем дә аңлап бетермичә, бутала башладым. Доцент Фирстов, «түгел» дигән мәгънәдә, баш кына селкә.

Менә кайда икән ул кабу!.. Аяк табаннарыма тикле утта кыза. Ни күрим, хөрмәтле профессорыбызның да җыерчыклы, киң маңгае чал чәч төпләренә кадәр кып-кызыл ялкында яна сыман.

Кинәт зиһенемне яшен чаткысы ярып үткәндәй булды һәм мин тоттым да:

— Без фигыльнең бу формасын үтмәгән идек шул,— дип уфтанып куйдым.

Профессор каһәр суккан әлеге сүз кисәгенә текәлебрәк карады. Йөзе чытылып китте:

— Дөрестән дә үтмәгән идек аны... Өлгермәдек.

— Ничек инде? — Доцент Фирстов өстәлдәге программага үрелде һәм, аның кирәкле урынын табып, төртеп күрсәтте.— Менә ап-ачык әйтелгән: үтәргә тиешле идегез... Гаҗәп, гаҗәп...— Аннары ул, миңа карамыйча гына, һавада бармагын селкеп алды.— Сезгә бүтән соравым юк, Кәримов... Чыгып торыгыз!

Соры томан эченә атладым: «өчле» куярлар микәнни? Стипендиядән колак кактырырлар микәнни?..

Озак киңәшмәделәр, безне дәштеләр...

Профессор торып басты. Зәңгәр күзләрендә таныш нурлы елмаю балкыса да, тавышы ят һәм бөтенләй кипкән сыман: Мишага «бик яхшы», ә Леонид белән миңа «яхшы» билгесе куйганнар икән. Минем түбәм түшәмгә тия язды!

Доцент Фирстов аудиториядән чыгып китүгә, профессор Одинцов инде монысында гадәтенчә дустанә көлемсерәп карады:

— Ничек соң, кадерлеләрем, канәгатьме сез? Әллә...

— Бик тә канәгать, Петр Дмитриевич! Әйбәт булды, рәхмәт! — диештек без, зачет кенәгәләребезне чалбар кесәләренә яшерә-яшерә.

Кинәт ул миңа табан борылды. Тавышы тагын сынып китте, хәтта бөтен гәүдәсе калтыранып куйгандай булды:

— Сез инде, мсье Кәримов, мин картлачны кичерә күрегез. Мин ул сүзне... Ах, ничек абайламаганмын! Текстка кертмәскә тиеш идем. Кертсәм дә, үзем әйтергә тиеш идем... Сез бер үк, зинһар...

— Сез ни сөйлисез, профессор! Юкка хафаланмагыз: «дүртле» миңа муеннан ашкан! — дип мин аны тынычландырырга ашыктым һәм култыклап алдым.

Бездә, совет илендә, алган беренче имтиханыннан ул нерваларын безнең үзебездән дә болайрак какшатып чыкты шикелле...

* * *

Устьеда йөк бушатабыз.

Төпсез зәңгәр күктә каз мамыклары йөзә. Кояш рәхимсез кыздыра. Ара-тирә тәнне суытырга күлмәкчән килеш кенә мазутлы суда чумып чыккалыйбыз. Арабызда янып пешкән шәрә тәнлеләр дә бар. Болар Идел ярында озаграк, дәвамлырак эшләгән егетләр. Яндыргыч нурлардан инде курыкмыйлар.

Бит-муеннар үземнең дә ком гарәбенеке төсенә керде. Университетка менә берничә көн инде бөтенләй барган, күренгән юк. Кызлар, мөгаен, шаккатыр иде. Ә Вятка буена үземнең калама кайткач, өйдәгеләр аптырар!

Соңгы имтиханны, ягъни борынгы грек телен, вакытыннан элгәре тапшыру бик тә ярап куйды. Сессияне иртәрәк тәмамлап, бер атнага якын вакыт янга калды. Инде Идел ярында шәплэп җегәрне күрсәтергә җай чыкты. Үлеп акча кирәк. Пиджак-чалбарлар тәмам эштән чыгып тузды, брезент ботинкадан чәнти бармаклар төртелеп тора. Өс-башны рәтләмичә һич ярамый.

Башта шактый авырга килгән иде. Күнегелмәгәнгә күрә, әлбәттә. Өч көн рәттән баржалардан такта һәм утын бушатып азапландык. Монысы көйсез һәм мәшәкатьле, шунлыктан Устьеда гомерен акча төшереп уздыручылар аңа якын да килми, төшемлерәген эзли. Андые гадәттә безнең ише тәҗрибәсезрәк студентларга җим булып кала. Шулай да, тырыша торгач, такта белән утында да, акчаны ярыйсы гына сугып алдык.

Дуртенче көнебездә төшемлерәк һәм җиңелрәк эшкә юлыктык: оль гына баржадан он капчыклары бушаттык. Монысында безнең белән Вил Вахитов та эшләде. Донской аны үзе дәшеп алды: әүвәлге таныш-лар икән. Вилның аңарчы да, аннан соң да күренгәне булмады. Аның берме-икеме имтихан тапшырасы бар икән әле.

— Кышкы сессиядә зур тырышлык белән стипендия эләктереп кал-ган идек, бусында да колак кагарга ярамас, ныклап әзерләнәсем бар. Безнең бит карап торганыбыз шул стипендия,— диде ул миңа.

Үзе ябык кына, чандыр гына гәүдәле булса да, эшләгәндә җилләр уйната икән лә бу башкорт! Сөякләре корычтан, ахрысы... Җитмәсә, шаян сүзләр ычкындыргалап, бүтәннәрне дә камчылап кына тора:

— «Без сугышта арысланнан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез», дип кем әйткән әле? Давай, давай, туздырыйк әле бураннар-ны, Идел шаккатсын! — ди.

Бүген Вил юк. Эшебез ансатрак та, кулайрак та: иске агач баржа-дан Иж минераль суы тутырылган шешәле ящиклар бушатабыз. Күбе-безнең йөк ташый торган мендәре юк, болай, ящикларны иңбашка күтә-реп кенә, ярга чыгарып, өеп куябыз.

Җегәр-дәрман дигәнең сиздереп кими, сыеклана бара. Эчтәге буш-лык йөрәкнең урта бер төшен сызландырып суыра.

Донской каяндыр бер чиләк бәрәңге алып килде һәм аны юып ишел-гән яр буена утка куйды. Дүрт-биш бәйләм яшел суган да юнәткән. Шәп бүген!

Бригадир мине үзе янына дәшеп алды:

— Кибет ачылгандыр инде. Тиз генә дүрт-биш буханка ак ипи алып кил әле! Аннан соң, арзанлырак колбаса булмасмы? Һич югында, мар-гарин... Акчаң җитәме? Җитмәсә, мә! Соңыннан исәпләшербез.

Ян-якларында тәбәнәк тупыл һәм өрәңге агачлары утыртылган юл белән портка юнәлдем. Сирәк-мирәк кибетләр һәм лареклар шунда,— артка таба урам булып тезелеп киткән шыксыз йортлар тирәсендә ур-нашкан. Елга вокзалында һәм дебаркадерларда халык мәш килә: китә-ләр, кайталар. Сыра һәм мороженый сатучыларны бөтенләй сарып алганнар — борын төртәсең юк. Ярар, ник кадалып китмиләр шунда. Миңа бик тиз йөрергә кушылды. «Сыраның үчен Иж суыннан кайта-рырбыз»,— дип көлемсерәдем.

Икмәк һәм азык-төлек кибетләре әле ябык иде: сатучылары ашха-нәдә утыра, ди. Ишек төбендә каңгырап торасым килмәде, мороженый сатучыларга таба атладым. Шунда барганда, кинәт борын төбемнән генә, юлымны аркылы кисеп, соры «Победа» үтте. Тукта, безнең ректор машинасы ләбаса! Ни кылып йөрүе микән?

Адымымны тизләттем.

Машина елга вокзалына җитәр-җитмәс зәңгәр койма янында бors-лып тукталды. Ләкин аңардан ректор түгел, бәлки... үзенең хатыны мадам Элизабет белән безнең профессор Одинцов чыкты.

Менә хәйран-тамаша!

Профессорның өстендә саргылт костюм, башында салам эшләпә. Ха-тыны да шулай җәйгечә киенгән. Беләкләрендә плащлар. Менә шофер-лары аларның зур булмаган көрән чемоданнарын һәм кара букчаларын күтәреп алды да ашыкмыйча гына дебаркадерга таба атладылар. Берәр сәфәргә-мазарга китүләре микәнни?

Мин майкадан гына. Күлмәк кияргә дә оныткан мын, каһәр. Шәп кыяфәт түгел... Бер мизгел икеләнеп торгач, кызыксынуым ташып кит-кәнгә, җәһәт-җәһәт куа киттем. «Шаккатса соң... аңлый торган кеше лә!..»

Терсәгенә орынып исәнләшүемә, капылт кына тукталдылар. Про-фессор аптыраган кыяфәттә күз кысып торды да, кисәк балкып китеп, салам эшләпәсен кулына алды:

— Ә, мсье Кәримов?! Сезне танырлык та түгел. Ничек монда, ни кылып йөрисез? Туристик походка китмәдегезмени?

— Юк, китмәдем, китәргә тиеш тә түгел идем,— дидем мин, кояш-та артык янудан ала-кола булып калган иңбашымны сыпыргалап.— Туристик походка Леонид Хотин гына җыенган иде. Ул хәзер Кавказ тауларында йөри торгандыр, бәлкем... Ә мин менә монда.

Устьеда нишләп йөрүем турында бер-ике сүз белән генә аңлатып бирүемә, профессор:

— Алай икән әле...— дип, ни әйтергә белмәгәндәй, сузып җибәрде.

Шул арада мадам Элизабет, һаман көләч елмайган көенчә:

— Молодец егет икәнсез: үз көнегезне үзегез күрергә тырыша башлагансыз! — дип әйтергә ашыкты.

— Ә Черепанов кайда?

— Миша хәзер үзенең Казагыстанында Кандагач станциясендә авыру этисе янындадыр. Бәлкем, ул да җәйге ялын эш белән башлап җибәргәндер инде... Ә сез, Петр Дмитриевич, кая җыендыгыз болай? Берәр җиргә сәяхәтме әллә?

— Әйе... Әнә безнең аккоштай ак пароходыбыз гөлдер-гөлдер килеп тә җитә бугай инде.

Югарыдан, Горький ягыннан, чынлап та бер пароход һавага кара-кучкыл төтен бөрки-бөрки төшеп килә — инде килеп җитәргә әллә ни күп тә калмаган иде.

— Еракками соң, Петр Дмитриевич?

— Идел буйлап түбәнгә... Саратовка! Минем бит бала чагым, яшьлек елларым шунда үтте. Сагынылган! Картлык көнемдә төшкә керә башлады.

— Ульяновскида да тукталачакбыз,— дип сүзгә катышып китте мадам Элизабет.— Анда безнең бик күп җирләрдә буласыбыз, бик күп нәрсәләрне күрәсебез бар. Ул бит, беләсез, нинди кала...

Аңлашылды.

— Зур сәяхәткә чыккансыз икән, юлларыгыз уң булсын инде! — дидем мин, үзем дә дулкынланып.

Аста дебаркадер күперчегендә безне, көрән чемодан белән кара букчаны аягы янына куеп, шофер көтеп тора иде. Профессор күперчек култыксасына таянган килеш тукталып, бер мизгел яр буйларына күз йөрткәләп торганнан соң:

— Яшьлектә мин Казан пристане аша бер генә үтмәдем... Ничәмә еллар! Үзгәргән дә кебек,— диде.

— Тиз генә үзгәрмәстер әле,— дип кыстырдым мин. Сугыш арты еллары иде шул, һәм без, тагын берничә еллар үткәч, Идел ярларында гигант төзелешләр башланып, борынгы Устьеның мәңгегә зур диңгез астында калачагын һәм Казанда өр-яңа порт төзеләчәген башыбызга китерми дә идек әле...

Кинәт профессорым:

— Суы җылымы Идел-анакайның? — дип сорап куйды.

— Май кебек, профессор!

— Шулаймы?.. Туктале, үзем белим әле. Әнә анда көймә дә бар икән. Әйдәгез!

Түбәндә, күпер астындарак, олы гына көймә яртылаш ярга чыгарып куелган иде. Без, вак-вак атлап, күпер башына комлы ярга таба юнәлдек. Мадам Элизабет юлыбызга аркылы басты:

— Акылыңдамы син? Пәриләр, ди... Җүләрләнмә! — дип ике кулын берьюлы селтәде ул. Әмма, картын җинә алмаячагын шәйләп, шундук чигенде тагы.— Тик, зинһар, аягыңны чылата күрмә... Абайлап кына сез аны, мсье!

Ашыкмыйча, иплэп кенә комлы ярдан түбән төштек. Профессор минем ярдәм белән көймәгә кереп, арткы утыргычка утырды һәм уң ку-

лын суга тыкты. Бу минутта аның йөзе-кыяфәте яшь балаларныкы сыман самими куаныч белән нурланып балкый иде.

— Ә сез, иптәш Кәримов, беләсезме, сизгәнегез булдымы, Иделнең бит тик үзенә генә хас исе бар? Менә бу ярларның, менә бу күперчекнең, шушы көймәнең... Идел суының да үз исе! Дөньяда юк андый җанга татлы ис!

Кинәт профессор Одинцов, аз гына янтая төшеп, учына су ала-ала битен, башын чылатырга тотынды. Аннары башын турайтты да, янә чиксез шатлык нурларына күмелгән хәлдә, миңа төбәлде. Аның чал мыек очларыннан алтынсу тамчылар тама иде.

— Юк дөньяда безнең Иделдәй җанга мәңге кадерле, мәңге тансык су! Шулай бит, иптәш Кәримов?

— Әйе, профессор...

Тегеннән, дебаркадер артыннан, якынлашып килгән пароходның, ике сәяхәтчене олы һәм изге сәфәрләренә ашыгырга дәшеп, дәртле гудогы яңгырады...

* * *

Вятка буйларында көч-җегәр туплап, августның соңгы көнендә янә укырга дип килсәм — яңа хәбәр: безнең «классик»лар бүлегеннән факультетның үз курсындагы теләсә кайсы группага күчәргә мөмкинлек туган, ди!

Аны миңа Миша Черепанов сөйләде. Ул, тулай торакта үзенә урын алу нияте белән, бераз иртәрәк килгән һәм инде урнашып та өлгергән икән.

— Югары белем министрының приказы булган,— дип сөйләнде ул, үз бүлмәсендә тыгыз пружиналы койкасында рәхәт селкенгәләп утырган килеш.— Классик филология бүлекләре хәзер Мәскәү, Ленинград, тагы кайсыдыр университетларда гына калдырыла, ди. Безнең Казан университетында бу елдан башлап кабул итү дә бетерелгән.

— Шуннан?

— Шуннан шул: теләсәң, элекке группаңда каласың, теләмәсәң, җаның тарткан икенче группага күчәсең. Пожалуйста, ректор каршы түгел... Мин үзем әүвәлгечә «классик» булып калам.

Уку елы тәмамланып килгәндә үк әле мин Мишага чын-чынлап «классиклык» җене кагылганын һәм монда профессор Одинцовның да йогынтысы барлыгын аермачык сизгән идем. Шунлыктан дусымның карарына әллә ни исем китмәде.

— Ә бүтәннәр?

— Леонид үзе теләгән тарих бүлегендә инде, тагын бер-ике кыз логика бүлегенә күчәргә ниятли, ахры... Соң, син үзең нишләмәкче буласың? Былтыр бик җенләнгән идең түгелме? Әллә күңелең икеләнә башладымы?

— Икеләнде, ди... Күчәм! — дип кычкырып куйдым мин һәм Мишаны, җиңеннән эләктереп, җилтерәтеп торгыздым.— Әйдә, әйбәт хәбәрең өчен киногә алып барыйм әле үзеңне!

Мин аны шаяртмады микән дип шикләнгән идем. Юк, шаяртмаган. Икенче көнне университетка барып, деканатта белештем.

— Рәхим ит, теләгән группаңа күчәрсең. Тик иң башта кафедра мөдире белән сөйләш,— диделәр анда.

Гаризаны язуын ректор исеменә язсаң да, аның үзен мәшәкатьләп йөрисе юк, деканатка гына кертеп тапшырасы, ди.

Татар теле һәм әдәбияты бүлегенең җитәкчесе Рабига Афзаловна, минем гаризаны укып чыккач, уфтанып куйды:

— Былтыр ук синең белән эшне хәл итәсе калган икән. Безнең беренче курстагы группадан ел азагына ике кеше төшеп калды. Ничектер уйламаганмын, абайламаганмын...

Шуннан соң, сөякчел кулын минем беләккә салды да, кыйгач кара кашларын югары чөеп, саран гына елмайды:

— Ярар, хафаланмыйк, энем. «Классик»ларда укуың файдага гына булгандыр әле. Кешедә кругозор дигән нәрсә дә булырга тиеш ләбаса. Ә бездә син иптәшләреңне куып та житәрсең, узып та китәрсең, шулаймы?

Һәм менә инде мин гаять тә җилкенеп, бар булган тырышлыгымны салып йөрим. Бер генә ел укысак та, аерма шактый җыелган: миңа, татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчү өчен, дүрт-биш зачет һәм имтихан тапшырасы. Бу үзе өстәмә сессия кебек ләбаса! Леонид Хотинга ансатрак: аңа ни бары бер-ике зачет кына бирәсе.

Шулай итеп, «классик»лардан киттек без. Аерылышканда кызларыбыз күлмәде дә, еламады да, тик күзләрендә яман утлар яндырып карадылар гына...

Атна-ун көнләп укыгач, безнең курсны бөтенләе белән колхозга бәрәңге алырга озаттылар. Рабига Афзаловна, әлеге «өстәмә сессияне» хәтерендә тотып:

— Болай да эше муеннан аның... Укысын, әйбәтләп имтиханнарын тапшырсын! — дип, мине җибәртмәде.

Япа-ялгызым диярлек калдым. Муенымда бүтәннәргә тимәгән өстәмә камыт. Үзем теләдем. «Тарт, зарланма, дим, йөгеңне үргә менгерә алсаң, анда тагын да биегрәк, тагын да яктырак үрләр ачылыр әле», дим...

Җәйге ялдан соң җегәр шәп чакта әллә ни кыенга килми икән. Алдымда тезелешеп торган әлеге фән баганаларын берәм-берәм аудара барам, аудара барам. Күпертмичә әйтәм: шәп тәгәриләр!

Инде гарәп теле генә калды. Шул гарәп имласы белән җелек кыптергәндә, нигәдер бик еш борынгы грек теле дәресе, профессор Одинцов исемә төшә...

Миша Черепанов колхозга китәр алдыннан хәлләрен белешү нияте белән аларга сугылып чыккан икән. Ишекләре бикле, ди. Күршеләреннән сорашкан. Тегеләр моңа:

— Мадам Элизабет белән Кырымда ял итә бит ул. Сентябрь азакларында гына кайтырлар,— дигәннәр.

Инде күп калмады, бәлкем, юлдадыр инде алар. Кызык: безнең «классик»ларны ташлап китүебезне белгәч, ни дияр икән профессор? «Ах сезне, хыянәтчеләр!» — дип, күзләре елмайган килеш бармак янаган булырмы?

Җаным теләп, «классик»лыктан үзем киттем. Шулай да күңелнең кай төшедер кителеп калган сыман тоелды.

Бер көнне университет ишек алдындагы бакчада утырам. Аяк астында куе-кызыл карама һәм сыек сары өрәңге яфраклары. Аркамны көзнең саран кояшы җылыта. Күзләрем, гарәп хәрефләренә манчылган энҗе бөртекләрен җепкә тезеп, Тукай шигырен укый...

Якында гына яфрак кыштырдады. Сискәнеп, башымны күтәрдем. Ни күрим, көзге яфраклар түшәлгән сукмактан кыштыр-кыштыр профессор Одинцов якынлашып килә.

— О, Петр Дмитриевич, саумысез! — дип сикереп тордым.— Ничек болай, кайчан кайттыгыз!?

Туганнарча якынлык белән галәмәт җылы күрештек. Профессор бер мизгел минем кулларны ычкындырмыйча торды...

— Үтеп барганда, монда бакчага күз салсам — сез. Песи кебек искәрмәстән генә артыгызга чыгып, күзегезне кысмакчы идем, булмады! Карт аю кебек шул без... ха-ха.

— Юк, Петр Дмитриевич, сез бик тә свежий күренәсез, хәтта яшәреп тә киткән кебек!

Ул чынлап та кояшта шәп кенә каралган, битендә аз гына кызгылт төс тә бар кебек, хәрәкәте дә әүвәлгедән күп җинел шикелле... Аның зәңгәр күзләрендә көзге аяз күк чагылгандай булды:

— Һай, юморист кеше дә соң үзегез, иптәш Кәримов!

Эскәмиягә утырдык. Профессор көзге соры пальтосының изүендәге төймәне ычкындырды, эшләпәсен күтәрә төште. Мин, әлбәттә, үз хәлемне күләгәдә калдырырга тырышып, аның әхвәлен сораша башладым. Әле өченче көн генә кайтып төшкәннәр икән, мадам Элизабет та таза-сау, ди.

— Ничек соң анда, Кырымда? Шәпме?

— О иптәш Кәримов, искитмәле икән ул Кырым җирләре! Ышанып гыз мин картлачка: берәрсе, бу фани дөньяда да оҗмах бар, диләр, кайда икән ул, дип сораса, һич икеләнмичә «Кырымда!» дип җавап кайтарыгыз — ялгышмассыз... Севастопольда булдык, Бахчасарайда йөрдек, анда Чуфут-калага менгерделәр — хәйран! Ә сез, кадерлем, беләсезме — без кайда ял иттек?

— Кайда?

— Ялта янында Ливадиядә... әүвәлге патша дачасында! Анда хәйран бер сарай бар — патшаның җәйге резиденциясе. Әйе, шәплегенә исең китәр! Хәзер анда профсоюзларның менә дигән санаториесе — хәйран!.. Шулай, иптәш Кәримов, тарихчы булганыма күрә микән, тарих минем итәгемә тагыла да йөри... хе-хе!

Кырымда төрле кызыкларны күп күргән, күңеленә татлы балны мул җыйган, ахрысы, профессорым кайбер нәрсәләрне иркенләп, нечкәләп сөйләргә кереште. Тавышы йомшак, сулыш алулары да киңәйгән-җинеләйгән төсле... Әмма сөйләве әллә ни озакка сузылмады, кинәт айнып киткәндәй, тукталды һәм:

— Ярар, минеке бетмәс... Соң үзегездә ни хәлләр? — дип миңа төбәлде.

— Әйбәт...

Бер-ике сүз белән генә мин аңа «классик»лардан китүебез хакында яңа хәбәрне җиткердем. Юк, шаккатмады.

— Ә мин көткән идем сездән, иблисләрдән. «Алтын биреп тә боларны борынгы дөньяга карата алмассың, барыбер китәрләр», дип уйлаган идем,— диде ул, баш чайкап.— Ярый, юлларыгыз уң булсын! Ә татар бүлеген тәмамлагач, кем булырга ният инде? Галимме, әллә...

— Журналист булырга иде.

— Журналист? Сезне шигырь, хикәя язып маташа дигәннәр иде миңа. Әллә язучы яисә шагыйрь булырга җыенасызмы дигән идем.

— Коры теләк белән генә анысына ирешеп булмый бит, Петр Дмитриевич.

— Хак сүз...

Профессор таяк очы белән аяк астында яткан сары өрәнге яфрагын читкәрәк җибәрде дә әчке бер сыкрану белән уфылдап куйды.

— Безнең дә менә сезгә охшаганрак бер егетебез бар иде. Ул инде журналист булган да иде. Шома-шома мәкаләләре бер-бер артлы чыгып кына торыр иде. Әлбәттә, сул прессада... Без аңардан язучы чыгар дип тә өметләнгән идек.

— Аның турында мадам Элизабет безгә бер сөйләгән иде инде. Гестапода бик яман газаплагач, атканнар икән аны,— дидем мин.

— Сүз алалмагач, атканнар... Мин иреккә чыгарылгач кына белдем. Коммунист булган икән...

— Коммунист?

— Әйе, коммунист... Хәтеремдә, әле яшьрәк чагында, Парижны фашистлар басып алмас борын ук: «Этием, тарихка нихәтле чумсаң да, бер аягың бүгенге заманда булырга тиеш», дияр иде мәрхүмем. Картлык көнемдә генә төшендем: хак сүзләр булган икән...

Минем өчен яңалык иде бу. Теге чакны мадам Элизабет улының коммунист булуы хакында бер сүз дә ычкындырмаган иде бит. Мин, ни әйтергә белмәстән:

— Ә кабере кайда соң аның, Пер-Лашездамы? — дип сорадым.

— Түгел... Кабере билгесез... Франция җирендә...

Петр Дмитриевич башын түбән игән килеш, таягы белән җирдәге яфракларны янә кыштырдатты. Сүзне ничектер икенче юнәлешкә борып җибәрергә кирәк иде. Ләкин мин моның җаен таба алмый интегә идем. Кинәт профессор, башын калкытып, миңа карады. Карашында сагыш һәм моңсулык сизелми, киресенчә, көләч мөлаемлык сирпелә сыман иде.— Ә сез, иптәш Кәримов, белмисез дә әле: миндә дә яңалык бар бит. Мин дә, сезнең кебек үк, «классик»лардан китәм. Борынгы грек телен бөтенләе белән доцент Фирстовка тапшырдым.

— Бик әйбәт, профессор. Инде иркенләп, тынычлап ял итәрсез.

— Ял?! Юк, иптәш Кәримов, мин бу елны тарихчыларда борынгы Россия тарихы буенча семинар дәресләре алып барачакмын. Үзем сорадым. Мин шуның белгече ләбаса!.. Сезнең күргәнегез юктыр, мин язган китапларның бик күбесе монда гыйльми китапханәдә бар икән. Карыйлар, укыйлар икән... О, ничек куандырды бу мине! Ә сез ял дисез...

— Сезнең сәламәтлегегезне кайгыртып әйткән идем мин.

— Аңсы өчен рәхмәт. Врачлар да шулай ди, эшләргә кушмый. Ләкин мин туган илемә түшәмгә текереп ятар өчен кайттыммыни? Юк инде, башымда акылым, тәнемдә җегәрем барында, аз булса да файда итсен!

Бу сүзләрне ул басым белән ялкынланып әйтте, артык кызып киткәнгәме, буылып ютәлләп тә алды. Аннары тавышы тынычлана төште:

— Озакламый Мәскәүдә тарихчыларның зур киңәшмәсе булачак икән. Мине дә чакырдылар. Анда доклад ясаячакмын. Минем өчен бик тә әһәмиятле һәм җаваплы доклад. Бик тә җаваплы! Тезисларын Ялтадан ук язып җибәргән идем. Инде алганнардыр. Укыйлардыр. Тик кемнәр таныша икән? Шул хакта менә шалтыратып белим әле дип чыккан идем. Күңелне тынычландырасы килә бит... Әйе, керим әле ректор янына, шуннан гына шалтыратыйк әле...

Профессор утырган җиреннән авыр гына кубып күтәрелде һәм, гадәтенчә мөлаем көлемсерәп, кулын минем иңбашка салды:

— Ә сезгә мин уңыш телим! Иренмәгез, тырышыгыз... Сез бит латинны әйбәт беләсез: пэр аспэра ад астра!..[1]

— Рәхмәт, профессор!

Ул сукмакка төшәлгән сары һәм куе-кызыл яфраклар өстеннән кыштыр-кыштыр атлап китеп барды. Бакча капкасыннан чыккач, тукталды һәм, эшләпәсен күтәреп, янә елмайды.

Мин гарәп имласы белән басылып чыккан борынгы китапка иелдем: «Пэр аспэра ад астра!..»

1969.

---

[1] Кыенлыклар аша йолдызларга табан!..

## Рәдиф Гатауллин

# ЗУР ТЕМАГА ЭСКИЗЛАР

●

О, бу тема!..
Ул — океандай миңа, чиксез күктәй...
Бер тамчыны алсам,
салсам да,—
ни ул океанга?
Күк тә шулай иркен калыр мәңге
җаным белән аңа баксам да...
Океан — тирән, төбе — энҗе тулы,
ләкин анда төшү җиңелме?
Күзләрем соң галәм йолдызларының
санын беләм дияр идеме?
Шул океанга, шул илаһи күккә
тамчы итәм җырым! —
Өсти алырмынмы матурлык!
Ләкин
үз күңелем, чиксезлекне тоеп,
бер горурлык эстәр, батырлык...
Мин халыклар Даһиена киләм,
омтылышым, юлым иркле.
Моңа кадәр узганнарым белән
җанны сынап
тәвәккәллек алган кебекмен.
Мин Ленинга җылы хисләремнән
сурәт эзлим,— җанлы, табигый.
Аңа киләм, Кешегә — кеше булып,
ышанам, уртак сүзләр табылыр.

●

Илле яшьлек республикам минем,
Татарстан! —
Гүя егет син;
йөз яшьтә дә гайрәт белән бәйге-
мәйданнарга чыгар кебексең.
Бишегеңә Ленин кулын куйган:
баштан сыйпап гүя, үс! дигән.
Хөсәене, Муллануры аша
халкымны ул искә төшергән.
Искә алган Казанымны шунда,
университетны — һәммәсен...

Сораган:
Тукайларга лаек алмаш бармы,
эдиплэре ничек, янэсе.
Декретка кул куйган — үзе биргэн
теллэр, иллэр дөньясына — визасын.
Татарстан! Нэкъ илле ел инде —
ул күрсэткэн юлдан узасың.
...Сөен, халкым!
Йөрэгендэ мэңге
Аның кулы җылысын тоясың!

●

Рэсемен карыйм:
Күзлэрендэ күпме сөйкемлелек!
Ягымлы йөз —
якын, аталарча...
Эндэшэсе килэ,
үзебезчэ гади итеп аңа,
татарча.
Табигатьтэ — һэр бөеклек гади;
сүзлэр, сурэт, төслэр, буяулар.
Кешелэр лэкин тормыш катлаулылыгын
күбрэк
шул гадилек аша тоялар.
Э гадидэн — катлаулыга кадэр,
катлаулыдан — тагын гадине
табар өчен
Кешелек үзе күпме үсеш үткэн,
гасыр саен туктый-туктый көткэн
Җирне
үзгэртергэ тиеш Даһины...
Рэсеменэ йотылам.
Күзлэренэ,
сүзлэренэ, тэгълиматына.
Гүя
смирнога баскан гаскэридэй
торам
Акыл, Ихтыяр, Көч катында.
Уйларымның, килер эшлэремнең
чын вэкиле итеп күңелемне
баш идереп аңа,
тоям мин үземне —
мэңгелекнең сорауларына
җавап тапкан кеше шикелле.
Җаннарының диалектикасын,
Килэчэккэ юнэлешне анык белергэ,
кешелэр килэ аңа,
иллэр, континентлар:
сөйли һэркем аңа телендэ.
Э ул — каршылый, тыңлый... сөйли.
Карашлары — җылы, аталарча...
Бар дөньяның күңелен, телен аңлый.
Мин дэ рэхмэт эйтэм... татарча.

Рөстәм Мингалимов

# МИНЕМ ДӘҮЛӘТ

ПОЭМА

## Үзем дәүләт башында

Юк, бүген мин
Олы дәүләтем —
Советлар Союзы хакында
Сөйләмим.
Болай да һәр кеше
Яхшы белә аны...
...Аның өстендә,
Бөтен дөньяга күренеп,
Җилферди ал байрак —
Җилферди бабам җаны,
Җилферди әткәм җаны,
Җилферди...

Минем җаным —
Әлегә миндә.
Ап-ак бер сын тора өстәлемдә.

Киштәдә китаплар.
Әнә
Йокысызлыктан,
Тынгысызлыктан
Төрле-төрле дарулар...
Күңелемдә — уйларым болыты,
Яшенле яңгырлар,
Кояшлы тынлык,
Һәм —
            тагын башлана
Давыллар, давыллар...

Ап-ак бер сын тора өстәлемдә.
Шактый иркен генә минем бүлмә.
Киеренке тормыш монда,
Шуның хакында
Сөйләргә иде бүген дәртем.
Минем шәхси бүлмәм түгел бу,
Шәхси дәүләтем.

Монда минем гомер уза,
Мин бер генә түгел,
Күп мин монда —
Яшиләр барысы да...
Сөйләшәләр,
Көлә беләләр,
Елый беләләр...
Сөешәләр,
Кавышалар...
Аерылышалар...
Көрәшәләр...
Яраланалар...
Һәм язылган,
Һәм языласы,
Һәм язылмыйсы геройларым арасында
Бер мин генә түгел,
Күп мин монда:
Үзем дәүләт башында,
Үзем дәүләт читендә,
Үзем игенче,
Үзем терлекче,
Үзем төзүче...

Гаепле үзем,
Гаепсез үзем.

Үзем әзер торам
Шәхси дәүләтемдә
Гаепләне аклап чыгарга,
Гаебе акларлык түгелгә
Кыска, кискен карар
Үзем чыгарам.

## Карарларның юлы үргә була

Карарларның юлы үргә була,
Үрләр безгә таныш, әлбәттә...
Мине катылыкта гаепләргә
Теләүче бар минем дәүләттә.
Гаепләсен әйдә, бәхәсләшсен,
Күрсәтсен ул миңа хатамны.
Хатам зурлыгына инандырса,
Мин үземне тотып атармын.
Ә хәзергә мин яшәргә тиеш,
Хет сорама ник дип, хет сора.
Яхшы ниятемә дәлил булып
Дәүләтемдә ап-ак сын тора.
Шулай күптән тора, эндәшмичә,
Тормышыма текәп күзләрен.
Минем дәүләтемнең нигезе булып
Тора аның васыять сүзләре...
...Нигез чиста, дәүләт чиста булсын!
Чиста акыл булсын, чиста кул! —
Кылганнарым шулар, кануным шул,
Максатым шул минем, юлым шул.

## Аның исеме белән

Беләм,
Сез таныгансыздыр
Шәхси дәүләтемдәге
Ак сынны,
Ул —
Владимир Ильич Ленин сыны.
Бөтен дәүләтемдә берәү генә ул,
Берәү генә ул.
Һәм тагы
аның исемен йөртә:
Бер бакча,
Бер урам,
Бер шәһәр,
Бер авыл...
Менә шулай минем дәүләттә.
Сагыналар,
Ераклардан киләләр —
Күрәләр сынын;
Аның исемен йөртергә лаек Бакчаны,
Урамны,
Шәһәрне,
Авылны күрәләр... кәгъбә итеп.
Аннан
Тараталар эшкә, көрәшкә —
Җиңү вәгъдә итеп.
Таралалар,
Аның гадәти түгеллегенә,
Гади кеше түгеллегенә,
Башкалардан үзгәлегенә инанып.

Кем соң ул?
Ул — кешенең иманы.
Аның исемен
Шыпырт кына кабатлыйлар.

Аның исеме...
Аның исемен
Яңгыратып әйткәннәр бар.

Аның исеме...
Аның исеме белән,
Фикере белән уйнаучы даирәләр,
Хаиннар,
Ялагайлар —
Иң зур җинаятьче!
Менә шулай минем дәүләттә,
Шунда
Минем дәүләтнең
Сәяси ныклыгы,
Матди көче.
Минем ышану
Шушы тәртипкә буйсына.

Минем дәүләттә
Һәр йөрәк —
Мәйдан,
Анда
Владимир Ильич Ленин сыны.

## Уйла, иптәш

Шәхси дәүләт белән эш итүе
Җинел дию булса ниятең —
Уйла, иптәш, миндә бер өлеше
Күп милләтле олы дәүләтнең.
Тыңлап торам шуны, аңлап торам,
Качып калмас миннән берни дә.
Сүзләрен дә беләм, моңнарын да,
Бар да монда — минем телемдә.
Матур сүзме, дорфа тиргәшүме —
Тулы килеш бары, саф бары.
Тылмач аша түгел, туп-турыга
Йөрәгемә бәрә уйлары...
Болай кыен, ләкин болай яхшы
Сөйләшергә, чара күрергә,
Идеалыма илткән изге юлдан
Тайпылмыйча бара белергә...
Барам дию генә бару түгел —
Атлый торсаң гына барыла.
Арымыйм дип җырлау ансат нәрсә —
Ләкин юлда шактый арыла...
Шәхси дәүләт белән эш итүе,
Җинел дию булса ниятең —
Уйла, иптәш, миндә бер өлеше
Күп милләтле олы дәүләтнең.

## Тыңлагыз, карагыз

Шәхси дәүләтем торган урын
Кызыксындырса Сезне,
Тыңлагыз, карагыз
Олы дәүләтемне һәм жир йөзен!
Тыңлагыз, карагыз —
...Дошман форсат көтә.

Дошман форсат көтә
Олы дәүләтем башына кереп
Оярга — микроб кебек...
Әйе,
Дәүләтнең башы бар,
Йөзе бар, күзе бар —
Дошман форсат көтә
Олы дәүләтем күзенә кереп
Оярга — микроб кебек...
Әйе, әйе!

Халык бар,
Бар анын куәте, кәсебе,
Эшләгән эше, эшләргә вәгъдәсе,
Һәм ул —
Олы дәүләт гәүдәсе,
Дошман форсат көтә
Олы дәүләтем гәүдәсенә кереп
Ояларга — микроб кебек.

...Күкрәп-яшьнәп узган заманнар —
Үтереп, изеп, кыйнап өйрәтте
Дошманны хәйләкәрлеккә,
Дошман — усал, түзем,
Көтә:
Кеше кирәк дошманга,
Олы дәүләтемнән
Кечкенә кеше кирәк,
Ул кемнедер кимсетә алсын.
Кайда кимсетә, ничек кимсетә —
Мөһим түгел анысы,
Кимсетә алсын,
Бүгенгесен танымасын кемнеңдер —
Барыбер,
Узганын тапласын —
Барыбер,
Киләчәген күрмәсен —
Барыбер,
Теленнән, гадәтеннән көлсен —
Барыбер,
Дәлилле фәнни хезмәтләр белән
Төртелсен —
Барыбер,
Уйланмаган сүз белән бәрелсен —
Барыбер,
Мыскыллы елмаю белән карап торсын —
Барыбер —
Кыерсыта алсын!
Күңелләргә яра салсын...
Дошман форсат көтә
Яраларга кереп
Ояларга — микроб кебек.
...Әнә шундый
Дошманның бөтен хәйләсен
Күзәтергә мөмкин урында —
Минем шәхси дәүләтем.
Ап-ак бер сын тора уртасында,
Аның исеме...
Аның исеме белән башлана һәр эш,
Һәр җиңү дәүләтемдә
Аның исеме белән тәмамлана.
Алда, еракта —
Бабам җанын,
Әткәм җанын,
Минем җанымны җилфердәтеп
Ал байрак узасы юллар өстендә
Аның исеме яна, яна!

## Сәер хәл кичерәм

Кызу эш өсте,
Ыгы-зыгы әле шәхси дәүләтемдә:
Сизелмичә генә ялганалар көннәр төнгә,
Төннәр көнгә.
Җиннәрем сызганган...
...И шатландыра,
Канатландыра көнелемне
Амбарларымда бодай артуы;
Хезмәтем үрентеләре —
Яңа йортлар калкалар
Рәт-рәт булып,
Биеккә омтылып.
Юлбашчым исемендәге урамыма
Өстәп утырткан наратларым
Имәннәрем, каеннарым бар.
Алар корымыйлар.
Алар —
Башларын болытларга сузып
Чайкарлар әле.
Шуңадыр бүген
Сәер хәл кичерәм,
Кичерәм
Поэма тәмамлаган шагыйрь хәлен.
...Әнә шәхси дәүләтемнән
Рельслар үрелә ялтырап.
Мин салган рельслар, таныймын.
...Һәр сүзем — вагон,
Поэмам — төялгән эшелон,
Олы дәүләтләр,
Кешеләр,
Сезгә озатам аны мин!

1969

## Ибраһим Йосыпов.

Каракалпак шагыйре

# Тукайга

Язлар килде. Килде, димәк, шигърияткә дә чират.
Чык, и дустым, кабреңнән син, шигъри учагың көйрәт.

Соклансын кояш, сөенсен татарның Тукаена,
Китик без Казан арты я Кырлай тугаена.

Анда тумасам да беләм, ул җир һаман исемдә,
Йөдәтте шүрәлеләрең байтак кереп төшемә.

Анда әле, әкият сөйләп, каеннар гүләшәдер,
Яфраклар үзгә шаулашып, җилләр үзгә исәдер.

Анда әле көчле, аһәңле, хуш авазың бар синең,
Аз чиртелеп, иртә өзелгән моңлы сазың бар синең.

Гүзәл татар музасының туган җире — бу якка,
Сазың тавышын ишетеп, халыклар агылмакта.

Йөгерек каләм ияләре изге күреп җырыңны,
Күзенә сөрмә итәр баскан туфрак-җиреңне.

Янә дә анда кодрәтле лираңа гыйшкын түгеп,
«Чиртсен» дип тырмашып яткан тезмәчеләр аз түгел.

Ә сиңа мең-мең рәхмәтләр Тукай булганың өчен,
Кара нан ашап, шагыйрь исемен аклаганың өчен.

Туган ил, туган телеңнең аһ-зарларын җырладың,
Биш шигырь көйгә салып, күкрәгеңә ун ормадың.

Төрки дөнья шигъриятен яңартып алга әйдәдең,
Шигъри ике материкны тоташтырып бәйләдең.

Байрон, Лермонтов шәрыкка танылды синең аша,
Сәгъди, Хафизлар белән хәзрәте Пушкин сөйләшә.

Казан өстендә кояш нурлар чәчә, тор, бер күрен,
Мин алып килдем сиңа ерак даланың бер гөлен.

Яз яме — сандугачларның сайраган чакларында,
Йөрикче, сәфәр кылыйк шул Кырлай якларына.

Бал кортлары кәрәзләргә күбрәк бал китерсен,
Начар шагыйрьләрне шүрәле кытыклап үтерсен...

Нәләт әйтеп син яшәгән заманның җәберенә,
Әгәр син терелер булсаң, ятар идем кабереңә.

**Марс ШАБАЕВ** тәрҗемәсе

Ибраһим Нуруллин

# ХӘСРӘТ БАКЧАСЫ

хикәя



1908 елның август урталары иде.

Габдулла соң гына уянды. Үзен «Болгар»дагы кечкенә бүлмәсендә түгел, бәлки Мәкәрҗәнең «Двухсветный» дип атала торган кунак йортында күргәч, бөтен барлыгын ниндидер әч пошу, сагыш биләп алды. Һични уйламый бераз яткач, ул, одеялын өстеннән шудырмаска тырышып, тәрәзәгә таба сузылды да тирләгән пыяланы учы белән сөртеп алды. Көн сүрән, караңгы, көз фасылындагыча вак яңгыр сибәли.

Каршыдагы бакча буш диярлек. Зонтик тоткан дама яисә әфәнделәр һәм башлыклы кожан кигән агайлар гына үтеп киткәли. Мәһабәт топольләр арасындагы эскәмияләрнең берсендә генә кемдер бөкрәеп утырган.

«Хәсрәт бакчасы» дип атала икән бу бакча. Имеш, ярминкәгә өмет баглап килгән — шәкертме, хәлфәме — берәү кангырып йөргән-йөргән икән дә, карт топольгә пәке белән уеп, шундый бер җыр язган:

Әхмәт бай йорты каршында
Тора хәсрәт бакчасы,
Кадалып китсен Мәкәрҗәсе,
Кайтырга юк акчасы.

Шуннан киткән, имеш, ул исем.

Бу бакча үзенә күрә хезмәт биржасы вазифасын да үти икән. Әнә тегә карачкы, мөгаен, ялланырга көтеп утыра. Әше кырыйга килеп терелгән булса кирәк. Югыйсә, таңнан торып, яңгыр астында күшегеп утырмас иде.

Тәне чымырдап куйгач, Габдулла, одеалын башыннан бөркәнеп, яңадан ятты.

...Галиәсгар Камал Мәкәрҗәгә барырга тәкъдим иткәч, Тукай берсүзсез риза булган иде. Күп язалар, күп сөйлиләр шул ярминкә турында, бер күргәндә, әлбәттә, зарар итмәс. Тик шулай да, уены-чыны бергә, сорап куйды:

— Мин нишләрмен анда? Сатар малым юк, акча китерер һөнәрем юк.

— Карарсың, күрерсең, гыйбрәт алырсың. «Сәйяр» да җыена, аны-сын да онытма.

Чыгып киттеләр. Галиәсгар «Йолдыз» газетасының мөхбире[1] булып бара. Артистларда исә — ярминкәгә җыелган мөселман агай-энегә мәдәни хезмәт күрсәтү теләге һәм труппаның янчыгында «мыек майлап» яшәрлек кенә булса да тиеннәр чылтырамасмы дигән өмет.

Галиәсгар белән Тукайның урыннары икенче класста иде. Габдулла пароходның шау-гөр килеп тора торган аскы катын артыграк күрсә дә, бу юлы аңа түбәнгә төшәргә туры килмәде диярлек. Чөнки өченче класска билет алган «сәйярчеләр» Казан белән Нижний арасын өске палубада йөреп үткәрделәр. Билгеле, Тукай да алар белән булды. Үз кешеләр, күңелгә якыннар. Җитмәсә, Тукайның күптәнге әшнәсе, быел труппаның башлыгы булып алган Габдулла Кариев та шунда.

Килеп җиттеләр.

Әнә нинди икән ул Мәкәрҗә. Кала эчендә үзе бер кала! Кайчандыр кечкенә Габдуллага әкият дөньясы булып күренгән Ташаяк ярминкәсе дә хәзер фил янындагы таракан булды да калды. Җиккән ат белән керерлек тәрәзәле магазиннар, үз эченә бер бөтен авылны сыйдырыр-лык таш складлар, өч-дүрт катлы гостиницалар... «Главный дом» дигә-не тагы! Ярты чакрымга сузылган зиннәтле мәһабәт сарай. Анда тик кыйммәтле нәрсәләр генә сатыла: алтын да көмеш, бриллиант та якут. Бөтен дөньяның байлыгы шунда дип уйларсың. Кемдер әйткән иде: Петербург — Руссиянең мие, Мәскәү — йөрәге, ә Нижний — кесәсе. Дөрес икән.

Мәкәрҗәдә һәркайсының үз шөгыле, үз мәшәкате башланды. Гали-әсгарнең эше муеннан. Мөхбир кеше бит, кибетләр буйлап чаба, йон-ябага, сукно-ситсы, тире-яры бәяләрен белешә, халык җыела торган урыннарга барып чыга, тыңлап, күзәтеп йөри. Аннары яза, язганын поч-тага илтеп сала.

Артистларның эше алай ук тыгыз түгел. Көн дә репетиция ясыйлар, Фо-ли Берҗер бакчасындагы театр бинасы буш булганда, спектакль куела. Труппаның үз мөхәррире[2] сыйфатында, Галиәсгар да еш кына алар белән була.

Тукайның хәл-әхвәле дә баштарак зарланырлык түгел иде. Хәйранга калып, ярминкәне карап йөрде. Репетицияләрдә утыргалады. Спектакль-ләр карады. Әмма тора-бара Мәкәрҗәнең шау-шуы, ыгы-зыгысы аны туйдыра башлады. Галиәсгар да, Кари да үз эшләре белән чабарга мәҗбүрләр. Шагыйрь белән булырга бик үк вакыт булә алмыйлар. Җитмәсә, һавалар да бозылып китте. Менә шунда инде уйламый-нитми генә: «Мин нишләрмен анда?» дигән сүзләр урынлы әйтелгән кебек тоела башлады.

...Габдулла иренеп кенә урыныннан калыкты да, аннан-моннан кие-неп, тагын тәрәзәгә күз салды. Яңгыр һаман сибәли. Баягы адәм дә кымшанмый утыра бирә. Бүтән эскәмияләрдә дә шундый ук затлар — әшсезләр пәйда булган.

Габдулла бер көрсенеп куйды да, сабын-сөлгесен алып, юынырга чыгып китте. Ул әйләнеп кергәндә, бүлмәдә Галиәсгар утыра иде. Кожан сыман нәрсәсен салып ташлап, костюмыннан гына калган. Кие-реп куйган зонтигыннан идәнгә тып-тып тамчы тама.

— Хәерле иртәләр! Яңа гына торгансың, күрәм. Мин әллә ни чаклы эш кыйраттым инде.

---

[1] Мөхбир — хәбәрче, корреспондент.

[2] Мөхәррир — язучы, автор.

— Эт йоны бүген ничә тиен?
— Үпкәләгән Габдулла, үпкәләгән...
— Ник үпкәлим? Үзегез эшләп, мине кунак шәкерт итеп асрыйсыз ич!
— Бик яхшы, бераз ял итеп кал!
— Тотынма балтага, тотынма чалгыга дип тә өстәмисеңме?
— Алайса, тотын каләмгә. Яз!
— Эт йоны турындамы?
— Ташла, юкка кәефең кырылмасын. Чәй эчик тә репетициягә китәбез. Араблинский «Нәдершаһ»та уйнарга кыстый. Мөфти ролен бирә.
— Бармыйм!
Шул вакыт ишек шакыдылар.
— Рәхим итегез,— диде Галиәсгар, тиз генә борылып. Уртадан түбәнрәк буйлы, тар җилкәле, бераз гына бөкрерәк кеше керде. Өстендә, яңа дип әйтеп булмаса да, ярыйсы гына сакланган кара костюм. Озын ияге астыннан ак күлмәк һәм кара «күбәләк» күренеп тора.
— Әйдүк, Хәйбуш дус, түрдән уз! — диде Камал.
Бу кеше «Сәйяр» артистларыннан Хәйбушев иде. Ул урындыкның читенрәк кенә утырды да галстугын бәйләп азаплануы Тукайга текәлде. Галиәсгар мыек астыннан көлемсерәп:
— Я, Хәйбуш, сөйләп җибәр. Нинди яңалыклар бар? — диде.
Артист ашыкмый гына йөзен Камалга таба борды. Аннары акрын тавыш белән җавап бирде:
— Яңалыкны сез күбрәк беләсездер инде, Галиәсгар әфәнде. Костюм бер төшеннән китә башлаган менә. Энәсе юк микән дип, Габдулла әфәндегә кергән идем.
— Ай-һай, бармы икән. Булса да, теләндә генә. Үзем бирим, әйдә,— диде дә Галиәсгар, костюмының капламасын кайтарып, энәгә уралган җепне сүтә башлады.
— Бәла да соң бу, нәгъләт камыты! — диде Тукай, үртәлеп.— Мәле, Хәйбуш, бәйләп бир!
Хәйбушев, Тукайның галстугын рәтләп биргәч, Галиәсгар кулыннан энә алып, яңадан урындыгына килеп утырды да ашыкмый гына пиджагын сала башлады. Аннары, нидер исенә төшкәндәй, бер секундка туктапып торгач, аны тиз генә яңадан киеп куйды: костюмы астында иягеннән сузылып төшкән бер сөям иңлеге манишкадан бүтән нәрсәсе юк иде... Галиәсгар хәтта шаяртып та алды:
— Менә бу артист ичмасам! Типичный! Хәер, чалбар үзеңнеке бугай. Үзеңнекеме? Әйт дөресен, Хәйбуш.
Йөзенә алсу төс чыккан артист күзен мелт-мелт йомгалап алды.
— Бар бит минем... Юарга бирдем...
Бу вакыт Тукай, башын чак кына кыңгыр сала төшеп, гаять җитди кыяфәт белән Хәйбушка текәлгән иде. Аннары рәнҗүле дә, үчегүле дә тавыш белән:
— «Русия кесәсе» һәркем өчен түгел шул,— дип куйды һәм чемоданнан ап-ак әчке күлмәк чыгарып Хәйбушевка сузды.
— Сез нәрсә, Габдулла әфәнде!.. Юарга бирдем ич...
— Ки дим! Тәкәбберләнгән була,— диде Тукай, ачулана төшеп. Хәйбушев чарасыздан күлмәккә сузылды.

Камал белән Тукай килеп кергәндә, гостиницаның ресторан залы ярым буш иде. Анда-санда гына агай-эне, зур ак чәйнектән агызып, пәрәмәчләп чәй эчә. Бер почмакта «Сәйяр» артистлары күңелле генә шаулашып утыралар. Нечкәрәк тавышлы берсе нидер әйтә дә бүтәннәрне көлешеп алалар.
— Дәүли мәзәк сөйли,— дип куйды Галиәсгар.

Тимераякта шуып килгәндәй, каршыларына половой егет килеп басты.

— Рәхим итәсез, кунаклар, рәхим итәсез. Кайсы өстәлгә әзерлик?

Артистлар ягыннан әлеге нечкә тавыш ишетелде:

— Габдулла әфәнде! Галиәсгар әфәнде! Бирегә килегез.

Артистлар яңарак кына кергән булсалар кирәк, өстәлләрендә чәй дә, ашамлык та күренми иде әле. Сәлам алышып, половойга заказ биргәч, әлеге нечкә тавышлы Дәүли, Тукайга карап:

— Безнең бер бәхәсне хәл итә алмассызмы, Габдулла әфәнде? — диде.— Кари әйтә: «Мәкәрҗә» сүзе «Макарья»дан алынган, ди. Минемчә, бильгакес [1], «Макарья» — «Мәкәрҗә»дән.

— Я, я, дәлилең, Дәүли туган? — диде Галиәсгар, үтә кызыксынып,— «Мәкәрҗә» үзе нәрсәне аңлата соң?

— Белмисезмени? — дип, Дәүли иптәшләренә күз кысып алды.— «Мә калҗа»дан үзгәртелгән.

— Кемгә — калҗа, кемгә — өч бармактан оештырылган нәмәстә,— диде Тукай.— Менә син әйт, бил каешыңа яңа тишек тишмәдеңме?

Дәррәү көлеп җибәрделәр.

— Без булса, хәзер үк тишеп җибәрер идем,— диде Дәүли, көлү тавышлары басылгач.— Каридан ничә тапкыр сорадым. Үзенә кирәк булмагач, без йөртми. Антипример [2] кеше булгач, снабжать итәргә тиеш иде югыйсә.

Моңарчы көлемсерәп утырган Кариевның калын кашлары җыерылды.

— Ташла әле шул ахмак сүзеңне!

— Бетте, бетте. Әйттем исә кайттым. Бервакыт шулай Габдулла әфәнде Кариев Мәскәүдә чакта...

— Тукта инде, тел бистәсе,— диде артистлардан берәү,— әнә пәрәмәч килә.

— Самовар! Самовар бит, җәмәгать,— дип кычкырды Дәүли. Чынлап та, өстәлгә калай чәйнек урынына, ялтырап торган кечкенә самовар килеп утырды. Берничә тәлинкә өеп тутырылган пәрәмәчләр килде. Тынлык урнашып, куллар, авызлар шактый җитез хәрәкәтләнә башлады. Кариев кына бераздан тынлыкны бозып куйды:

— Дәүлинең дә тавышы тынды бит, җәмәгать!

Дәүли бу вакыт, ике битен дә кабарткан хәлдә, бик тырышып чәйни иде. Нидер әйтергә азапланып мыгырданды, ләкин сүзе аңлашылмады.

Тәлинкәләрнең төбе күренә башлаганда, өстәл янына тырпаеп тора торган саргылт мыеклы, кысыграк күзле бер кеше килде. Өстендә — тройка-костюм. Ак яка, кара галстук. Костюм җиңеннән ак манжетлары, ә күкрәк кесәсеннән кульъяулыгының почмагы күренеп тора.

— Исәнмесез, әфәнделәр. Аш тәмле булсын.

— Исәнмесез, Тимерхан әфәнде. Бергә-бергә булсын.

Көлке журналы чыгару өстенә, китап нәшриятында хуҗалык эшләрен башкаручы, Мәкәрҗә чорында шушы «Двухсветный»ны идарә итүче Тимерхан әфәнде Гандәлипов иде бу.

— Ничек соң, әфәнделәр? Әйбәт хезмәт күрсәтәләрме? Шикаятьләрегез юкмы? Булса, тартынмый әйтегез. Милли әдәбиятыбызны, милли театрыбызны тәрәккый иттерүчеләр, әйтик, безнең, әйтик, иң кадерле кунакларыбыз.

— Рәхмәт илтифатыгызга, Тимерхан әфәнде,— диде Дәүли.— Миндә бер шикаять... Хәер, шикаять тә түгел инде ул... Бер мәсьәлә димме?

«Нинди мөгез чыгармакчы икән бу?» — дип сагаеп калдылар.

— Әйтегез, Дәүли әфәнде, әйтегез.

---

[1] Бильгакес — киресенчә.

[2] «Антрепренер» сүзен юри бозып әйтә.

— Бер нәрсәгә акылым житми минем, Тимерхан әфәнде. Ник бу пәрәмәч бер женесле генә була икән?

Кайсыдыр пырхылдап куйса да, түзделәр, көлмәделәр. Тимерхан әфәнде, гадәтенчә, сөйләшкән кешесенә түгел, бәлки бүтән бер тыңлаучыга — бу очракта исә Кариевка карап:

— Төшенмим, Дәүли әфәнде,— диде.

— Соң бит ике женесле булса, үрчер иде.

Бу юлы инде тыелып кала алмадылар. Урынлы-урынсыз шаяруны яратып бетермәсә дә, Тимерхан әфәндегә дә бүтәннәргә кушылып көлүдән бүтән чара калмады.

— Ай-һай, бу Дәүлиегез! Авызына шайтан төкергәндер, мөгаен. Хәер, артистларның шул инде. Әйтик, кызлар кебек. Ярыктан да көләләр. Мөхәррирләр менә — икенчерәк халык.

Аннары, әле Галиәсгарга, әле Тукайга карый-карый, дәвам итте:

— Булмагездән канәгатьме, Габдулла әфәнде? Жайсызлык сизмисезме? Йомышыгызны үтиләрме?

Тукай жиңелчә генә әйтеп куйды:

— Безнең ише кара корсакка ярамаган тагы!

— Алай димәгез, Габдулла әфәнде. Милләт өчен сезнең кем икәнегезне, әйтик, беләбез.

— Зинһар, артык мактый күрмәгез, Тимерхан әфәнде. Юкса, журналыгызны тешли алмам.

— Булды инде, булды, Габдулла әфәнде. Безнең бәхетсез журналга Жаектан да күп ук аттыгыз, Казаннан да яшен жибәрә башладыгыз. Бусы, әйтик, хәттан ашып китмәгәндә, гаеп эш түгел. Мине, Габдулла әфәнде, икенче әйбер борчый. Соңгы елларда милләтне буржуйга һәм пролетарга бүлү бик модага кереп китте. Менә сез мине дә, әйтик, буржуй ясадыгыз.

Аннары ул, карашын Галиәсгардан Кариевка күчереп, дәвам итте:

— Милләткә төрлечә хезмәт итеп була, минемчә, Габдулла әфәнде. Сез буржуй иткән шушы фәкыйрегез иртә таңнан кара төнгә чаклы аяк өстендә. Һаман эш, һаман мәшгулият. Матбага, нәшрият, журнал, инде шушы мөсафирханә. «Двухсветный»ны, әйтик, табыш өчен идарә итә диярсез инде сез. Мәсьәләгә мин икенче төрлерәк карыйм. Шушы мөсафирханә Макарьяда татар мәдәнияте мәркәзенә әверелеп бара түгелме, Габдулла әфәнде?

— Шулай, Тимерхан әфәнде. Тик шуны әйтсәгез иде: сезне, әйтик, мадди як бер дә кызыксындырмыймыни?

— Кызыксындырмый дисәм, гөнаһлы булыр идем. Хезмәтеңә күрә килерең, Габдулла әфәнде.

Тукай артистларга таба кул изәде дә:

— Бу халыкны да эшләми дип булмый,— диде.— Ә берсе бүген костюмын салырга тартына. Манишка өстеннән генә кигән икән.

Мәҗлес халкының, артык житди, артык киеренке сөйләшүне туктатып, күңеллерәк темага күчәсе килә иде булса кирәк, Тукайның соңгы сүзләреннән соң, Хәйбушевка таба борылып көлә башладылар. Жайлы вакыт кына көтеп торгандай, Дәүли дә сүзгә кереште:

— Бервакыт шулай безнең Хәйбуш... Төртмә әле, Сәгыйть! Ярый әле хатыным түгелсең, көн күрсәтмәс идең.

Ләкин Тукай үзен борчыган мәсьәләдән арынып бетә алмый иде, күрәсең, үз-үзенә сөйләнгәндәй, әйтеп куйды:

— Кайчан гына әле «сайрап тора милләтнең былбыллары» дип, бик шәбәеп, шигырь яза идек. Баксаң, байлар сандугачы гына сайраган икән.

Уңайсыз тынлык урнашты. Чөнки уйламый-нитми әйтелгән бу сүз-

ләр Тимерхан әфәнде Гандәлипов[1] бакчасына таш булып төшкән иде. Әллә киная барып җитмәде, әллә хуҗа кешенең аны аңлап та аңламамышка салышырга акылы җитте, ул, берни булмагандай, болай диде:

— Сәясәткә бик тирән кердек. Мин бит сезгә, егетләр, бер мәслихәт белән килгән идем. Минем белүемчә, артист әфәнделәрнең эше артык тыгыз түгел. Әллә, мин әйтәм, буш вакытларыгызда концерт сыман нәрсә маташтырасызмы?

— Кайда? — дип сорады Сәгыйт.

Хуҗа, Габдулла Кариевка карап, җавап бирде:

— Шушында, «Двухсветный»да. Халыкка мәдәни азык булыр иде. Үзегез дә, әйтик, буш калмассыз... Я, ни дисез, Габдулла әфәнде?

Кариев, болай да пөхтә тора торган галстугына орынып алгач:

— Егетләр ни әйтер,— дип куйды. Дәүли җавап биреп өлгерде:

— Безгә нәрсә, син кая — без шунда. Син бит анти, анти... Тфү, кадалгыры, университетның баганаларын санау гына җитми икән шул каһәр сүзне әйтергә. Башлыгыбыз бит син. Сүзең закон.

Кариев, шаяртыбрак, Дәүлигә йодрык күрсәтте дә Тукайга эндәште:

— Яшьтәш, син ничек карыйсың?

Габдулла уйга калган иде. Тимерхан Гандәлиповның тәкъдиме аны ярыйсы гына кызыксындырды. Уральскида Габдулла Кариев белән бергә оештырган концертлары исенә төште. Күңелле дә булган иде соң, Тукай үзе бу кичәдә, хәерче булып киенгән иптәшенә карап, «Теләнче» шигырен укыган иде. Габдулланың уе аннары Казандагы концертларга күчте, хыялы кызурак эшли башлады. Күз алдыннан рояль, яисә оркестр моңнарына кушылып башкарыла торган хор, ялгыз җыр, бию номерлары үтеп китте. Үзенең дә сәхнәдән шигырь укуы күз алдына килде. Зал бирелеп тыңлый. «Зиләйлүк» яисә «Тәфтиләү» башкарылганда ханымнар батист кулъяулык белән күзләрен сөртәләр, артист җырны тәмамлап баш игәндә гөр килеп алкышлыйлар. Җырчының аяк астына чәчәк букеты килеп төшә.

— Тотынызгыз бу эшкә, ике Габдулла,— дип куйды Галиәсгар Камал.— Минә бит, Тукай, эш юк дип зарлана иден.

Габдулла, уянып киткәндәй, башын күтәрде. Әйе шул, бер шөгыль булыр...

— Мин риза.

— Ура! — дип кычкырды Дәүли.— Сездән пәрәмәч, Тимерхан әфәнде. Үрчи торганнары.

— Аннан эш калмас.

Тимерханның щетка-мыегы як-якка озынаеп китте.

— Бәлкем әле пәрәмәч алды да булыр?

— Аннан эш калмас.

— Фәрештәнең бисмилла әйткән чагына туры килсә, белмәссең...

...Габдулла, артистлар белән киңәшеп алгач, Кариев белән бергәләп, концертның программасын төзеде. Әлбәттә, бу программа артык бай була алмады. Күпчелек номерлары ирләр тавышыннан гына тора торган хорга йөкләнде. «Бәхилләшү» һәм шуңа охшаш җырларны беренче яисә икенче «сада» көенә җырларга булдылар. Арага «Ашказар», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» кебек көйләр кертелде. Габдулла үзе Уральскида элеккеге Миңлебай, ә хәзерге Кариев белән бергә үткәрелгән кичәдә зур уңыш казанган номер белән чыгарга ниятләде. Бер шәкертне хәерче итеп киендереп, анда ул үзенең «Теләнче» исемле шигырен шуңа карап сөйләгән иде. Татар биюе белән чыгачак Дәүлине конферансье итәргә булдылар.

— Арттырып җибәрмәскә ләкин,— дип кисәтте Кариев.

Аккомпанемент ягы исә шәптән түгел иде. Эстрадада рояль тора

[1] Гандәлип — фарсыча «сандугач» дигән сүз.

торуын, ләкин пианист ялларга кирәк. Тимерхан әфәндегә бу турыда әйткәннәр иде, тегенең мыегы гына тырпайды.
— Берегез дә маташтыра алмыймыни соң?
Аннары, чак кына уйланып торгач:
— Пианиносыз гына булмыймы? — дип куйды. Сүз озайтуның мәгънәсе юк иде, ике мандолина һәм бер гитарадан торган үз «оркестр»ларына егылырга булдылар.
Репетицияләр Тукай бүлмәсендә үткәрелде. Габдулла, үзе дә сизмәстән, яңа «труппа»ның житәкчесенә әверелеп китте. Халык көйләрен гаять нечкә сизә торган шагыйрьнең киңәшләре дөрес һәм файдалы була иде. Көй башкарылганда, гади колак тота алмый торган кимчелекләрне эләктереп алып, туктата, кат-кат кабатлата, «Садыйк! Бозау түгелсең, мөнгерәмә», янсә, «Ясин чыгасыңмы әллә, Сәгыйть?» кебек сүзләр дә ычкындыргалый иде. Көйнең борылышларына, түбән яки югарылыгына, тавышның куәтле яки зәгыйфь булуына ишарәләп, дирижерлык итүе дә табигый килеп чыкты, беркем дә елмаю уятмады.
Тукталып ял иткәндә, артистлардан берсе, шаяртып:
— Габдулла әфәнде, «Сәйяр»га дирижер гына булып киләсегез бар,— дип куйды.
— Авызыннан жил алсын! — дип эләктереп алды Дәүли.— Жан тирләренне чыгарыр бу... Анысы-анысы, егетләр, Тимерханнан бераз тамар микән?
— Пәрәмәчкә килештен ич инде.
— Анысы особый статья.
— Дәүли дус, чыкмас синнән артист,— диде Кариев.
— Нигә, Габдулла әфәнде?
— Искусство эшне мәгаштан башлаганны яратмый.
— Шулай да хаталанасың, Кари. Әллә кайчан коеп куйган артист инде мин. Өем күршенеке, чалбарым кешенеке. Корсак кына собственный. Әнә шул нәгъләт, ягъни мәсәләң, корсак шәрифе, эшне мәгаштан башлауны артыграк күрә. Бервакыт шулай Әстерханда...
— Башлыйбыз, егетләр,— диде Тукай. Дәүли сукранып алды:
— Режиссерың мондый була күрмәсен! Бер эч бушатырга да бирми.
— Бушның ниен бушатасың инде,— дип куйды Сәгыйт дигәне.
...Хор номерлары белән мавыгып китсә дә, Тукай үзенең «Теләнче»сен дә онытмады. Хәер, эш сәләмә кием табуда гына тора иде. Андый мал житәрлек анысы. Әнә мәчет янында эт талаган өс-башлы саилчеләр теләсәң ни чаклы. Яше дә, карты да. Әмма чишендереп кайтасыңмыни?
Хәер, мәсьәлә бик жиңел хәл ителде. Габдулланың сөйкемле сөяге бардырмы, малай-шалай аңа бик тиз ияләшеп ала. Күңелләрен ауларга тырышып төчеләнми дә югыйсә. Кырыйрак та торгалый, шелтәли дә, кушамат тагарга да оста. Тегеләр исә колакларына да элмичә, Габдулла абыйларының күзенә генә карап торалар, йомыш кушса, ут капкандай йөгерәләр.
«Двухсветный»да Рамазан исемле малай өйрәнчек булып хезмәт итә. Атасы Тимерхан әфәнденең танышларыннан булуга карамастан, ашау хакына таңнан төнгәчә чаба.
Габдулланың «Исемең ничек?» дип соравына каршы шушы малай «Ромео» димәсенме!
— Ничек, ничек?
— Ра-ми-у!
Тукайның һаман аптырап торуын күргәч, ике кулын күкрәгенә кушырып, күзен еракка төбәде дә:
— Бит или ни бит,— дип куйды. Габдулла, аңышып алып, көлеп жибәрде.
— Кем өйрәтте сине?

— Кари абый. Рамиунын атасы ни атлы икәнен дә әйткән ие дә, оныттым. Әллә Пешекчир, әллә Тишексыйрие.

Тукай ләззәтләнеп бик озак көлде.

— Син үзең тишек сыр,— диде аннары.— Шекспир.. Онытма, Шекспир!

— Онытмыйбыз инде хәзер: Шекспир.

— «Бит ли ни бит»не Ромеоның абыйсы[1] әйткән. Анысын да борынына сызып куй.

— Әй, абыйсыннан ишетеп, энесе дә әйткәндер әле, ярар.

Репетиция бетеп, Хәйбушев белән генә калгач (ул теләнче карт булып киенергә тиеш иде), әлеге Ромео, ягъни Рамазан, килеп керде.

— Ярыймы, Габдулла абый?

— Әйдүк, Шекспиров. Ничек соң, бүген бит или не бит?

— Бүген ни бит.

— Ә без кругом бит. Кара әле, Ромео, бәлки син берәр җаен табарсың, ә?

— Баш өсте, Габдулла абый. Нәрсә кирәк?

Тукай мәсьәләне аңлатып биргәч, Рамазан:

— Була ул,— диде дә ишеккә атылды.

Кичен халык алдына чыктылар. Буш өстәлләр булса да, кеше гадәттәгедән күбрәк иде. Тимерхан әфәнденең аршин ярымлык кәгазьгә игълан ябыштыруы, күрәсең, бушка китмәгән.

— Хөрмәтле әфәнделәр һәм ханымнар (соңгылары күренмәсә дә),— дип башлады Дәүли.— Безнең сезнең каршыгызда Русиянең барлык почмакларында шөһрәт казанган «Сәйяр» труппасы артистлары атаклы милли шагыйребез Габдулла әфәнде Тукаев тәхте капельмейстерлеге астында милли җыр, милли шигырь, милли бию башкарачаклар. Әгәр ошаса, бик каты итеп кул чабарсыз, ошамаса, тавыш-тынсыз гына чыгып китәрсез. Шулай да учларыгызны сакларга киңәш итәм: югыйсә аршин тота алмассыз.

— Җитәр инде, тозсыз,— дип пышылдады Кариев.

— Тозсыз дигәннән, әфәнделәр, бервакыт шулай ике кыз әлбә пешерергә уйлаганнар. Тоз салыргамы, юкмы — белмиләр икән. Шуннан берсе болдырга чыккан да үтеп баручы бер агайга кычкырган: «Әй, тозсыз әлбә, кая барасың?». «Һии, җүнсез, әлбә тозлы буламыни?» дигән теге кеше. Шуның шикелле, концертыбыз тозсыз чыкса, без дә «концерт тозлы буламыни?» дип кенә җавап бирербез.

Анда-санда көлгән тавышлар һәм «әтә белә бу» кебек сүзләр ишетелеп китте.

— Хәзер хор «Шәкертләр садасы»н башкара.

Артистлар сәхнәгә чыгып тезелделәр. Гитарачы белән мандолиначылар аларның алдына утырды. Тукай исә залга арты белән басты да кулларын күтәрде. Бер кулын изәгәч, «оркестр» көйнең ахыр өлешен уйнап чыкты, ике кулын да изәү белән хор күтәреп алды.

Җыр тәмам булгач, эстрададан бер читтәрәк басып торучы Тимерхан Гандәлипов бик тырышып кул чаба башлады. Аллан кисәтеп куелган булсалар кирәк, половой һәм бүтән хезмәтчеләр дә аңардан калышмадылар. Ашап-эчеп утыручылар да, болардан күрмәкче, кул чаба башлады. Тукай, залга таба борылып, җиңелчә генә баш иеп алды. Шул кыска вакыт эчендә дә аның үткен күзләре залны бер айкап чыгарга өлгерде. Кунакларның күбесе алкышласа да, «бу нинди тамаша» дигән кебек, каш астыннан карап утыручы картлар да байтак иде. Картлар картлар инде, алардан ни көтәсең? Эстрада кырыендагы өстәл янындагы егет ник кул чапмый? Болай да матур, чиста йөзен бизәп тора торган зур зәңгәр күзләрен Габдуллага төбәгән дә кымшанмый-нитми

[1] «Быть или не быть» дигән сүзләрнең Гамлетныкы икәнлеген искәртә.

тын гына утыра. Алдында бер чынаяк чәйдән бүтән нәрсә юк. Кем ул? Кайдан? Ник тамашага аның бер дә исе китми?

Тора-бара сәхнәгә игътибар кими төште. Кайнар су сорап, чәйнек шалтырату, «половой!» дип сөрән салу, кычкырып-кычкырып сөйләшү, туктаусыз череп-чыгып йөрүләр шуны күрсәтә иде. Кул чабулар да сыекланды. Дәүлинең шамакайланып биюе генә залга беркадәр җан кертсә дә, озакламый агайлар, голдыр-голдыр кикергәләп, чыга башладылар. «Теләнче»гә зур өмет баглап, Габдулла аны ахыргарак куйган иде. Әмма бу номерга чират җиткәндә зал бөтенләй диярлек бушап калды... Хәйбушевның, әлә-танагы калмаган бишмәт кигән хәлдә, тирләп-пешеп утыруы бушка гына булды.

Йөзе балкыган Тимерхан әфәнде килеп җитте.

— Афәрин, егетләр! Булдырдыгыз! Муафакыятегез белән тәбрик итәм, Габдулла әфәнде.

Башта Тукайның, аннары Кариевтан башлап, артистларның кулларын кысып чыккач:

— Әйдәгез, рәхим итегез,— диде,— карыныгыз ачкандыр.

Кеше күзеннән читтәрәк сыйланырга теләүче байлар өчен тотыла торган бүлмәгә килеп керделәр. Чиста, пөхтә. Савыт-саба, чәнечке-пычак — бар да ялт иткән.

— Тимерхан әфәнде,— диде Дәүли, теленә салынып,— алдан ук әйтеп куям: Габдулла әфәнде белән миңа — икешәр порция. Ник дисәң, без артыграк көч түктек. Габдулла әфәнде кул белән, мин аяк белән.

— Була ул, Дәүли әфәнде. Бүген — пәрәмәчнең сез теләгәне, ягъни үрчи торганы.

— Дәүлигә өч порция тиеш,— дип куйды Сәгыйт.

— Сәбәбен сорап тормыйм. Әмма дөрес сүз.

— Алайса сәбәбен мин әйтим,— диде Кариев.— Син тел белән дә эшлисең. Бирегез үзенә дүрт порция — бераз колагыбыз тынып тормасмы.

Булары чыгып торган пилмән килгәч, тынлык урнашты: мәҗлес халкы ашау белән мәшгуль иде. Тукай гына бу мәсьәләдә артистлар белән ярыша алмый иде. Шуңадырмы, Тимерхан аны кысташтыргалап куя иде:

— Начар ашыйсыз, Габдулла әфәнде. Бу ашау белән, әйтик, ничек җан асрап йөрмәк кирәк?

Аннары өем-өем пәрәмәч куелды, көмеш самовар килеп утырды.

— Ура! — дип кычкырды Дәүли.— Күк капусы ачылган көндер бүген. Әйдәгез, дуслар, сызганыйк җиңнәрне!..

Озаклап чәй дә эчкәч, артистлар канәгать булып таралдылар. Тукай аларны озата китте. Кариев белән арттарак калып, сүз катышмый гына атладылар. Икесенең дә күңелендә ниндидер төен утыра иде, күрәсең. Аерылышканда, Кариев:

— Җаек түгел инде бу,— дип куйды.

Тукай сүзнең ни турыда барганын бик яхшы аңлый иде.

Икенче көнне Тимерхан әфәнде Гандәлипов тагын бер әкәмәт уйлап чыгарды. Бер-берсенә кигезелгән фәсләр алып килде дә өстәлгә утыртып куйды. Артистлар берсе яшел, калган алтысы кызыл төстәге фәсләргә аптырабрак карап тордылар. Йөзенә хәйләле кыяфәт чыккан Тимерхан, бераз көттергәч:

— Фәс киеп җырларсыз дидем, егетләр. Агай-эненең күзе шар булсын әле,— диде.— Яшеле — Габдулла әфәндегә.

Дәүли бер фәсне киеп тә өлгерде. Юк мыегын бөтергәли-бөтергәли:

— Я, әйтегез, төрек пашасыннан кай төшем ким? — диде.

Тимерхан, Дәүлигә карап, Тукайга эндәште:

— Сез ни дисез, Габдулла әфәнде?

— Белмим, белмим, Тимерхан әфәнде. Безнең башлар инде зурая төште бугай. Төрек фәсенә сыяр микән?

Артистларга фәс киеп җырлау фикере ярыйсы гына ошады булса кирәк, алар Тукайга ялына башладылар.

— Я инде, Габдулла әфәнде. Аның ние бар соң?

— Оригинально булачак бит.

— Теләсәгез нишләгез, капельмейстер әфәнде, мин салмыйм,— диде Дәули,— киеп йоклыйм.

Тукай, әче елмаеп, болай диде:

— Малайлыктан чыгып килгән заманда, фәс киеп кеше көлдергәч, салып аткан идем. Тагын кияргә туры килер микәнни?

— Фәсне белмим, әмма картуз кигәнсез дип ишеткән идем, Габдулла әфәнде,— диде Тимерхан. Кариев аңлатма бирүне кирәк тапты:

— Төрекчәләтеп шигырь язуың әйтә, Габдулла.

Тукай багана булып утыра торган фәсләрне бармагы белән төртеп аударды да:

— Барысы да бер төстә булсын иде, ичмаса. Ник миңа гына аерылып торырга? — дип куйды.

— Ярамый, Габдулла әфәнде,— диде Сәгыйт.— Сәхнә шуны таләп итә.

...Тукай, залга килеп керү белән, халыкның кичәгедән күп артык булуын чамалады. Тамаша турындагы хәбәр агай-эне арасына бик тиз таралган, күрәсең. Зәңгәр күзле теге матур егет шул ук урында, шул ук рәвештә утыра иде.

Концерт башланып китеп, борып җибәргән машинадай, үз җае белән бара башлады. Артистлар вазифаларын тырышып башкардылар. Бүген яшьләр күбрәк килгәнгә, алкышлар да мулрак булды. Әмма Тукайда кичәге күтәренкелекнең әсәре дә юк иде. Ниндидер борчу, ярамас эш эшләү тойгысыннан ул бер минутка да арына алмады. Вакыт-вакыт каһәр төшкән фәсне салып таптап, залдан чыгып чабасы килә иде. «Теләнче» исә бүген дә башкарылмады. Дөрес, Габдулла аны алданрак үткәреп җибәрә ала иде. Шулай да элеккечә калдырды. Чират житсә — хуп, житмәсә — үпкә юк. Хәтта эченнән генә халыкның «Теләнче»гә кадәр үк таралуын тели иде. Шулай булды да. Ә Хәйбушев исә бүген остарак эшләде: сәхнәгә чыгарга әзер торса да, бу юлы сәләмә бишмәттән тирләп утырмады.

Концерт тәмам булгач, Тукай янына Рамазан килде. Аңа теге зәңгәр күзле егет ияргән иде.

— Габдулла абый, менә синең белән танышасы килә. Авылдаш бу минем.

— Харис,— диде егет, ләкин башлап кул сузмады. Тукай сузгач, бик теләп, шагыйрьнең кулын кысты.

— «Хәсрәт бакчасы»ннан таптым,— диде Рамазан, кәләпүшен арткарак шудырып.— Эш табалмый йөри, мескен. Берәр бай белән сөйләшми булмас.

— Шулай, мелла Рамазан, булдырсаң, син генә булдырасың аны.

Йөзе тулган айдай балкыган Тимерхан әфәнде килеп житте:

— Габдулла әфәнде, рәхим итегез, сезне көтәләр.

— Рәхмәт, мин соңрак керермен.

Бер-ике сорау белән генә чикләнсә дә, сәгать-сәгать ярым чамасы йөренгән арада Тукай Харисның егерме еллык гомер тарихын белеп алды. Егетнең, күрәсең, эч бушатасы килеп йөргән. Зарланудан бигрәк, уйлану, фикер йөртү иде бу, үзенә карата да, мөхиткә карата да ачы ирония белән сугарылган уйлану иде.

Харисның атасы Оренбург янындагы татар авылларының берсендә атаклы хәзрәт икән. Үз мәдрәсәсендә башлангыч белем биргәч, Харисны

ул Буби мәдрәсәсенә җибәргән. Сәләтле яшь егет, рус теле укыта торган учитель йогынтысында, университетка керү фикеренә килеп, өлгергәнлек аттестатына имтихан бирергә әзерләнә башлаган.

Карт хәзрәт исә улын һәр яклап варисы итеп күрәсе килә икән. Харисны авылның бер мәхәлләсенә мулла итү турында приговор җыелган, җиткән кызы булган бер бай белән сөйләшенгән. Кыскасы, йөз шәкерттән туксанының хыялында йөргән бәхет Харисны көтеп тора икән. Йомшак күңелле күндәм егеткә бу чаклы үзсүзлелек кайдан килгәндер, атасының яхшылап та, ачуланып та язган хатларына кырт кисеп җавап биргән: «Мулла булмыйм, укыйм!» Мондый хәлнең нәтиҗәсе билгеле инде. «Күзеңә кырып салырга бер тиен акча көтмә», дигән хәзрәт. Тамак дигән нәрсә дә бар бит, оят җирләрне дә каплыйсы бар. Аннан да битәр, аттестатка әзерләүче учительләргә түләргә кирәк. Ә кулда бертөрле дә һөнәр юк. Быел берәү киңәш биргән икән: бар Мәкәрҗәгә, фарт килсә, буш кайтмассың, дигән. Кая ул! «Хәсрәт бакчасы»нда арка бөкрәйтеп утырудан бүтән эш чыгара алганы юк әле.

— Көч бар, тазалык бар, рәхәтләнеп йөк ташыр идем, ялланыр өчен чәйнәшә алмыйм. Кемнеңдер авызыннан кисәкне тартып алу була төсле. Чистарак хезмәткә урнашыр өчен рекомендательный хатым юк. Булса да... Лакейлык хезмәтен булдыра алмыйм. Тәләмим түгел, булдыра алмыйм. Менә бит ул зыялы булуның хикмәтләре...

Аннары, иреннәрен кыйшайтып, елмайгандай итте дә өстәп куйды:

— Үзе кеше типкесендә яши торган малай протекциясенә калгач, күзе ачылган татар шәкертенең хәле турында сөйләп торасы да юк.

Тукай, бераз уйланып торгач, кинәт сорап куйды:

— Безнең шамакайлану сезгә ошамады бугай, Харис әфәнде?

— Ник алай дисез, Габдулла әфәнде? Концерт начар түгел...

— Бармакка бармак та тидермәдегез ич.

— Торгашларга кушыласым килмәде.

— Әйтеп бетермисең, туган. Ярып сал: тук мәчеләрнең күңелен ачу татар шагыйре Габдулла Тукаев эше түгел, диген.

— Анысы шулай инде...

— Шул шул! Ә мин, җүләр балык, фәс киеп, кул болгап торам. Кеше сүзе белән йөргәч, шулай була ул. Ни дип килешкәндер бу Кари! Хәер, аны да гаепләп булмыйдыр бәлки. Артистларының хәле тәкәбберлек күрсәтергә бик үк ирек бирми шул. Әйтәсең бит әле, теләсә нинди кара эштән дә баш тартмас идем дип. Ичмаса Галиәсгар да чабудан тартмады. Бүген килмәгән дә...

Бу вакыт алар «Двухсветный»га якынлашып киләләр иде. Каршыга Дәүли килеп чыкты.

— Кая югалдыгыз, Габдулла әфәнде? Көттек, көттек тә, корсак шәрифләренең золымына түзә алмыйча, пилмән белән пәрәмәчне дөньяга килмәгәндәй иттек.

Аннары Дәүли корсагына шапылдатып сукты да:

— Мәкәрҗә баеныкымыни! — дип куйды.

Тукай, «әнә бит ул ничек» дигән шикелле, Харискa бер күз төшереп алды.

Егет белән саубуллашып, номерына килеп кергәндә, Габдулланың өстәлендә суынмасын дип яхшылап томаланган пилмән һәм пәрәмәчләр тора иде.

Иртәгесен Тукай, суярга илтә торган мал кебек үзен көчләп, тагын ресторанга төште. Тимерхан аны гына көтеп торган булса кирәк.

— Габдулла әфәнде,— диде,— гармунчы мишәр килеп чыккан. Арага кыстырып җибәрерсез, шаять.

Габдуллага барыбер иде.

Халык шактый җыелган. Харис — үз урынында. Ерак та түгел Галиәсгар да күренә.

Концерт дигәнебез көндәгечә башланды. Алкышлар белән чиратлаша торган шул чәйнек шалтырату, официант чакыру, кычкырып сөйләшү, тыз-быз йөрүләр.

Бервакыт эстрадага гармунчы мишәр килеп чыкты. Буйга уртача. Кыек якалы кызыл күлмәк өстеннән гадәти генә пиджак кигән. Башында — чиккән көрән кәләпүш. Кулында — кыңгыраулы кечерәк гармун. Урындык китереп куйдылар, утырмады, менә башлый, менә башлый дип көттеләр — тамагын кыргалап, һаман басып тора бирде. Шактый көттергәч, гармунчы тагын бер кат тамагын кырды да нечкә тавыш белән:

— Гурланы мали торган канатны мачы ашаган, мур кыргыры. Майтап апагыз күрми калган,— дип куйды. Аннары, көлү басылгач, гармунына иелә төшеп:

— Я, саратский дус, синдә бар өмет,— диде.— Дәдәләреңнең берсәк күңелен табыйк.

Халык сагаеп көтә иде. Менә мишәр, кыңгыравын чылтыратып, гармунын бер кычкыртты да хатын-кызларныкы кебек нечкә тавыш белән «Баламишкин» көенә җырлап җибәрде. Җыр тәмам булуга, ду иттереп кул чаптылар. Һич тик тормый, төрле-төрле кыяфәтләргә кереп бетүеме, тавышының моңарчы ишетелмәгәнчә нечкә булуымы,— ни булса да бар, мишәрнең җырлавы агай-эненең күңеленә хуш килде.

Бер-ике көй башкарырга дип чыккан гармунчыны кат-кат җырлаттылар. Моңа аның «репертуары» да сәбәп булды бугай. Җыен кабак көйләре һәм шул көйләргә туры китереп сайланган шактый әдәпсез җырлар.

Моңарчы каккан казык кебек, туры гына, тын гына утырган Харис, залның бер ара тын калуыннан файдаланып:

— Җитәр! Артистлар җырласын! — дип кычкырды. Кемдер ачы итеп сызгырды, аяк белән идәнне дөбердәтә башладылар. Гармунчы мишәр, үпкәләгән булып:

— Әдә, саратский, сүмәделәр безне,— диде дә, гармунын култык астына кыстырып, эстрададан төшә башлады. Зал ду купты:

— Җырла, җырла!

— Карама кызыл авызлар сүзенә.

— Сиптер әйдә!

— Курыкма. Авызларын кан белән юарбыз.

Тукайның «концертмейстерлыгы гәхетендә» оешкан концертларның тарихы әнә шулай очланды...

Габдулла «Двухгазетный»дан чыкканда, кояш офыкка якынлашып килә иде. Шагыйрьнең күңелендә — каршылыклы тойгылар. Бер яктан, ул Тимер Гандәлиповның кесә исәп-хисабыннан чыгып оештырылган әкәмәтеннән котылуына канәгать булса, икенче яктан, үзе оештырган «труппа»ның бер кабак җырчысы тарафыннан җинелеп хур булуы аны гарьләндерә иде.

Максатсыз-нисез «Главный дом»га таба атлаганда, аны Галиәсгар Камал белән Габдулла Кариев куып життеләр.

— Кая бу кадәр чабасың? — диде Галиәсгар.

Тукай хәтере калган кыяфәт белән аңа бер карап алды да:

— Ясин чыгарга килдегезме бүген, Галиәсгар әфәнде? — диде.

— Нинди ясин? Нигә мондый рәсми тон?

— Безнең шәһрәт бүген җан тәслим кылды ич. Кеше сүзе белән йөргәч, шулай була ул.

— Кем сүзе белән?

— Син, мин, Мөхәммәтәмин.

— Әзерлән, Кари, хәзер сиңа ташлана.

— Ник ташланыйм,— диде Тукай.— Без бит аның белән милләткә бик зур хезмәт күрсәттек. Тимерхан әфәнде белән Әхмәт бай кесәсенә ничә тәңкәне салганынны беләсеңме син, Кари? Белмисең? Аның каравы, артистларына ничә тарелка пилмән, ничә пәрәмәч ашатканынны беләсең. Беләсең бит?

— Төшереп алмагансың бит, Габдулла? — диде Кариев.

— Ха-ха-ха. Киресенчә, яшьтәш, киресенчә. Исергән идем — айныдым. Ә синең Хәйбушың барыбер көлмәксез кайтып китәчәк. Үзеңә чалбарсыз калырга туры килмәгәе.

— Куй әле, Габдулла.

«Главный дом»ның аргы башына җитеп килгәндә, аларның игътибарын көлешә-көлешә нидер карап торучы бер төркем халык җәлеп итте. Кысыла-кысыла эчкә уздылар. Түгәрәк уртасында аю биетүче үзенең һөнәрен күрсәтә иде.

— Яле, Миша, күрсәт, хатыннар ничек судан кайта?

Көрән аю алгы аякларын көянтә тоткандагыча як-якка җәйде дә, чылбырын чылтырата-чылтырата, алпан-тилпән атлап китте.

— Килештерә, шельма!

— Мастеровой получка көнне ничек өенә кайта?

Аю, алгы аякларын бутый-бутый, ава-түнә түгәрәк тирәли йөри башлады.

— Чистый үзе!

— Ха-ха-ха.

— Городовой аны нишләтә?

Мишка, дүртаякланып, хуҗасы янына килде дә, яңадан калкып, тегенең якасыннан эләктерде һәм, артына типкәли-типкәли, түгәрәк буйлап алып китте. Халык бөгелә-сыгыла көлә башлады.

Шул вакыт карлыккан калын тавыш ишетелде.

— Разойдись!

Юан околодочный тыкшынып эчкә керде дә, аюга якынаерга базмыйча, читтәнрәк җикерде:

— Ты, морда! Белмисеңмени — монда ярамый. А ну, марш!

— Господин унтер, уйнатсын инде,— диештеләр.

— Разговоры. Разойдись!

Аю биетүче, Мишканың чылбырыннан тотып, түгәрәк эченнән күндәм генә чыгып китте. Халык тарала башлады. Габдулла аюны күзләре белән озатып калды да, Кариевка таба борылып:

— Менә бу да артист,— диде.— Синең кебек үк, яшьтәш. Хәер, кая инде безгә шундый аю булырга! Маймыл уйнатучыны күргәнең бармы?

Габдулла Кариевның кашлары җыерылды.

— Ачуланышабыз, Тукай!

— Турсайма, яшьтәш. Барыбыз да шул. Ничә көн рәттән кеше көлдердек!

Аннары үкенечле дә, әрнүле дә тавыш белән өстәп куйды:

— Их, юк бит ул Тимерханнарга да бер җантимер![1]

Кариев белән Камал ары киттеләр, Тукай кайту ягына борылды. «Двухсветный» парадные янында ул Рамазанны очратты. Тегенең нечектер сөмсере коелган иде.

— Син нәрсә, Шекспир малае? Әллә бүген «бит»?

— Аңа түгел, Габдулла абый. Китәм мин бу Тимерханнан.

— Кая?

— Теләсә кая!

— Әйдә әле, керик, әйбәтләп сөйләшербез.

---

[1] Тукай полицейскийны шулай атый.

Өстәлдәге томалаулы ашамлыкны күргәч, Тукайның иреннәре кыйшаеп куйды.

— Мөкафәт...[1]

— Нәрсә дисең, Габдулла абый?

— Берни түгел. Әйдә әүвәл ашап алыйк.

Рамазан, башта карышып маташса да, аннары, үзе дә сизмәстән, пилмән белән пәрәмәчкә ялт иттерде. Тукай исә чемченеп кенә утырды.

Сүз уңаенда малайның турсаю сәбәбе аңлашылды. Концертның шулай бетүе аның хәтерен калдырган икән. Гармунчы мишәргә һәм аны, артистка санап, җырлаткан Тимерхан әфәндегә җен ачулары чыккан. Тагын шунысы да мәгълүм булды: кичке ашка артистларның кергәне кергән, кермәгәне юк. Махсус чакыручы булмаган. Мишәрне исә шартлаганчы сыйлаганнар.

— Син, мелла Рамазан, буының катканчы түз инде,— диде Тукай.— Бер Тимерханнан икенчесенә күчүдән мәгънә юк.

Иртәгесен, чәй эчеп тамак ялгагач, Габдулла, «Двухсветный»дан чыгып, «Хәсрәт бакчасы»на таба юнәлде. Эшкә яллаучы килгән булса кирәк, гаять чуар өс-башлы халык бер урынга өелешкән иде. Шуннан ерак та түгел эскәмиядә Харис моңаеп утыра иде. Тукайны күргәч, ул аяк өскә калыкты. Күзләр белән генә сәламләшеп, эскәмиягә утырдылар да әлеге тамашаны күзәтә башладылар.

Эшсезләр колакны тондырырлык итеп кычкырышалар, һәркайсы этәтөртә эчкә кермәкче була. Тик сугышмыйлар гына.

Шактый вакыт үткәч, өстенә чесуча костюм, башына салам эшләпә кигән кеше төркем эченнән килеп чыкты да, гәүдәсен төз тотып, китеп барды. Аңа биш-алты кеше ияргән иде. Яллану бәхетенә ирешә алмаган дистәләгән кеше исә, шундук тынычланып, хәтта ара-тирә көлешкәләп, урыннарына таралдылар.

— Аю хезмәтеннән котылдым бит мин,— дип куйды Тукай. Харис, сүзнең дәвамын көтеп, шагыйрьгә карады. Әмма Габдулла бу турыда сүз озайтып маташмады.

— Әйдә, киттек бу «Хәсрәт бакчасы»ннан.

— Кая, Габдулла әфәнде?

— Казанга! Минем анда таныш учительләр бар. Җае табылыр.

Тукай торып ук басты.

— Бүген үкмени?

— Хәзер үк!

«Русия кесәсе»ндәге тиеннәргә өмет баглап килгән бик күп өлешсез кешеләрне күләгәләре астына алган мәһабәт топольләр, талгын җилдә яфракларын лепердәтеп, ике егетне билгесез киләчәккә озатып калдылар.

---

[1] Мөкафәт — эш хакы.

Газиз Мөхәммәтшин

# ЙӨРӘКТӘГЕ ЭЗЛӘР

ПОВЕСТЬ[1]

## 9

Шул чак борылмадан машиналар колоннасы килеп чыкты. Аның артыннан, каты юлга әләгүенә шатлангандай, сыек зәңгәр төтенен бөркеп бәләкәй автобус — кинопередвижка, ә иң арттан, янадан батса килгән шәпкә этеп чыгарырга җыенып, бая аның белән батып яткан зур машина килә иде.

Кайсы кая таралышкан халык бергә җыелып, колонна каршына чыга башлады.

Һәркем кабат үз урынына утырды. Айзат Нурбакның Тамарага тутырып-тутырып каравын, Тамараның да аңа ничектер уңайсызланган, бераз оялган шикелле елмаебрак күз салуын күреп, ну тиз дә дуслаша соң кешеләр, дип көнләшеп куйды. Ул үзен беренче күргән кешеләр белән, бигрәк тә кыз-кыркын халкы белән тиз генә уртак тел табып сөйләшеп китә алмаучы җебегән баш дип йөри иде. Моңа эче поша һәм, нәселең шулай авыр нәсел булгач, очкын шикелле чәчрәп тормагач, ни хәл итәсең, дип күңелен юатырга тырыша иде.

Аучы, иягенә таянып, күршеләренең әле берсенә, әле икенчесенә ялт та йолт каранып, нидер әйтергә теләгән шикелле утыра иде. Журналистның күзе үткер, күңеле сизгер була диләр, дөрес икән. Нурбак аның сүз башларга теле кычытып, ымсынып утыруын сизеп алды да:

— Карагыз әле, сез кышкы тайганы бик матур тасвирлый идегез. Ник сөйләп бетермәдегез? — диде.

Бүтәннәр дә елмаешып:

— Әйе, сез бит сөйләп бетермәдегез. Ярты юлда калдырмагыз инде,— диештеләр.

[1] Дәвамы. Башы 3 нче санда.

Аучының шаян соры күзләреннән шатлык очкыннары бөркелде. Ул, канәгатьләнеп, аяк очында яткан брезент чехоллы мылтыгына тибеп алды.

— Кай урында тукталган идем соң? — дип сорады.

— Иртәнауга киткән идегез.

— Ярый, исемә төште,— диде Аучы.— Ләкин сөйлисе күп калмаган инде. Менә шула-ай... Тегеләр, билгеләнгән урыннарына барып җиткәч, җиң сызганып эшкә керештеләр. Әйтергә мөмкин, кызу урак өсте башланды. Ин әүвәл бүре капкыннарын корып куйдылар, йөз-ике йөз метр ара калдырып. Шулай иткәндә алдан баручы бүре капкынга эләгә икән дә, арттан килүчеләре, аны әйләнеп үтеп, яңадан сукмакка төшәләр һәм икенче капкынга эләгәләр икән.

Озын дус көз көне үк яланрак җиргә, түшен һәм муены белән башын гына өстә калдырып, болан үләксәсе күмгән булган. Болар шуның янына җиттеләр дә, алып килгән эчәк-бавырларын төрле якка өстерәп киттеләр. Кар өстеннән. Кып-кызыл кан эзләре калдырып.

— Төлке, бүре бу урынга ияләште инде. Эзләр буйлап тагын килсен,— диләр.

Түшкәдән илле-алтмыш адым читкә, агач, куак төпләренә капкыннар кордылар.

— Нигә капкыннарыгызны түшкә янына куймыйсыз? Алар ит ашарга килә бит, бигрәк җайлы,— дим.

— Алдавыч түшкә янына киек-җанварлар сакланып кына килә. Бигрәк тә элек капкын тәмен татып караганы булса. Шуңа күрә аның янына капкыннарны сирәк куялар. Җәнлек, ашап туйгач, читкәрәк китеп, агач, куак, үлән төпләренә барып... сиякәй итә. Шунда шалт капкынга,— диләр.

Банкадагы сасы нәстәкәйләрне дә агач һәм түмгәк төпләренә сибеп, капкын-тозаклар куеп чыктылар. Ачыграк урыннарга кылый куяннар өчен тозлы сәйлүн чәе түктеләр. Ах та ух киләләр. Маңгайларыннан тир ага, өсләреннән пар бөркелә. Шулай да авызлары колакта.

— Күрдеңме, агай-эне ак мыек, өйрәнеп тордыңмы? — ди Озын дустым.

— Сунарчының эшен җиңел дип йөргән булсаң, мөгаен, ул көфер уйларыңнан тәүбә итәрсең инде,— дип аны куәтли Кыска дустым.

— Белүен белдем,— мин әйтәм,— әмма болай пычранып йөрүгезгә кул куймыйм. Сунарчылык — актив ял. Мылтык күтәреп әкрен генә ял итеп урманда йөрергә кирәк. Киек очраса — атарга, очрамаса — атмаска. Аткан тәкъдирдә дә, тисә — кошка, тимәсә — бушка дияргә, борчылмаска. Нервлар болай да кыл кебек тартылган — чирттең исә зыңларга тора. Бигрәк тә XX гасыр бәндәсенеке. Ник үз-үзеңне бетерергә? Саф һава сулавы, күкрәк тутырып азон йотып кайтуы — үзе бер гомер,— дим.

Уф та ыф киләләр. Үзләре көлә.

— Син анысын, энекәш, фотоаппарат белән ауга йөрүчеләргә әйт. Әле без пока кулларыбыз сау чакта мылтык атудан туктамабыз, күзләребез үткер чакта прицелгә караудан туймабыз,— диләр.

— Фотоаппарат күтәреп йөрүчеләр дә табигать сөючеләр түгелмени? Сүзләрегездә аларга карата санга сукмау шикеллерәк бер тон ишетәм.

— Без аларны кимсетмибез, алла сакласын. Ләкин алар чын аучы күргән татлы газапларны, алар кичергән рәхәт тойгыларны бер вакытта да татый алмыйлар.

— Карагыз әле, мылтыклы кешеләр,— дип кычкырам тегеләргә,— соң, инәгезнең башлары, дөньяда сезнең шикелле ничә аучы барлыгын беләсезме? Әгәр алар бөтенесе берьюлы залп бирсәләр, һәм аларның һәр аткан ядрәләре, могҗиза булып, кош-кортка, я җәнлек-җанварга

тисә — ул чагында җир шарында бер кош та һәм җәнлек тә калмаячагын беләсезме? — дим.

— Беләбез,— диләр.

— Соң?

— Сиңа борчылыр урын юк,— ди Озын дустым.— Беренчедән, андый залп һич кайчан булмаячак.

— Икенчедән,— дип аңа ялгый Кыска дустым,— залп булган тәкъдирдә дә барлык җәдрәләрнең кошка, я җәнлеккә эләгүе мөмкин түгел. Сер итеп кенә әйткәндә, мылтык күтәреп йөрүчеләрнең һәммәсе дә Мәргән түгел бит.

Бүре, төлке, куян ише нәрсәләргә бөтен хәйләләрен, әзерлисе әйберләрен әзерләп бетерделәр. Тирләрен сөрттеләр. Ял иттеләр. Аннары миңа:

— Мылтыгыңны алтылы, я бишле җәдрә белән кор. Тиенгә киттек,— диләр.

— Ә бүре? — дим.

— Бүрене төнлә засададан атабыз,— диләр.

— Төнлә кар астында ятуга караганда юрган астында ятуны яратарак төшәм,— мин әйтәм.

— Һәр кемнең яраткан нәрсәсе бар, ләкин ул мур кырган үзе генә күп очракта безне яратмый,— диләр.

Ешкынгарак кереп киттек.

Эт алдан ялт-йолт каранып бара. Без аның артыннан. Кар өстенә, нарат, чыршы башларына күз салабыз. Вакыт-вакыт туктап тыңлыйбыз. Һава тын чакта тиеннең кетер-кетер чикләвек кимерүен йөз метрдан да ишетеп була икән. Билгеле, колагың нормальный колак булса.

Карны иснәштергәләп эт бара, эт артыннан — без. Кар тирән булса да, тиен эзләре нигәдер очрамый. Ышаныч эттә. Шул мәхлук тапса таба. Шулай бара торгач, эт югалды. Ягъни алга чабып китте. Юрмырый түгел, чынлап эзли башлады. Безнең үзебездән рәт чыкмавын кара акылы белән булса да сизенде кара колак.

— Тукта,— ди Озын дустым.— Ял итик. Тапса сигнал бирә ул,— ди.

— Дөрес,— ди Кыска дустым, аның сүзен куәтләп.— Бүгенгә болай да житкән иде дә, тик бу әфәндегә чын ауны күрсәтәсебез килде, ни хәл итик, чыдарга туры килә,— ди.

Бер мәлне агачлар арасында этебез өрә башлады. «Килегез, таптым, менә ул җан кисәк» дигән шикелле шатланып өрә. Мылтыкларын кулларына алып ике дустым чапты, алар артыннан — мин.

Барып җиттек. Этебез, бер карагайга үрелеп баскан да каеры тырный-тырный өрепме өрә. Әле өскә, әле безгә карый. «Нәрсә мыштырдыйсыз инде, бер аягыгызны атлаганчы икенчесен эт ашый» дип безне әрләпме әрли саб-бака.

Ул күрсәткән төшкә карыйбыз. Юк, тиен күренми.

— Ботагы бик куе бу агачның. Поскан ул,— ди Кыска дустым.

— Без аны хәзер поскан төшеннән чыгарабыз,— дип, Озын дустым балта түтәсе белән агачка сукты. Тиен шундук яшеренгән урыныннан атылып чыгып икенче ботакка сикерде.

— Мин аны хәзер әйләндереп төшерәм,— дип, Озын дустым куш көбәген күтәргән иде, Кыска дустым аны туктатты.

— Бу иптәш атып карасын әле. Чын атучы итәргә дип алып килдек түгелме соң?

— Дөрес, старик,— диде Озын дустым. Миңа борылып:— Тере кеше бер һөнәрсез булмас. Әйдә, күрсәт һөнәреңне. Тиресен бозма, башына төбә,— диде.

Алар алдында җебеп торасым килмәде. Бияләйләремне салып, мылтыгымны күтәрдем. Әкрен генә төзи башладым.

Төзи башладым башлавын. «Чебенне» нәкъ маңгаена утыртып куйдым. Нәкъ ике каш арасында тора. Әмма, иптәшләр, ике каш астында теп-тере ике күз бар, минем күзләремә туп-туры мөлдерәп карап торучы ике күз бар бит әле!..

То да се... Эһем... һем... Эххем!..

Курыкмый. Кәүсә артында гәүдәсе. Бу якта башы. Миңа карап тора. Курыкмый. Әҗәле җитүен сизгәнгә күрә батырга әйләнәләр бит алар. Куянны искә төшерегез. Куркак дип даны таралган куян яралы чакта аучыга ташлана... Бер-беребезне гипнозларга теләгәндәй карашып торабыз...

— Атма, зинһар! — дип ялвара энҗе күзләр.

— Мылтык алып чыккан идем шул, нишләргә соң? — диләр минем күзләр.

— Мине үтереп сиңа ни файда? Без бит дөньяда болай да бик аз — фәкать тугыз ел гына яшибез. Минем әле яшисем килә,— ди тиен.

— Кешеләргә синең үзең түгел, тунның кирәк. Тыныч яшисең килгәч, нишләп шундый шәп тун киеп йөрисең? — диләр минем күзләр.

— Без бит тайгада яшибез. Ә кыш көннәрендә зәһәр суыклар була. Җылы тунсыз яши алмыйсың, шулай булгач нишләмәк кирәк! Атма инде! — дип үтенә һаман тиеннең күзләре.

— Әгәр мин сине атмасам, Озын дустым белән Кыска дустым көләр бит,— дип җавап бирәм киеккә.

— Синең иптәшләрең дә кеше бит, ди бу. Аңларлар. Көлмәсләр. Безнең болай да дошманнарыбыз бик күп. Болай да гомер буе дер калтырап яшибез. Агач башларында гына торабыз. Төрле хәйләләр корган булабыз. Атма, кирәкми. Тыңла, мине, Кеше?!.

— Әйе, сезнең тормышка кызыкмас идем мин.

— Кара син миңа, Кеше: мин дә сезнең шикелле үк җан иясе бит. Минем дә башым бар, гәүдәм. Кулым, аягым. Күзләрем. Йөрәгем, үпкәм, тешләрем. Кара син миңа, Кеше, ныклабрак кара: мин нинди матур, тере килеш мин нинди җиңел, үткер! Ә үтерелгән тиендә нинди матурлык бар?!.

— Сүзләрең дөрес, чибәр тиен. Сез — тере килеш матуррак.

— Син акыллы, Кеше! Үтермә син мине! Минем яшисем килә! Мин торган урман нинди киң, нинди матур! А-а-а, дөнья нинди киң, нинди матур! Дөньяда сезгә дә, безгә дә урын җитәрлек! Без — барыбыз да табигать балалары! А-а-а, яшисем килә, яшисем килә, Кеше!?. Атма, атма син миңа, киң күңелле, мәрхәмәтле Кеше?!. Төшер мылтыгыңны, Кеше?!.

— Менә күрәсеңме, мин мылтыгымны төшердем, гүзәл тиен. Яшә! Уйна! Шатлан! Гомереңбәхетле үтсен, иркен табигать тудырган бәләкәч киек.

— Рәхмәт сиңа, мәрхәмәтле Кеше!!.

— Сау бул, бәләкәй дустым!

— Сау бул, миһербанлы Кеше!..

Мин мылтыгымны төшердем дә аркама астым. Эт, җүләрме, акылымы бу бәндә дигән шикелле гаҗәпләнеп, миңа карады. Хәтта өрүдән туктады. Эт хуҗалары да аптырады.

— Корылмаганмы әллә? Патроның юкмы? — дип кычкырды Озын дус.

— Мә минем мылтыкны! — диде Кыска дус.

— Кирәкми,— мин әйтәм.— Әйдәгез киттек.

— Киттек?! Кая?!.

— Өйгә.

— Ә тиен?!.

— Ә тиен калсын.

— Син нәрсә, инәннен... Без күрмәгәндә урлап спирт эчтеңме әллә?.. Шундый шәп, уңай...
— Атасым килми, гомер итсен, әйдә. Безгә аның ни зыяны тия?
— Аучы һәвәслеге юк икән синдә. Хәтерең калмасын, боламык син.
— Мин аны үзем... Менә кара... Башына гына...
— Тимә! Мәңге бәхил түгел минем тиенгә кагылсаң...
— Нәрсә, нәрсә?!.
— Ә?!.
Ауның рәте китте. Озын дустым белән Кыска дустым үзләрлек булып гаҗәпләнде. Соңыннан көлеп сөйләделәр: ул чагында алар миннән башына зәгыйфьлек килмәде микән дип тә шикләнгәннәр...
Кайтыр юлга борылдык. Иң алдан — мин, минем арттан — алар.
Алар артыннан, күңелле генә башланган сунарның кинәт өзелүен башына сыйдыра алмыйча аптырап, эт иярде.
Ә тиен, сөенеченнән яшьле күзләрен сөртә-сөртә, миңа койрыгын болгап калды.
Кайтабыз, кар — шыгырт-шыгырт, шыгырт-шыгырт, дуслар — уф-ых, уф-ых, эт — һәү-һәү, һәү-һәү. Бер мәлне «һәү-һәү» кинәт бетте китте. Карасак, Трумэн, койрыгын сөңге итеп, бер аягын күтәреп сузылып каткан. Алдында очы кара озын колакларын шомырайтып, ак койрыгын кысып ак куян утыра.
Озын дустым әкрен генә мылтыгын сала башлады.
— Атасы булма!
— Тфү, тагын — атасы булма. Без аучымы, балыкчымы, сүз талкучымы, наконец? — дип сүгенә Озын дустым.
— Монда нинди дер хикмәт булырга тиеш. Үз күләгәсеннән дә курка торган нормаль куян аучы белән эт алдында болай җәелеп утырмас. Әйдәгез, кул белән тотып карыйк әле,— дим тегеләргә.
Аптырауның аръягына чыктылар. Пыш-пыш килеп мине әрлиләр, сызгырышалар.
— Куян нормаль монда, бу үзе ненормаль,— диешәләр.
И бу ике тел бистәсенә ачуым килде. Йодрык күрсәттем. Сакланып кына куянга якынлаша башладым. Сарык, кәҗә бәрәне чакыргандай, бәрәкәй-бәрәкәй дип бераз иелебрәк, тезләрне бөгебрәк, тавык тотарга баргандай кулларны ике якка җәебрәк әкрен генә якынлаштым. Күзләрен тутырып карый, исләгән шикелле мыекларын уйната, алга-артка колакларын йөртә. Ә китәргә кыймый. Урманда өнсез, кырда койрыксыз мәхлук.
Ышанасызмы-юкмы — арслан өстенә сикергәндәй сикердем дә эләктердем тегене! Җәдрә эләккән шикелле дырт итеп тартылып кына китте. Кысып тоттым. Чабаланмый. Дер-дер дерелди дә, йөрәге, чыгарга теләгәндәй, дөп-дөп тибә.
Озын дустым белән Кыска дустым һәм алар артында торган эт, моны күргәч, бер-берсенең каралыгына гаҗәпләнгән өч карга шикелле авызларын ачып, шаккатып калдылар. Ышанырга да, ышанмаска да белмиләр. Ышанырлар иде — моңа хәтле ялан кул белән куян тоткан кешене күргәннәре түгел, ишеткәннәре дә булмаган. Ышанмаслар иде — каршыларында куян кочаклап мин басып торам. Куян да тегенди-мондый нәрсә генә түгел, куянның атаманы: буе алтмыш-алтмыш биш сантиметр, авырлыгы биш кило, биш кило ярым булыр.
Озын дустым белән Кыска дустымныңниләр диюен, ул көнне ниләр эшләвебезне сөйләп тормыйм. Анда әллә ни кызык юк. Ә куянны мин тәки өйгә алып кайттым. Ветпунктка илттем — иренмәдем. Аның тамагына гөлҗимеш шырпысы кадалган икән. Шырпыны алгач тагын ике-өч көн өйдә асрадым да мәктәп-интернатка бүләк иттем. Ул интернатның тере почмагы бик бай. Балалар ана, ялан кул белән тотырганын уйлапмы, «Юаш» дип исем куштылар. Ул озак еллар шунда яшәде.

Хәзер юк инде, картаеп үлде. Юашның балалары, балаларының балалары гына бар. Укучылар шулай да үзен онытмыйлар. Балаларына һәм балаларының балаларына, патшаларга кушкан шикелле «Юаш II», «Юаш III», «Юаш IV» дип тәртип белән исем кушалар. Әле яз көне шул мәктәп-интернатка баргач, бер малайның «Юаш XII» дип сөйләшеп торганын ишетеп калдым.

— Шуннан, шуннан? — диде Нурбак.— Сез бит әле ничек аучылар җәмгыятенең башлыгы булуыгызны әйтмәдегез.

— Инде әйтеп бетердем, әз генә калды,— диде Аучы.— Тегеләр икәүләп шуннан соң мине мактарга тотындылар, мин сезгә әйтим. Шартлаталар гына. Мин, имеш, бөтен тирә-якка атаклы аучы, мин, имеш, бөтен тайганы биш бармагым шикелле беләм. Алай гынамы әле! Тайгадагы җәнлек-җанварларның ояларын, ул ояларындагы балаларына хәтле белә, диләр. Ул хәтта куян, кыр тавыгы ише нәрсәләргә безнең шикелле җүләрләнеп мылтык күтәреп йөрми, аларны артларыннан куып коры кулы белән генә эләктереп ала, диләр... Китте сүз, таралды сүз. Бер ни эшләр хәл юк.

Кайберәүләр ышаналар. Ау белән әз-мәз таныш булганнары мыек астыннан гына елмаеп тора.

Менә шул көннәрдә мине бу эшемә тактылар да инде. Кызыл тел кызык итте. Көлке генә бит бу, туганкайлар, Озын дустым белән Кыска дустым дип аталган нәстәкәйләр шаярып кына сөйлиләр, дидем. Беләбез, безгә шундый кеше кирәк тә инде, диделәр.

— Күренә, тегеләрнең ышанычларын аклагансыз! — диде Петр Петрович.

— Акладым. Хәзер өлкәдә дә безнең районны бик яхшы беләләр. Менә әле тагын киңәшмәдән кайтып киләм. Тагын бүләкләделәр. Тагын сәгать...

Аучы сул кулының җиңен күтәрде. Кул беләзегенә рәттән ике сәгать тагылган иде.

— Монысы, хәзерге бүләк — «Свет». Тузан да, су да үткәрми. Монысы үткән елгы иде. Өйдә тагын икәү бар. Инде алар миңа дүрт сәгать бирделәр. Сәгать тә сәгать... Нигә? Биргәннең битенә карама. Сәгате дә ярап тора.

— Димәк, чыннан да яхшы эшлисез. Районыгыздагы аюларның кирәген бирәсез икән. Бөтен өлкәне мех белән күмгәнсездер инде?

— Нәкъ киресенчә,— диде Аучы, пинжәк төймәсен каптырырга тырышып.— Без инде моннан өч ел элек язгы һәм көзге ауны тыйдык. Җәнлекләрнең һәм кошларның баш санын исәпләдек. Безнең җәмгать инспекторлары районыбыздагы һәр аккош оясын, сазларда торна күкәй баса торган һәр түмгәк башын белә.

— Кызык сез! Ул чакта аучылар җәмгыяте нигә кирәк соң?

— Җәнлек-җанварларны һәм кош-кортларның хәзер булганнарын саклап калу, баш саннарын арттыру өчен.

— Шуның белән мәтәшмәсәгез, тайгада киек азмы әллә?

— Аз. Соңгы елларда безнең район территориясендә алар бик нык кимегәннәр иде. Чара күрмәсәң, җир йөзеннән бик күп кыйммәтле җәнлекләр югалган шикелле, болары да югалырга мөмкин иде. Аларны кырып бетерәчәкләр иде...

Нурбак, бәләкәй блокнотыннан аерылмады, сызгалый торды. Аның башында ау турында, тайга җәнлекләре тайга сукмакларында еш булмаса да очрап торган маҗаралар турында язу теләге туды бугай. Күзләренең ялтыравыннан һәм кулларының кызу-кызу хәрәкәтеннән шул сизелгән төсле иде. Ул, мөгаен, әгәр бу кеше минем районда булса, мин моның хакында һичшиксез бер-ике подваллык шәп кенә очерк язган булыр идем дип тә уйлады булса кирәк. Аучыга тутырып-тутырып

караган чакларында күзләрендә үкенү һәм эз генә уфтану да бар иде шикелле.

Уйчан кеше, Аучыга башта игътибар итмәсә дә, соңга таба кызыксынып китте. Янакларына таянып, вакыт-вакыт күзләрен күтәреп аңа карады. Кешеләргә кушылып көлгәндәй итте: ирен читләре сизелерсизелмәс кенә дерелдәп китте. Һәрхәлдә, уйчан һәм моңлы күзләрендә шаян очкыннар кабынып-кабынып куйды.

Аучы хикәясе Тамара өчен география белән зоологиянең мәктәпләрдә һәм ВУЗларда үтелмәгән әр-яна бүлеге иде. Менә хәзер бу чит-ят кешеләр янына утырып, моңа хәтле күрмәгән һәм белмәгән, күрермен дип тә уйламаган чит-ят җирләргә барганда алар турында азмы-күпме белебрәк баруы кыз өчен бик әйбәт иде. Бер карасаң, кызыктыра иде бу, икенче яктан, куркыта да иде. Юк, җәнлек-җанварлары, усал кышлары белән дә, чебен-черкиләре, төпсез сазлыклары белән дә түгел, таныш булмаган серлелеге белән куркыта иде аны ул барып дөнья көтеп яшәргә, тормыш корырга тиеш булган яңа яклар. Хәер, таныш түгел һәр нәрсә башта серле тоела. Танышып алгач, кеше аларның бернинди сере юклыгын, хәтта кул белән капшап, күз белән күреп карарга мөмкин булган гади нәрсәләр, гади тормыш икәнен белә.

Юлга чыгып, яңа җирләргә килүче кешеләргә бик таныш бу тойгы.

Петр Петрович Аучыга текәп карап:

— Мин сезнең турыда ишетеп белә идем инде. Менә танышырга да туры килде,— диде.

— Юкты-ыр,— диде Аучы, шатланып,— мине шул... районда танышлар белсә белә инде.

Петр Петрович, аның бу сүзләрен игътибарсыз калдырып:

— Буш вакытыгыз булса, мин сезнең белән кайбер нәрсәләр хакында киңәшер идем,— диде.

— Рәхим итегез, рәхим итегез! — диде Аучы тагын да нык шатланып.— Киңәшер-сөйләшер өчен берничә минутны һәр вакыт табып була.

— Рәхмәт!

Аучы тулы ияген уч төбе белән ышкый-ышкый шаян соры күзләре белән юлдашларына карап алды. Аннан күлмәк якасының юл буе һич каптырылырга теләмәгән төймәсен меңенче тапкыр каптырырга азапланa башлады...

## 10

Айзат аңа карап көлемсерәп куйды. Ул әле моңа хәтле тайга урманнарын җәнлек-җанварлар белән кайнап торган шикеллерәк күз алдына китерә иде. Китапларда шулай язалар, киноларда шулай күрсәтәләр бит. Айзат шундый картиналарның берсен Чәчкә белән дә караган иде.

Казанга Олег Лундстрем килгән, һәм шәһәр яшь-җилкенчәгенең шул сәбәпле кая басарга белми тилмереп йөргән көннәре иде. Бер кичне Айзат белән Чәчкә дә, аның концертына эләгә алмабызмы дип, җыенып чыгып киттеләр. Бүген генә стипендия бирүләре дә ярап куйды. Артык байлык адәмне аздырыр дигәннәр бит: малай да эшне байларча тотты. Башта «Чыршы»га кереп өчәр йомарлам мороженое ашадылар, салам белән сөт коктейле суырдылар. Нәзакәтле кыз-кыркын чат ябышып ятучы бу баллы һәм шикәрле тәгамнәрне электән үк өнәмәсә дә, Чәчкә белән йөри башлагач, Айзат та аларга яхшы гына ияләшеп килә иде инде. Коктейльләрен суырып бетергәч, урамга чыгып, Болак буйлап спорт сараена юнәлделәр. Юлда барганда Айзат Чәчкәгә ландыш букеты алып бирде. Болар әле кыңгырау сыман ак таҗларын яңа гына ачып килүче беренче чәчәкләр иде.

Чәчкә букетны рәхәтләнеп исни-исни:

— Рәхмәт! — диде. Ләкин шунда ук йөзен җитди итеп: — Син бигрәк байларча кыланасың. Киләсе көннәр турында да уйларга кирәк,— дип өстәде.

— Пүчтә-әк! — диде Айзат, кулын селкеп.— Ир бай түгел, күңел бай. Мин сиңа миллион сумлык чәчәкләр букеты бүләк итәр идем әле, кызганычка каршы, миллион сумым гына юк. Ләкин кайгырмыйбыз.

Акча бездә күп түгел,
Кирәгенә юк түгел,
Килә тора, китә тора,
Кирәгенә җитә тора...

Алар шулай уйнап-шаярып Болак башына барып җиттеләр һәм спорт сараена борылдылар. Борылдылар да шаккатып туктап калдылар: бүген Олег Лундстрем оркестры концертлар бирә торган спорт сараеның алды, чуп-чуар шәлъяулык япкан шикелле, аллы-гөлле төсләргә кергән иде. Төрле төстәге, төрле фасонлы матур кием кигән матур кызлар, сөйкемле егетләр, парлы һәм парсызлар ишек ачылуын көтеп төркем-төркем, ялгыз-ялгыз басып тора, аллеялар буйлап әкрен генә арлы-бирле йөри, сөйләшә-көлешә, ә кайберләре, Киров урамыннан агылып төшкән трамвай, троллейбуслардан чыккан кешеләрнең җиңнәренә асылынырдай булып, «артык билетыгыз юкмы?» дип теләнә иде. Кыскасы, спорт сараеның киң баскычлары да, тирә-яктагы урам-мәйданнар да, зур ярминкәләрдәге шикелле күзнең явын алып, шаулап-гүләп тора иде.

— Бәхет булмады,— диде Чәчкә.

— Бәлки булыр әле, бераз көтик. Өметеңне өзмә, күңелеңне бозма,— диде Айзат.

— Оптимист,— диде Чәчкә.

— Пессимист,— диде Айзат.

— Белмим шул, егеткәем, нинди җүләр бәндә мондый концертка билетын ычкындырырга теләр икән?

— Өметегезне өзәргә ашыкмагыз дим бит. Хәй Вахит абзагыз ни дигән? Бәлки безнең дә кинәт күк капуыбыз ачылып куяр! [1].

Ләкин егет белән кызга күк капусы ачылмады. «Теләнчеләр» төркеменә кушылып, «артык билетыгыз юкмы?» дип күпме генә сорап торсалар да — булмады. Сарай ишекләре ачылды. Бәхетлеләр эчкә кереп китте. Бүгенгә керә алмаганнар тагын әзрәк тордылар да таралыша башладылар. Айзат белән Чәчкә дә «Спутник»ка күтәрелде. Соңгы билетларны эләктереп «уф, тәки булды» дип, тар һәм караңгы баскычтан залга чабып менеп киттеләр.

Картина Себер аучылары турында иде. Ул болай да бик шәп, осталарча төшерелгән, шуның өстенә төсле дә булгач, тәэсир көче бик нык иде. Тайганы кыш көне дә, җәй көне дә, астан да, өстән дә күрсәттеләр. Менә аучылар һәм җәнлек-җанварлар тормышы башланды. Кырмыска оясын туздыручы соры аю күренде. Баласын Иман елгасына алып төшеп су коендыручы кара аю, аның шук баласының чыелдап елавы, качарга омтылып чабалануы, әнкәсенең ул тыңлаусыз җанга ачуы чыгып, колак төбенә кундыруы залда рәхәт көлү уятты. Аннан соң кешеләрнең ерткыч хайваннарны аулавы, ерткыч хайваннарның, үз чиратларында, үз туганнарын — көчсезрәк җәнлекләрне аулавы күрсәтелде. Уссури юлбарыслары сөңге тешле зур авызларын киереп ачып, күк күкрәгән тавышлар белән ырылдаганда көләргә теләүчеләр табылмады. Һәркем, йөрәгенең дерелдәвен һәм әз-мәз шомлануын

---

[1] Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» дигән водевиленә ишарә.

күршесеннән яшерергә тырышып, бу кансөяр ерткычларның зәһәр матурлыгына һәм тимер мускуллы көч-кодрәтенә сокланып утырды.

Менә бер чакны агач ботагында корбанын сагалап яткан селәүсен кар өстеннән сикерә-сикерә үтеп баручы зифа боланга ташланды. Һавада дуга ясап, анын нәкъ аркасына килеп төште. Мескен болан адәм тавышлары белән чыр-чыр акырып, җан көче белән тартышып, тыпырчынып караса да, хәлсезләнеп җиңелде. Селәүсен аны егып салып умыра, ботарлый башлады. Салкын һавага җылы иттән пар күтәрелде, ап-ак кар өстенә кып-кызыл каннар акты. Алдагы язмышыннан һич тә гаме булмаган, әле моннан күпме генә вакыт уйнап-шаярып йөргән яшь һәм сәламәт болан инде пыялаланырга өлгергән тонык җансыз күзләре белән залдагы кешеләргә бик озак карап ятты.

Бу — нечкә күңелле ханымнарны гына түгел, гомерләрен кибеттә ит чабып үткәргән үгез муенлы ирләрне дә тетрәтерлек күренеш иде. Картина төсләр белән дә эшләнгән булгач, ак кар, ак кар өстендәге кызыл кан таплары, кызгылт-көрән ит кисәкләре кешеләрнең зиһененә һәм психикасына тәэсир итә, үзеннән-үзе күзләрне йомдыра, аска карарга мәҗбүр итә иде.

Шул чагында Чәчкә, үзе дә сизмәде бугай, шытырдатып Айзатның беләген кысып алды. Бәләкәй генә, матур гына кулга шундый көч кайдан килгәндер: Айзат кычкырып җибәрә язды.

Кинодан чыккач, Чәчкә:

— Айзат, син шунда яшәр идеңме? Аучы булыр идеңме? — дип сорады.

— Син кушсаң, мин җәһәннәмгә китәргә риза. Син әмер генә бир,— диде Айзат, шаярып.

— Мин чынлап сөйләшәм,— диде Чәчкә, моңа бераз хәтере калып.— Табигатьнең кырыс урыннарында, мина калса, нинди дер батыррак, түземлерәк кешеләр яшидер һәм эшлидер кебек. Син дә шулар арасында була алыр идеңме? Моңа синең көчең җитәрлекме? Соравымның мәгънәсе шул.

— Алыр идем дип уйлыйм. Башта кыен булса да, әкренләп күнегелер иде. Адәм баласы мичтә кызган тимер шикелле — аны теләсә нинди формага кертергә мөмкин,— диде Айзат, җитди итеп.

— Миннән булмый. Мин бик көчсез кеше,— диде Чәчкә, уфтанып.— Мин үземне беләм. Төрле яклап өйрәндем. Физик яктан та, рухи яктан да мин үземнән-үзем канәгать түгел. Ничекләр генә укытырмын мин? Балалар тыңламаслар мине, юк, тыңламаслар. Мин практика үткән мәктәптә алтынчы класста өч ел утырган бер малай бар иде. Фамилиясе Маршалюк. Класстагы бүтән малайларга үзен «Маршал» дип йөртергә куша икән. Аңа IX класста булырга кирәк, ә ул һаман алтынчыда. «Мәктәптә беренче көнем» дигән сочинениесендә ничек дип язып куйган шул малай, беләсеңме? Ужас! «Бөтенесе дә тантаналы линейкага киттеләр, ә мин мәктәп артына тәмәке тартырга киттем»,— дип язган. Шундыйлар әләксә — беттем. Алар мине елатачаклар. Я шунда үзем колакларына ябышырмын.

— Физик яктан канәгать түгел дип юкка борчылмыйсың микән? — диде Айзат, һаман да авыртып торган беләген капшап.— Шулай ук рухи яктан да батыр кыз син, теләсә нинди класска үзеңне яраттыра аласың. Ләкин кара аны, класс җитәкчеләреннән үзенне яраттырырга тырышма. Ир зат класс җитәкчеләреннән дию ем...

Аннан сүз әле генә карап чыккан картина тирәсендә әйләнә башлады. Картинада җәнлек-җанварлар бик күп төрле һәм үзләре дә күп иде. Тайга киек-кошлар белән мыжлап тора икән, дип уйларга мөмкин. Һәрхәлдә, тайга белән әз таныш тамашачыда шундыйрак тәэсир калырга мөмкин иде. Операторларның шул җәнлекләрне генә саклап торып пленкага эләктерүләрен кем белгән!

Әмма алай түгел икән. Дөрес, җанварлар күп тайгада. Ләкин тайга үзе дә Татарстан урманнары гына түгел бит. Тайга үзе дә меңнәрчә чакрымнарга сузылган. Җәнлекләр әнә шул иксез-чиксез урманга таралганнар. Шуңа күрә аларның күплеге сизелми. Аларны еш күреп тә булмый...

Алар, кинодан чыккач, хәзер генә күргән урманнарга үзебез дә барып керербез дип уйламадылар, әлбәттә. Кайта-кайта, сөйләшә-сөйләшә тайга темасы сизелмичә генә телләреннән төшеп калды. Стадион алдындагы трамвай тукталышына җиткәч, Чәчкә Айзатка көтелмәгән сүз әйтте:

— Мин сине иртәгә кунакка чакырам,— диде.

— Кунакка!? — диде Айзат, аны бик үк аңлап бетермичә.

— Әйе,— диде Чәчкә, елмаеп.— Кунакка. Үзебезгә.

— Нәрсә? Мәҗлес җыясызмыни? Бәйрәм вакытлары да түгел шикелле. Әллә берәрегезнең туган көне-мазармы?

— Юк. Болай гына.

— Кемнәр килә? Кунак-төшем күп җыеламы?

— Курыкма, батыр егетем, һич кем юк. Әти дә әни, плюс син дә мин, буладыр дүрт бөртек.

— Һе, кызык әле бу, менә, тора торгач бер амин!..

— Аминыңны өстәл яныннан кузгалганда тотарсың. Ә иртәгә үзеңне карабрак кил. Кырыныбрак, чистарыныбрак дигәндәй. Хәер, үзең беләсең. Син һәр вакытта бик купшы йөрергә яратасың. Кешедән оялмасаң, пудра белән иннектән дә баш тартмас идең... Шулаймы, егетем?.. Үпкәли күрмә тагын, ходаем.

Шунда кинәт Айзатның зиһене яктырып киткәндәй булды.

Ул Чәчкәгә туп-туры карап торды да:

— Ә-ә-ә, аңладым! — дип кычкырып җибәрде.

— Әкрен,— диде Чәчкә.— Нигә кычкырасың? Күрмисеңмени, якягында кешеләр ич! — һәм аны пыяла будкага алып керде.— Я, нәрсә аңладың?

— Әти дә әни, син дә мин, Мөхәммәтәмин...

— Соң?!.

— И Чәчкә! Нигә аны әти-әниңнең сине күрәсе, танышасы килә дип кенә әйтмисең?..

Бу — егеткә бик нык тәэсир итте. Аларның авылында һәм тирә-якта Айзат андый гадәтне белми. Кыз күзләү, кыз күзләргә бару гадәтләре бар. Ләкин авыл халкы һаман да үзенең ата-бабадан калган гадиЙолалары белән яши. Авыл җирендә, гадәттә, егетләр һәм кызлар бер үк урамнарда, урман-болыннарда, су буйларында бәләкәйдән үк бергә шаярып, уйнап-көлеп, бергә эшләп үсәләр. Бер мәктәптә укыйлар. Бер-берсенә өйрәнәләр, ияләшәләр. Аннан соң кинәт серле һәм матур көн килә дә кичә бернәрсә дә сизми йөргән егет белән кыз бүген әллә нишләп бер-берсенә күтәрелеп тә карый алмый башлыйлар...

Ике яшь йөрәк кеше күзенә күренмәгән моңлы һәм рәхәт җепләр белән тоташа.

Шулай, сиздерми генә, дөньяда тагын бер мәхәббәт туа...

Көнелләр уяна, күңелләр нурлана. Җан азабын да, җан азыгын да белә башлый.

Әти кеше белән әни кеше, егетнеке булса кызны, кызныкы булса егетне — тууларыннан алып хәзерге көннәренә чаклы энәсеннән җебенә кадәр белеп торалар. Гадәтен дә, акылын да, сәләтен дә, холкын да. Шуңа күрә авыл халкы егет, я кыз белән танышу мәҗлесләре үткәрми.

Күрше авыл егетләрен һәм кызларын да белеп, күреп йөриләр хәйләкәр әткәй-әнкәйләр. Бу очракта да өйгә чакырып танышу кирәкми.

Тагын өченче төрле дә була: шәһәрдәге малайларыннан хат килеп төшә: өйләнгән; читтәге кызлары сәлам яза, сәлам ахырында: тормышка чыккан. Монда инде башны ташка орыр хәл юк — язмышына язган икән, өлешенә тигән көмешен яшьлек әллә кайлардан эзләп таба. Хәер, бабай белән әбиләр, әткәй белән әнкәйләр башларын ташка бәрергә таш эзләп йөрмиләр. Быелгы тәкәләрне көтүдән алып калып, ипи, көрпә ашата башлыйлар. Тозлы итләрне янә бер карап кисмәккә салалар һәм кисмәкне кар базына төшереп бозга күмеп куялар. Какланган казларны кояшта тагын ике-өч көн җилләтеп алалар. Балыкчыларга алдан ук кара балыкларга, табан балыкларга заказ бирәләр, кибет тирәсендә бик еш күренә башлыйлар...

Шулай итеп сабан туйлары җитә. Авылга әле моңарчы хат аша гына таныш яшь кияүләр, яшь киленнәр кайтып төшә. Алар белән рәтләп танышу менә шунда гына була...

Ә монда икенче төрлерәк шул...

Айзат, Чәчкәне тугызынчы трамвайга утыртып озатып җибәргәч, анә шуларны уйлый-уйлый кайтты. Күнелле дә иде аңа һәм бераз шикләндерә дә иде. Килүдән чакыру кыйбат дип гади кунакка чакыру гына түгел бит. Аны карау өчен, сынау өчен чакыралар. Безнең Чәчкә белән чуалган егет кәмәше нинди рәк бәндә икән, янәсе. Чәчкәгә торырлык микән? Авылның пешеп җитмәгән төче күмәче түгел микән? Үз-үзен тота беләме? Акыллымы? Кеше белән сөйләшә беләме? Төскәбиткә бик төшеп калганнардан түгелме? Буе-сыны ничек? Бик бәләкәй түгелме, я баскетбол уйнарга йөрмиме? Алаймы-болаймы? Тегеләйме? Фәләнме-төгәнме?.. Кыскасы, бер баш алдында мең сорау. Бөтенесенә дә җавап бирергә кирәк. Һәм фәкать бишле белән дүртлегә генә. Теләсә нинди дәүләт имтиханнарыннан каты бу, каты!..

Айзат Чәчкәгә дә үпкәләп куйды. Авылда кызлар белән егетләрнең кем белән йөрүләрен әтисе белән әнисенә сөйләп торганын кемнең күргәне бар? Алла сакласын! Тегеләр бер нәрсә дә белмичә, уйламастан боларның күңел кошлары турында сүз кузгатсалар да, яшьләр оятларыннан комачтай кызарынып тизрәк ишек алдына чыгып таярга тырышалар. Әти-әнигә кайтып сөйләү — кая ул! Дөньяда юк андый хәл!..

Ә монда бар икән андый хәл. Чәчкә аның турында әтиләренә әйтеп бара икән, ә! Шулай тәрбияләнгән. Оялмый. Алар өчен бу гап-гади эш. Хәтта зарурый. Бала-бала ди-ди, бала йоннарын коеп үстергән фәрештә валчыгыдай бер бөртек кызларының киноларга кем белән йөрүен, буш вакытларын кем белән үткәрүен белергә тиештер инде алар...

Айзат монастырьга кайтып керде дә караватына сузылып ятты. Әле бер якка, әле икенче якка әйләнде. «Һе, кызык әле бу, менә, тора торгач бер амин», дип сөйләнде.

Ни кадәр җор егет, батыр егет булып кыланырга тырышмасын, үз-үзенә «пүчтәк, кеше күрмәгәнме, барырмын да кайтырмын» дип тукымасын, күңел тынычлыгы югалган иде инде.

Иртәгә булачак очрашу аны оялта да, куркыта да иде...

Нариман,— Айзатның ярты кабымлык икмәкне икегә бүлеп каба торган, бер җептәге ике төймә, бер төптәге ике тирәк шикелле яшәгән дусты,— акча барда бүредәй, акча юкта шүредәй бергә көн күрүче, эч серләрен уртаклашучы элекке старшина түр почмактагы урыныннан аңа карап-карап ятты да торып янына килде.

— Бар әле, тегендәрәк ят әле,— диде.

Айзат стена буенарак күчеп ятты.

— Ботинкаларыңны сал, ичмасам,— дип куйды.

Нариман яткан килеш аягын аякка ышкып алды. Ботинкалары дөпелдәп идәнгә төште.

Старшина Айзатның колагыннан тартып, башын үз ягына борды да күзләренә карады.

— Я, ни булды?

— Бер ни дә булмады.

— Чәчкә белән ачуланыштыгызмы әллә?

— Ю-ук.

— Нәрсә «юк» булсын! Күреп торам бит — дельфин шикелле пошкырып ятасың.

Айзат аңа үзенең иртәгә кунакка чакырылуы турында сөйләп бирде.

— Да-да,— диде Нариман түшәмгә карап яткач,— сезнең эшләр тирәнгә киткән икән. Ну, һәр хәлдә, молодец! Менә дигән беренче сорт Казан кызын кулга төшердең. Менә бит танцевать итә белүнең файдасы!

— Нишләп кулга төшерим, мин аучы, ул кош түгел лә!

— Кош, кош!.. Гыйшкыннан сары булган сандугач, карлыгач — күңлемне ач! Кошның да ниндие әле!

— Нариман!..

— Я, ярар, бетте. Болай гына... Әйтелә торган сүз.

— Син лутчы киңәш бир: нишләргә миңа?

— Ничек «нишләргә»? Барырга. Күрәселәре килә икән — күренеп кайт. Тынычлансыннар. Куркасыңмы әллә?

— Әзрәк.

— Ира белән Мамадышка кайтып килдек. Әниләренә. Мин булып мин шөлләдем, малай. Синең сыңар гынамы әле — старшина! Яшь солдатларның котын алып тора идем.

— Соң?

— Мең мәртәбә сөйләдем, беләсең. Утырып көлә-көлә бер чәй эчкәч курку бетте. Чуртым да юк. Әнисе дә, апасы да бик шаян, гади булып чыкты.

— Болар гади түгелләр. Әтисе — фән кандидаты, доцент. Әнисе, домохозяйка булса да,— доцент хатыны. Кайбер зур кешеләрнең хатыннары ирләреннән яман була, ирләрен кар өстеннән ялан аяк йөгертә.

— Шулай икән, үзеңне алар алдында именно бик шәп итеп күрсәтергә кирәк. Простой түгел — ут егет! Ничек киенергә, баргач нишләргә, өстәл янында үз-үзеңне ничек тотарга — минем Ира белә инде аны. Хәзер әйтим әле.

Нариман утырып ботинкаларын кия башлады.

— Тукта, җенләнмә,— диде Айзат, аны тотып.— Моны бөтен кешенең белүе мәҗбүри түгелдер лә?

— Ира чит кешемени? Минем йөргән кызым, синең группадашың. Әзрәк репетиция кирәкме — кирәк. Без, ике кара мужик, бу нәзакәтле мәсьәләләрдә ни беләбез. Сукыр тавыкка бары да бодай. Аннан — син безнең институт егете. Пединститут йөзенә тап төшерергә ирек бирмәбез без сиңа, малай. Белеп тор!..

Нариман, көзге алдында юка чәчләрен тарап алганнан соң, унөченче бүлмәдә яшәүче Ирасы янына киңәш-табышка китте. Айзат: «Әй, теләсән ни эшләсәнә», дигәндәй кул селтәп, тагын ятып калды.

Әмма киң күңелле Нариман белән анын үзенә ошаган Ира, икәве генә киңәш-табышның очына чыга алмыйча, ярдәм сорап күршеләренә дә мөрәҗәгать иткәннәр иде, ахрысы. Ираны җитәкләп Нариман кайтып керде. Ира ак тешләрен ялтыратып:

— Карале, Айзат, чынмы бу? Иртәгәме? Чәчкәнең әти-әнисен күргәнең юк идемени? Аларның да сине күргәннәре юк идеме? — дип гадәттәнчә, үзенең бер соравына да җавап көтеп тормыйча кызу-кызу төпченә башлаган иде, туктарга мәҗбүр булды: каты гына ишек шакыдылар.

— Мөмкинме? — дип, бер кемнән дә, бер нәрсәдән дә курыкмаучы, укытучы Фруменьны күзенә карап «Трумэн» дип йөртүче, киң холыклы, шаркылдык, каты сөякле, каты куллы, кызлар атаманы Әминә атылып керде. Аның артыннан ике юаш кыз — ике Равилә күренде. Биш секундтан соң тагын ике кыз — ике Роза ишек шакыды. Ишек шакымый гына түгәрәк гәүдәле, килешле генә китек тешле Илзирә, сипкелле Сима белән сипкелле Наилә, бәләкәй Бәйнә, башкорт кызы Әлфия, күнел төшенкелеген белмәүче, һәр вакыт көләч Августина һәм бер кәтү башка кызлар күренде. Иң соңыннан, иптәш кызларының жилкәләренә кача-поса, әле һаман да дуңгыз ите эләкмәгәе дип, ашханәләргә кермәүче һәм моны һаман да бик нык яшерүче мыштым Сания керде, һәм караватт башына аркасын терәп, башкаларның чыр-чу килүен шыпырт кына тыңлап тора башлады.

Сигезенче бүлмә малайлары аптырап калды. Уку-язуларын ташлап: «Ни булган, ник бу чәчле бикәләр монда тулды, танца ясыйлармы әллә бүген?» дип сорашырга тотындылар. Сәбәбен белгәч, көлеп җибәрделәр, шундук кызларга кушылып киттеләр һәм Айзатка алардан да уздырып киңәш яудыра башладылар.

— Туктагыз, бака күле ясамагыз,— диде армиядә танкист булган һәм аннан кайткач Актаныш районында ике ел укытып, өс-баш карап запас белән килгән тәжрибәле Гариф.— Мин беләм: мондый чакта иң әүвәл кием кирәк. Киендерсәң, киндер таягы да кияү була.

— Гариф абый дөрес әйтә. Килеп керү белән аларның күзе синең киеменә төшә,— дип кычкырдылар кызлар.

— Киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар,— диде, бу җен туена катнашуны кирәк тапмыйча һаман укып утыручы күзлекле Равил.

— Син тыгылма, «ученый»,— дип кычкырды Әминә.— Безнең Айзат, аллага шөкер, кайберәүләр шикелле акыл сорап күршегә кермәле түгел.

— Ә-әй, миңа калса... Әйттем исә кайттым, тәүбә-тәүбә... Акыллыдыр, акыллыдыр. Акылсыз булса, көтүегез белән артыннан чабып йөрмәс идегез, — диде Равил, көлемсерәп, һәм янадан фонетикасына чумды.

Рус-татар бүлегендә укучылар старостасы Закир да (аны үзенең группа кызлары Захар Петрович дип йөртәләр иде) сүзгә кушылды:

— Сез туктагыз, шаулашасыз да шаулашасыз, һич ни аңлап булмый. Кешегә барырга кирәкме — кирәк. Бару өчен кием кирәк. Шулай булгач, әйдәгез, иплән кенә тикшерик — нинди киемнәр белән барырга тиеш ул?

— Айзат, институтка йөри торган костюмың ярамый, минемчә,— диде нәкъ ике кара кашы арасында һинд хатын-кызларыныкы шикелле матур гына миңе булган Регина.

— Бәй, мин бүтән нәрсә киим ди! Бальзакның гыйза ул йөз утыз жилеты булган,— диде Айзат, аптырабрак.

Пөхтә һәм сак торырга яратучы Рәйсә:

— Башта карарга кирәк, нинди нәрсәләрең бар соң? Бәлки үз күлмәкләрең дә ярый торгандыр,— дип, күзләре белән аның чемоданын эзли башлады.

— Рәйсә дөрес әйтә, кызлар,— дип, ак мәрмәр кебек ак йөзле, кап-кара күзле, кара кашлы, кара чәчле, тулырак кына алсу иренле, зифа гәүдәле чибәр Ләлә аның сүзен куәтләде.— Үзенең дә әйбәт әйберләре бар ич аның. Каралган булса хәзер юып, үтүкләп бирербез.

Айзатның чемоданы ачылды. Аннан күлмәк-майка һәм вак-төяк шырдым-бырдым алып караватка тезделәр. Монысы ярый, тегесе ярамый дип бәхәсләшә-бәхәсләшә, яшел нейлон күлмәк сайлап алдылар.

— Карале, шушындый матур күлмәгең дә бармыни әле?! — дип гаҗәпләнделәр.

— Менә саран!

— Кими. Сандык төбендә яшереп яткыра.

— Әл-Җәһизнең «Сараннар турындагы китабындагы» Хөрәсән сараннары кебек.

Равил китабыннан башын күтәрде:

— Әгәр бик беләсегез килсә, Әл-Җәһиз ул язучының кушаматы гына. «Акай күзле» дигән сүз. Аның чын исеме — Абу Госман Амр ибн бахр ибн Махбуб аль-Кинани аль-Барси. Менә вәт! Бик беләсегез килсә — белегез.

— Тик тор син, «ученый»,— дип кычкырды аңа берьюлы берничә кыз.— Нинди әйбәт нәрсәләрең бар — давай? Галстугың шәпме?

— Бәй,— диде Равил, юри шаккаткан кыяфәт белән.— Мин нигә җиде ятка хәләл галстугымны тактырып җибәрим! Мин куеныңа керәсе кызмы?!.

Равилне кызлар коридорга куып чыгардылар. Ул шулай да соңгы минутта ишекне ачып кычкырырга өлгерде:

— Исмәгыйльне чишендерегез. Ул кичә чех бишмәте алды.

Исмәгыйль — сигезенче бүлмәдәге иң бәләкәй кеше. Тар күкрәкле, нечкә беләкле һәм ябык йөзле бу егетне бүлмәдәшләре еш кына дусларча котыртып, кыздырып алалар иде.

— Исмәгыйль, әпәйне күбрәк ашарга тырыш син, нәнәм. Көч — әпәйдә.

— Көн саен сыра эч. Сыра симертә.

— Сыра эчне күпертә.

Узган елны Исмәгыйль җилле генә кызып кунактан кайтты. Башта бер кулы белән карават башына тотынып, икенче кулын болгый-болгый, товарищи, Советский союз... дип, халыкара хәл турында озын гына лекция сөйләде. Лекциясен игътибар белән тыңламауларына ачуы килеп, бокс буенча РСФСР чемпионы исемен алган Шәүкәтне коридорга куып чыгарды. Әле моның белән генә канәгатьләнмичә, бүлмәдән бүлмәгә кереп Шәүкәтне эзләп: «Кая качырдыгыз ул малайны, мин аны тапсаммы... Ул имансыз минем кулга эләксәме... Мин аны муеныннан менә болай гына тотам да... Менә болай гына күтәреп атам да бәрәм...» дип күкрәк сугып, күркәләнеп йөрде.

Бу мәзәк кичтән соң егетләргә көлү өчен тагын бер сәбәп артты.

— Исмәгыйльгә эчәргә ярамый — котыра!

— Якын бармагыз — җаныгызны ала! — дип шаярта башладылар.

Исмәгыйль моңа үзе үпкәләми. Туктагыз әле, көлегез әле, көл. Бер көчләнеп кирәгегезне бирермен әле дип, көлеп кенә тора иде.

Исмәгыйль Равилгә тавык күкәе хәтле йодрыгын янап калды.

— Кара аны, телеңә бик салынасың әле. Конспектыңны күчерт дип ялынып килмәссең микән?!.

Аннан соң чемоданыннан капрон галстук алып бирде.

— Галстукның размеры юк. Ул Тарапунькага да, Штепсельгә дә ярый. Мә!

— Менә!.. Менә!..— дип шатланып кычкырдылар кызлар.— Яшел күлмәккә яшел галстук. Ачты да җибәрде. Молодец!

— Минемчә, болай ярамый.

Кызлар, егетләр Карлга борылып карадылар.

Карл бик культуралы, күп укыган, күпне белүче, аның өстенә, һәр кешегә ярдәм итәргә, киңәш бирергә, гомумән, берәрсенә кечкенә генә булса да файда итәргә атылып тора торган, коңгырт чәчле, уйчан ак йөзле студент иде. Ул кием-салым мәсьәләсендә дә яхшы гына «йөзә». Ыспай киенеп йөри, бурычка һәрвакыт акча биреп тора.

Аның бер генә сәер гадәте бар: сөйләшкән кешесенең беләгеннән эләктереп ала да аны озын бармаклары белән кыса-кыса сөйләшә иде.

Карл әле дә кызларны аралап уртага керде дә Айзатның терсәктән югары жирен эләктереп алды.

— Тантаналы һәм рәсми җирләргә барганда кара костюм кияләр. Синең бу — тантаналы нәрсә бит, минемчә!

— Тантаналы, тантаналы! — дип, Айзат өчен җавап бирделәр икесе дә озын ике Наилә берьюлы.— Сөйгән ярының эти-әнисе белән күрешергә барсын да... Моннан зур тантана дөньяда юк.

— Кара костюмга ак күлмәк, сары, көмеш сыман, я кара галстук сайлыйлар. Кара оекбаш, кара ботинка кирәк.

Үзенең мич янындагы урынында, гомуми шау-шуга әлегә катнашмыйча, кыздырылган аю ите ашап, Башкортстан егете географ Ирек утыра иде. Ул бүлмәдәге егетләрдән әз генә өлкәнрәк: институтка армиядән соң килгән. Үзе уку өстенә, Казанның ниндидер кечкенә мәктәбендә укыта да. Стипендия дә алгач, укыткач та, сигезенче бүлмәдә иң бай кеше шул. Кырыкмыш тай шикелле койрык чәнчеп чабар яшьтән узган, сабырланган. Кайвакыт ике борынга бер савыт оештырабызмы әллә дигән коткы сүзләрне башлаучы булса да, акчасын артык әрәмшәрәм итми. Җаны теләгәнне — бәясенә карап тормый — рәхәтләнеп ашый. Китап җыя, кием-салым ала, әз-мәз әнисенә сала.

Менә шул географ Ирек хәзер аю итенең соңгы кисәген чәйнәп йотты да, кулларын кәгазьгә сөртә-сөртә:

— Айзат, теләсәң ал, минем әле бер дә киелмәгән ак нейлон күлмәк бар. Кара галстук та бар. Безнең җилкәләр бер төсле булырга тиеш,— диде.

Кызлар рәхмәтләр әйтеп Ирекнең күлмәге белән галстугын алдылар. Айзатны шкаф артына этеп керттеләр дә, ай-ваена карамыйча, күлмәкне кигертеп карадылар. Күлмәк егетнең үзенә үлчәп теккәндәй тап-таман булып чыкты.

Ирек моны күргәч сөенде. Кара күзләрен елтыратып:

— Әйттем бит, безнең җилкәләр бер,— диде.

Башка егетләр Айзатка майкаларын, трусикларын, оекларын һәм эшләпәләрен тәкъдим иттеләр. Әллә ничә пар туфли, ботинка килде. Тик Айзат аларны алмады. Башка киемнәре үзенеке дә ярарлык иде. Шулай итеп, сөйләшүләрнең һәм киңәшүләрнең ахыры «кунакка чит әйберләрдән Ирекнең ак күлмәге белән кара галстугы гына барачак» дигән нәтиҗә белән бетте.

Көн тәртибенең беренче мәсьәләсенә нокта куелды.

Икенче көн тәртибенә күчтеләр.

Кызлар инициативаны тагын үз кулларына алып өлгерделәр.

— Син аларга ничек барып керәсең — звонокны ничек шалтыратасың, ничек исәнләшәсең, шуны җентекләп өйрәнергә кирәк,— диделәр.

— Урындыкның читенә генә эләгеп утырма, ботинны ерма, селкенмә, аягыңны урындык аягына куйма,— диделәр.

— Тавышсыз утыр, тавышсыз тор,— диделәр.

— Мине бәләкәй бала дип уйлыйсызмы әллә? Урындыкта гына утыра беләрмен инде,— диде Айзат, кызларга әзрәк хәтере калып.— һе, кызык әле бу! Менә, тора торгач бер әмин! Сез нәрсәгә монда җыелып кердегез әле? Ни дип бака туе ясыйсыз, ә?

— Кызма! Сабыр ит! Тукай бабаң әйтмешли: и карендәш, син кирәксә суга бат йә сөткә бат, ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сәбат! — диде Нариман.— Алар сиңа чын күңелләреннән ярдәм итәргә кергәннәр.

— Ярдәм?!. Урындыкта утырырга өйрәтәләр. Шул да ярдәм буламы?

Телче Равил инде күптән кереп сүзгә кысылырга җай эзләп тора икән. Борын очындагы бөрчек-бөрчек тирен сыпырып төшерде дә, ашыгып:

— Алай димә! Бәрәңге ашауның да рәте бар. Ашау дигәннән, син менә балыкны ничек ашар идең? — диде.

— Ә?!. Балык?!.

— Рәте бар, иптәшкәем. Ә устрица бирсәләр? Устрицаны, беләсеңме, өстәлгә ничек китерәләр? Төбенә вак боз түшәлгән тәлинкәгә салып. Дүрт кисәккә ярылган лимон бирәләр. Берничә устрица аласың да кабырчыгыннан чыгарасың. Лимон суы тамызып чәнечке белән ашыйсың. Белә идеңме моны, малай? Авылыгызда ашап караганың бар идеме?

— Әллә син Чәчкәләрдә устрица булыр дисеңме?

— Белмәссең. Кем әйтмешли, галим кешеләр дә ашамагач, кем ашый соң ул баканы?.. Тфү!..

— Син беләсең инде! Ученый!

— Беләм шул. Чәчкәнең әтисе фәннәр кандидаты булса, без дә арба төбеннән төшеп калмаган: минем әни дә — РСФСРның атказанган укытучысы... Грог эчәргә теләмисезме дип сорасалар, бу нинди җанвар икән дип аңгыра шалканланып утырма. Шикәр суы кушылган ром, я коньяк кына ул...

Бүлмәдәгеләр Равилне башта әрләсәләр дә соңыннан сүрелделәр. Белеп сукалый мөртәт, диделәр. Чыннан да өстәл янында утыру, әңгәмәгә катнашу өчен зур культурага ия булырга кирәк. Шуннан соң Айзатның башына ашау-эчү мәсьәләләренә кагылышлы киңәшләр ява башлады:

— Иң элек аппетит ачар өчен вермут, я коньяк тәкъдим итәләр. Нәфсеңне тый! Бердән артык эчмә!

— Шуннан соң коры-сары булырга мөмкин. Паштет, винегрет, салат ише нәрсәләр. Ләкин аларны да сыптырып атарга тырышма — аның артыннан икенче ашлар да була әле. Урының калсын.

— Әйе. Чөнки соңыннан шулпалы аш китерүләре мөмкин.

— Аштан соң балык, балыктан соң ит бирелә.

— Иттән соң инде мороженое, конфет, кофе ише тәмле-тәмле әйберләр белән сыйланалар.

— Әй малайлар, безнең Айзат неужели боларның бөтенесен дә ашап бетерер, ә?

— Тырышыр. Студент корсагы киң ул: сузсаң бер чакрымга җитә.

— Бәхетле бала!..

Айзат бу киңәшләрдән бөтенләй буталып:

— Туктыйсызмы сез — юкмы? Кунакка мин барам бит — сез түгел! — дип ялварды...

Сигезенче бүлмә бик озак шау-гөр килеп торды. Күрше бүлмәләрдән дә, үткән-сүткәннәр дә, ни бар монда, нәрсә биетәләр, дигән булып, җыела тордылар. Хәлне аңлагач, кабынып, гомуми сүз — киңәшкә кушылып киттеләр.

Айзатка тагын, мәсәлән: такт һәм зәвык, этика, исәнләшү, күрешү, үбешү, «син» һәм «сез»не куллану, котлау, туйга чакыру, кунакта үзүзеңне тоту, кайчан, ничек, кемгә нинди бүләк бирү, аракыны күпме һәм ничек, кем белән һәм кайда эчү, тәмәке тарту, урамда йөрү, театрга бару, трамвайда һәм судта үзеңне ничек тоту, спорт уеннарына катнашу һәм, кызып китептер инде — караңгы төндә парашют белән дингез өстенә сикерү һәм күкрәк баласын имезү кагыйдәләре өйрәтелде...

Кунаклар, хуҗалар чишенеп ята башлагач кына, анда да әле теләртеләмәс кенә таралыштылар. Таралырга теләмәгәннәрен Нариман

белән Шәүкәт, әле генә Айзатка өйрәтелгән этика кагыйдәләренә бик үк туры китереп тормыйча, куып чыгардылар.
Айзат ут сүнгәч тә йоклый алмыйча уйланып ятты. Аңа рәхәт тә һәм кыен да иде. Нариманга үпкәлисе килде. Кунакка бару гаеп эшмени! Аны нигә чебеннән фил ясагандай күпертергә! Ник сабын куыгы шикелле кабартырга! Бөтен тулай торакка таратып өлгерделәр.
Әй таратсыннар ла! Белсәләр ни булган! Кешедән куркып ятарга! Гаеп эш эшләми ич ул. Сөйгән кызының әти-әнисе белән күрешергә бара...
Айзат әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнде. Санарга тотынды. Тәрәзәләрдән кызгылт таң яктылыгы сузылып кергәндә — өченче меңне санаганда гына, ниһаять, йокыга талды...
Иртән институтта кызлар бүген булачак вакыйганы тагын бик дәртләнеп тикшерергә җыенганнар иде, ләкин Айзат аларга:
— Җитәр сезгә! Бер балык башын чәйнәмәгез. Бүтән эшегез булмаса, тун чабуыгызны уа торыгыз,— дип кычкырды.
Кызлар шым булдылар. Хәтта ни батыр Әминә дә авыз ачарга кыймады.
Чәчкә лекция араларында аның янына гел менә торды. Шул билгеләнгән вакытта үзебезнең Воровский тукталышында көтәрмен, соңга калма, диде.
Айзат соңга калырга теләмәде. Билгеләнгән сәгатьтән бик күп алда киенеп-ясанып капкадан чыгып китте. Аны бик күп тәрәзәләрдән кызыксынучан ялтыр күзләр озатып калды.
Ул троллейбустан төшкәндә, Чәчкә витринадан «Социалистик Татарстан» газетасы укып тора иде. Айзатны күргәч куанып:
— Нәкъ минутында. Төгәл дә кеше инде үзең,— диде.
Алар өченче катка күтәрелделәр.
Айзатның йөрәге, имтихан бирергә кергән чаклардагы шикелле, ярсып тибәргә тотынды, чәч төпләре парланды. Ул кинәт тирләгән уч төбен, Чәчкәгә сиздерми генә, чалбарына ышкыды: үзләре кул бирсәләр, күрешергә туры киләчәк. Иллә кирәкмәгән чакларда тирли бу уч төбе!
Чәчкә аның дулкынлануын сизеп елмайды.
— Курыкма, минем әти белән әни кешегә тими.
— Баскычыгыз биек. Әзрәк сулыш алыйм.
Чәчкә бармак селекте.
— И мескен. Шул хәтле каушамасаң.
Янында көтеп торганнар диярсең: звонок төймәсенә кагылуга, ишек ачылып та китте.
— Ә-ә, әйдәгез, рәхим итегез, килеп җиттегезме? Рәхим итегез! Керегез! — диде Чәчкәнең әнисе.
Чәчкә бусагадан атларга кыймыйча таптанып торган егетнең аркасыннан этте.
— Әйдә инде!.. Исәнләшергә онытма,— дип пышылдады.
Айзат әчкә керде һәм тагын туктап:
— Исәнмесез... Ләбибә апа! — диде.
— Исәнмесез! — диде Ләбибә апасы һәм аңа кулын сузды.
Айзат аның йомшак учына үзенең каты учын тигезде.
— Исәнмесез, исәнмесез! — дип кабатлады.
Ләбибә апа бүлмәгә таба борылып:
— Ким, син ишетәсеңме, кунаклар килде бит,— дип дәште.
Эчке бүлмәдән, кулына журнал тотып, өстенә аксыл костюм кигән озын буйлы кеше — Чәчкәнең әтисе килеп чыкты. Айзатка бер генә секунд текәлеп карап торды да журналын телефон өстәленә куеп кулын сузды. Гади генә итеп:

— Исәнмесез! — диде. Аннары.— Әйдәгез, әчкә үтегез,— диде дә, боларның үз артыннан иярүләренә һич шиге юк кеше шикелле, борылып кереп китте.

Айзат бераз аптырый төшеп аякларын салды, җәлт кенә көзгегә күз төшерде һәм, Чәчкә йомшак кына аркасына төрткәч, залга үтте. Ким Риазовичның тавышы ишетелде:

— Кабинетка керегез, минем янга!

Ләбибә апа:

— Сез сөйләшә торыгыз,— дип, бер як ишектән кереп югалды. Чәчкә башта әнисе артыннан иярергә уйласа да, икеләнде. Аннан, Айзат әти белән үзе генә калса бигрәк нык уңайсызланыр дип, аның белән кабинетка үтте.

Ким Риазовичның кабинеты Айзатны гаҗәп-хәйран итте. Аның башка өйләрдә һәр көн күрергә гадәтләнгән — я төрле төстәге майлы буяуларга буялган, я булмаса чәчәкле-чуптарлы обой ябыштырылган стеналары юк иде. Стеналар урынында китаплар иде. Дүрт якка да, түрдәге бердәнбер тәрәзәне һәм ишекне генә калдырып, идәннән түшәмгә кадәр китапханәләрдәге шикелле киштәләр ясалган һәм алар, бармак тыгарлык та урын калдырмыйча, китаплар белән шыплап тутырылган иде.

Ким Риазович, студент егетнең шул китапларга комсызланып каравын күргәч, канәгатьләнеп көлемсерәп куйды. Үзенең нинди байлыкка ия булуын һәм аның беренче күргән кешеләргә ничек тәэсир итүен ул бик яхшы белә иде. Андый чакларда кунакларының йөзләрен күзәтергә ярата, ул йөзләрдә аптырау, соклану билгеләрен күреп горурлык һәм мактануга охшаганрак рәхәт хис кичерүдән үзен тыеп кала алмый иде. Ул, Айзатка китапларын карарга мөмкинлек бирү өчен, сүз-фәлән әйтмичә, язу өстәле янындагы йомшак кәнәфигә утырды.

Кабинетта, китаплардан тыш, тагын әнә шул зур өстәл һәм каракаршы куелган борынгы ике кәнәфи бар иде. Кабинетта китаплар — телсез мөгаллимнәр патшалыгы, фән һәм белем патшалыгы. Эшләгән чакта игътибарны читкә тартучы артык нәрсә юк.

Айзат кәнәфигә утыргач, Ким Риазович өстәл тартмасыннан кыйммәтле сигарет, шырпы һәм зиннәтле көл савыты алды.

— Тартырга теләсәгез, тартынып тормагыз,— диде.— Сезгә, бәлки, папирос, я сигара кирәктер? Алары да бар. Үзем шаярмыйм. Кунактөшем өчен тотам.

— Рәхмәт, мин дә тартмыйм,— диде Айзат.— Дөресрәге, элек суыргаладым, хәзер ташладым.

— Төтене гөлләргә файдалы икән,— диде Чәчкә. Аннан соң, әнигә булышыйм дип, кухняга чыгып китте.

Бүлмәдә ирләр үзләре генә калды. Сүз башлау өчен тәмәке ярап куйды. Ким Риазович җан эретерлек җайлы сүзләр белән генә Айзатның әти-әнисен, туып-үскән иле турында сораштыра башлады. Егет башта каушабрак, әмма торган саен кыюланыбрак җавап бирә барды. Ләкин бу әңгәмә өлкән кешенең яшь кешедән сорау алуы шикелле нәрсәгә ошамады. Ким Риазовичның әңгәмәчел, итәгатьле адәм икәнлеген егет сизеп утырды.

Ул бу сөйләшүнең төбендә нинди максат яшеренгәнлеген, әлбәттә, яхшы белә иде. Чәчкәнең дус егетен күреп, ниндирәк кош икәнен белергә, сынарга телиләр икән — рәхим итсеннәр. Кешенең эче караңгы, үтә күренми. Моның гаебе-кыегы юк. Ләкин үзеңне рухи халәтеңне белергә теләп тикшерүче врач кабинетында шикеллерәк хис итү, һәрхәлдә, әйбәт үк тойгы түгел. Бу — кешеләрнең нервларын бик талкый.

Айзат шундыйрак хис кичерде. Тик ул да күкрәгендә ут кайнаса да борыннан төтен чыгара, сыны катса да сер бирә торган егет түгел иде шул.

Көчле рухлы һәм шактый кыю булганлыктан, шунын өстенә кеше төсле сөйләшә дә белгәнлектән, ул тиз тынычланды. Ким Риазович әкрен-әкрен, җайлап-җайлап кылларын тарткан чакта, үзе дә шыпырт кына аны күзәтеп утырды.

Чәчкәнең әтисе озын буйлы, югарак гәүдәле кеше икән. Төсе-бите матур. Яңаклары чип-чиста. Тешләре тигез, кертичкә шикелле ап-ак. Кие чачларенә чал төшкән. Бу аңа бик килешә. Җитди итеп күрсәтә. Күзләре Чәчкәнеке шикелле төбәп караучан. Уй-хисләрен тышка чыгарып түкми — яшерә белә. Сул кулының исемсез бармагында алтын никах балдагы, беләзегендә алтын чылбырлы юка алтын сәгать. Куллары кипшенә, ахры, ул аларны өстәл астында ара-тирә бер-берсенә ышкып куя.

Аякларында җылы оек белән киез өй башмаклары гына булса да, ул Айзатны кершән шикелле ак нейлон күлмәк, чем-кара галстук, сизелер-сизелмәс вак шакмаклы аксыл костюм киеп каршылады. Кабинетта сөйләшеп утырганда да, хәтта соңыннан кичке аш ашаганда да салмады.

Ярты сәгать чамасы вакыт үткәч, Ләбибә апа кереп:

— Аш өлгерде. Залга рәхим итегез! — диде.

Айзат бая үтеп киткәндә залны рәтләп карый алмаган иде. Хәзер ул аның матурлыгына, байлыгына, җыйнаклыгына һәм чисталыгына кызыгып куйды. Тора белә кешеләр, дип уйлады. Шул чак аның башына икенче юнәлештәрәк бер уй килде: ә ник безгә дә яшәп карамаска шулай? Ярый, без әле хәзергә студент халкы, ди. Кырык җирдән җыелган кырык ата баласы, ди. Арабызда Чәчкә шикелле зур кеше кызлары да, алардан түбәнрәк баскычта торучыларның балалары да бар, ди. Әйтик, аның үзе шикелле: төрле эштә йөрүче гади колхозчы улы. Кыскасы, кырык төрле язмыш ияләре. Ә менә ул, сәнәк-көрәк күтәреп төрле эштә йөрүче гади колхозчы малае, көннәрдән бер көнне болар кебек яши башласа, кем моны гаепкә санар? Киресенчә, а-а, фәлән агайның малае укый-укый зур кеше булган икән, хәзер Казанда яши, фатирына керсәң, борылып чыккысыз ди, әкият төсле ди. Хәер, шулай булмыйча мөмкин дә түгел: монда укыганда ук башлы малай иде, министр башы бар иде ул малайда, дип кызыгыбрак һәм авылларыннан шундый «башлы» малай чыгуына горурланыбрак сөйләсәләр, начар булыр идемени?..

Айзатның кинәт матур һәм мул тормышта, интекми һәм авырлык күрми генә, акча дип аптырамый гына, кешеләр белән талашмый-кычкырышмый гына — кыскасы, борчылмый гына рәхәттә яшисе килеп китте...

Ким Риазович хуҗа буларак түргә утырды. Аңа каршы Ләбибә апа урнашты. Яшьләргә өстәлнең ике яны калды.

Ким Риазович өстәл уртасындагы шешәләргә үрелеп:

— Сез нишдине эчәсез, Айзат иптәш? — дип сорады.

Айзатның мондый «тамак кипкәндә чүмечләп эчә торган әйрәннәр»не генә түгел, аннан кәттәрәкләрен дә күргәләгәне бар иде. Тик беренче танышу минутларында ук боларның өстәл башында (бәлки булачак әбисе, бабасыдыр!) эчеп утыруны килештермәде. Ни әйтсәң дә сынау бит.

— Юк, юк, рәхмәт, Ким Риазович, мин бөтенләй эчмим, эчкәнем юк,— дияргә ашыкты.

Ләбибә апа күзлеге аша көлемсерәп:

— Тартынып тормагыз, аппетит өчен аш алдыннан бераз ярый,— диде.

Ким Риазович хатынының сүзен куәтләде.

— Ләбибә дөрес әйтә. Болар чип-чиста йөзем шәраблары.

— Сез гафу итегез инде, мин алар белән чыннан да дус түгел,— дип, Айзат һаман үгеткә бирешмәде.

Ләбибә апа, аның бу сүзләре белән килешкәндәй, яратып карап куйды. Чәчкә өстәл артыннан аягын сузып Айзатның аягына басты һәм көлемсерәп:

— Ие, әчми ул, әчми. Беркөн туган көндә дә авызына алмады,— дип, Айзатны яклаган булды.

Хуҗа бөкесе ярым ачылган, кәгазь медальләр белән чуарланган бер озын шешәгә үрелде:

— Ә без картларга кайвакыт ярап куя. Мин берне үземә салыйм әле, сез инде гафу итегез!

Ул рюмкага вино салып эчеп җибәрде. Аннан икмәк өстенә ашыкмый гына май һәм кара икра ягып бутерброд ясады...

Беренчегә тәмле кәбестә ашы пешерелгән иде. Айзат аны бик яратып, әмма кунак булсаң, тыйнак бул дигән сүзләрне хәтереннән чыгармаска тырышып ашады. Ләбибә апа икенчегә турамый кыздырылган түгәрәк бәрәңге белән шулпалап пешерелгән Идел чөгәсе китерде. Тәмен авызында озаграк тоеп тору өчен, монысын Айзат ашыкмый гына ашады. Өченчегә паштет, өй печеньесе, җиләк вареньесы, кипкән карлыган лимонады һәм чәй иде. Аш ашка, урыны башка, дисәләр дә, боларына Айзатның көче җитмәде. Кайда һәм кайчан туры килсә — шунда, ни эләксә — шуны ашык-пошык чәйнәп, коры куас, сай чүмеч белән көн күргән студентның бүтән бер йотымлык та урыны калмады. Ләбибә апаның, артык бәйләнмичә, вакыт-вакыт кыстап торуына да карамастан, ул бер стакан хуш исле цейлон чәе генә эчте.

Ашап-эчкәч Ләбибә апа Айзат белән утырды һәм аналарча сак, йомшак тавыш белән аның әти-әнисен, туганнарын сораштыра башлады. Айзат ипле генә җаваплар бирде. Бу хәйләсез әңгәмәдән алар икесе дә канәгать калдылар бугай. Һәрхәлдә, Айзатка шулай тоелды.

Чәчкә, әтисенең үтенүе буенча, ялындырмый гына пианино уйнарга утырды. Башта, кирәкле көен эзләгән шикелле, клавишаларга баскалап торды да ялкынланып «Шәрык биюе»н уйнап җибәрде.

Айзат, дөресен әйткәндә, музыка өлкәсендә, бигрәк тә рус һәм чит илләр музыкасында, кирәк хәтле тирән йөзә торган кешеләрдән түгел иде әле. Дөрес, ул үзе музыка җанлы егет. Музыканы, бигрәк тә симфоник әсәрләрне яратып тыңлый. Ләкин бер композитор белән икенче композитор иҗатын дөрес үк аера алмый иде.

Әгәр аннан иптәшләре:

— Ни өчен яратасың бу көйне? — дип сорасалар:

— Үзем дә белмим,— дип җавап бирә иде.

Менә хәзер дә аның күңеле урыныннан кузгалып, җилкенеп китте. Ул үзен яшәве бик җиңел, сулавы бик җиңел, серле, сихерле дөнья эчендә калгандай хис итте. Чәчкәнең ак һәм кара клавишалар өстеннән күз иярмәс тизлек белән йөгергән озын матур бармакларына карап, мин әле бу һөнәреңне белми идем, бәгырем, рәхмәт гүзәл көең өчен, бәгырем, мине сөюең өчен рәхмәт, бәгырем Чәчкәм, дип куанып утырды.

Чәчкә «Шәрык биюен» тәмамлап икенче көйгә күчте: ягымлы һәм моңлы, мәңге яшь, мәңге үлмәс «Галиябану» яңгырый башлады.

Чәчкә урамга чыгу белән Айзаттан:

— Я, ничек минем әти белән әни? Ошадыלармы? — дип сорады.

Айзат, икеләнеп-микеләнеп тормыйча, чын күңеленнән:

— Бик ошады. Алардан да әйбәт кеше дөньяда юктыр,— диде.

Бераз баргач:

— Алар икесе дә синең кебек әйбәт, икесе дә сиңа охшаган,— дип өстәде.

Чәчкә аның беләген кысып көлеп җибәрде:

— Бәлки мин үзем аларга охшаганмындыр? Шулай дип әйтергә телисеңме?..

Алар Восстание урамына җиттеләр дә «Костер» кино-театры янына килеп бастылар. Кич Һиндстан фильмы «Тузандагы чәчкә»не күрсәтәләр икән. Чәчкә, әллә керәбезме, дигән иде дә, Айзатның мондый матур кичтә бөркү залда утырасы килмәде.

— Минем Чәчкәм үз янымда. Миңа әллә ниткән тузандагы чәчкәләрне эзләп йөрисе юк. Анда урындык аралары бик тар, утыруы кыен,— диде.

Кино-театр каршындагы бакчага керделәр. Айзат сөеклесенең нечкә биленнән кочаклап алды. Бер-берсенә сыенып, бер-берсенең тәненнән бөркелгән җылыга рәхәтләнеп, тын гына утырдылар. Сүзләр кирәкми иде.

Урамнарда халык азаеп, шәһәр гөрелтесе йокыга ойый башлаганда, анда да теләр-теләмәс кенә саубуллаштылар. Икесе ике бинада укыганлыктан, иртәгә лекция араларында очрашу мөмкинлеге юк иде.

— Кичке җидедә үзем «монастырьга» килермен,— диде Чәчкә.— Я киногa, яисә паркка барырбыз.

— Мин сине нәкъ җидедә Кремль тукталышында көтәрмен...— диде Айзат, куанып.

Ул кайтып җиткәндә сигезенче бүлмәнең яртысы караваты буш, яртысында биләмгә чыкмаган хуҗалар йоклый иде. Нариман гына үз урынында аның кайтканын көтеп тәмәке пыскытып ята иде. Ишек ачылуга:

— Я, ничек? — диде.

— Хәзер,— диде Айзат.— Чишеним инде.

Нариман аның янына килде. Алар, ике әзмәвердәй егет, бергә кысылышып яттылар. Айзат дулкынлана-дулкынлана кунак хәлләрен сөйләп бирде.

— Молодец! — диде Нариман.

Уйланып ятты да «Молодец!»ка аңлатма ясады:

— Ни өчен молодец: чөнки алар сине яратып калганнар. Ә кызның әти-әнисенә ошау бик зур эш ул. Хәер, синең шикелле егетне дә ошатмасалар!..

## II

Гаҗәп бу студент халкы! Кырык ата баласы кырыкмаса кырык җирдән бердә-бер көнне институтка килә. Факультетларга аерыла, факультетлар бүлекләргә, бүлекләр группаларга бүленә. Егерме-утыз кешелек группа, атна-ун көн үтүгә, егерме-утыз төрле кайгыны һәм егерме-утыз төрле шатлыкны уртак күтәрүче бер бөтен организмга әйләнә дә китә.

— Берләр — меңнәр өчен, меңнәр — берләр өчен,— дигән әйбәт сүзләр студентлардан да бигрәк, белмим, тагын кемнәргә туры килә икән! Студентның берсе «уф!» дисә, бөтенесе уфылдый башлый. Берсе елмайса, бөтен бүлмә яктыра.

Бүген дә Айзатның шатлыгы группаның күңелен күтәреп җибәрде. Кичәге хәл группа кызларында әйтеп бетергесез кызыксыну уятты. Каршы торса да, үпкәләсә дә, хәтта, ачуланып һәм куркытып караса да — алар Айзатны барыбер җиңде. Ул кичәге «югары даирәләр очрашуы» хакында өстән-өстән генә сөйләп бирергә мәҗбүр булды. Соңыннан йөз сорау. Айзат йөз җавап бирде. Кызлар бу эшкә «каһәгатьләнерлек» билгесе куйдылар.

Лекцияләрдә дә чыш-пыш килеп утырдылар.

Морфологиядән коллоквиумнарны тел фәннәре кандидаты Фатыйха Вәкилевна укыта, һәм анда һәр вакыт зур бәхәсләр куба иде. Группа

икегә, кайчакларда хәтта өчкә бүленеп, теге яки бу кагыйдәдә үз карашын яклый, шау-шу килә, мисал өстенә мисал китерә. Фатыйха Вәкилевна бәхәсләрне бер якка да катнашмый гына тыңлап утыра да иң соңыннан кайсы төркем хаклы булуын әйтә, кагыйдәне ныклап аңлатып бирә.

Бүген бәхәс купмады. Укытучы ни әйтсә, шуңа риза булып ияк кагып тик утырдылар. Фатыйха Вәкилевна Әминәне кинәт тактага чыгарды һәм ымлыклар турында сөйләргә кушты. Билгеле, бу ике көн эчендә Әминәнең башында бөтенләй бүтән төрле уй иде. Ул алай итте, болай итте, хәйләләп карады, ләкин дөрес җавап бирә алмады. Групланың бүгенге хәленнән аптыраган Фатыйха Вәкилевна, аңа карап-карап торды да башын чайкап әйтте:

— Бу инде ымлык булмады, Әминә иптәш, ык-мык булды,— диде.

Алгарак китеп әйтергә кирәк, шуннан соң мескен Әминәгә «ык-мык» дигән кушамат ябышып калды. Ул моннан котыла алмады, хәтта «пычак теле»дә ярдәм итмәде. Ул шуннан соң кара язмышы белән риза-лашты һәм, укытырга киткән җиремдә белмәсләр әле дип, институтны тәмамлау көннәрен түземсезлек белән көтә башлады...

Икенче лекция рус әдәбияты булып, аны Бөек Ватан сугышында авиадесант гаскәрләрендә хезмәт иткән һәм шул еллары турында сөйләргә ярата торган озын буйлы, юаш Николай Викторович укыта иде. Хәйләкәр студент халкы аның бу йомшак ягыннан теләгән чагында, бигрәк тә лекциягә әзерләнеп килмәгән чакларда, бик оста файдалана иде.

Бүген дә шушы методны кулланырга карар бирделәр.

Звонок булды. Ике-өч минуттан Николай Викторович калын портфелен тотып аудиториягә килеп керде, журнал алып лекциядә кемнәр барын тикшерде, кафедрага конспектларын куйды һәм кичәге лекцияне искә төшереп бүгенгесе белән бәйләү өчен «корбан» эзли башлады.

Шунда бөтен күзләр Равиләгә текәлде. Равилә, беренче классның әйбәт укучысы шикелле, кулын күтәрде дә:

— Николай Викторович, бер кечкенә генә сорау бирергә мөмкинме? — дип сорады.

Кешеләргә гомерендә яхшылыктан бүтән нәрсә эшли белмәүче, теләсә нинди ир затын күрсә дә комачтай кызаручы бу басынкы һәм акыллы кыз тарафыннан һич тә явызлык көтмәгән кафедра мөдире, башын күтәрми генә:

— Әйе. Рәхим итегез, сорагыз! — дип куйды.

Равиләнең йөзенә гөнаһсыз сабый кыяфәте чыкты.

— Николай Викторович, бу спартакиадада хатын-кыз парашютчылардан кем җиңәр икән? Безнең Мария Петровамы, әллә югославакларның Смоличларымы? Сезнең фикерегез ничек?

— Безнең Мария парашютын ачмый төшү буенча Смоличтан алгарак чыккан.

— Әйе, әйе. Өч бөтен уннан фәлән очкосы артык икән. Бүген иртән соңгы хәбәрне тыңладым,— дип тагын кайсыларыдыр кызган табага май өстәп җибәрде.

Николай Викторович кәгазьләрен читкәрәк этеп куйды.

— Күрәм: сез парашют спорты белән бик нык кызыксынасыз, ахры? — диде ул, тавышын калтыратмаска тырышып.

— Бик! — дип, хор белән шәрран ярды аудитория.

Николай Викторовичның күзләре учак яктысы төшкәндәй ялтырый башлады.

Хәйләсез укытучы хәйләкәр студентлар корган җәтмәгә кереп капты бит.

Шуннан соң ул лекциянең беренче сәгатен СССРда парашют спортының елдан-ел киңрәк колач ала баруы, аның чын мәгънәсендә кыю

йөрәклеләр спорты булуы, хәзерге спартакиаданың төп бурычлары, аның характеры турында сөйләп үткәрде, тәнәфестә (тәнәфескә бераз дә чыкмады) батыр кызыбыз Петрова Мариянең җинеп чыгу өчен бөтен мөмкинлекләре булуына нигезле дәлилләр китерде. Лекциянең икенче сәгатенә кирәргә звонок булгач, үзенең Бөек Ватан сугышында авиация десанты частьларында хезмәт итүенә күчте. Сталинград сугышларына катнашуын, караңгы төннәрдә иптәшләре белән күп тапкырлар дошман тылына сикерүләрен, безнең һөҗүм итүче төп гаскәрләр килеп җиткәнче стратегик яктан әһәмиятле булган төрле объектларны һәм күперләрне саклап торуларын сөйләде.

Чираттагы лекциягә звонок булып, философ Барашкин ишеккә подаука башын тыккач кына, кинәт аңына килгәндәй, күңеленә бик якын истәлекләреннән аерылырга мәҗбүр булды. Әйберләрен җыеп портфеленә тутырды да, Барашкинга: «Гафу итегез, зинһар!» дип, укучыларына: «Калганын икенче лекциядә сөйләп бетерермен».— дип чыгып китте.

Бүген сөйләнергә тиешле «имажинизм»нар, «футуризм»нар һәм тагын әллә никадәре «изм»нар, телгә килә алмыйча, портфель эчендә кире чыгып китте.

Айзат кош тоткан шикелле көн буе куанып йөрде. «Һе, кызык әле бу, менә, тора торгач бер амин!» дип сөйләнеп куйгалады. Бүген көн буе Чәчкәсен күрмәгән иде, сагынган, саргайган иде. Өзелеп көткәнгә көн озын тоелды. Җитмәсә, сүз гел алар турында булды. Сагынуын шул да көчәйткәндер, дөрләп янган учакка коры утын шикелле булгандыр.

Юк, көрәшергә бару өчен сәгать җиде тулуын көтә алмады Айзат, түземлеге җитмәде. Билгеләнгән вакыттан бик алда Кремль янына чыгып йөгерде. Ленин урамына күтәрелгәч, өметләнеп Кремльнең Спасс манарасына карады. Андагы сәгатьнең алтын теле алтыны гына күрсәтә иде әле. Айзат Муса Җәлил һәйкәле янына килеп басты. Сөекле шагыйрьнең мәрмәргә уеп язылган ялкынлы сүзләрен укыды. Мәрмәр эскәмиядә утырып торды. Музей ягына чыгып, һәйкәлнең алгы ягыннан карады. Муса кыя башындагы бөркет кебек алга ыргылган. Үзен кол итеп тотучы богауларны һәм чәнечкеле тимер чыбыкларны өзәргә теләп, зур көч белән киерелгән. Ул богаулар хәзер менә-менә чалтырап җиргә төшәр кебек, ул чәнечкеле тимер чыбыклар хәзер менә-менә шартлап өзелер кебек. Җәлилнең көчле рухы иреккә чыгар, ул төз һәм киң Ленин урамы буйлап атлап китәр кебек...

Тауларны урыныннан кузгаткан Муса!

Юл башлар аргамак шикелле мәңгелеккә юл башлаган, биектән курыкмаучы бөркет, колачы киң лачын Муса!

Ир егетнең ике юлдашы бар: берсе батырлык, икенчесе тәвәккәллек. Син батыр да, син тәвәккәл дә, ир-егет Муса!..

Кыяга богауланган Прометей — Җәлил! Кешеләргә ут өләшеп һәлак булган татар шагыйре!

Рәхмәт сиңа!..

Айзат аның бөтен «Моабит дәфтәре»н яттан диярлек белә. Чәчкә дә шулай.

Айзат сугышта арсланнан көчле сугышучы, эшләгәндә аттан артык эшли белүче үз халкы белән горурлана. Шул халыкның лаеклы улы булу турында хыяллана, үзен шыпырт кына шуңа әзерли.

Шул ук вакытта егерме ике яшьлек көчле һәм белемле бу егет бик курка да.

Ул — куркак булудан курка.

Куркак белән юлдаш булудан, моңсыз белән моңдаш булудан курка.

Иле алдында бер көн оятка һәм хурлыкка калуыннан курка.

Бик курка.

Ул, Казанның бу урынына килеп басса, һәр вакыт ике төрле тойгы кичерә. Беренчедән, һәр кеше кебек, бу һәйкәл белән ул хаклы рәвештә

горурлана. Ләкин шул ук вакытта, аның күнелендә горурлык тойгыларына кушылып, ниндидер авыр хис кузгала. Ни өченме?

Әгәр хәзер аның каршысында чын Муса абыйсы басып торса, Казан урамнары буйлап көлә-көлә шат күнелле исән-сау, тере шагыйрь йөрсә, бу куанычның да куанычы булыр иде бит!

Бронза сыннарга караганда чын кешеләр кадерле бит!

Җирне һәйкәлләр түгел — җанлы адәмнәр бизи бит!..

Айзат күрсенде. Манарадагы сәгатьләрнең алтын телләренә күз салды да, Кремль стенасы буеннан сузылган таш баскыч буйлап аскы — Бауман урамына төшеп китте. Шундагы троллейбус тукталышында ул Чәчкәне бик озак көтте. Сәгатьләр жиде мәртәбә чыңлатып суктылар, сигезенчене саный башладылар, беренче һәм дүртенче троллейбуслар гөжелдәп килә торды, аларның киң ишекләреннән тезелешеп кешеләр төшә торды, ләкин Чәчкә күренмәде.

Айзат аптыраудан гаҗиз булып, газета витриналары янында таптанды, политик мәгариф йортына кереп, киоскадагы китапларны актаргалады, каршы яктагы чиркәүнең яшел ишекләренә, алтын тәреләренә карап торды, әледән-әле тукталышка барып, борылмадан килеп чыккан троллейбусларны дүрт күз белән көтеп алды, ышанган тауга кар явар дигәндәй, хәзер гөшә, менә хәзер, әнә тегесендә — арттан килгәнендә икән дип өметләнде, тагын берне, юк — өчне генә көтәм дә кайтып китәм дип, белә торып, үз-үзен алдады. Бу өметләре дә акланмагач, хәле китеп, өметсезләнеп Кремль стеналары буена менде һәм эскәмиягә утырды.

Ни булды икән?!.

Чәчкә моңа кадәр һәр вакыт әйткән сүзендә тора иде.

Ул сәгать һәм минутларның кадерен белә, очрашуларга төгәл килә иде. Аның әле моңа хәтле бер генә тапкыр да чакырган җиргә соңга калганы булмады. Кар-боз яуса да, таш яуса да.

Чирләп егылганмы?!. Өйләрендә берәр күңелсезлек килеп чыкканмы?!. Нишләргә?!. Баш эшләми. Бөтенләй буталган... Кара, ике кәҗәсен берьюлы суйган дивана шикелле нишләп утыра соң әле ул монда?!. Барырга, белергә кирәк!.. Минутны да заяга уздырмыйча, жиде тулгач ук чабарга иде.

Айзат урыныннан сикереп торды.

Шул вакытта чыңлатып Кремль курантлары суга башлады. Бер... өч... жиде... ун тапкыр...

Бу чыңнар егетнең чуалчык уйларын тәртипкә китереп, зиһенен ачып җибәрде. Шунда кинәт аның бәгырен телеп, йөрәген өзеп алгандай булдылар. Хәсрәтле уй кинәт яшен утыдай башына бәрде.

Егет аңлады: аның Чәчкәсе сау-сәламәт, авырмаган, кичәге шикелле ук шат, Айзат үзе... үзе сынауны үтә алмаган, кызның әти-әнисенә ошамаган!..

Менә кайда икән хикмәт! Менә кайда икән! Менә кайда!.

Айзат, уфылдап, урынына кире утырды...

## 12

Машина кинәт туктады. Юлаучылар алга сөрлегеп куйды. Шофер кабинасыннан сикереп җиргә төште.

— Перекур,— дип кычкырды һәм йөгереп куак артына кереп китте.

Бүтән машиналар да туктадылар. Алардан да кешеләр төште. Кайберләре төшкән шәпкә урманга кереп китте, кайсылары тәмәке кабызып юл читендә аяк-кул язып йөрена башладылар.

Нурбак сакалын ышкый-ышкый юлдашларына карап утырды да эре ак тешләрен ялтыратып елмайды.

— Безнең шофер нигәдер озакланды, эзләп кайтыйм әле үзен,— диде һәм жиргә сикерде.

Ул китеп бераз торгач, Аучы кузгалды.

— Безнең эзләргә киткән егетебез үзе дә адашты бит әле. Хәзер инде икесен дә миңа табарга калды,— дип, тайга эченә кереп китте.

Көлештеләр дә аның артыннан калганнар да кузгалды...

Соныннан, машинага утырыр алдыннан, Нурбак портфеленнән фотоаппарат алды, ялына-ялына, әллә ничә урынга әллә ничә төрле басты-рып, Тамараны фотога төшерде.

— Бу искиткеч фотогеничный йөз, бу шаккаткыч озын сары толымнар газетаның беренче битенә генә лаек инде болар!..— дип сөйләнде. Тамараның адресын төпченә-төпченә куен дәфтәренә язып куйды, шушы атна эчендә үк карточкаларын җибәрергә кат-кат вәгъдә биреп, антлар итте.

Моны карап көлеп торган ир-ат халкы:

— Безне дә чыртлат инде бер онгайдан әйдә, юл газабын бергә кичерәбез, карточкәгә дә бергә төшик,— дигәннәр иде дә, Нурбак риза булмады:

— Булмый, дуслар. Ни өчен дисәгез, бу аппарат та, аның эчендәге пленкасы да редакциянеке. Ә редакция объектларның бик шәпләрен генә төшерергә куша. Теләсә кемне «чыртлатып» дәүләт милкен әрәмшәрәм итәргә ярамый,— диде һәм фотоаппаратын портфеленә салып куйды.

Янадан кузгалып киттеләр. Кояш килеп чыкты. Юлдагы уелдык-уелдык суларда, машина тәрәзәләрендә аның нурлары чагыла башлады. Юл читендәге канауларда моңа кадәр бик тирән шикелле булып, каракучкылланып торган сулар да кинәт яктырып китте. Төпләрендәге вак балчык һәм таш кисәкләре, чуалып яткан үләннәр, хәтта су өстендә йөзеп йөргән сары яфракларның бәләкәй кара күләгәләренә хәтле күренә башлады. Җылытып җибәрде. Җылыга һәм кояшка куанып агач башларында кошлар чыркылдашырга тотынды.

Агачлар өстеннән көтмәгәндә пырылдап «кукурузник» килеп чыкты. Колонна өстендә әйләнә башлады.

— Безне эзләми микән бу энә карагы? — дип көлеште машинадагылар.

Самолет бу юрауларны ялганга чыгарырга теләгәндәй, читкәрәк күчте. Нәкъ баягыча әйләнергә кереште. Дүртенчеме-бишенчеме әйләнгән чагында кинәт түбәнәйде. Самолеттан ак төргәк аерылып җиргә төшеп китте.

— Вымпел!.. Вымпел ташлады! — дип кычкырды Тамара, ни өчендер шатланып.

— Вымпел түгел бу,— диде Петр Петрович.— Берәр кирәкле әйбердер. Я машина белән килгәнен көтеп торырга мөмкинлек булмагандыр.

— Бәй, монда кеше яшәми иде бит,— дип, сүзгә кушылды Нурбак.— Бик яхшы беләм мин бу урыннарны. Болар — Зур Күлле саз башланган төшләр. Бер җан әсәре дә юк. Үрдәк-каз халкына оҗмах...

— Белмәссең хәзер тайганы,— диде Петр Петрович, канәгать тавыш белән.— Бүген җан әсәре юк, ә иртәгә килсәң һушың китә, үз күзләренә ышанмый торасың: поселок салып куйган булалар. Урман арасын тутырып машина ташып куйган булалар.

— Геологлар килгәндер.

— Әйе, бу урыннарда да нәрсәдер булырга тиеш дигәннәр иде.

— Хәзер «нәрсәдер» булмаган төш юк та бугай инде безнең илдә.

— Үкенмә, җүләр. Сөенергә кирәк.

— Мена кызык! Мине үкенә дип беләсезмени? Нилектән алай уйлыйсыз?

— Үзгәрде тайга-а! Бу соңгы ун елда элекке илле елда күрмәгәннәрен күрде...

Сүз шулай җанлы гына башланып китсә дә, тора-бара сүрелә башлады. Инде төш вакытлары җиткән, һәм машинада селкенеп килү йончыткан иде. Барысының да ашыйсылары-эчәселәре килә. Геологлар һәм казылма байлыклар турында сүзне өзеп, ашханә турында уйлый башладылар. Өметләнеп алга таба карадылар: авыл-мазар күренмиме, янәсе. Авылы булса, ашханәсе булмый калмас. Ашханә очрамаса, кибетсез, һич югында, дом-лавкасыз авыл сирәк инде дөньяда.

Башка килгән алга килә дигәндәй, өметләре буш булмады. Юл кинәт ачык яланга чыкты. Чакрым чамасы кара ләпек ерып баргач, сөзәк үр башланды. Пычрак кимеде. Юл корыды, киңәеп китте. Әз-мәз чуер таш түшәгән урыннары да очрый башлады. Каршы машиналар күбәйде. Шофер, ирекгә чыгуына шатланып, әйбәт кенә җилдереп алып китте. Тагын бераздан юлның ике ягыннан да бәрәңге басулары башлангач, һәм басулар артында авыл өйләре күренгәч, юлчыларның шатлыгы йөзләренә чыкты.

Авылның алар килеп кергән башы бик борынгыга охшый иде. Урамы тар, юлы чокырлы-чакырлы. Чокырларында кара сулар җыелып тора. Аларның берсендә, оҗмахка эләккән изге кебек, рәхәтләнеп, мыркылдый-мыркылдый зур ана чучка ята. Янында, әнкәләреннән мыркылдарга өйрәнеп, аның шикелле ләпеккә баткан егермеме-утызмы кап-кара, бәп-бәләкәй балалары йөгерешә. Өйләрнең күбесе икешәр катлы. Биек баскыч тыштан ук икенче катка менеп киткән. Кайбер өйләрнең аскы кат тәрәзәләре кадакланган, күп коймалар вакыт үтүдән картаеп мүкләнеп беткән. Ныклабрак өрсәң дә мең кисәккә таркалып китәрләр кебек. Гомумән, авылның бу башы, әгәр урам буенча тезелгән электр һәм радио баганаларын чутламаганда, тирә-яктагы яңалыкны тоймыйча яшәгән кебегрәк хис уята.

Ләкин ул, бәхеткә каршы, озакка бармый, икенче якты хис белән алмашына. Унлап электр баганасын узгач, юл уңга борылды, һәм алда тирә-ягына бик матур яшь чыршылар тезеп утырткан клуб күренде. Клуб яныннан өчесе өч якка киткән өч киң урам ачылды. Болары инде төрле яңа корылмалы, шыңгырдап торган нарат я чыршыдан салынган яңа өйле урамнар иде. Монда кеше дә күп, электр, радио чыбыклары да күп һәм, ни өчендер, монда яшәүчеләрнең теге урамдагыларга караганда шатлыклары да күбрәк сыман тоела иде. Капка һәм койма буйларына тигезләп өелгән эре каен әрдәнәләре генә теге оч белән бу очның өзелеп бетмәгән уртаклыгы турында сөйли иде.

Айзат моңа аптырап, нишләп авылның ул башына күчмиләр икән, әллә түбәндәрәк утырганлыктан язгы ташу баса микән, дип уйлап куйды. Шул арада машиналар «Ашханә» каршына килеп туктадылар. Шофер, «Ашханә»нең хуҗасы шикелле, юмартланып:

— Я, төшегез, туганнар, хәл җыегыз, ашап, чәйләп алыгыз,— диде.

— Ә мәйләп алырга ярыймы? — дип сорады Аучы.

— Сезгә — пожалуйста! Без фәкыйрьләрегезгә генә ярамый,— диде шофер...

Күңелләнеп, шаулаша-шаулаша «Ашханәгә» кереп киттеләр. Керделәр дә, ишек төбеннән узмыйча, туктап калдылар. Эчтә кеше бик күп иде. Өстәл тирәләренә, стена буйларына тезелешеп утырганнар. Тәмәке тарталар, шаулашалар, көләләр. «Ашханә» ярминкә шикелле гөрләп тора. Кемнең ни сөйләвен аеруы кыен. Шулай да зал уртасына баскан озын буйлы бер картның тавышы башкаларныкын басып, бөтен залны тутырып яңгырый. Ул бер уч акча тоткан да аны һавада болгый-болгый кызмачарак тавыш белән кычкырыпмы кычкыра:

— Бу ни хәл була инде, кадерле агайлар, ә?.. Мин аларга күпме бәрәңге саттым... Тавык саттым... Кортка пешереп кенә куйган җиде

күмәч саттым... Ярты капчык ярма һәм шулай ук бер кәҗә саттым... Ә кәҗәсе кәҗәгенәме — ут, ут, бәгырем! Кермәгән тишеге, урламаган нәрсәсе юк иде. Сат, диләр бит, сат, бабай җаным, диләр мескеннәр, ялыналар... Ә нигә сатмаска? Сатам: үземнеке... Ә менә хәзер, туганкайларым... күрәсезме... минем бу учымда уч тулы акча инде... Ә беләсезме, күзегезне корт чаккырлары, ник кирәк миңа бу акчалар?! Акчаны ахмак кына ярата. Бер тиенгә дә кирәге юк, беләсезме?.. Аларга бит хәзергесе көндә бер чәкүшкә аракы да алып булмый, рәхәтләнеп сыра да эчеп булмый, чөнки авылда юк ул нәстәләр, беләсезме шуны?!. И-их, әйтте миңа карчык түтәгез, әйтте, сатма, диде... И-их!..

Зал эче катып көлә, бабайга дәрт биреп котыртып тора:

— Баз нигезенә күмгән спиртың күптер әле...

— «Үзем куган»га өйрәнгән ул...

— Кирәкмәсә, акчаларыңны миңа бир, бабакаем? Менә минем кесәдә үлгән черкидән башка нәрсә юк.

— Синең сатар кәҗәң юк, шуңа күрә ул...

— Кайт та акчаңны карчыгыңа бир, бабай, үзеңне кочаклап кына ятар...

— Болай да кочакларга тиеш ул, законы шундый,— дип, карт моңа каршы төшә.

Шунда ишек төбендәрәк утырган бер егет:

— Бабай, нигә аптырадың? Синең кәҗәңне алганнар бит. Шулай булгач, син дә, кайт та күршеңнең кәҗәсен сатып ал. Кәҗәсе бармы күршеңнең? — ди.

— Бар, бар,— дип кычкыра бабай, шатланып.— Бар, юлбасар. Безнең лапас түбәсеннән төшкәне юк. Мин инде аның бик күптәннән арт чәкәнен сугып сындырырга йөрим. Кортка гына әрли, күршеләр белән талашлы булмыйк, ди, штраф салырлар, гомер буена түләп бетерә алмабыз, ди. Бар, юлбасар, бар кәҗәләре.

— Алай булгач, син аның арт чәкәненә сугып маташма инде,— дип, теге егет бик җитди төс белән тагын киңәш бирә.— Кайт та сатып ал син аны. Алу белән рәхәтләнеп суй да аша. Акчаңа да урын табылыр, карак кәҗәдән дә җаның тынар, нерваң тынычланыр, тамагың туяр — берьюлы никадәр файда!..

Карт уйга кала. Теге юньсез кәҗәне сатып аласы бик килә бабаның. Суеп ашап күңелен тынычландырасы килә. Аның кыяфәте үк шуны әйтеп тора. Ләкин әзрәк шикләнә дә карт. Әле егеткә, әле акчасына карый.

— Кәҗәсен сатар микән соң ул юлбасар? — дип сорый.

— Ник сатмасын, сата. Син саткансың бит,— ди егет аны тынычландырып.— Син аңа кәҗәнең торыр бәясеннән чүт кенә артыграк бир.

— Улыкаем! — дип кычкыра карт, куанып.— Кая, изге сүз чыккан авызыңнан бер үбим әле! — һәм егетне кочаклап үбәргә килә. Егет чыгып кача. «Ашханә» эче гөрләп тора.

Бабай көлүләргә әһәмият бирми, егетнең чыгып качуына да исе китми. Уйлап-уйлап тора да акчасын бүреге эченә салып, бүреген басып кия.

— Ие шул. Ник миңа, карт тилегә чәкүшкә!.. Яшь вакытта эчкәннәр җитмәгәнмени!.. Менә хәзер барам да, күршенең юлбасар кәҗәсен сатып алам да карчык белән рәхәтләнеп кәҗә ите ашарбыз,— дип сөйләнә-сөйләнә күршесенең кәҗәсен алырга китә...

Залдагылар шунда гына яңа кергәннәргә игътибар иттеләр. Керүчеләр дә, үз чиратларында, өстәлләрнең буп-буш, буфет һәм кухня тәрәзәләренең капланган икәнлеген хәзер генә шәйләп алдылар. Сорашулардан, сөйләшүләрдән соң хәл ачыкланды. Ләкин ул хәл безнең ачыккан юлчылар файдасына түгел иде.

Эш менә нидән гыйбарәт икән. Моннан илле километрда, саз аша керүе бик кыен булган ешкынлыкта, урман кисүчеләр яши икән. Янгыр коеп торганлыктан, соңгы ярты айда анда машиналар керә алмаган. Тегеләрнең ашарларына бөтенләй беткән. Ачыга башлаганнар. Чыдар әмәлләре калмагач, жыелышып бу авылга чыкканнар. Өч көн буе ашаганнар, эчкәннәр, мунча кергәннәр, кер юганнар. «Ашханә»дәге бар ризыкны, складындагы бар запасны бетергәннәр.

«Һе, кызык әле бу, тора торгач бер амин! — дип уйлады Айзат.— Бөтен авылларын ашап чыкмаганнардыр инде? Алай итәргә ничә кеше кирәк? Гаскәр!»

Бүтәннәрнең дә башларында шундыйрак уй бөтерелә иде, ахрысы. Петр Петрович алга чыкты. Үзенә якынрак торган күн бишмәтле таза кешедән:

— Әйтегез әле, дускай, аңлатып бирегез әле. Бу ничек була инде? «Ашханә»дә ни бар бөтенесен ашап бетереп киттеләрмени? Запаслары бары өч көнгә генә життемени? — дип сорады.

Теге кеше ничектер көлебрәк жавап бирергә дип авызын ачкан иде дә, каршысында торган адәмнең арган күзләрен һәм житди чыраен күргәч, уеннан кире кайтты, гафу үтенгән тавыш белән рәтләп жавап бирде:

— «Ашханә»нең әлегә хәтле запас продуктасыз торганы юк иде. Ләкин тегеләр дә әз түгел бит — ике йөз кеше. Һәммәсе таза ир. Ашап кына бетерделәр дип әйтмәдек, минемчә. Алып та киттеләр.

— Ә-ә, ул чакта аңлашыла,— диде Петр Петрович, калын тавышы белән.— Анысы яраган. Тик кутәреп кенә киткән азыклары тагын күпкә бармас ич аларның?

— Борчылмагыз. Аларга үзәктән автоколонна чыкты инде. Ризык төягән егерме машина.

— Бәлки күргәнсездер? Яңа гына монда иделәр. Хәзер киттеләр.

— Ә-ә-ә, шулар идемени ул? — диде Айзатлар шоферы сүзгә кушылып.— Бик авыр килгәннәр. Жиде урында батып ятканнар. Кичә иртүк чыккан килеш.

— Очраттыгызмыни?

— Юл сөйләде.

— «Ашханә» булмады бу — «Ачханә» булды. Киттек алга,— диде Аучы.

Шоферлар тәмәке тарттылар да машиналары янына таралдылар.

— Инде күп калмады. Бахта авылына уналты чакрым. Сәгать ярымнан барып житәрбез,— диде Айзатлар шоферы.

— Анда ашханә шә-әп! — дип, Аучы иреннәрен чәпелдәтеп куйды.

— Минем соңгы тукталыш,— диде Нурбак.

Тамара егеткә күз керфекләрен сирпеп карады.

— Сез төшәсез дә мени инде? Районда түгелмени?

— Бахта — минем туган авылым. Шунда этиләр-әниләр яши. Бүген өйдә куныл, редакциягә иртәгә барам.

— «Зәңгәр бака» ни әйтер? — диде Петр Петрович.

— Әйе-е, ул нәстәкәй бар әле, жанны алмаса ярар иде.

— Ни соң ул «зәңгәр бака»? — дип сорады Тамара.

Нурбак аңлатып бирде:

— Сазлык. Ун тамчы янгыр яудымы — чыгармын димә.

— Ә ник күпер-фәлән салмыйлар? Бирәр нәрсә түшәмиләр? — дип, Айзат сүзгә кушылды.

Нурбак, Айзатка гади нәрсәне дә аңламаган бәләкәй балага караган шикелле өстәнрәк карап (Айзатка, һәр хәлдә, шулай тоелды, һәм ул ник сораганына үкенеп кызарды):

— Суыра,— диде,— күпер салып булмый. Төпкә бата тора. Чынлан да, ул кабахәт ни күрсәтер? Көн әйбәт шикелле дә соң!..

Юраулары юш килде. Каһәр суккан «Зәңгәр бака» сазлыгы күрмәгәнне күрсәтте. Урман бетеп, ике яктан да биек саз камышлары үскән юлдан кырык-илле адым китеп өлгермәделәр, Айзатлар машинасы ләпекле кара суга арт тәгәрмәчләре белән кереп тә утырды. Шоферлар жыелды, юлчылар төште. Шофер халкы, юлга чыкканнан бирле инде ничәнче мәртәбә, үзенең «тозлы» киңәш-табышына кереште.

Киңәш беткәч, эшкә күчтеләр. Икенче машинага тимер чыбык аркан тагып Айзатларныкын артка тарттырмакчы булдылар. Тартучы машина, әйдә әз генә кузгал инде, күрәсеңме, синең өчен ничек тырышам дигәндәй, кара төтеннәр атып озак үкерсә дә, иптәшен бәладән коткара алмады, аны ләпектән куптарырга, каты юлга чыгарырга куәте житмәде.

Икенче машинага өченчесе ялганды. Икәүләп беренчене тарта башладылар. Беренче үз хәленнән үзе дә ояла иде бугай, моторын үкертә-үкертә ул да тырышты.

Моннан да рәт чыкмады. Арткы тәгәрмәчләр кайнар пар һәм пычрак балчык атып әйләнә торгач, тирәнрәк кенә төште. Беренченең моторы, моны күрде дә, куркуыннан телдән язды.

Ахырында, тартучы ике машинаның көчен арттырырга, өченче машинаны ялгарга, дигән нәтижәгә килделәр.

Инде берьюлы дүрт машина үкерә башлады. Һавага төтен һәм биялә-биялә балчык кисәкләре очты.

Баткан машина кузгалам, менә кузгалам дигәндә, шартлап аркан өзелде һәм юл читендәге камышларны кыеп ташлады.

Дүрт кабинаның да ишекләре ачылды, дүрт шофер йодрык яный-яный акырды:

— Үләсегез киләмени,... иткән нәрсәләр?!. Нәрсә авызыгызны ачып торасыз!? Башыгызны өзеп алып китүен көтәсезмени! Китегез машина яныннан!..

Юлчылар ашыга-ашыга читкә тайпылды. Чөнки шоферлар хаклы иде. Машиналар тартылганда өзелгән трос очы бик хәтәр нәрсә. Аның күзе юк, эләксә — беттең...

Ниһаять, шактый озак азапланганнан соң, байтак бензин исраф иткәч, машинаны арурак урынга өстерәп чыгардылар...

*Дәвамы бар*

**Рафаэль Мостафин**

# МИНЕМ ГОРУРЛЫГЫМ

Эшем алга бармаганда, язарга теләгән әйберемне яза алмый азапланганда, үземнең хаклымы-түгелме икәнлегемә шикләнгән минутларда китап киштәсеннән мин Ленин томын алам, алдан сайлап-нитеп тормыйча, аның теләсә кайсы битен ачам һәм анда һәрвакыт Ленинның чиста, шифалы чишмәне хәтерләткән фикерен укып, уйга калам. Юк, аның томнарыннан мин барлык сорауларыма да җавап табуны үземә бурыч итеп куймыйм, һәм бу мөмкин дә түгел. Барыннан да элек, Ленинның корыч пружина кебек тыгыз һәм зур потенциаль көчкә ия булган логикасы, аның һәр нәрсәгә карата булган ачык карашы, нигезле ышанычы миңа әйтеп бетергесез көч бирә, һәркөн туып тора торган проблемалар һәм сорауларга дөрес җавап табарга ярдәм итә, төрле уйларга, яңа фикерләргә этәрә.

Минә Владимир Ильич Ленинның күләме ягыннан артык зур булмаган, әмма киң таралган «Великоруссларның милли горурлыгы турында»[1] дигән хезмәте. Илебездә аны белмәгән яки аның турында ишетмәгән кеше юктыр. Бу әсәр белән мин студентлык елларыннан башлап, ким дигәндә унлап тапкыр танышып чыкканмындыр. Ләкин аны кабат укыганда Ленин фикерләренең көченә, тирәнлегенә яңадан бер тапкыр хәйран каласың, моңарчы кагылмый үткән яңадан-яңа нюанслар ачасың.

Белмим, шушы бөек фикерләргә карата булган эчке хисләремне, кичерешләремне сүзләр белән аңлатып бирә алырмынмы икән... Ленин фикеренең көче, югарыда әйткәнемчә, нәкъ әнә шул тимердәй нык логикага ия булуында, әйткән сүзен раслау һәм исбатлау өчен кулланылган бәхәссез дәлилләренең ышандыргыч һәм эзлекле булуында. Монда һәрбер абзац, һәрбер җөмлә һәм сүз, бер-берләренә үзара нык бәйләнештә булганнары хәлдә, кире кагылмаслык һәм көтелмәгән нәтиҗәләр өчен хезмәт итә.

«Миллилек турында, Ватан турында хәзер ничек күп сөйлиләр, сөйләнәләр, кычкыралар!» — Ленинның мәкаләсе менә шушы җөмлә белән башланып китә. Ул 1914 елның 12 декабрендә, беренче бөтендөнья сугышының иң кызган көннәрендә, шовинистик һәм милли хисләр сереме соңгы чиккә җитеп куерган вакытта басыла. Бу җөмләдә, беренчедән, ачы мыскыллау яңгырый, чөнки әлеге сүзләрне кычкыручылар «Англиянең либераль һәм радикаль министрлары», «Франциянең чиксез күп «алдынгы» публицистлары», «Россиянең иксез-чиксез күп казенный, кадет һәм прогрессист язучылары». Икенчедән, шушы ук фразада йөрәк тетрәткеч әрнү ишетелә. Чөнки сүз — эчтәлеге кара эчле, мәкерле кешеләр кулы белән пычратылган, ләкин һәрбер чын гражданинның йөрәгенә якын булган нәрсәләр турында бара. һәм Ленин үзенең нибары өч-дүрт битлек мәкаләсендә, кәгазь буяучы әлеге этләр өере-

---

[1] В. И. Ленин. Великоруссларның милли горурлыгы турында. Татар телендә. Казан. 1950 ел. 8 бит. Барлык цитаталар шушы басма буенча китерелә.

нен ялганын, сатлык җан булуларын фаш итеп, мәсьәләне икенче ягы белән куя, аның тирән һәм чын мәгънәсен ача.

«Милли мәсьәләнең гаять зур әһәмияткә ия булуы» турында искәртеп, «бигрәк тә «халыклар төрмәсе» дип атала торган бер илдә, нәкъ менә Европаның ерак Көнчыгышында һәм Азиядә күп кенә «яңа», зур һәм кечкенә милләтләрне тормышка һәм аңга уяткан бер вакытта», В. И. Ленин барлык бу милли лозунглар артында «дворяннар һәм Гучковлар, Крестовниковлар, Долгоруковлар, Кутлерлар, Родичевлар» интересы яшеренгәнлеген кыска һәм ышандырырлык итеп исбатлый. Ләкин бу әле милли горурлык тойгысыннан бөтенләйгә ваз кичәргә кирәк дигән сүз түгел.

Ленинның: «Безгә, великоруссларның аңлы пролетарийларына, милли горурлык тойгысы чит нәрсәме соң? Әлбәттә, юк! Без үз телебезне һәм үз Ватаныбызны яратабыз»,— дигән сүзләре шулкадәр таныш ки, монда аны тулысынча китереп торуның бернинди дә хаҗәте юк. Бу сүзләр, мәсәлән, минем үземне менә нәрсә турында тагын бер тапкыр уйланырга мәҗбүр итте: милли горурлык белән янәшә милли мактанчыклык дигән нәрсә дә бар, үзенең халкына, туган теленә карата тирән мәхәббәт белән бергә милли эгоизм тойгысы да яши.

Күптән түгел минем кулга кызыклы бер китапчык килеп керде. Ул эчтәлеге янсә әдәби эшләнешенең камил булуы ягыннан түгел, ә авторның фикер йөртүе ягыннан кызыклы. Бу шигырьләр җыентыгы безгә таныш булмаган ниндидер татар шагыйре тарафыннан язылган һәм Мюнхенда татар телендә басылып чыккан. Аның авторы — Ватан сугышы елларында иленә хыянәт иткән бер сатлык җан. Ул үзенең таушалып беткән идеяләр белән сугарылган шигырьләрендә татарлар күңелендә төрле милли тойгылар уятмакчы була. Ул Чыңгыз хан җир йөзендә тиңдәше булмаган бөек дәүләт төзегән, кан агызып, «дошман илен — рус илен» яулап алган вакытларны сагынып искә ала. Аныңча, татар дөньясының алтын чоры нәкъ әнә шул вакытларда — «каһарман татарлардан бөтен дөнья куркып торганда», «Азияне генә түгел, ярты Европаны безнең бабаларыбыз яулап алганда» булган.

Ике халык арасында булган олы дуслыкны бозарга теләп, ул «заманның көчле иле булган Алтын Урда дәүләте чәчәк атканы», «Мәскәү иле Казан каршысында башын түбән иеп торган» вакытларны сагына.

Әмма шагыйрьнең «татарлыгы» ташка үлчим. Гитлер Германиясе тар-мар ителеп, Татарстанга кайчан да булса җиңүче булып кайтырына өмете киселгәч, беркемгә дә кирәге калмаганлыгын сизеп, әлеге сатлык җан «изге Төркиягә»

●

...Ул сыйнфый көрәшне ала, моның пролетариат диктатурасына китереп чыгарачагын күрә, капитализмнан социализмга күчү шуның аркылы гына булуына ышана, шул юлда пролетариатны өйрәтә, буржуазиягә каршы ут ача.

...Шуның белән бергә ул бик талантлы мөхәррир дә, аның теле үткен, каләме ут чәчә.

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ. Ленинның әдәби хезмәтләре. «Эшче» газетасы. 1920 ел. 22 апрель.

●

Безнең телләр
«Корьән» сүзе түгел,
Ленин сүзе белән ачылды.
Безнең күзләр башлап аны күрде,
Аңа тартты йөрәк ярсуы.

Бик яшь кее аннан
Ятим калып,
Үткәрсәк тә көнне Ленинсыз,
Мәңге үлмәс безнең исемебез бар:
Без — көрәшче,
Эшче, Ленинчы!!!

МУСА ҖӘЛИЛ.
1930

●

Иптәш Ленин XI партия съездында ачык итеп: «Укырга!» дигән шигарьне ташлады. Менә без коммунистлар бу шигарьне яхшы аңлап, алдагы көннәрдә шуның буенча эш күрергә һәм бу сүзләрне үзебез өчен барачак юлыбызда маяк итеп тотарга тиешбез.

ШАҺИТ ӘХМӘДИЕВ. Коммунистлар байлыгы. «Безнең юл» журналы. 1922 ел. 1 сан.

баш ора, аңа сәҗдә кыла башлый: «...анда иминлек, анда гаделлек, бүгенге көндә анда дөнья оҗмахы...»

Узган елның җәендә, «Муса Җәлил» теплоходында йөзгән чакта, Төркия яры буйларында тукталып торганда, миңа төрекләр белән очрашып сөйләшергә туры килгән иде. Алар миңа үз тормышларының авыр булуы, балаларын укыта алмаулары, медицина ярдәме акча җитмәслек дәрәҗәдә кыйммәт булуы турында зарланып сөйләделәр. Бу хакта Төркиянең үзенең алдынгы язучылары да бик күп яздылар. Кая соң ул алай булгач эмигрант шагыйрь әйткән «дөнья оҗмахы?!»

Кайда гына син торсаң да
Истамбулга юнәлт йөзеңне.
Сөй син аны туган анаң кебек,
Сакла аны кызганмыйча үзеңне,—

дип яза ул. Бу юллардан безгә инде күптән таныш булган пантюркизмлык исе аңкый.

Аның шигырьләрен укып чыккач, шагыйрь Сибгат Хәким болай диде: «Мәнә кеше ничек түбән төшә! Шигырьләрендә безгә каршы куярлык бер генә дә төпле фикер, төпле дәлил юк. Ул шигырьләр бик примитив, формалары ягыннан да алар тиешенчә эшләнмәгәннәр. Шуннан мәнә мондый бер фикер туа: иленә, халкына турылыклы Муса Җәлилләр кая күтәрелгән дә, Ватанын саткан хыянәтче шагыйрь кая тәгәрәгән! Гомумән, талантлы шагыйрьләр элек-электән үз халкы белән бергә булганнар, прогрессив идеяләрне яклаганнар. Кыскасы, талантлы шагыйрь булса, ул анда да калмаган булыр иде».

Эмигрант-шагыйрь алга сөргән идеяләр, андый «милли горурлык» күңелдә әчке бер протест һәм җирәнү тойгысы гына уята. Юк, безнең милләт кан коюлары, сугышлары, талау һәм үтерүләре белән түгел, ә бәлки В. И. Ленин сүзләре белән әйткәндә, «азатлык һәм социализм өчен көрәшнең бөек үрнәкләрен бирергә дә сәләтле икәнлегене» күрсәтүе белән горурлана.

Мин В. И. Ленинның рус милләте турында әйткән бу сүзләрен зур канәгатьләнү белән күчереп үтәм: чөнки, минем карашымча, ул сүзләрне бүген безнең татар халкына һәм шулай ук бүтән халыкларга карата авыз тутырып әйтергә мөмкин. Бу хакта язганда мин беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев һәм йөрәге патша чынбарлыгының тимер читлеге эчендә типкән зирәк Тукайны, Ленинның якын көрәштәше Мулланур Вахитов һәм Гитлер гильотинасы астына башын куяр сәгате җиткәндә дә Германиягә Маркс һәм Гейнене кайтарырга хыялланган үлемсез Җәлилне искә алам.

Бик кызыклы бер вакыйга искә төшә. Моннан берничә ел элек немец язучысы, публицисты, Германия Демократик Республикасының күренекле җәмәгать эшлеклесе Леон Небенцаль Казанга килгәч, ифрат кызыклы бер детальгә игътибар иткән иде. Моабит шигырьләренең берсендә Җәлил болай дип яза:

Борыгыз муенын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман иленә.

Татар шагыйре үтерелүгә һәм гитлеризм тар-мар ителүгә берничә ел үткәч, немец шагыйре Иоганес Бехер Германия Демократик Республикасының яңа гимнын язганда Җәлил фикерен үзенчә кабатлый:

Беркайчан да янмаганча янсын кояш
Яңа Германия өстендә.

Иоганес Бехер Җәлил шигырен, әлбәттә, белмәгән. Ләкин шунысы характерлы, татар һәм немец шагыйрьләренең фикерләре бер үк максатка юнәлтелгән, алар бер үк нәрсә турында хыялланалар.

Менә, минемчә, милли үзенчәлекләрне кире какмаган һәм аңа каршы килмәгән чын интернационализмның искиткеч матур үрнәге!

Үзенең илен күптән югалткан өлеге кәгазь буяучы (аны шагыйрь дияргә минем телем бармый, чөнки үзенең иҗатында ул кызганыч бер эпигон гына) «татарларның колы — рус князьләре аларның идәненә башларын орган» вакытларны искә алып, татар һәм рус халыклары арасына чөй кагарга маташа. Минем аңа безнең иң өлкән һәм талантлы шагыйребез Хәсән Туфанның уртак Ватаныбыз-Россиягә мөрәҗәгать итеп язган һәм искиткеч җылы, гаять бай лирик хисләргә ия булган түбәндәге шигъри юллары белән җавап бирәсем килә:

**Тугры улың хәлдә, Русиям,**
**Кичтем барлык авыр елларны.**
**Бу — Тукаең биргән васыять,**
**Юлларымны минем нурлады.**
**Азмы синнән җылылар алдым,**
**Салкыннарга тарыган чагымда.**
**Әнкәм бардыр, кояш бардыр күк**
**Синең изге, җылы янында.**
**Иңнәремдә азмы, Русиям,**
**Җылысын тойдым изге куяныңның.**
**Йөз кат, мең кат бурычлы сиңа**
**Минем бүген исән булуым.**

Шагыйрь Сибгат Хәким үзенең күптән түгел басылган «Дуга» поэмасында, безнең кешеләребезнең узган сугышта күрсәткән тиңдәшсез батырлыкларының сәбәпләре турында уйланып, шулай ук үз халкының мең еллык тарихына мөрәҗәгать итә. Ләкин аның бу мөрәҗәгать итүе «Чыңгыз һәм Батый каныи» эзләү өчен, миллилекнең әерым сызыкларын күпертеп юри алгы планга куеп күрсәтү өчен түгел, ә хезмәт халкының үлемсезлеген һәм аның рухи көчен аңлау өчен кирәк. Алгы сызыкка аш китерүче ике солдат белән бергә, өстенә миндидер ят киемнәр кигән чал чәчле таныш түгел бер кешенең — тәз, мәһабәт, горур сынлы, XIII гасыр башында иҗат иткән шагыйрь Кол Галинең килүен тасвирлаган күренеш — поэманың иң уңышлы эшләнгән урыны, минемчә. Поэмага бу образның килеп керүе сугыш елларында рус шагыйрьләренең үзләренең борынгы бабалары — Александр Невский, Суворов һәм Кутузов образларына мөрәҗәгать итүләре шикелле үк табигый. Бу картның сүзләре гади, ләкин ышандырырлык булып яңгырый:

**Шигырьләрем карады ул тыңлап,**
**Безнең тарих — сезнең кулда,— ди.**
**Улларының батырлыгын таңда**
**Тикшерергә чыккан Кол Гали.**

Шагыйрь Сибгат Хәкимгә шулай ук милли горурлык хас. Ләкин бу горурлык эмигрант-шагыйрьнекенә капма-каршы.

Без Ленинның тормышы һәм революцион эшчәнлеге Татарстан белән, Казан белән тыгыз бәйләнгән булуына горурланабыз. Әле Казан университетына укырга кергәнче үк яшь Володя әнисе белән берничә тапкыр Казанда була. Ул ялгызы гына тар һәм кәкре-бөкре булып сузылган тузанлы урамнар буйлап йөрергә ярата, Кремль биеклегеннән карап, үзенчәлекле ярым Азия, ярым Европа стилендә төзелгән шәһәрне, аның чиркәү һәм мәчет манараларын, йокымсырап узган извозчикларын, Болак буйларын, кояшның соңгы нурларында тонык кына җемелдәп аккан аз сулы Казанканы күзәтә. Нәкъ менә шушында, Казанда Ленин беренче революцион чыныгу ала, беренче тапкыр шушында кулга алына һәм сөргенгә җибәрелә.

Ә утыз елдан соң Татарстан республикасын төзү мәсьәләсен хәл итү өчен Мәскәүгә, Ленин янына Казан губернасы работниклары делегациясе килә.

Без Совет власте елларында республикабызда булып узган зур үзгәрешләрне күреп, горурлык хисе кичерәбез. Менә ул үзгәрешләрне чагылдырган меңнәрчә фактларның берничәсе.

Революциягә кадәр Казан губернасы русча укый-яза белмәүчеләрнең саны ягыннан Россиянең Европа өлешендәге илле губерна арасында кырык дүртенче, промышленностьның үсеше һәм сәламәтлек саклауның торышы ягыннан иң соңгы урыннарның берсендә тора. Ул бары тик бер генә күрсәткеч — ачлык елларында халыкның кырылуы буенча гына беренче урынны били.

Ә хәзер Татарстан автономияле республикасы югары һәм гомуми белем бирүнең үсеш дәрәҗәсе, әерым алганда, һәр мең кешегә туры килә торган студентлар саны буенча Көнбатыш Европаның Англия, Франция, Швейцария кебек дәүләтләрен узып китте.

1913 елда Казан губернасында киң халык массалары файдалана торган бердәнбер китапханә булып, аннан да татарларга файдаланырга рөхсәт ителмәгән. Алар бу китапханәнең бары тик филиалына гына йөри алганнар. Ә хәзер республикада ике мең-

нән артык китапханә бар. һәм аларның ишекләре барлык милләт кешеләре өчен дә ачык.

Кайчандыр патша наместнигы резиденциясе булып саналган Казан Кремле капкасында татарларга анда керергә рөхсәт ителми, дигән белдерү эленеп торган. Ә хәзер биредә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы урнашкан. Нәкъ менә ленинчыл милли политика безнең илебездә социаль һәм милли чикләүләрне бетерде, милли культураларның чәчәк атуы өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр тудырды.

Барлык бу уңышлар һәм үзгәрешләр бездә горурлык хисе, совет горурлыгы, үзенең социалистик милләтенең үсеше өчен горурлык хисе уятмый калмый. Шагыйрь Сибгат Хәкимнең республикабызда киң таралган «Бер горурлык хисе» дигән шигыре нәкъ шул темага багышланган. Шагыйрь туган иле — Татарстаны турында болай дип яза:

> Керосины да юк, көндезен ул
> Телеп куя иде чырасын.
> Кем юрады икән нефть тәяп
> Океаннарга аның чыгасын...

Шагыйрь корабларга төялгән индустриаль йөкнең Бишбалтадан ерактагы Һиндстан портларына озатылуын, азат Татарстанның кара тәнле великан — уянган Африка халыкларына туганнарча ярдәм кулын сузуын күреп горурлана. Үз халкы, яңа, иркенле тормыш белән яшәүче татар халкы исеменнән ул дөньядагы барлык парламентларда чыгыш ясарга әзер.

Миңа Сибгат Хәкимнең бу тойгылары якын һәм таныш. «Муса Җәлил» теплоходында Азия илләре буйлап сәяхәт кылып йөргәндә кайда гына тукталсак та — һәр җирдә милли проблемалар турында сүз чыгу белән, безгә бер үк традицион сорауны бирәләр иде: — Ә сездә ничек?

Мин шуңа ышандым: Азия илләренең һәркайсында милли хисләрнең, милли тойгыларның торган саен ныграк уяна баруы, азатлык һәм бәйсезлеккә көчлерәк омтылу, үз милләтенең культурасын һәр яклап үстерергә тырышуы күзгә ташлана. Тагын бер нәрсә: Азиянең изелгән халыклары үзләренең көрәшләрендә безнең Советлар Союзы тәҗрибәсенә таяналар, безнең илдә милли мәсьәләнең ничегрәк хәл ителүен зур игътибар белән күзәтәләр. Менә боларның барысы да безгә бу мәсьәләдә аеруча сизгер булу, милли политиканың ленинчыл принципларыннан аз гына читкә тайпылуның да тамырын үз вакытында кисү бурычын йөклиләр.

Үз милләтеңне ихлас күңелдән сөю үз илеңдә, үз халкыңда хәзерге көндә һәм узганда булган барлык нәрсәләрне, сайлап-нитеп тормыйча, күккә чөюдән гыйбарәт түгел. Бу мәхәббәт кайбер нәрсәләргә тәнкыйть күзлегеннән карауны һәм кирәк икән, аерым очракларда аларны кире кагуны да үз эченә ала. Н. Г. Чернышевскийның: «Кызганыч милләт, коллар милләте, югарыдан түбәнгәчә — барысы да коллар...» дигән сүзләрен В. И. Ленин: «...великорусс халкы массаларында революционлыкның юклыгы сәбәпле пошынып әйтелгән сөю сүзләре иде» дип бәяли. Рус халкының рухын бары тик самоварларда, сарафаннарда, чабата һәм иконаларда, ә татар халкының милли үзенчәлеген комганнар, чапан һәм түбәтәйләрдә генә күргән кеше никадәр ялгыша!

«Бездә милли горурлык хисе бик зур һәм нәкъ менә шуның өчен дә без үзебезнең колларча булган үткән заманыбызны (Венгрия, Польша, Иран, Кытайның азатлыгын буар өчен, алпавытлар, дворяннар мужикларны сугышка куган чакны) һәм колларча булган хәзерге заманыбызны — капиталистлар ярдәме белән шул ук алпавытлар, Польшаны һәм Украинаны буар өчен, Ирандагы һәм Кытайдагы демократик хәрәкәтне басар өчен, безнең великорусс милләтенең дәрәҗәсен хурлыкка төшерүче Романовлар, Бобринскийлар, Пуришкевичлар шайкасын көчәйтү өчен безне сугышка алып барган хәзерге заманыбызны аеруча дошман күрәбез. Үзенең кол булып тууына беркем дә гаепле түгел; ләкин үзенең азатлыгына омтылмау гына түгел, бәлки үзенең коллыгын саклаучы һәм бизәкләп күрсәтүче (мәсәлән, Польшаны, Украинаны һ. б. ны бууны великоруссляр «ватанын саклау» дип атаучы) кол законлы рәвештә ачу, нәфрәт һәм җирәну хисе тудыручы холуй һәм хам ул».

Нинди көчле һәм нинди игелекле сүзләр, һәр җөмләдә күпме энергия һәм аяусыз кыюлык! Ә бит бу юллар власть башында «Романовлар шайкасы» утырганда, шовинизм һәм милләтчелек агуын чәчү юнәлешендә алып барыла торган пропаганда өчен ел саен дистә миллионнарча сум акча тотылган чорда язылган! Һәм Ленин идарә итүче даирәләрнең күпчелеге фикеренә каршы төшәргә һич тә курыкмый.

Аның бу сүзләре турында уйланганда мин Совет власте елларында безнең илебездә бөек милләтне мыскыллый торган великодержавный шовинизмның һәм асылында аннан һич тә калышмаган милләтчелекнең төбе-тамыры белән йолкынып ташлавына сөенеп бетә алмыйм. Ләкин шайтан таягын ничек кенә йолкып атма, җирдә аның барыбер өзелеп бетмәгән тамырлары гына булса да кала. Әгәр аңа каршы көрәшне йомшартсаң, аның кабат яңа үрентеләр җибәрүе бик мөмкин.

Моннан берничә ел элек Саратовта Идел буе китап нәшриятында Ю. Сагановның Иван Грозныйның Казанны яулап алуы турындагы «Новоград Свияжский» исемле тарихи романы басылып чыкты. Бу китапның әдәби эшләнеше ифрат йомшак, теле һәм стиле укучыны канәгатьләндерерлек түгел, анда тасвирланган характерлар бик примитив. Ләкин бу очракта сүз ул хакта бармый. Аның битләреннән миңа В. И. Ленин кайчандыр аяусыз рәвештә фаш иткән «колларча булган заман»ны аклау һәм бизәп күрсәтү сулышы бәрде. Хәзер инде барлык тарихчылар да Казанны Россиягә кушу — берничә гасыр аша, шул җөмләдән, Россиядә социалистик революция үсеше күзлегеннән чыгып караганда, прогрессив күренеш, диген уртак фикергә килделәр. Ләкин шул нигезгә таянып, явыз патшаның барлык хәрәкәтләрен, барлык эшләрен акларга, царизмның һәм аның тарафыннан алып барылган барлык феодаль сугышларның төп асылын — сыйнфый асылын онытырга беркемнең дә хакы юк. Ә Ю. Сагановның китабына нәкъ әнә шул кимчелекләр хас.

Мәсьәләгә сыйныфлар һәм тарих күзлегеннән карамау авторны котылгысыз рәвештә милли үзенчәлекләрне беренче планга куеп, аларны күпертеп күрсәтүгә китергән. Әсәрдә барлык руслар — патша Иван Грозныйдан һәм аның якыннарыннан алып хезмәтче кызга кадәр уңай яктан күрсәтелсә, татарлар бары тик яулап алучы варварлар, чакырылмаган кунаклар, талый, үтерә, яндыра торган халык сыйфатында гына тасвирлана. Ю. Сагановның тарихи чынбарлыкка шулай бер яклы гына килүе татар укучылары арасында гына түгел, рус укучылары арасында да протест тудыра, һәм бу бик урынлы.

●

Иптәш Ленинның төп өстенлекләреннән берсе шул: ул — бөтен дөньяда бердәнбер бөек юлбашчы булу белән бергә, шушы көрәш һәм яңа тезелешнең бөтен вак мәсьәләләренә кадәр төшенә һәм шуларда бик нык катнаша иде. Татар халкының үз эшен үз кулына бирү мәсьәләсендә дә иптәш Ленин, моны эшкә ашыру нигезләнеге турында мәсьәләне нигез ягыннан чишү белән генә калмыйча, икенче дәрәҗәдәге мәсьәләләрне, хәтта моның иң нечкәнә якларын чишүдә дә безгә ярдәм итте. Автономияле Татар Социалистик Советлар җөмһүриятен төзү эшендә Владимир Ильичның турыдан-туры нык катнашуын миңа да бераз күрергә туры килде.

САХИПГӘРӘЙ САЕТГАЛИЕВ. Татарстан җөмһүрияте һәм иптәш Ленин. «Кызыл Татарстан» газетасы. 1925 ел. 28 январь.

●

Тарихның иске фигураларын, иске тормыш хакимнәрен «архив» материалына калдырган, эше — көрәш, яшәве — көрәш, юлы — көрәш булган бөек шәхес — Ленинның утыз еллык эш тәҗрибәсе исән, тау-тау дулкынлы көрәш диңгезләрен кичәргә «кораб» исән, тиран оноплы дошман позицияләрен айкарга Ленинның туплары исән.

...Авыр минутларда, караңгы томаннарда компас — исән!

Көчне күбәйтеп, көрәшне көчәйтеп, җиңүне якынайтабыз!

ГОМӘР ГАЛИ. Ленин — көрәш. «Ленин» исемле җыентык. Казан. 1924 ел.

●

Ленин миллионнарча гаммәнең көрәшен идарә итүдә иң көчле дошманнарына, иң куркынычлы мохит шартларына галәбә күзе белән карап, үзенең корыч фикерләрен тимер куллар белән гамәлгә куючы гаскәр башы булды.

...Аның калдырган чиксез күп хезмәтләре, васыяте һәм тәҗрибәләре һәр кешенең, һәр пролетарийның күкрәгендә кадерләнеп сакланганда, без аның алган юлын тәмамларбыз.

ФӘТХИ БУРНАШ. Ленин тактикасы. «Безнең юл» журналы. 1924 ел 4—5 саннар.

Башка халыкларның милли хисләрен бер генә нинди очракта да мыскыл итәргә ярамый, дип күп тапкырлар кабатлады Владимир Ильич. Вак милләтләрне яклап, Ильич моның башка милләтләрнең халык массалары интересларында икәнлеген күрсәтә. «Ә Великоруссиянең экономик яктан чәчәк атуы һәм тиз үсеше илне великоруссларның башка халыкны җәберләвеннән азат итүне сорый».

В. И. Ленин үзенең мәкаләсендә дәүләт аппаратын мәҗбүри үзәкләштерүне яклап чыга, чөнки идарә итүнең ул формасы, Ленин фикеренчә, бүтән тигез шартлар булганда, башка формаларга караганда, прогрессиврак. Ул, барыннан да элек коммунистик революциянең төп двигателе буларак, рус пролетариатының социалистик роле турында басым ясап әйтә. «Ә пролетариат революциясе өчен эшчеләрне иң тулы милли тигезлек һәм туганлык рухында озак вакытлар тәрбияләү зарур».

Ленинның бу фикерләре миндә яңадан чиксез күп хисләр һәм уйлар ташкыны уята. Әйе, милли тигезлек һәм туганлык, милли культураларның үсеше һәм үзәкләштерү социализм шартларында бер-беренә каршы килмиләр. Башка милләтләрнең бай, алдынгы культура үсешеннән теләсә нинди изоляция бу милләтнең үзе өчен үк үлем белән бер. Әгәр миңа: башка халыклар белән аралашмыйча, үзеңнең милли мөхитеңдә генә калган хәлдә, үз телеңне, үз халкың культурасын үстерү өчен чикләнмәгән ирек ал дип әйтсәләр, мин: «Кирәкми миңа андый ирек» дияр идем. Чөнки Пушкиннан, Блоктан, Есениннан, Ахматовадан, Твардовскийдан һәм бөтен рус әдәбиятының бетмәс-төкәнмәс байлыкларыннан башка, мин үземнең эчке дөньямны Тукайдан, Такташтан, Туфаннан, Җәлилдән башка хис итә алмаган кебек үк күз алдыма китерә алмыйм.

Мин татар теленең үсеше һәм шул ук вакытта үз халкымның тормышында рус теленең күбрәк кулланыла баруы ягында. Чөнки шулар ярдәмендә безгә, алтын ачкыч белән ачылгандай, фән, техника һәм бөтен кешелек культурасы ишекләре киңрәк ачыла.

Мин соңгы вакытта бөтенләй хәксыз рәвештә онытылып бара торган милли һөнәрләрнең (ювелирлык сәнгате, милли чигү, татар орнаменты) чәчәк атуы ягында. Ләкин бу миңа күкрәк кагып мактану, үземнең милли дөньячыгыма кереп бикләнү өчен түгел, ә бәлки башка халыкларның да культурасын баету, гомум социалистик культурабыз хәзинәсенә үзебездән дә индивидуаль үзенчәлеккә ия булган сәнгать әсәрләрен өстәү өчен кирәк.

Мин үзенең көчле тавышы булган татар һәм башка халыкларның әдәбиятларын, үрнәкләре XIII гасырдан бирле сакланган туган поэзиябезнең тарихын өйрәнү һәм аны үзләштерү ягында. Ләкин безнең милли әдәбиятыбыз бөтенсоюз күләмендә куела торган олы таләпләргә җавап бирерлек булырга тиеш. Шулай булмаганда, «үзебезнеке», «безнең милләтнеке» булганы өчен генә теләсә нинди халтура һәм аяк белән язылган әсәрләр алдында минем баш иясем килми.

Мин безнең шәһәрләребезнең һәм авылларыбызның кабатланмас архитектура йөзен күрергә телим. Миллилек ул әле үзебезгә генә хас аерымлылык дигән сүз түгел. Әйтик, Казан елга порты яки Татар ашлары йорты биналарының бүлмәләре татар халкының иң яхшы милли традицияләрен исәпкә алып җиһазландырылган. Ләкин алар татарларны гына түгел, шәһәребезгә көн дә килеп торучы бихисап кунакларны да сокландыралар.

Чын мәгънәсендәге милли сәнгать үзенең рухы белән һәрвакыт интернационализм таләпләренә җавап бирә. Габдулла Тукай Пушкинны һәм Лермонтовны кояшка тиңләп, үзен, ай кебек, шул кояшның нурын иҗатында чагылдыручы итеп саный. Кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов, авар Рәсүл Гамзатов, башкорт Мостай Кәрим, татар шагыйре Муса Җәлил китаплары күп гаиләлә Ватаныбыз халыкларының һәркайсының культура хәзинәсенә әверелде.

Мин илебез халыкларын бер-берсеннән аера, чикли торган культура ягында түгел, ә аларны берләштерә, туганлаштыра торган культура ягында.

Бөек Ленинның искиткеч тирән эчтәлекле хезмәте белән яңадан танышканда миндә әнә шундый фикерләр туды.

## *ЛЕНИН ДОКУМЕНТЛАРЫ ЭЗЕННӘН*

# КИҢ ФАРВАТЕРГА ЧЫККАНДА



**1918** елның январь ае. Идел суы боз астында. Затоннарда пароходлар һәм баржалар яз җитүен көтеп, тынып калганнар. Хәер, навигация башланырга да күп калмаган инде. Әмма бу пароходларның, баржаларның хуҗалары ремонт эшләрен башлау турында уйлап та карамыйлар әле. Алар яшь Советлар республикасына ничек итеп күбрәк зыян китерү турында баш ваталар. Идел — Кама бассейнында иң зур транспорт фирмаларының берсе булган «Бертуган Каменскийлар һәм Мешков» пароходчылыгы управляющие менә шул көннәрдә: «...кичекмәстән ремонт эшләрен ахыр чиккә кадәр киметергә, ... бушаган хезмәткәрләрне һәм эшчеләрне эштән чыгарырга»,— дип боера.

Бүтән хуҗалар да бу фирма үрнәгенә кушылалар. «Самолет» фирмасы ремонт эшләрен дә, эшчеләргә хезмәт хакы түләүне дә туктата.

Аларның максаты бик ачык: навигацияне өзеп, Совет дәүләте экономикасына җитди удар ясау.

Ләкин елгачылар, флот хуҗаларының мәкерле максатларын бик тиз аңлап, аларга үзләренең сыйнфый оешканлыкларын каршы куялар.

Халык Комиссарлары Советының «Эшче контроле һәм саботаж белән көрәштә җирле Советларның хокуклары турындагы положениесе»нә таянып, Казан елгачылары хуҗаларның бу эшләренә комачаулауны кирәк дип табалар, ә Чистай затонында эшчеләрнең гомуми җыелышы: «Әгәр хуҗалар командаларны эштән куа икән, моңа буйсынмаска, 1918 ел навигациясендә флот үз эшен башкарсын өчен судноларны ремонтлауны дәвам итәргә»,— дип карар чыгара. Шулай ук Аракчино — Красногорск затоны эшчеләре дә хуҗалары боерыгына буйсынмаска булалар.

Бу тынгысыз көннәрдә Идел һәм Кама елгачылары, большевиклар инициативасы белән, җыелышларда шундый карарлар кабул итәләр: «Хөкүмәттән елгалардагы барлык судноларны, пристаньнарны, ремонт заводларын национальләштерүне сорарга».

Мәкерле саботажга тизрәк чик кую өчен елгачылар, урындагы партия һәм совет органнары ярдәмендә, пароход хуҗаларына турылыклы ялагай хезмәткәрләрне эшләреннән чыгарып, хуҗалыкны үз кулларына алырга керешәләр.

Владимир Ильич затоннардагы хәлләр белән даими кызыксынып тора. Аның инициативасы буенча, 1918 елның 2 январенда (иске стиль белән) Халык Комиссарлары Советы утырышында сәүдә флотын национальләштерү мәсьәләсе карала. 18 январьда бу мәсьәләне ахыргача хәл итү өчен ХКС утырышында өч доклад: Идел елгасы профсоюзы оешмасы — «Центроволга», сәүдә флоты диңгезчеләре һәм елгачылары союзы Үзәк Комитеты һәм Халык Хуҗалыгы Советы вәкиле докладлары тыңлана.

Бу тарихи утырыш турында Идел флоты вәкиле С. Ф. Авдеев үзенең истәлекләрендә болай дип яза:

«В. И. Ленинның секретаре Лидия Александровна Фотиева безгә, бик ягымлы итеп, утырып торырга кушты, яңа килгән газеталар бирде, ә үзе утырышлар залына кереп китте.

Менә безнең янга Владимир Дмитриевич Бонч-Бруевич чыгып, барыбызны да залга чакырды. Зур өстәл артында хөкүмәт җитәкчеләре утыра, алар арасында — безгә бик якын кеше Владимир Ильич.

Диңгезчеләр һәм елгачылар профсоюзы Үзәк Комитеты члены Игнат Сергеев доклады кыска һәм эшлекле булды.

Владимир Ильич, аркасын урындык артына җиңелчә терәгән хәлдә, башын күтәреп, игътибар белән Игнатка карап куйды, аннары өстәлгә иелде һәм блокнотына ике-өч сүз язып куйды.

Сергеев докладыннан соң, сүз Шляпниковка бирелде. Аның флотны национальләштерүгә каршы дәлилләре шуңардан гыйбарәт иде: янәсе, аерым кешеләр карамагында кечкенә судноләр бик күп, барлык флотны национальләштерсәк, бу таркау хуҗалык белән идарә итү мөмкин булмаячак.

— Ә сез ничек уйлыйсыз? — дип, Владимир Ильич яңа чакырылганнарга мөрәҗәгать итте.

— Рөхсәт итегез, Владимир Ильич,— дидем мин.

— Әйе, рәхим итегез, сезнең фамилиягез ничек? Кайдан? — дип сорады Ленин.

— Мин Авдеев, Иделдән.

Мин акционер җәмгыятьләренең елгачыларны ачлыктан интектерергә теләүләре, ремонт өчен кирәкле булган материаллар юклык аркасында судноларның җимерелүе хакында сөйләдем.

Аннары Владимир Ильич урыннардан килгән хезмәткәрләрнең фикерләре һәм тәкъдимнәре белән кушылуы... турында әйтте.

Смольныйдан без канатланып чыктык» [1].

1918 елның 23 гыйнварында (иске стиль белән) В. И. Ленин сәүдә флотын национальләштерү турында декретка кул куя.

Декрет басылып чыкканнан соң икенче көнне үк Казанда Идел флотының Казан районы елгачылары съезды җыйнала. Анда флотны национальләштерүне тормышка ашыру комиссиясе сайлана, судноларны һәм барлык милекне саклау, ремонт эшләрен дәвам итү, судноларны, материалларны дәүләткә тапшыру буенча алда торган эшләр планы раслана. Шунда ук Владимир Ильичка телеграмма тексты кабул ителә:

«Петроград. Ленинга. Су юлы транспортының Казан районы делегатлары съезды, коммунизм хисе белән рухланган хәлдә, Сезне, кадерле остазыбыз һәм җитәкчебез, караңгылыктан һәм изелүдән җанлы, якты тормышка чыгаручы итеп санап, сәламли. Якын киләчәктә булачак якты тормышка без нык ышанабыз һәм пролетариат диктатурасы казанышларын ныгытуга бөтен көчебезне куячакбыз...» [2].

Беркадәр вакыт узганнан соң, Петроградка тагын бер хәбәр җибәрелә. Бу юлы су транспорты хезмәткәрләре профсоюзы Үзәк Комитеты хөкүмәткә түбәндәгеләрне белдерә: «...Казанда елгачылар союзының Вакытлы Комитеты һәм аның янында Казан районы пароходчылыгы белән идарә итү буенча эш Советы... үзенең эшен башлап җибәрде».

Казан елгачылары Ленин декретын тормышка ашыруны тиз тоталар. Мәсәлән, 26 гыйнварда Казан банкасында Идел — Кама сәүдә бүлегенең «Самолет», «Русь», «Любимов», «Якимов» һ. б. җәмгыятьләренең пароход предприятиеләре исеменә счет ачылуы турында билгеле була. Казан Совдепы бу счетларга арест салу турында ордер бирә һәм 180 мең 584 сум акча шунда ук конфискацияләнә.

1918 елның июлендә Казан елгачылары Мәскәүгә: «...районда түбәндәге пароход предприятиеләре национальләштерелде: «Кавказ», «Меркурий», «Восточные», «Самолет», «Русь», «По Волге 1843 года»... барлыгы 13 предприятие һәм 200 дән артык пар белән йөри торган һ. б. судноләр дәүләт карамагына күчте».

---

[1] Ул көннәрнең даны онытылмас. «Речьтранспорт» нәшрияты. 1958, 9—10 битләр.

[2] ТАССРның ҮДА. 534 фонд. 1 тасвирлама. 79 эш. 27 бит.

Елгачылар дәүләт флоты белән идарә итүнең яңа формаларын эзлиләр. Бу эштә аларга В. И. Ленин җитәкчелегендәге Совет хөкүмәте зур ярдәм күрсәтә. 1918 елның 27 февралендә Халык Комиссарлары Советы Халык Хуҗалыгы Советы янында су юллары бүлеге булдыру турында декретны раслый. Ә соңрак бу су юллары бүлеге, ХКС карары нигезендә, су юллары транспортының Баш идарәсе итеп үзгәртелә. Бу чаралардан соң елга транспорты белән идарә итү структурасы шактый камилләшә.

Елга флотын национальләштерү тагын шуның белән бик катлаулы була: бу эш судноларны 1918 елгы навигациягә әзерләү чорында башкарыла. Ремонт эшләре бик кыен шартларда алып барыла, белгечләр җитми, затоннарда акча булмый.

Шушы кыен моментта В. И. Ленин, коммунистлар партиясе һәм яшь Совет хөкүмәте елгачыларга зур ярдәм күрсәтә. Югарыда исеме телгә алынган С. Ф. Авдеев үзенең шул үк истәлекләрендә болай яза:

«14 февральдә елгачылар профсоюзы съездында мине ХКСда транспорт эшләрен алып баручы Марк Тимофеевич Елизаров һәм... М. М. Володарский белән таныштырдылар.

Мин аларга Идел елгачыларының хатын күрсәттем. Елгачылар бу хатта элеккеге хуҗаларның саботажлары турында зарланганнар иде...

— Ә сез, иптәш Авдеев, ярдәм сорап Ленинга мөрәҗәгать итегез,— дип киңәш бирде Марк Тимофеевич.

Икенче көнне мин ХКСына шалтыраттым, аннан: «Пропускка заказ бирелде»,— диделәр.

Миңа кабул итүне озак көтәргә туры килмәде. Ильич бүлмәсеннән озын буйлы бер хәрби кеше чыкты һәм Л. А. Фотиева миңа Ленин янына үтәргә кушты.

— Утырыгыз, сөйләгез, сезне нәрсә минем янга килергә мәҗбүр итте,— диде Ильич, елмаеп.

Мин ремонт хәлләренең торышы, эшчеләрнең хәле, балаларның ачыгуы турында сөйләп бирдем...

— Акча юклыктан бик нык җәфа чигәбез, Владимир Ильич,— дидем соңыннан...

— Мин иптәш Елизаровка сезгә ярдәм итәргә әйтермен,— диде Владимир Ильич.— Ничек кенә булмасын, язга кадәр флотны ремонтлап өлгертергә кирәк. Судноларны елгага чыгарга тиеш. Тимер юл транспортындагы җимерекләкне белесез, шуңа күрә елгачылар алдында зур эш тора... Кыенлыклар туса, уңайсызланып тормагыз, шалтыратыгыз, керегез.»

Казан елгачыларына да дәүләт зур ярдәм күрсәтә. Аларга навигациягә әзерләнү өчен өч миллион сум акча күчерелә.

Су транспортының Казан районы идарәсе Идел бассейнында иң зурларның берсе була. Аның чикләре Чабаксардан Сембергә, Сарапулдан Кама Тамагына кадәр сузыла. Күп санлы затоннарда судноларны халык кулына тапшыруны тәгәлләргә, аларны сакларга һәм бөтен флотны навигациягә әзерләргә кирәк — моны В. И. Ленин, барлык хезмәт иясе халкы таләп итә.

Без Казан елгачыларының ул вакыттагы эшләре белән горурлана алабыз. Алар бу зур бурычны менә дигән итеп үтиләр. Ләкин, югарыда әйтелгәнчә, ул бик кыен шартларда башкарыла. Иң кыены: тәҗрибә булмау. Чөнки флотны национальләштерүне эре промышленностьны дәүләткә тапшыруның иң беренче үрнәкләреннән санарга була. Елгачылар бик зур пролетар сизгерлек белән эш алып баралар.

Кулаклар, сәүдәгәрләр, буржуаз татар милләтчеләре, меньшевиклар, эсерлар бердәм рәвештә Советлар властеның декретларына каршы чыгалар. Су транспортының Казан районы идарәсенә һәм профсоюз Комитетына кереп оялап, алар елгачыларны үз артларыннан ияртергә маташалар, Идел флоты таркалу-җимерелү алдында тора, дип паника тудырырга тырышалар.

Ләкин затоннардагы партия ячейкалары флотны халык кулына тапшыру эшен уңышлы башкаралар. Тиздән Казан район идарәсенең техник бүлегенә түбәндәге отчет җибәрелә:

«Судноларның күбесе елгаларга чыгарга әзер. Аларның шактый өлеше утын ягарлык итеп җайлаштырылды, пароходларга ягу өчен ике мең кубометр утын, дүрт мең бүрәнә һәм өч мең пот сумала әзерләнде».

9*

Беренче Совет навигациясен ачу тантаналы төстә башкарыла, митинглар оеша, судноларны Казан елгачылары һәм шәһәр халкы зур алкышлар белән озата.

Идел һәм Кама суларын ерып, буксирлар, баржалар шәһәрләргә икмәк, хәрби йөкләр ташырга керешәләр...

**А. КОСТИН,**
**Казан елга порты начальнигы.**
**И. МОРАТОВ,**
**Елга портының партком секретаре.**
**А. МӨСЛИМОВ.**

# ЯГУЛЫК ФРОНТЫНДА



Губерна Халык Хуҗалыгы Советының урман бүлеге мөдире Александр Михайлович Нагоркин шәһәр Башкарма Комитетына ашыга. Мөгаен, гадәттән тыш берәр хәл бардыр, югыйсә, губерна Халык Комиссарлары Башкарма Комитеты председателенең үзе янына чакырмаслар иде.

Председатель бүлмәсендә кешеләр күп иде. Тәмәке төтене— «балта эләрлек». Председатель өстәле тирәсендәгеләрдән берәү Нагоркинга телеграмма кәгазе сузды.

— Менә укы!

Нагоркин күзләрен кәгазьгә төбәде.

Телеграмманы Псков, Новгород, Вологда, Пермь, Самара, Сембер, Казан һәм башка шәһәр башкарма комитетларына Халык Комиссарлары Советы председателе махсус җибәргән.

«24 сентябрь, 1919 ел.

Чираттан тыш

Елгаларда сал белән килгән бик күп утын һәм бүрәнәләр ята. Салкыннар башланырга бик аз вакыт калганын истә тотып, килеп җиткән һәм, агызуны дәвам иттерү мөмкин булмаган очракта, елгалардагы саллардан утыннарны, бүрәнәләрне кичекмәстән чыгарырга тәкъдим итәм. Бу эшкә халыкны тартыгыз һәм хәрби частьлардан файдаланыгыз. Барлык саллар, кая җибәрелүенә карамастан, губерна башкарма комитетларының шәхси җаваплылыгы астында, елгалар туңганчы судан алынырга тиеш.

Халык Комиссарлары Советы председателе Ленин».

Әйе, яшь Советлар республикасының промышленность үзәкләре өчен ул вакыт ягулык җитми иде. Илнең таш күмер һәм нефть районнары аклар кулында. Шуңа күрә ягулык балансында утын зур урын алды. Ләкин аны ничек китерергә? Җимереклелектән иң күп зыян күргәне, мөгаен, транспорт булгандыр. Бик табигый, ягулыкны тиешле урыннарга җиткерүдә иң төп рольне елгалар уйнады...

Губерна Башкарма Комитеты председателе И. И. Ходоровский Нагоркинга сорау бирде:

— Елгаларда күпме агач ята?

— Берничә мең кубометр.

— Аларны яр кырыена чыгарып өлгерә алабызмы?

— Кыен эш. Салкыннар башланырга тора. Ләкин бөтен көчне куярбыз. Ышандыра алам: суда бер генә бүрәнә дә калмас. Утынның бер өлешен чаналарга төяп, атлар белән күчерергә туры киләчәк.

Менә көзге штурм башланды. Кешеләр бернигә карамый ярсып эшләделәр...

Ул көннәрдән шундый бер документ сакланып калган:

«Губерна урман комитеты утырышы.

Тыңланды: «...урман әзерләүчеләргә ике йөз мең пар чабата булдыру турындагы мәсьәлә...»

Әйе, чабата мәсьәләсе дә проблема иде. Тагын ачлык, салкыннар... Куллар туңып ярғалана. Кешеләр эштән кайталар да авалар. Шулай да җирле ячейка коммунистлары һәр кичен җыйналышып эшләгән эшләргә йомгак ясыйлар. Ә иртәләрен большевиклар, үз артларыннан йөзләрчә эшчеләрне ияртеп, тагын эшкә ашыгалар. Салларны буксирлар белән сөйрәп Казанка елгасына кертәләр. Бүрәнәләрне, утыннарны җилкәләргә күтәреп чыгаралар. Казан завод-фабрикалары эшчеләре дә ярдәмгә килә. Ансыз һич мөмкин түгел. РКП(б) Үзәк Комитеты партия оешмаларына җибәргән махсус хатында болай дип мөрәҗәгать итә:

«Һич нигә карамый ягулык кризисын җиңеп чыгарга кирәк. Шунсыз азык мәсьәләсен дә, хәрби мәсьәләне дә, гомумхуҗалык мәсьәләсен дә хәл итү мөмкин түгел...»

Ул елны көз бик иртә килә. Менә инде Идел, Кама сулары боз астында. Меңнәрчә кубометр утын яр буйларына чыгарып өелгән. Аларны тимер юл вокзалларына, әзерләү пунктларына ташырга, моның өчен меңнәрчә олаулар әзерләргә кирәк...

Һәм озакламый куңелле хәбәрләр дә килә башлый:

«Култәскә Мамадыш өязеннән 1682, Чыпчыктан 500 олау килде».

«Казанга 1000 олаулы обоз оештырылды».

«1 декабрьгә 2560 олау утын әзерләнде, 13 декабрьгә — 1965, 16 сына — 3155...»

«Советлар республикасы өчен 450 мең кубсажин утын әзерлик!»

...Бу көннәрдә Нагоркин бөтенләй өйдә утырмый диярлек. Бүген ул Козмодемьянск өязендә, иртәгә — Чабаксарда, берсекөнгә — Царевококшайскида. Барлык җирдә аны начальник итеп түгел, иптәш итеп, дус итеп каршы алалар. Чөнки ул, кирәк икән, үзегеңә үрнәк итеп орыша да, эшләгәннең дә кадерен белә. Татарлар белән татарча, чувашлар белән чувашча, марилар белән марича сөйләшә...

Владимир Ильич ягулык әзерләүнең барышын игътибар белән күзәтә. Мәсәлән, «Ленин һәм Татарстан» дигән җыентыкта эшче-крестьян оборонасы Советының 1920 елның 7 февралендә үткәрелгән утырышы беркетмәсе басылган.

«Тыңланды: ...Казан губ. № 5 һәм № 6 тегермәннәрен ягулык белән тәэмин итү мәсьәләсе. (Бакинский).

Карар:

...а) Тулы көчләрен эшләсеннәр өчен № 5 һәм № 6 Казан тегермәннәрен ягулык белән тәэмин итүне якларга һәм моңа тиешле кешеләрне мәҗбүр итәргә...

Эшче-крестьян оборонасы Советы председателе

В. Ульянов (Ленин)».

Татарстан АССРның Үзәк дәүләт архивында Ленинның бу күрсәтмәсенә җавап документы бар. Казан шәһәрен ягулык белән тәэмин итү өчен җаваплы оешма түбәндәге карарны кабул итә:

«Тыңланды: Аракчино затонындагы № 5 һәм № 6 тегермәннәрен утын белән тәэмин итү турында иптәш Ленин телеграммасы. Телеграмма № 69729/29.

Карар: телеграммадагы күрсәтмәләрне кичекмәстән үтәргә.»

Димәк, Владимир Ильич эшче-крестьян оборонасы Советы утырышы беркетмәсенә кул куеп кына калмаган, бу турыда Казанга телеграмма да җибәргән булган. Кызганычка каршы, бу телеграмма текстының әлегә кадәр табылганы юк...

Менә яз якынлаша. Яз — утын әзерләүнең соңгы этабы — ул сал агызу чоры. Затоннарга ике йөз мең кубометрдан артык агач китерелергә тиеш. Әзерлек эшләре уңышлы башкарыла: азык-төлек, кирәкле кораллар эш урыннарына үз вакытында китерелә. Язгы су ярларына төшкәнче, салларны агызып бетерергә кирәк. Иделгә Зур Кокшага елгасыннан 800, Кече Кокшагадан — 1000, Илеттән 600 сал чыгарылырга тиеш.

...1920 елның 12 июлендә Казанда Халык Хуҗалыгы Советының III нче губерна съезды үткәрелә. Халык Хуҗалыгы Советы председателе үзенең докладында болай ди:

«Партия, Ленин һәм Главлеском заданиесен алганнан соң, без шундый лозунг ташладык: «Ничек кенә булмасын, мөмкин кадәр күбрәк утын әзерләргә!» Бу бурычны тормышка ашыру өчен 331 мең 69 кеше, 25 мең 414 ат олавы мобилизацияләнде. Запас армия частьлары Краснококшайск һәм Чабаксар өязләренә хезмәт күрсәтте... һәм менә нәтиҗә: 1919—1920 ел сезонында утын әзерләү заданиесе 120 процентка үтәлде...»

Альберт ХӘРӘВИЕВ.

## Фәләх Насыйров

# «ЛЕНИНГА ХАТ ҖИБӘРИК!»

*Мамадыштан репортаж*

**«Казан губернасы, Мамадыш өязе татар укытучыларының 3 нче съезды резолюциясе.**

**16 январь, 1919 ел.**

**Мәскәү. Ленинга**



**Мамадыш өязе мөселман укытучыларының өченче съезды үзенең шушы елның 13 январь утырышында, иптәш Маняновның агымдагы момент турындагы докладын тыңлаганнан соң, бертавыштан түбәндәге резолюцияне кабул итте:**

**«Без, Казан губернасы, Мамадыш мөселман укытучылары, дөнья пролетариатын азат итүгә бөтен тырышлыгын бирүче Совет властеның дөрес политикасын таныйбыз.**

**Үз бурычыбызны бик яхшы аңлаган хәлдә, без, яшь революционерлар, капиталга каршы алда торган соңгы бәрелеш өчен көрәшчеләр хәзерләүне үзебезнең бурычыбыз дип саныйбыз һәм бу хәлиткеч сугышта җиңү шушы яшь геройлар кулында булачагына тирәнтен ышанабыз. Әгәр капиталистлар һәм аларның ялчылары безнең фронтны өзсәләр һәм безнең революциябезгә янасалар, без, укытучылар, кулыбызга корал тотып явыз дошманга каршы фронтка китәрбез һәм аңа каршы актык тамчы каныбызга кадәр көрәшергә тантаналы ант итәбез.**

**Яшәсен иптәш Ленин!»** [1]

* * *

**Бөек Ленинга язылган бу хат безне Мамадышка алып китте. Съездда катнашкан һәм революция юлбашчысына шундый ялкынлы хат җибәргән укытучыларның үзләрен күреп сөйләшәсе, аларның кадерле истәлекләрен ишетәсе килде.**

**Менә без Газизә әби Хисаметдинова янында. Йорт чиста. Бүлмәләре киң. Тормышлары мул күренә. Улы Фарид — укытучы, кызы Әлфия — врач. Безнең нинди йомыш белән килүебезне ишеткәч:**

**— Хәтерлим, хәтерлим...— диде ул, зиһенен җыеп.— Мин үзем дә ул съездга катнаштым. Анда язып утырган дәфтәрләрем дә саклана әле минем.**

**Газизә апа, өстәл тартмасын ачып, кәгазьләр актара башлады.**

---

[1] Ленин һәм Татарстан. Татиздат. 1964 ел. Рус телендә. 170 бит.

— Менә ул...

Гарәп хәрефләре белән язылган дәфтәрне алып, аны ашыкмыйча гына актара башлады. Урта бер җиренә җиткәч, шигырь язылган битендә тукталып калды.

— Менә моны шул съездда минем янымда утырган Гомәров дигән егет язган иде. Кара гына егет иде ул.

Газизә апаның күзләре нурланып, җыерчыклар каплаган йөзе яктырып китте. Ул карчыкларга хас бер көй белән әлеге шигырьне укып чыкты:

«Ханымнәр, атлагыз алга,
Бу юлда шаулый матбугат...
Хатыннарны кысучыларга каршы
Сугыш ач вә ук ат!

16 январь, 1919 ел, революционер Гомәров».

Әйе, бу шигырь Ленинга хат җибәрелгән көнне язылган.

«Гомәров!..» Таныш фамилия. Бу Латыйф ага Гомәров түгел микән! Аны «Социалистик Татарстан» газетасы, «Совет мәктәбе» журналы редакцияләрендә, республика радиокомитетында еш күрергә мөмкин. Ул актив хәбәрче. Үзе күптән инде пенсиядә булса да, тыныч кына өендә ята торган кеше түгел.

Әйе, бу шул, без белгән Гомәров булып чыкты. Казанга кайткач, без аңа Газизә ападан кайнар сәлам тапшырдык. Ул да Газизә апаны һәм Мамадыш өязе укытучыларының ул чакта булып узган съездын яхшы хәтерли икән. Латыйф ага анда халык мәгарифе бүлегендә эшләгән. Татар укытучылары съезды белән бер үк вакытта, рус укытучыларының да өяз съезды узган. Менә шул рус укытучылары съездында каралган мәсьәләләр белән танышу һәм тәҗрибә уртаклашу өчен татар укытучылары съезды вәкил итеп Мөҗип Искәндәров һәм Латыйф Гомәровларны җибәргән. Шулай итеп, Латыйф ага ике съездга да катнашу бәхетенә ирешкән.

Ул съездга катнашкан кешеләрне табуы хәзер җиңел түгел. Моңа инде шактый күп вакыт узган. Аларның күбесе безнең арабызда юк.

Әмма алар башлаган изге эш ярты юлда калмаган. Бөек Ленинга бирелгән изге антка тап төшмәгән. Ул, эстафета рәвешендә, буыннан-буынга, йөрәктән-йөрәккә күчә бара. Бу андагы укытучылар, мәктәпләр белән якыннанрак танышкач, аеруча ачык сизелә.

Без икенче номерлы Мамадыш урта мәктәбенең ана теле укытучысы, мәгариф отличнигы Илһамия Сафина дәресендә булдык. Ул традицияләр турында сөйли иде. Укытучы:

— Ленин. Кадерле Ильич! — дип башлады сүзен.

Класс тынып калды. Педагогның сүзләре йөрәк түреннән иң изге, иң кадерле хисләргә уралып чыга да күренми торган җепләр белән һәр укучының йөрәгенә барып тоташа һәм һәр баланың күңелендә Ленинга карата чиксез зур хөрмәт һәм мәхәббәт тойгылары уята.

— ...Бөек һәм даһи, тыйнак һәм гади. Кешелек дөньясының имиңлек һәм тигезлек, тынычлык һәм бәхет өчен көрәшүче һәрбер кешесе йөрәгендә ул шулай яши. Без барыбыз да бу кешене иң изге, иң бөек итеп хәтеребездә саклыйбыз. Иң кыен һәм шатлыклы минутларыбызны аның белән уртаклашып, якын күреп, чын йөрәктән: «Безнең Ильич!» дибез. Мамадыш өязенең III съездына җыйналган татар укытучылары да 1919 елның салкын кышында, илебез тарихында кыен көннәрдә, үзләре өчен иң кадерле кешегә мөрәҗәгать итәләр. Якын һәм үз итеп: «Ленинга!» дип башлыйлар алар хатларын...

Укытучы сөйли. Ә балаларның күз алдына бер-бер артлы узган тарихи вакыйгалар, дәһшәтле еллар килеп баса.

Ленин!

Яшь Совет властеның беренче көннәреннән культура фронтына аяк баскан татар укытучыларының беренче буыны Ленинның кем булуын һәм аның хезмәт халкына нәрсә бирүен яхшы аңлый. Алар бары тик Бөек Октябрь Социалистик революциясеннән соң гына белем алып, халык мәгарифе фронтына аяк басу бәхетенә ирешәләр. Моңа кадәр аларга мәктәп ишекләре ябык була. Чөнки бөтен Мамадыш өязендә [хәзерге Кукмара, Саба һәм Мамадыш районнары территориясендә] дәүләт кара-

магындагы татар мәктәпләренең саны ни бары алты, ә укытучы хокукы булган татар педагоглары аннан да азрак — дүрт кенә исәпләнә.

Юк, бу бер Мамадыш өязе өчен генә түгел, ә бөтен Казан губернасы өчен хас күренеш. 1915 елда хәзерге Татарстан территориясендә яшәүче халыкларның яртысы татарлар булуга карамастан, казна карамагындагы земский мәктәпләрнең өч процентында гына татар балалары укый алган»[1]. 1916 елда башлангыч татар мәктәпләренең саны бөтен Казан губернасы буенча 35 тән артмый. Аларда ни бары 2220 бала белем ала[2].

Аның каравы, Казан губернасында 1913 елда 1438 кабак, 1890 мәчет, 680 чиркәү була. һәр 800 кешегә 5 дин әһеле һәм... 1 укытучы туры килә.

Бу гади саннар түгел. Бу патша самодержавиесенең халыкны аракы, дин сөреме белән агулап торган җинаятьчел йөзен фаш итә торган факт.

Хәерчелектә һәм караңгылыкта яшәгән татар авылларына Октябрь революциясе мәгърифәт нуры китерде. Революциядән соң ел ярым вакыт эчендә Мамадыш өязендә татар мәктәпләренең саны 215 кә җитә, аларда 317 укытучы эшли. Шундый ук үсешне бөтен Татарстан республикасы буенча да күрергә мөмкин. 1921 ел башында, илдә сугыштан соңгы җимереклек һәм ачлык хөкем сөрүгә карамастан, беренче баскыч татар мәктәпләренең саны 1215, икенче баскыч татар мәктәпләре — 26 га, ликбез мәктәпләре 2114 кә җитә...

Әйе, яшь Совет иле эчке һәм тышкы дошманнарның тимер боҗрасы эчендә калып, Колчак бандалары Мамадышка якынлашкан куркыныч көннәрдә өяз укытучыларының съезды ачылу очраклы гына хәл булмый. Анда бик мөһим мәсьәләләр карала.

Съездда мәгариф бүлеге мөдире Галим Зиннуров «Өяздә мәгариф эшенең торышы турында» доклад сөйли. Укытучылардан Мөхәммәтхан Фазлуллин, Фәйзерахман Солтанбеков, Госман Бакировлар «Мәктәпләрдә эшнең куелышы һәм укыту методлары турында» чыгыш ясыйлар. Соңыннан өяз мөселман мәгариф комиссары ярдәмчесе Фатих Манянов «Агымдагы хәл турында» доклад ясый.

«Безнең алда ике фронт тора,— ди ул.— Без бөтен көчебез белән караңгылыкка каршы көрәшергә, халыкка белем бирергә, революция өчен яшь каһарманнар хәзерләргә яки иске, караңгы дөньяны кире кайтару өчен тәреләр күтәреп килүче дошманга — Колчакка каршы кулларыбызга корал алып, фронтка китәргә тиешбез. Башка юл юк, иптәшләр!»

Аның соңгы сүзләре алкышларга күмелә.

— Яшәсен бөек Ленин! — дигән тавышлар бөтен залны яңгырата.

Шул чак кемдер:

— Ленинга хат җибәрик! — дигән тәкъдим ясый.

Бу фикер делегатлар арасында бердәм яклау таба. Шунда ук хатның тексты языла һәм съезд тарафыннан ул зур күтәренкелек белән кабул ителә.

Мәгариф фронтына аяк баскан татар укытучыларының күбесе, кулларына корал алып, яшь Совет илен дошманнардан сакларга китәләр. Аларның байтагы үзләренең туган якларына кире әйләнеп кайта алмый. Халык бәхете өчен корбан булучылар арасында съездда ялкынлы речь сөйләгән Фатих Манянов та була.

Өяздә калган укытучыларга да җиңел булмый. Алар бөек Ленинга биргән вәгъдә һәм антларын намус белән тормышка ашыру өчен бөтен көч һәм тырышлыкларын бирәләр, авыл фанатикларына каршы көрәшеп, халык мәгарифен юлга салалар, яшь Совет иленең политикасын крестьяннарга җиткерәләр, авыл Советлары һәм ярлылар комитеты эшендә актив катнашалар. Салих Билалов, Иван Дымолазов, Тәкыя Мөхәммәтова, Сара Касыймова һәм башка бик күпләр авылларда кайнап торган эш җәелдерәләр. Өяздә татар укытучыларын хәзерләүгә, аларның квалификацияләрен күтәрүгә зур әһәмият бирелә. Бу эштә Мөхәммәтхан Фазлуллин, Мәрьям Мускиева, Мозаффар һәм Хәмит Мөштәриевларның башкарган хезмәтләре мактауга аеруча лаеклы.

---

[1] Н. К. Крупская һәм күп милләтле урта Иделдә халык мәгарифе. Казан. 1968. 52 бит.

[2] Шунда ук.

Тыныч төзелеш еллары башлангач, Мөхәммәтхан Фазлуллин Казанга күчә. Монда ул балаларны укыту өчен беренче татар әлифбасын төзи һәм тел буенча профессор дәрәҗәсенә күтәрелә. Латыйф Гомәров республика күләмендә партия һәм Совет оешмаларында төрле җаваплы эшләр башкара. Мамадыш өязе татар укытучыларының III съездында катнашкан педагоглар арасыннан мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Иң мөһиме: алар халыкка мәгърифәт, нур алып килделәр. Яшь буынга аң-белем бирү белән бергә, аларны Ватанга һәм коммунизм идеяләренә бирелгәнлек рухында тәрбияләделәр.

Яшь Совет иленең беренче кешенәреннән культура фронтына эшкә килгән бу укытучыларның хезмәт җимешләре Бөек Ватан сугышы елларында илебез авыр көннәр кичергәндә аеруча зур була. 1941 елда фашистлар Германиясе безнең илгә каршы сугыш башлагач, менә шулар тәрбияләгән егетләр һәм кызлар, туган илебез халыклары белән бергә, изге көрәшкә күтәреләләр. Мамадыш районыннан унөч меңгә якын кеше фронтка китә. Шуларның өч мең ярымы канлы сугыш кырларында батырларча корбан була, мең ярымнан артыгы — яралана. Күрсәткән батырлыклары өчен сигез меңнән артыгы орденнар һәм медальләр белән бүләкәнә. Иван Тихонович Максимовка, Гафият Ярмөхәммәт улы Нигъмәтуллинга, Михаил Кирилловичч Москвинга, Михаил Андреевч Просвиринига илебезнең иң зур бүләге — Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Район халкы арасыннан Дымолазов, Вилданов, Алексеев, Смирнов, Ясавиев кебек генерал һәм полковниклар үсеп чыга.

Район укытучыларының күпчелеге кешелекнең явыз дошманы — немец фашистларына каршы көрәшү өчен, кулларына корал алып, үзләре тәрбияләгән егетләр һәм кызлар белән бер сафка басалар.

Бөек Ватан сугышында катнашкан укытучыларның саны районда йөздән артык. Шәдче урта мәктәбе директоры Нәҗип Фәхриев сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы өчен Икенче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, шул ук мәктәп укытучысы Сәгыйт Ильяс улы Ильясов Кызыл Йолдыз һәм Дан орденнары, Түбән Шөндер мәктәбе укытучысы Василий Иванович Овчинников Икенче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнарына лаек булалар. Бу исемлекне озак дәвам итәргә мөмкин булыр иде.

Мамадышта үсеп чыккан академиклар, профессорлар, фән докторлары һәм кандидатлары, төрле өлкәдә эшләүче галимнәр, шагыйрьләр, композиторлар, язучылар, артистлар, врачлар һәм хезмәт маяклары күп. Алар арасында медицина фәннәре докторы, академик Павлов исемендәге премиянең беренче лауреаты Кибяков, профессор Горохов, фән өлкәсендә эшләүче Зәйнуллин, Заһриев, Житкин һәм башка иптәшләр бар.

Беренче татар музыканты Заһидулла ага Яруллин, беренче татар балеты авторы Фәрит Яруллин, язучы Шәйхи Маннур, композитор Мирсәет Яруллин, Минзәлә театрының баш режиссеры һәм художество җитәкчесе Муллачур Мостафин, Татарстанның атказанган артисты Фердинанд Фәрсин һәм атаклы дуңгыз караучы, Социалистик Хезмәт Герое Миңнури Хәйруллиналар белән район халкы хаклы рәвештә горурлана.

Санап китсәң, хезмәтләре белән дан һәм хөрмәт казанган кешеләр Мамадышта күп. Менә шуларның һәркайсына укытучы хезмәте кергән.

Мамадыш педагоглары өлкән буын укытучылар башлаган изге эшне лаеклы дәвам иттерәләр. Гомуми урта белем бирүгә күчү, укытуның сыйфатын яхшырту, яңа программа белән эшләүгә яхшы әзерлек белән керешү һәм башлангыч мәктәпнең дүртенче классыннан фәннәр укыта башлау кебек җитди бурычларны уңышлы хәл итәләр.

Мәгариф өлкәсендә эшләүчеләрнең осталыклары елдан-ел арта. Хәзер Мамадыш районында мәгариф отличникларының саны 68 гә җитте. Дүрт кеше РСФСР һәм Татарстан АССРның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем йөртә. Хәзер Мамадыш районында 126 мәктәп бар. Шулардан 13 урта, 28 сигезьеллык һәм 84 башлангыч мәктәп. Аларда 18 меңгә якын бала укый. Моннан тыш, яшьләр кичке мәктәпләрдә, махсус урта һәм югары уку йортларында белемнәрен күтәрәләр. Икенче төрле итеп әйткәндә, 70 меңле район халкының 20 меңе, ягъни 30 проценты укый. Районда бер меңгә якын укытучылар армиясе эшли.

## Илдар Низамов

# «САГЫНДЫМ МИН ИДЕЛНЕ!»



Бу сәяхәтне мин бик яхшы хәтерләп калганмын,— дип яза Анна Ильинична үзенең истәлекләрендә.— Июнь ае иде, елганың җәелгән чагы, шуңа күрә Идел буйлап, аннары — Кама һәм, ниһаять, Агыйдел буйлап пароходта бару гаҗәп әйбәт булды. Барлык көннәрне дә палубада үткәрдек. Володяның кәефе бик күтәренке иде, ул елгадан һәм тирә-як урманнардан бәркелгән искиткеч һаваны ләззәтләнеп сулады. Кама һәм Агыйдел буйлап барган кечкенә пароходның өске буш палубасында төнгә кадәр сузылган озын әңгәмәләребезне хәтерлим. Әни, арып, каютага төшеп китә. Сирәк-мирәк пассажирлар аннан да элегрәк юк булалар. Палуба безнең икебезгә генә кала, һәм тынган елга, йокыга талган ярлар арасында яшерен сөйләшүләр алып бару бик уңай иде. Владимир Ильич үзенең гомум рус газетасы планын миңа җентекләп, рухланып сөйләде. Газета партияне кору өчен төзелеш басмалары ролен уйнарга тиеш иде... Без аның белән «Кредо һәм Антикредо» турында да — ул чактагы барлык җитди мәсьәләләр турында сөйләштек. Володя кер кәефле, үзенә тартып торучан иде, һәм аның белән үткән бу сәяхәт минем иң әйбәт хәтирәләремнән берсе булып калды».

...Уйлап баксаң, 1900 елның июнь урталарыннан соң әллә ни күп вакыт та үтмәгән бит. Идел-ананың, чал Чулманның дистәләрчә гасырлардан торган озын гомере өчен җитмеш ел күпмени ул, шушы кадәр дәрьяда бер тамчы шикелле генә ләбаса.

Җитмеш ел. Бер тамчы. Ә күпме үзгәреш биредә. Нинди хисләр кичерер иде икән Владимир Ильич тагын да бер тапкыр шушыннан үтәргә туры килсә, таныр иде микән бу тирәләрне? Таныр иде, әлбәттә! Туган йортына кайтып төшкән кеше кебек иркен сулап куяр иде дә, күзләрендә очкын уйнатып, рәхәтлектән бер елмаер иде. Шушы тирәләрдә генә Камага Мишә коя. Володяның яраткан икеше Үшнә суларын да алып килә ул. Аннан алар бөек Иделгә — Владимир Ильичның туып-үскән төбәгенә, «зәңгәр бишегенә» барып тоташалар. Бик яраткан Ильич бу якларны, сагынып искә ала торган булган үзе йөзеп үскән, сәяхәт иткән су өсләрен, яр буйларын.

Бу сәяхәтне дә ул мәңге онытмаслык итеп хәтерендә калдыргандыр, чит-ят җирләрдә йөргәндә аны кабат-кабат искә төшергәндер. «... Шәп тә булыр иде җәй көне Иделгә кайтканда! 1900 елның язында без синең белән, Анюта белән пароходта ничек

күңелле барган идек!» — дип яза ул энисенә эмиграциядән. Бу сүзләрне кәгазьгә төзеп киткәнче ул, бер тын уйланып, бергәләп үткән күңелле юлны бәйнә-бәйнә күз алдыннан кичереп алгандыр, вак кына күренеш, вакыйгалар да күңелен эретеп, сагындырып үзенә тарткандыр. Гомумән, Иделен, туып-үскән якларын Владимир Ильич ифрат җылы, тәэсирле сүзләр белән искә ала. Менә чит җирләрдән М. Т. Елизаровка язган хатыннан бер өзек: «Хатыгыз өчен зур рәхмәт! Монда үзеңне шулкадәр аерылган итеп хис итәсең, «Иделдән алынган» (Сагындым мин Иделне!) тәэсирләр һәм күренешләр турында мондый сөйләүләр — чын бальзам инде...»

Әмма бу ярларда йөрергә, шушы суларда йөзәргә Ильичка башкача насыйп булмады. Тик туры килгән һәр очракта ул бу яклар турында белешергә, сорашырга ашыккан, үзенең кызыксынуын, сагынуын, туып-үскән якларын якын күрүен белдергән. Бөтен ил күләмендәге зур җитәкче, бөтен дөньяга танылган бөек кеше булгач та РКП(б)ның X съезды делегаты анкетасындагы: «Россиянең кайсы урыннарын яхшы беләсез?» — дигән сорауга ул: «Идел буен башка яклардан яхшырак беләм»,— дип җавап биргән.

Ә аның якташларын ничек якты йөз белән каршылавы, алар белән очрашканда ничек бирелеп сөйләшүләре! 1918 елның җәендә ул, мәсәлән, Казаннан килгән А. В. Ивановны кабул итә. Сүз эшчеләрне икмәк белән тәэмин итү, урыннарда Совет властен ныгыту турында бара. Бөтен ил өчен авыр көннәр, юлбашчының һәр минуты кадерле. Шулай да Ильич Ивановның Казаннан килгәнлеген хәтереннән чыгармый, сүз арасында:

— Ә сез кайда тугансыз? — дип сорый.

— Казанда, Владимир Ильич.

— Мин бит шулай дип уйлаган идем. Без сезнең белән якташлар диярлек.

Һәм ул, бераз вакытын бүлеп, Казан турында, шул яклар турында кызыксынып, онытылып сораша башлый.

Безгә, якташларга, рәхәт менә шундый истәлекләрне укуы! Рәхәт Владимир Ильичның Казан турында, Идел турында онытылып, сагынып сөйләвен, үзенең Иделдән икәнлеген горурланып телгә алуын уйлаганда. Владимир Ильичның үз Иделенә, туып-үскән якларына мәхәббәтен, турылыклы икәнлеген бөтен эше, бөтен гомере белән раславын яхшы белгәнгә, шуны үз тормышыбызда тойганга күрә дә шулай рәхәт безгә. Ленинның якташыбыз булуына шулай чиксез горурланабыз без. Шуңа күрә дә безгә Ильичның безнең якларга кагылган һәр истәлеге, шул чираттан әлеге сәяхәте дә бик кызыклы һәм кадерле.

Әле менә ул үткән юл буйлап уйланып барганда, моннан бер генә тапкыр үткән булса да, Владимир Ильич бу тирәләрне соңыннан да онытмаган, күңеленнән генә булса да бирегә әледән-әле әйләнеп кайткан, дибез. Чөнки шушы тирәләрдә күз алдына аны искә төшерерлек, аның белән бәйләнгән яңадан-яңа күренешләр, вакыйгалар килеп баса.

...1918 ел. Революция ялкынында Россия әр-яңадан туып килә. Ләкин беренче көннәреннән үк аның муенына салкын элмәк киертелгән, интервентларның шул мәрхәмәтсез элмәге илнең сулышын кысканнан-кыса. Көнчыгышта хәл аеруча куркыныч. Карта янына ничә тапкыр килеп басса да, Владимир Ильичның карашы иң башта Иделгә төшә. Анда бит хәзер су түгел, ут агадыр кебек. 6 августта Казан да контрреволюция кулында кала.

Юк, бер генә секундлык та каушау булмаска тиеш. Революция әле башлана гына! Менә Ленин кискен, әмма ышанычлы хәрәкәт белән язарга керешә. «...Революциянең бөтен язмышы хәзер бер картада тора, Казан — Урал — Самара фронтында чехословакларны тизрәк җиңү. Барысы да шуңа бәйләнгән».

Шушы җиңү өчен ул үзе барысын да эшли, бөтен көчен бирә: турыдан-туры аның җитәкчелегендә Үзәк Комитет көнчыгыш фронтны ныгыту турында карар кабул итә: Петроградтан, Мәскәүдән һәм башка шәһәрләрдән күп санлы агитатор отрядлары оештырылып, комиссарларның күпчелеге шушы якларга җибәрелә, аларны фронтка Владимир Ильич үзе озата; Иделдә хәрби флотилия төзүгә турыдан-туры җитәкчелек итә, Ф. Раскольниковка җибәргән телеграммасында: «Казан фронтын тәэмин итүгә, анда ашыгыч резервлар җибәрүгә» игътибарны арттырырга куша.

Юкка гынамыни дошманнар аның гомеренә нәкъ менә шундый көннәрдә кул сала. Мәкерле пуля аны аяктан ега, әмма җиңүгә омтылышын какшата алмый, аның һәр сүзе дошман өстенә снаряд булып ява. һәм менә яралы Ильичка бер-бер артлы сөенечле хәбәрләр килә: ниһаять, Казан да азат итәлде! Шәһәрне алуда катнашкан кызылармеецларга Ильич хат язып җибәрә: «Иптәшләр! Казанны алуның бөтен рус революциясе өчен нинди зур әһәмият казанганлыгы сезгә билгеле инде. Ул безнең армиянең настроениесендә зур борылыш туганлыкны, аның нык, кискен төстәге җиңүле хәрәкәтләргә күчкәнлеген күрсәтте...»

Әйе, зур борылыш туды. Бу — Ленинга килгән телеграммалардан да ачык күренә иде: Сембер азат. Самара безнең кулда, һәм башка, һәм башка шәһәр, авыллар... Сөенечле хәбәрләр арасыннан Владимир Ильич менә монысына да, Идел флотилиясе сугышчылары язган хатка да игътибар итмичә калмагандыр. «Кама Тамагын яулап алып һәм шуның белән Петроград, Мәскәү эшчеләрен икмәк белән тәэмин итү өчен иң мөһим артерияне чистарта башлап, Идел хәрби флотилиясе ике бөек елга чатына килеп басты һәм шушыннан Совет үзәк учреждениеләренә, аларның җитәкчесе, хезмәт ияләренең һәм көрәшче сыйныфларның юлбашчысы Владимир Ильич Ленинга сәламнәр җибәрә. Флотилиянең хәрби моряклары Совет гаскәрләренең уңышлары кадерлебез Ильичның терелүе өчен иң шифалы дару икәнлеген яхшы беләләр... Ак гвардиячеләрнең хәрби флотилиясе Камага куып кертелде һәм шунда үзенә үлем табачак. Идел хәрби флотилиясе Иделне, Каманы, Вятканы һәм Агыйделне революциянең һәм халыкның явыз дошманнарыннан чистарту теләге белән бер кешедәй яна. Совет территориясе чикләре көннән-көн киңәя барачак. Социалистик революция дәвам итә».

Бу сүзләрне укыганда да Ильичның йөзе яктырып, яра сызлавы беразга басылып, күзләрендә күңелле очкыннар җемелдәп киткәндер.

* * *

...Бу шәһәр безгә яхшы таныш. Монда тукучылар һәм судно ремонтлаучылар, машина ясаучылар һәм агач осталары, кондитерлар, тегүчеләр һәм башка һөнәр ияләре яши. Чистайда Каманың зур затоннарыннан берсе урнашкан, ул — елгачылар шәһәре. һәм, ниһаять, монда килгән саен сәгать заводына керәсең килеп тора. Ул бит бөтен Татарстан горурлыгы! Нинди генә дөнья-күләм күргәзмәләрне алма, барысында да Чистай сәгатьләре катнаша, мактаугa, бүләккә лаек булмыйча калмый.

Чистай елдан-ел үсә, чибәрләнә. Ә 1900 елда, Ульяновлар семьясы үткәндә нинди булды икән ул? Тарихка мөрәҗәгать итик. Кулыбызда П. И. Ивановның шул елларда чыгарылган сәяхәтнамәсе. «... Казан губернасының гына түгел, бөтен Кама елгасының өяз шәһәрләре арасында иң яхшыларыннан...»

Тик бераз әптырабрак каласың: шәһәрдәге бүгенге завод-фабрикаларның ул чорда әзе дә булмаган, бу казанышлар барысы да Совет власте җимешләре бит, гомумән, Чистай, республиканың бүтән уннарча калалары кебек үк, Октябрь баласы ул. «Шәһәрдә — дәүләт банкысының бүлекчәсе, шәһәр банкы, хатын-кыз прогимназиясе, духовный училище» — бөтен хәзинә менә шул. Сәяхәтчеләр игътибарына тәкъдим ителгән иң күренекле нәрсә: «...тезелешләр һәм сәүдә». Менә нәрсә белән дан тоткан Чистай. «Тезелешләр» дигәненә дә шул елларда чыккан «Халык яши торган пунктларның алфавит буенча исемлеге» дигән җыентыктан аңлатма табып була. «...Вакыт үтү белән каралып беткән, читән белән уратылган йортлар тәртипсез рәвештә тауга сырышканнар. Текә яр өч чиркәү һәм мәчет белән чикләнә, аста бөтен ярны иңләп лабазлар, лабазлар тезелгән — икмәк, сүс, патока һәм башка товарлар...» Менә шундый булган Рәсәйнең «иң яхшы» өяз шәһәрләреннән берсе. Нишләмәк кирәк, мактанырлык бүтән нәрсәң булмагач, халык әйтмешли, «гөл булса, гөлгә куан, гөле булмаса, бөресенә куан».

Шундый итеп күргән Владимир Ильич Чистайны әлеге сәяхәте вакытында. Тагын унтугыз елдан соң бу исемне өш ишетергә, шушы ярларны, ярга сырышкан өйләрне күз алдына китереп, тирән уйларга чумарга туры киләчәген сизенде микән ул Чистай пристаненнан китеп барганда?

...Миллионнарның карашы янә көнчыгышта. Ленинныкы да шунда. «Иптәшләр! Көнчыгыш фронтта хәл бик начарланды. Бүген Колчак Воткинск заводын алды, Бөгелмә һәлакәттә; ихтимал, Колчак алга килүен тагын дәвам итәр. Куркыныч бик зур...» Бу сүзләрне Владимир Ильич Петроград эшчеләренә яза, көнчыгыш фронтка ярдәм итү өчен алардан бөтен көчләрен туплауларын үтенә. Петроград та, башка шәһәрләр дә, юлбашчы чакыруына берсүзсез кушылып, фронтка үзләренең иң нәзләрчә улларын җибәрәләр. Идел, Кама буйлап һәр авыл, һәр кала өчен аяусыз көрәшләр бара.

Россия зур, Чистай анда бер бөртек. Шулай да 1919 елның март, апрель айларында гына да Ленинга бу төшләргә берничә тапкыр игътибар бирергә туры килә. «Чистайга ярдәм итү өчен экстерн чаралар күрергә кирәк. Сез моңа җитәрлек игътибар иттегез микән? Барлык мөмкинлекләр дә кулланылып беткәнме? Телеграмма белән җавап бирегез! Ленин»,— дип хәбәр җибәрә ул Көнчыгыш фронтның реввоенсоветына.

Чистайны кулга эләктерү өчен Колчак бөтен көчен бирел тырмаша. Чөнки биредәге затонда нефть, икмәк, башка кирәк-ярәк белән тулы баржалар, флот кышлый. Боз эреп, елга ачылганчы, пароходлар шул байлыкны алып чыгып киткәнче, шәһәргә керү акларга бик мөһим. Кызыл сугышчылар, шәһәр коммунистлары, бөтен халык, зур каһарманлык күрсәтеп, аларга каршы тора. Ләкин көчләр тигез булмый. Дошман шәһәргә якынайганнан-якыная. Әмма затонга килеп җитсәләр, күзләре акая: флоттан җилләр искән!

Бу да Владимир Ильич кул астында башкарылган кыю операция иде. Менә таныш, кадерле имза: «В. Ульянов(Ленин)» дип куелган тагын бер документ. Иван Тимофеевич Гавриловка бирелгән мандат. Октябрь штурмнарында чыныгу алган Балтик морягы Чистайга флотны коткаруны оештыру өчен җибәрелә. Һәм шушы батыр большевик җитәкчелегендә Кама елгачылары Ленин ышанычын аклау өчен барысын да эшлиләр, бик авыр, әмма бик кирәкле заданиене башкарып чыгалар. Моның өчен юлбашчы аларга кайнар рәхмәт белдерә. Бу исә елгачыларны яңа җиңүләргә дәртләндерә. Шул уңай белән су транспорты работниклары союзының Казан комитеты тараткан өндәмәдә менә нинди сүзләр бар: «Кадерле юлбашчыбыздан шушы моментта алган рәхмәт елгачыларның рухын тагын да ныгытыр, болай да киеренке энергияләрен контрреволюция аждаһасы белән көрәштә тагын да арттырыр...»

**Мансур Хәсәнов,**

*филология фәннәре кандидаты*

# ЛЕНИН ТӘГЪЛИМАТЫ һӘМ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ФИКЕР ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Бу көннәрдә илебез халыклары зур тантана, олы бәйрәм хисе белән яши: Карл Маркслың һәм Фридрих Энгельсның революцион тәгълиматын даһиларча дәвам иттерүче, Советлар Союзы Коммунистлар партиясен төзүче, иң зур социаль революциянең җитәкчесе һәм дөньяда беренче социалистик дәүләткә нигез салучы, халыкара эшчеләр сыйныфының, барлык хезмәт ияләренең юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулды.

Чорыбызның иң зур казанышлары аның исеме белән бәйләнгән, егерменче йөзнең иң мөһим вакыйгалары Ленин исеменнән аерылгысыз.

Ленин тәгълиматының, ул калдырган бай иҗат мирасының тормышыбызда тоткан урыны гаять мөһим, бәя биреп бетергесез зур. Бүгенге көннең нинди генә актуаль мәсьәләсенә килеп тотынмыйк, без һәрвакыт Ленин белән киңәшәбез, аның хезмәтләренә таянабыз.

Ленинның иҗтимагый-политик фикер үсеше һәм мәдәният тарихы мәсьәләләрен эшкәртүгә керткән казанышы да ифрат зур һәм кыйммәтле. Ул XVIII йөз ахыры, XIX йөз башындагы рус мәгърифәтчелегенә төгәл һәм тулы характеристика бирде, бу характеристика феодаль-крепостной строй җимерелгәннән соңгы Россиядәге иҗтимагый-политик фикер үсешенә караган күп нәрсәләрне аңларга һәм дөрес хәл итәргә мөмкинлек тудыра.

Буржуаз галимнәрнең буш һәм нигезсез сафсаталарыннан аермалы буларак, Ленин Россиядәге азатлык хәрәкәтен чорларга бүлүнең гениаль тезисын бирде, бу мәсьәләне хәл иткәндә, ул шул елларның объектив чынбарлыгына һәм, иң элек, яшәп килгән стройга каршы көрәштә теге яки бу сыйныфның (дворяннар, крестьяннар һәм пролетариат) җитәкчелек роленә таянды. Азатлык хәрәкәтен чорларга бүлүнең Ленин эшләгән әлеге алымы Россия халыкларының иҗтимагый-политик фикер үсешенең төп этапларын билгеләү өчен дә, ул этапларның эчтәлеген ачу өчен дә һәм, күп милләтле Россия пролетариаты, большевиклар партиясе көрәш мәйданына чыгу белән бәйле рәвештә, XIX—XX йөзләр арасында төрле халыкларның иҗтимагый-политик фикер үсешендә барлыкка килгән кискен үзгәрешләрне тирәнтен өйрәнү өчен дә чикләнмәгән мөмкинлекләр тудырды.

Ленинның даһи акылы милли мәсьәләне дөрес хәл итүнең фәнни һәм практик юлларын күрсәтте. «Ленин милли мәсьәләне яңа тарихи шартларга ярашлы рәвештә һәрьяклап эшләде,— диелә КПСС Үзәк Комитеты тезисларында,— пролетариатның сыйнфый көрәшен милли изүне юк итү өчен көрәш белән, социализм өчен көрәшне коллыкка төшерелгән халыкларның антиимпериалистик азатлык көрәше белән бергә кушу идеясен күтәрде һәм нигезләде». Бөек юлбашчының милли мәсьәлә буенча язылган хезмәтләре бу өлкәдә эшләүче

совет галимнәре өчен юл күрсәткеч маяк, методологик нигез булып санала.

Ленинның культура һәм культура революциясе турындагы фәнни өйрәтүләре зур тарихи әһәмияткә ия. Иң элек ул мәдәниятнең тарихи үсешен аңлау өчен фәнни ачкыч бирде: һәр буржуаз милләтнең культурасында ике милли культура булуын ачты. «Һәр милли культурада,— дип аңлатты ул,— яралгы хәлендә генә булса да, демократик һәм социалистик культура элементлары була, чөнки һәр милләттә хезмәт ияләре һәм изелүче массалар бар, аларның тормыш шартлары исә котылгысыз рәвештә демократик һәм социалистик идеология тудыра»,[1] әмма һәр милләттә шулай ук, хәтта әле хөкем сөрүче, буржуаз культура, ә күпчелек очракларда тагын карагруһ һәм клерикаль культура була. Бу — В. И. Ленинның сыйныфлар һәм сыйнфый көрәш турындагы марксистик тәгълиматны культура фронты мәсьәләләренә карата куллануы иде. Әлеге тәгълимат яктылыгында буржуаз җәмгыятьтәге төрле көчләрнең үзара көрәшен, антагонистик сыйныфлар идеологиясенең сәнгать-әдәбиятта һәм фәнни әсәрләрдә ничек чагылуын күз алдына китерергә мөмкин. Шуның белән бергә, В. И. Ленин тезисы мәдәни мираска мөнәсәбәт мәсьәләсен дөрес хәл итәргә дә нигез бирде.

Икенче яктан, В. И. Ленин хезмәтләрендә безнең илдәге культура революциясенең закончалыгы һәм объектив характерда булуы тирәнтен дәлилләнде. «Культура революциясе» дигән төшенчә үзе дә фәнгә башлап аның тарафыннан кертелде. Ул культура революциясенең характерын һәм бурычларын, шулай ук аны тормышка ашыруның конкрет юлларын билгеләде. Ленин фикеренчә, культура революциясе җәмгыятьнең бөтен рухи тормышын үзгәртеп кора торган катлаулы процесс иде. Культура революциясе барышында халык массалары алдынгы фән казанышларын үзләштерәләр, әдәбият-сәнгать җәүһәрләре, техника яңалыклары белән танышалар. Җәмгыятьнең рухи яңару процессында яңа социалистик культура барлыкка килә. Кешеләрнең социаль һәм мораль йөзләре үзгәрә, аларда дөньяга коммунистик караш формалаша, коммунистик әхлакның яңа нормалары гамәлгә керә.

В. И. Ленинның 1923 ел башында язган соңгы хезмәтләрендә («Көндәлек дәфтәреннән битләр», «Кооперация турында», «Революциябез турында», «Рабкринны ничек үзгәртеп корырга», «Аз булса да әйбәт булсын») культура һәм культура революциясе мәсьәләләре дәүләт эшләре, политик, социаль бурычлар белән аерылгысыз бәйләнештә карала. Шуның белән бергә, В. И. Ленин культура революциясен асылда халык массаларын дәүләт, хуҗалык һәм культура төзелеше мәсьәләләре белән идарә итүгә тартуның бер формасы дип санады.

Шул кадәресен басым ясап әйтергә кирәк, социалистик культура төзү турында сүз барганда, В. И. Ленин үткәндәге культура мирасына, буржуазия хакимлек иткән чорларда фән, техника, әдәбият, сәнгать ирешкән казанышларга сак карарга өйрәтте. Төрле эпохаларның культура үсешендәге һәм төрле илләр культурасындагы үзара бәйләнешне Ленин алдан күрде. Зур яки кечкенә булуларына карамастан, барлык халыклар һәм милләтләрнең гомум кешелек культурасы казанышларына үз өлешләрен кертә алуын, теге яки бу милләтнең казанышы саналган иң яхшы культура байлыкларының котылгысыз рәвештә, милли чикләрне үтеп чыгып, дөнья-күләм күренешкә әйләнәчәген Ленин тирән аңлады. Социалистик культура үткән эпохаларның казанышларын тәнкыйть аша үзләштерү, файдалану җирлегендә генә туа, үсә ала дигән фикер аның хезмәтләрендә кызыл җеп булып сузыла.

...Тиздән Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының төзелүенә 50 ел тула. Бу ике бәйрәмнең бергә туры килүе ифрат күңелле һәм тантаналы хәл. Чөнки Татарстан Ленин исеме белән аерылгысыз бәйләнгән.

Казан тарихчыларының, бигрәк тә СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренең тырышлыгы нәтиҗәсендә, без бүген Татарстан республикасын төзүдә һәм аны үстерүдә В. И. Ленинның никадәр якыннан катнашуын шактый ачык һәм тулы итеп күз алдына китерә алабыз. Бер-ике факт белән генә эш итүче 20 нче еллар, хәтта әле 50 нче еллар башындагы тарихчылардан аермалы буларак, бүгенге галимнәр бөек юлбашчының бу юнәлештәге һәр көнен, һәр сәгатен диярлек яхшы беләләр. Сүз Россия федерациясе эчендә Татарстан автономиясе төзү турындагы декретка кул кую, я булмаса яңа республиканың чикләрен һәм башкаласын билге-

[1] В. И. Ленин. Полное собрание сочинений. Рус телендә 24 том. 120—121 битләр.

ләү турында барамы — һәр очракта бәхәссез дәлилләребез җитәрлек. Татарстанның экономикасын һәм культурасын үстерүдә В. И. Ленинның роле искиткеч зур.

Боларның һәммәсе хакында тарих фәннәре кандидаты М. Сәйдәшеваның күптән түгел Мәскәүдә «Фән» нәшриятында басылып чыккан «В. И. Ленин һәм Татарстанда социалистик төзелеш» дигән китабында тулы сөйләнә. Бу китап бөек юлбашчының юбилеена һәм Совет Татарстанының 50 еллыгына зур бүләк. Ул Бөтенсоюз фәнни ленинианага керергә лаеклы хезмәт.

Илле ел эчендә Татарстан республикасы ирешкән уңышлар исә чын мәгънәсендә таң калырлык. Артык зур булмаган вакыт эчендә татар халкының экономикасы, культурасы чын мәгънәсендә яңадан туды. Ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру процессында республиканың социаль-экономик һәм мәдәни йөзе үзгәрде. Артта калган гадәти авыл хуҗалыгы районыннан ул эре промышленность, алдынгы фән һәм культура үзәкләренең берсенә әйләнде. Республикада Совет власте елларында мәгариф, югары белем һәм фән үсешенең колачын күрсәтү өчен түбәндәге саннарны китерү генә дә җитә. Хәзер бездә 3052 гомуми белем мәктәбе бар, аларда 652 мең бала укый. 52 техникумда 50 мең кеше, 78 һөнәр училищесында 35 мең кеше белем алалар һәм илебезнең халык хуҗалыгында һәм культура өлкәсендә эшләячәк белгеч булырга хәзерләнәләр. Мәктәпләрдә, техникумнарда һәм һөнәр училищеларында 40 меңнән артык укытучы һәм тәрбияче эшли.

Республиканың 11 югары уку йортында 61 мең студент укый, югары уку йортларында һәм фәнни-тикшеренү институтларында 267 фән докторы һәм профессоры, ике меңгә якын фән кандидаты эшли.

Татарстан республикасының уңышлары халыкара политик әһәмияткә ия. Ул уңышлар үткәндә изелеп яшәгән талантлы бер халыкның социалистик җәмгыять шартларында нинди үрләргә күтәрелә алуын күрсәтә, ул уңышлар безнең ил халыклары арасындагы какшамас дуслыкның бетмәстекәнмәс көче турында сөйли. Хәер, бәйрәм алдыннан чыккан газета-журналларда 50 ел эчендә ирешелгән казанышлар турында күп языла. Мин аларны кабатлап тормыйм. Татарстан хезмәт ияләре узган юлга йомгак ясаганда, мәкаләнең темасына бәйләнешле рәвештә, бары тик төп ике моментны гына басым ясап билгеләп үтәсе килә.

Беренчедән, Совет Татарстаны узган юл, социалистик татар милләтенең тарихы һәм уңышлары татар халкының революциягә чаклы узганын, аның үсешенең тарихи закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен тагын да тирәнрәк һәм дөресрәк бәяләргә мөмкинлек бирә. Сүз үткән тарихны бүгенге көн позициясеннән торып яхшырту турында бармый, билгеле. Без татар халкының борын заманнардан бирле үткән юлын, капитализм эпохасында татар милләтенең формалашуын һәм үсешен татар хезмәт ияләренең большевиклар партиясе җитәкчелегендә гомум Россия күләмендә барган революцион хәрәкәткә катнашуын һәм зур фәнни кыйммәте булган башка күп кенә мәсьәләләрне өйрәнүдә ленинчыл тарихи методологияне киңрәк һәм тирәнрәк куллануны күздә тотабыз.

Икенчедән, Татарстан республикасының экономика, культура, демократия үсеше өлкәсендәге тарихи уңышлары — ленинчыл милли политиканың тантанасы. Һәм, бу яктан караганда, Социалистик Татарстан — татар халкының тарихын төрлечә бозып аңлатучы буржуазия идеологларына каршы көрәшү өчен иң көчле корал һәм берничек тә кире кага алмаслык дәлил. Күрәсез, капитализм белән идеологик көрәштә тормыш үзе, объектив чынбарлык — безнең көчле ярдәмчебез, бу көрәштә ул социализмның позицияләрен чагыштыргысыз көчәйтә...

Владимир Ильич Ленинның 100 еллыгы һәм Татарстан республикасының 50 еллыгы уңае белән искә төшерәсе килгән фикерләрнең кайберләре әнә шулар иде.

Татарстан республикасының казанышларын, татар халкының узган һәм бүгенге тормышын Ленин идеяләре яктылыгында фәнни өйрәнү эше ничегрәк куелган? Галимнәребез олы бәйрәмнәргә безне куандырырлык нинди уңышлар, нинди ачышлар белән киләләр?..

Билгеле булганча, соңгы еллар илебез тормышының барлык тармакларында барган тирән үзгәрешләр белән характерлы. Экономик һәм политик тормышта, идеология өлкәсендә урнашкан иҗади атмосфера иҗтимагый фәннәрнең үсеше өчен дә киң мөмкинлекләр, күп уңай шартлар тудырды. Нәтиҗәсе күз алдында: фәнни иҗат эше бермә-бер җанланып, активлашып китте.

Бүген без куанып әйтә алабыз: иҗтимагый фәннәрнең теге яки бу рәвештә рес-

публикадагы гыйльми кадрлар катнашмый калган бер генә тармагы да юк хәзер. Галимнәребез өйрәнә торган тема һәм проблемаларны санап чыгу өчен генә дә күп вакыт, зур урын кирәк булыр иде: КПСС тарихы, фәнни коммунизм һәм Совет дәүләтенә караган мәсьәләләрне фәнни өйрәнү; Татарстан территориясендә яшәгән халыкларның тарихи тәҗрибәләрен гомумиләштерү; философия, экономика һәм хокук фәннәренең актуаль проблемаларын эшкәртү; әдәбият һәм тел белеменә, этнография һәм сәнгатькә, педагогикага, социологиягә караган тикшеренүләр һ. б. һ. б. «Татарстан партия оешмасы тарихы буенча очерклар», «Октябрь кояшы астында», «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр», «Октябрь революциясе һәм иҗтимагый прогресс», «Идел буенда Октябрь», «Татарстанда ленинчыл милли политиканың тантанасы» кебек коллектив хезмәтләрнең, Совет чорына караган күп кенә документаль җыентыкларның басылып чыгуы Совет власте елларында Татарстанда барган зур социаль-политик һәм экономик үзгәрешләрнең, иҗтимагый фикер үсешенең, культура революциясенең шактый тулы картинасын күз алдына бастырырга ярдәм иттеләр. Шуның белән бергә, бай фактик материалга таянып язылган мондый коллектив хезмәтләр иҗтимагый фәннәрнең башка тармакларында эшләүче галимнәр өчен ныклы база, методологик нигез булып торалар. Бу — аларның фәнни һәм практик кыйммәтен тагын да үстереп, көчәйтеп җибәрә.

Татар халкының иҗтимагый-политик фикер үсеше һәм Татарстандагы культура революциясе мәсьәләләренә соңгы елларда язылган хезмәтләрдә күп урын бирелә башлады. Бирергә без, барыннан да элек, СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан хәзерләнеп, 1955—1960 елларда дөньяга чыккан ике томлык «Татарстан АССР тарихы»н билгеләп үтәргә тиешбез. Татарстан республикасының тарихи үткәнә һәм бүгенгесе эзлекле төстә беренче тапкыр шушы китапта яктыртылды. 1968 елда институт коллективы «Татарстан АССР тарихы»ның бер томлык яңа басмасын чыгарды (редакция коллегиясе Ж. Гыйльманов, М. Мөхәррамов, Ю. Смыков, А. Халиков, Х. Хәсәнов). Элекке басмасы белән чагыштырганда, бу хезмәттә Татарстан тарихына караган күп кенә мөһим проблемалар, шул исәптән, татар халкының иҗтимагый-политик фикер үсешенә һәм мәдәниятенә караган мәсьәләләр дә, яңача куелган, яңача чишелгән. Татар халкының этногенезы хакындагы мәсьәләгә яңача киленгән, Казан ханлыгының иҗтимагый-политик тарихы һәм культура үсеше сыйнфый позицияләрдән чыгып аңлатылган, XIX йөз ахыры һәм XX йөз башындагы буржуаз татар милләтендәге социаль көчләрнең көрәше тагын да ачыграк һәм тулырак сурәтләнгән, Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларында татардагы төрле катламнарның политик позицияләре тулырак аргументлар ярдәмендә яктыртылган. Безнең уебызча, Татарстандагы культура революциясенә караган төп проблемалар исә, киресенчә, уңышсызрак тасвирланган, аны аерым бүлекләр буйлап таратып-чәчеп бетергәннәр, культура революциясенә караган мәсьәләләр алдан билгеле фикерләрне фактлар белән беркетеп бару планында гына яктыртылган. Әмма, кайбер җитешсез яклары булуга да карамастан, Татарстан тарихы буенча язылган яңа коллектив хезмәт галимнәребез игътибарын безнең республика тарихының актуаль проблемаларын киләчәктә тагын да тирәнрәк тикшерүгә юнәлтә.

Татар халкының революциягә хәтле булган мәдәнияте һәм иҗтимагый-политик фикерен яктыртуга багышланган хезмәтләр арасыннан тагын Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында мәрхүм проф. Н. Воробьевның һәм Г. Хисаметдиновның фәнни җитәкчелегендә эшләнгән «Идел буе һәм Урал алды татарлары» исемле китапны күрсәтергә мөмкин. Хезмәттә Урта Идел һәм Урал буйларындагы татарларның төп группаларына хас бөтен якларны (материаль, социаль, рухи тормыш, фольклор) яктыртырга беренче омтылыш ясала, озак гасырлар дәвамында культурадагы төрле элементларның формалашу тарихы һәм, социаль-экономик шартларга бәйле рәвештә, аларның үзгәрә барулары күздән кичерелә. Татар халкы формалашуның барлык яклары тигез һәм тулы яктыртылмаса да, бу мәсьәләнә хәл итүдә алга таба җитди адым ясалган. Китапның исеме татар милләте барлыкка килү проблемасына күп мәртәбә тирәнрәк, төптәнрәк карауны таләп итсә дә, авторлар аңа, кызганычка каршы, шактый схематик һәм декларатив төстә генә якын килгәннәр.

Совет чоры тарихына караган коллектив хезмәтләрдән 1965 елда басылып чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы» турында да

җылы сүз әйтми узып булмый. Үз вакытында бу китап җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәя алган иде, хәзер ул рецензияләрнең эчтәлеген сөйләп торуның хаҗәте юктыр дип уйлыйм. Шул кадәресен генә билгеләп үтик: беренчедән, хезмәттә совет власте елларында татар совет әдәбияты узган зур юл, милли әдәбиятта социалистик реализмның формалашуы тәүге тапкыр диярлек эзлекле рәвештә һәм билгеле бер системага салып күзәтеп чыгылды, икенчедән, татар культурасындагы бик күп күренекле кешеләрнең хаксызга онытылган исемнәре кабат кайтарылды. Нәтиҗәдә әдәбият тарихчылары буржуазия идеологларына каршы көрәштә үз позицияләрен күп мәртәбә ныгыта алдылар.

Гомум теоретик характердагы яки совет чоры тарихы буенча аерым галимнәрнең хезмәтләренә килгәндә исә барыннан да элек проф. М. И. Абдрахмановның диалектик материализм турындагы китабын күрсәтеп үтәргә кирәк. Ул үз өлкәсендә татар телендә язылган беренче оригинал хезмәт булды, киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты.

Совет властеның 50 еллыгына И. М. Ионенко һәм И. Таһировлар «Казанда Октябрь» исемле китап чыгардылар. Аның эчтәлеге турында сөйләп торуның хаҗәте юк, ул укучылар тарафыннан җылы каршыланды, матбугатта уңай бәя алды.

Татарстанда гражданнар сугышы һәм 1917—1920 елларда милли дәүләт төзелеше проблемаларын фәнни тикшерену өлкәсенә проф. М. Мөхәррәмов зур өлеш кертте. 1969 елда аның ике зур хезмәте — «Октябрь һәм Татарстанда милли дәүләт төзелеше» (Мәскәү, «Фән» нәшрияты) һәм «Татарстанда гражданнар сугышы. 1918—1919» исемле китаплары басылып чыкты.

Татарстан АССР төзелүе темасының кайбер аспектлары проф. И. М. Климов («Татарстан АССРның төзелүе һәм үсеше. 1920—1926». Казан, 1960), проф. Ф. Фаткуллин, доц. Ш. Хафизов һ. б. хезмәтләрендә яктыртылган.

Фәннәр докторы Я. Шәрәпов РКП(б)ның милли секцияләре хакында монография язды. Анда, совет тарих фәнендә беренче буларак, Коммунистлар партиясе милли секцияләренең эшчәнлеге, аларның КПСС-ның милли политикасын, В. И. Ленин һәм Партиянең Үзәк Комитеты директиваларын тормышка ашырудагы роле киң яктыртылган. Доц. М. Р. Булатов татар социалистик милләте формалашуын өйрәнү өлкәсендә уңышлы эшләп килә. Фәннәр кандидаты М. Мусин СССРдагы милли мөнәсәбәтләрне һәм культура мәсьәләләрен тикшерә. Доц. Т. Насыйров Татарстанда партия-совет матбугатының формалашу һәм үсү тарихы турындагы зур хезмәтен тәгәлләде.

Татарстанда революцион хәрәкәт, Октябрь революциясен хәзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашкан күренекле революционерлар һәм партия-дәүләт эшлеклеләре, гражданнар сугышы геройларының бай тормыш юлын, якты образларын укучыларга җиткерү өлкәсендә дә шактый эш башкарылды. Х. Ямашев, Е. П. Табейкин, М. Вахитов, К. Якубов, С. Сәетгалиев, С. Гафуров, Х. Урманов, Ш. Усманов һ. б. турында Р. Нәфиков, М. Мөхәррәмов, Х. Хәсәнов, И. Анисимов, М. Сәйдәшева, А. Юсупов, М. Касыймов, А. Яхин китапларын һәм брошюраларын күрсәтеп үтәргә кирәк.

Соңгы вакытта галимнәребез татар халкының иҗтимагый-политик фикер тарихын һәм Татарстандагы культура революциясенең күп кенә актуаль мәсьәләләрен өйрәнү буенча да мәгълүм бер эш башкардылар. Хәзер инде татар халкының борынгы һәм урта гасырлардагы (иҗтимагый, сәяси, материаль һәм рухи) тарихын проф. А. Халиков һәм доц. Ш. Мөхәммәдъяров хезмәтләреннән, алдынгы иҗтимагый-политик фикернең үсешен һәм, иң элек, узган йөз ахырында, егерменче йөз башында марксистик идеологиянең татар халкының иҗтимагый фикер үсешенә уңай йогынтысын проф. Р. Нәфиков монографияләреннән, XIX йөзнең икенче яртысындагы һәм XX йөз башындагы алдынгы иҗтимагый фикер агымнарына һәм аның аеруча күренекле эшлеклеләренә бәя бирүне доц. К. Фасеевның мәгълүм китабыннан, татарның төрле сыйныфый катламнарының 1905—1907 еллардагы революциядә үз-үзләрен ничек тотышын фәннәр докторы Х. Хәсәнов хезмәтләреннән башка күз алдына китерү кыен булачак. Профессор Е. П. Бусыгин Идел буе халыкларының, шул исәптән татар халкының этнографиясе буенча кыйммәтле хезмәтләр бирде. Татар халкының экономик фикер тарихын өйрәнү өлкәсендә доцент Ф. Газизуллин уңышлы эшләп килә.

Әдәбият белгечләре, әдәбият тарихын өйрәнүчеләр көче белән мең еллык әдәбият тарихыбызның азмы-күпме тулы картинасы булдырылды. Профессорлар М. Гайнуллин, Х. Госман, И. Нуруллин, фән докторы Г. Халит тарафыннан бу өлкәгә

караган житди тикшеренүләр эшләнде, фәннәр кандидаты Х. Хәйри татар романының формалашуы һәм үсеше турындагы монографиясен тәмамлады, фәннәр докторы Х. Ярми һәм фәннәр кандидаты И. Надиров халык авыз иҗатына караган, фәннәр кандидаты Б. Гыйззәт театр тарихы буенча кызыклы хезмәтләр яздылар, Татарстанның музыка һәм сынлы сәнгатенә багышланган аерым җыентыклар басылып чыкты, мәрхүм профессор В. М. Горохов һәм фәннәр докторы Я. Ханбиков татарлардагы мәгариф эшенә һәм педагогик фикер тарихына караган җитди хезмәтләр бирделәр. Н. Исәнбәтнең 3 томнан торган «Татар халык мәкальләре» культурабыз үсешенә зур казаныш булып керде.

Шулай итеп, хәтта иң гомуми характерда, өстән-өстән генә ясалган күзәтү дә Совет власте елларында татар халкының иҗтимагый-политик фикер үсеше тарихын һәм культурасын өйрәнү юлында җитди адымнар ясалуы хакында сөйли. Нәтиҗәдә, бу өлкәгә караган күп нәрсәләргә фәнни ачыклык кертелде, тарихның моңа чаклы безгә билгесез булган яңа сәхифәләре ачылды. Башкарылган эшләр күп, нәтиҗәләр куандырырлык. Болар иҗтимагый фәннәр өлкәсендә марксизм-ленинизм методологиясен эзлекле куллануның нәтиҗәсе. Шуның белән бергә, эшләнергә тиешле нәрсәләр, галимнәребез инде тотынган һәм уңышлы рәвештә хәл итеп килә торган актуаль проблемалар да җитәрлек. Хәзер шуларның кайберләренә тукталып үтик.

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга карата КПСС Үзәк Комитеты тезислары татар совет халкы тарихын, социалистик Татарстанның иҗтимагый-политик тормышын һәм культурасын өйрәнүче галимнәр алдында чикләнмәгән мөмкинлекләр һәм зур перспективалар ача. Татар халкының Совет власте шартларында узган илле еллык тарихы, социалистик Татарстан тарихы күп кенә актуаль мәсьәләләрне кабат көн тәртибенә куюны һәм яңача яктыртуны таләп итә.

Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, иҗтимагый фәннәр беренче чиратта хәл итәргә тиешле актуаль мәсьәләләрнең берсе социалистик татар милләтенең формалашу һәм үсү тарихын һәрьяклап тирәнтен өйрәнүгә кайтып кала. Бу, башка күп кенә сәбәпләрдән тыш, соңгы елларда СССР халыклары арасындагы мөнәсәбәтләргә игътибарның бик нык артуы белән дә аңлатыла. Мәскәүдә, Балтик буенда, Кавказ һәм Урта Азиядә, Волгоград шәһәрендә уздырылган фәнни конференцияләр шул хакта сөйли. «Вопросы истории» журналы битләрендә милләтләр хакында уздырылган мәгълүм дискуссия дә шул фикерне раслый. 1967 елда Татарстанда ленинчыл милли политиканың тантанасы, интернациональ тәрбия мәсьәләләренә багышланган фәнни конференция үзебезнең Казан шәһәрендә дә уздырылды.

Социалистик татар милләте күптән формалашты, бу мәсьәлә буенча әллә никадәр әдәбият тупланды, теманың методологик нигезләре дә җитәрлек эшкәртелгән, тик әлегә хәтле төпле бер монографиянең генә басылып чыкканы юк. Билгеле булганча, Советлар Союзындагы теләсә кайсы милләтнеке кебек үк, социалистик татар милләтенең формалашуы да гаять катлаулы һәм күп планлы процесс. Ул тарихи, экономик, философик, тел, әдәби һәм башка күп мәсьәләләрне хәл итүне сорый, димәк, фәннең төрле өлкәләрендәге галимнәрнең бергәләп эшләүләре таләп ителә. Кызганычка каршы, бездә нәкъ әнә шул нәрсә йомшаграк куелган.

Социалистик татар милләте формалашу процессының эчтәлеген тәшкил иткән эреле-ваклы төрле аспектлар арасыннан тагын бер мәсьәлә аерым игътибар бирүне сорый. Сүз иҗтимагый-политик фикер үсешенең югары казанышы булган марксизм-ленинизмның татар халкы аңына үтеп керүен өйрәнү турында бара. Безнең тарих фәнендә халыкның Октябрьдан соңгы иҗтимагый-политик фикер үсеше я тиешенчә өйрәнелми, я бу процесс артык гадиләштереп аңлатыла. Хәлбуки, әлеге рухи байлыкның татар халкы аңына кереп урнашуы, яңа тормыш төзү уе белән көрәшкә күтәрелгән меңнәрнең күңел түренә барып җитүе өчен еллар һәм дистә еллар кирәк булган, революцион карашлы алдынгы укымышлыларның армыйталмый эшләве таләп ителгән. Фәнни социализмны эшчеләр хәрәкәте белән кушу турындагы ленинчыл положение Октябрьгә кадәрге чорга гына карый дип аңлау дөрес булмас иде. Тормыш раславынча, бу бурыч үзгәртелгән төстә һәрбер яңа буын алдына килеп баса. Бу мәсьәлә тагын шул яктан мөһим, Татарстанда дөньяга марксистик-ленинчыл карашның кешеләр аңында, фәндә, культурада ныгып урнашуы төрле вак буржуаз милләтчел группалар белән, республиканы ленинчыл милли политика юлыннан тәртеп төшерүгә азапланган группалар белән кискен көрәш процессында барды. Болар һәммәсе В. И. Ленинның идеялар

тарихы — идеяләрнең алмашыну, димәк ки, аларның көрәш тарихы да ул, дигән фикеренә менә дигән иллюстрация була ала.

Безнең галимнәргә Татарстандагы культура революциясе тарихының хезмәт иясе массаларын рухи коллыктан һәм томаналыктан чыгарган, аларны кешелек җәмгыяте тудырган мәдәни байлыкларга тарткан икенче бер актуаль проблемасын эшкәртү буенча да күп көч куярга туры киләчәк. Тарихи яктан алып караганда, кыска гына бер ара эчендә элекке күпчелек халкы укый-яза белмәгән республика фән һәм культура биеклекләренә зур сикереш ясый. Татарстандагы культура революциясе, бигрәк тә аның сугышка кадәрге этабы, тарих, әдәбият буенча язылган китапларда, төрле статистик җыентыкларда шактый яктыртылган. Бүгенге көнгә бу проблеманың аерым аспект һәм мәсьәләләрен өйрәнү буенча билгеле бер тәҗрибә тупланган, нигездә 20—30 нчы еллардагы культура революциясенә караган күп кенә чыганаклар барланган һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Шулай да безнең әле Татарстандагы культура революциясенең тулы эчтәлеген (үткән эпохаларның мирасын тәнкыйть күзлеге аша карап файдалану, халыкның культура дәрәҗәсен күтәрү, аң-белем тарату, элекке милли төбәкнең артталыгын бетерү, түләүсез гомуми укыту кертелү, хезмәт ияләрен яңа баштан тәрбияләү, яшь буынны коммунизм һәм интернационализм рухында тәрбияләү, милли интеллигенциянең артуы, социалистик милли әдәбият һәм сәнгатьнең тууы һ. б. һ. б.) чагылдырган фундаменталь бер хезмәт күрү бәхетенә ирешә алганыбыз юк. Тагын шунысын истә тотарга кирәк: әлеге процессларның барысы да гаять үзенчәлекле шартларда барды. Шулар арасыннан республика халкының милли яктан төрлелеге, төбәкнең аграр характерда булуы, ислам диненең көчле йогынтысы һәм кайбер башка факторларны күрсәтергә мөмкин.

Шунысы куандыра, хәзер бу теманы эшкәртүгә тәҗрибәле галимнәребез алынды, ул СССР ФА Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни-тикшеренү эшләре планына кертелде. Бу үзенең уңай нәтиҗәләрен бирергә тиеш.

Киң колач белән коммунизм төзү чорындагы культура үсеше мәсьәләләрен тикшерү һәм яктыртуга җитди игътибар кирәк. Бусы культура революциясенең соңгы этабы булачак. КПСС Программасында күрсәтелгәнчә, бу этапта коммунизмның җиңүе өчен кирәкле бөтен культура шартлары тудырылырга тиеш. Культура революциясен тормышка ашыруда партиянең җитәкчелек ролен күрсәтү — галимнәребезнең җаваплы һәм мактаулы бурычы.

Иҗтимагый-политик фикер тарихын өйрәнүче галимнәрнең игътибары, һичшиксез, Татарстанның совет чоры тарихын, республикадагы социаль-политик процессларны, культура проблемаларын, интернациональ тәрбия мәсьәләләрен фәнни тикшерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Шуның белән бергә, Октябрьга кадәрге чор тарихы проблемалары да читтә калырга тиеш түгел. Бу өлкәдә эшләнәсе эшләр күп әле.

Иң элек татар халкының этногенезы, ягъни килеп чыгышы хакындагы мәсьәлә күзгә ташлана. Шуны ахыргача дөрес хәл итми торып, иҗтимагый-политик фикер үсешенә һәм культурага, шулай ук татарларның ерак узганына караган башка мәсьәләләрне тирән тикшереп булмаячак. Бу мәсьәлә буенча нинди генә теория һәм концепцияләр, капма-каршы тезислар яшәп килмәде. Аларның үзләре белән танышып чыгу өчен генә дә калын бер том әсәр язарга кирәк булыр иде.

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга СССР Фәннәр Академиясенең тарих һәм философия бүлеге татар халкының килеп чыгышы буенча фикер алышу уздырды. Ул җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уяткан иде, ләкин ниндидер бер төпле, уртак фикергә киленмәде.

Аннан бирле 20 еллап гомер узды. Шул вакыт эчендә Казан галимнәре (Х. Гыймади, Н. И. Воробьев, Н. Ф. Калинин, А. Халиков, Ш. Мөхәммәдъяров һәм кайбер яшь тикшеренүчеләр) бу темага караган гаять катлаулы һәм буталчык мәсьәләләрне чишүдә билгеле бер адым ясадылар. Шулай да татар халкы һәм татар милләте формалашуның кайбер яклары хәзергә хәтле җитәрлек өйрәнелмәгән, фәнни хәл ителмәгән, татар халкы барлыкка килүнең төп этаплары анык билгеләнмәгән. Татар халкының килеп чыгышын һәм этник тарихын башка кардәш һәм күрше халыкларның этногенезы белән бәйләп өйрәнү җитми. Һәм инде хәзер үк бер нәрсә ачык: тарихчылар, археологлар, этнографлар, антропологлар, телчеләр, әдәбиятчылар, фольклорчылар, философлар һәм иҗтимагый фәннәрнең башка вәкилләре берләшеп, кулга-кул тотынып эшләгәндә генә бу мәсьәләне уңышлы хәл итеп булачак.

Татар халкының килеп чыгышын фәнни

хәл итү эше үз вакытында СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырылган иде. Хәзер бу мәсьәләләрне өйрәнү буенча киеренке эш бара. Күп тә үтмәс, институт галимнәре безне бу мәсьәләгә караган кызыклы яңа хезмәтләр белән шатландырырлар дип ышанасы килә.

Галимнәребезнең игътибар үзәгенә куелган актуаль темаларның тагын берсе — XVI йөзнең беренче яртысында һәм XVIII йөзләрдәге татар халкы тарихы. Татар халкының иҗтимагый-политик карашлары һәм культурасы формалашуда бу дәвер әһәмиятле роль уйнаган. Казан ханлыгы Россия составына кушылганнан соң, татар халкының язмышында тирән үзгәрешләр барлыкка килә. Россия составында яңа тормыш башлана, татар, рус һәм күп милләтле Россиянең башка халыклары арасында үзара дуслык, хезмәттәшлек көчәя, халыкларның көндәлек тормышында, культурасында үзара йогынты ясашу һәм ярдәмләшү күренешләре барлыкка килә.

Кызганычка каршы, татар халкы тарихындагы, аның иҗтимагый-политик фикер үсешендәге һәм культурасындагы бу этап турында моңарчы без бик аз белә идек. Хәлбуки, унсигезенче-унтугызынчы йөздә дөньяга чыккан буржуаз галимнәрнең басмалары арасыннан татар тарихының бу дәверен тегә яки бу рәвештә бозмаган бер генә әсәрне дә атап әйтүе читен. Рус халкының Н. Г. Чернышевский, Н. А. Некрасов кебек революцион-демократ уллары исә шул вакытта ук буржуаз тарихчыларның, рәсми фән вәкилләренең бу бозуларына кискен каршы чыкканнар, алар Казан татарларына карата җылы һәм дустанә мөнәсәбәттә булганнар, татар халкының телен, гадәт-йолаларын, тормыш-көнкүрешен өйрәнгәннәр. Әмма, ни генә булмасын, безнең тарихның бу чоры хәзергә җитәрлек өйрәнелмәгән һәм үзенең тикшеренүчеләрен көтә. Дөрес, галимнәребез татар халкы тарихындагы бу чорны эшләүгә дә ныклап керешеп киләләр шикелле. Халкыбыз тарихының бу дәвере буенча да «ак битләр» нык кимер, тарихчыларыбыз XVI—XVIII йөзләрне каплап торган караңгылык пәрдәсен тиздән алып ташларлар дип өметләнергә кала.

Совет галимнәренең революциягә чаклы иҗтимагый-политик фикер һәм культура үсеше тарихына багышланган хезмәтләре белән танышканда, шул нәрсә ачыклана: безнең фәндә XIX йөзнең икенче яртысы һәм XX йөз башы шактый тулы һәм нык өйрәнелгән. Шулай да бу чорга караган мәсьәләләр арасында да хәзергә хәтле җитәрлек өйрәнелмәгәннәре яки яңа тикшерелеп кенә ята торганнары байтак икән.

Капитализм эпохасында татар милләте формалашуның социаль-экономик алшартлары, закончалыклары һәм үзенчәлекләре, хронологик чикләре һәм компонентлары хакындагы мәсьәлә ахырынача чишелмәгән килеш кала бирә. Китаптан китапка, дәреслектән дәреслеккә татар милләте XIX һәм XX йөзләр арасында формалашты дигән тезис күчеп йөри. Әмма моңарчы шушы мәсьәләне һәрьяктан әйбәтләп яктырткан берәр монография чыкканы юк. Бу проблеманы уңай хәл итүдә соңгы сүзне Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре әйтергә тиеш, чөнки ул институт коллективы башкарырга тиешле эш планына кертелгән.

Унтугызынчы йөзнең икенче яртысындагы һәм егерменче йөз башындагы иҗтимагый-политик хәрәкәттә төрле социаль көчләрнең бүленеше мәсьәләсен өйрәнүгә аеруча нык басым ясарга кирәк. Чөнки бу хакта әледән-әле бәхәс, дискуссияләр чыгып тора. Буржуаз һәм вак буржуаз карашлардан аермалы буларак, марксистик тарих фәне татар милләтенең бердәмлеге, татарлар арасында сыйныфлар һәм социаль каршылыклар булмау турындагы фикерләрне баштан ук кискен тәстә кире какты.

Буржуаз җәмгыятьтәге һәр сыйныф, интеллигенциянең алар интересын яклаучы төрле катламнары милли хәрәкәтнең характерына һәм максатларына үзләренә кулай эчтәлек салырга тырыштылар. Бу хәрәкәттәге революцион-демократик юнәлеш вәкилләре саналган шәһәр һәм авыл хезмәт ияләре милли, социаль изүгә аеруча кыю һәм эзлекле тәстә каршы чыктылар. Татар демократик интеллигенциясенең алдынгы вәкилләре шулай ук халык массаларының интересларын якладылар, татар җәмгыятендәге мәгърифәтчелек юнәлешенең төп эчтәлеген шуларның эшчәнлеге тәшкил итте. Чын күңелдән халыкны сөйгән, аның караңгылыкта яшәве һәм күргән җәбер-золымнары белән әрнеп яшәгән мәгърифәтчеләр крепостное правога һәм феодализм калдыкларына дошманлык күзе белән карыйлар, татар тормышын Европалаштыру, бөтен халыкны мәгърифәтле итү, аларны рус культурасына якынайту, милли әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерү өмете белән хыялланып яшиләр. Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннәр, Г. Махмудов, С. Кукляшов,

Г. Вәһапов, Х. Фәезханов кебек татар галимнәренең эшчәнлекләрендә һәм фәнни хезмәтләрендә, татар мәгърифәтчелегенең күренекле вәкилләре К. Насыйри һәм Ш. Мәрҗани иҗатларында мәгърифәтчелек идеяләре зур урын тота. Аларның демократлыгы бөтен халык, бөтен милләт өчен буржуаз прогресс таләп итүдән югары күтәрелмәсә дә (җәмәгать эшлеклеләре булварак аларның кимчелеге дә шунда), мәгърифәтчеләрнең тарихыбыздагы уңай ролен күрми узу гаделсезлек булыр иде.

XIX йөзнең соңгы чирегендә капитализмның кызу темплар белән үсүе аркасында ныгып һәм көчәеп өлгергән буржуазия үзен милли хәрәкәтнең җитәкчесе итеп игълан итәргә һәм ул хәрәкәтне үзенең сыйнфый максатларын тормышка ашыру өчен файдаланырга карар кыла. Милләтчелек аның идеологиясенә әйләнә, шулай итеп Россиянең мөселман халыклары арасында шактый киң таралган буржуаз милләтчелек юнәлеше формалаша. Безнең галимнәрнең хезмәтләрендә татар буржуазиясенең политик платформасы һәм идеологиясе, аның революцион-демократик һәм марксистик идеологиягә каршы көрәше шактый тулы яктыртылган. Ул хезмәтләр билгеле, аларның эчтәлеген сөйләп чыгу кирәкмәс. Шулай да, XX гасыр башындагы милли хәрәкәт һәм безнең әдәбиятта аңа бирелгән бәя уңае белән, бер генә моментка тукталып үтәсе килә. Тегеләр яки бу тарихи шәхеснең иҗтимагый хәрәкәттә тоткан урыны турында сүз барганда, кайбер әдәбият һәм тел галимнәре еш кына әлеге кешенең әдәбиятка, тел белеменә, журналистика өлкәсенә керткән конкрет өлеше буенча гына хөкем йөртергә яраталар, ә аның политик карашларын, нинди идеология уздыруын оныталар. Әгәр мондый юл белән барсак, безгә ачыктан-ачык буржуазиягә хезмәт иткән шәхесләрнең һәммәсен дә аклап бетерергә туры килер иде. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, без мондый юлга баса алмыйбыз. Әдәби-тарихи мираска мөнәсәбәттә без марксистик-ленинчыл принципларда нык торырга тиешбез. Татар халкының иҗтимагый-политик карашларын Ленин фикерләре яктылыгында өйрәнү үзенең уңай нәтиҗәләрен бирде инде, киләчәктә бу, һичшиксез, тагын да зуррак уңышларга китерер.

Әгәр без иҗтимагый хәрәкәткә 1905—1907 елгы революциядә үзләрен аеруча нык күрсәткән революцион-демократ интеллигенция вәкилләре (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Ш. Мөхәммәдов һ. б.) керткән өлешне билгеләп үтмәсәк, бу хәрәкәтнең төп юнәлешләре хакындагы карашыбыз тулы да, фәнни дә булмас иде. Бу юнәлешнең аерым күренекле вәкилләре соңыннан кыю рәвештә марксизм позицияләренә басты, яшәп килгән стройга каршы көрәштә марксизм положениеләрен яклап чыктылар (Х. Ямашев, Г. Коләхметов һ. б.). Галимнәребез Татарстандагы революцион хәрәкәтнең һәм иҗтимагый-политик фикернең нәкъ менә шушы юнәлешен өйрәнүдә зур уңышларга ирештеләр дә инде. Бу пландагы хезмәтләрдә татар, рус халыкларының иҗтимагый-политик фикер һәм культуралары үсешендәге үзара йогынты һәм ярдәмләшүне өйрәнү өчен зур мөмкинлекләр ачыла, ә шунсыз татар иҗтимагый фикерена, аның культурасына караган күп мәсьәләләрне бөтенләй аңлап та булмас иде.

Татар халкының революциягә кадәрге иҗтимагый-политик фикер һәм культура тарихы буенча соңгы елларда басылып чыккан хезмәтләрне күздән кичергәч, тагын бер мөһим мәсьәләгә игътибар итәргә кирәклеге аңлашыла. Сүз милли хәрәкәтнең аерым вәкилләренә, тарихи һәм әдәби күренешләргә һәм бигрәк тә революциягә кадәр чыккан вакытлы матбугат органнарына бәя биргәндә марксистик, сыйнфый, партияле мөнәсәбәтне көчәйтү кирәклеге хакында бара. Капитализм белән социализм арасындагы идеологик көрәш аеруча кискенләшкән бүгенге шартларда тарих, әдәбият, философия, хокук һәм башка фәннәр буенча язылган хезмәтләрдә «гомуми милли» яки «гомуми демократик» позицияләрдән торып фикер йөртүләргә урын калдырылмаска тиеш.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, соңгы елларда иҗтимагый фәннәрнең иҗади үсеше өчен уңай шартлар туды, галимнәр зур, катлаулы мәсьәләләргә кыюрак алына башладылар, фәнни кулланылышка кергән чыганаклар даирәсе чагыштыргысыз төрләнде. Ләкин бу әле үткән тормышның һәм бүгенге көннең актуаль мәсьәләләрен яктыртканда сыйнфый позицияне йомшартуга юл куярга яки аны күрми узарга хакыбыз бар дигән сүз түгел.

Һәрберебезгә мәгълүм: бүгенге идеологик көрәштә буржуазия берни белән санашып тормый. КПСС Үзәк Комитетының «Иҗтимагый фәннәрне тагын да үстерү һәм коммунистик тәзелештә аларның рольләрен күтәрү турында»гы 1967 елның августында

кабул ителгән карарында буржуаз пропаганданың бик нык көчәюе һәм антикоммунизмга каршы системалы һөҗүм сугышы алып барырга кирәклеге әйтелә.

Бүген марксистларга, шул исәптән иҗтимагый фәннәр өлкәсендә эшләүче галимнәргә, буржуазия агентларының ачыктан-ачык яла ягуларына, шау-шулы шапырынуларына каршы көрәшүдән бигрәк, аларның заманга яраклашырга тырышкан һәртөрле «модный» тезисларына, үтә оста яшеренгән әшәке теорияләренә каршы сугышырга туры килә. Үзләренең диверсия планнарын әзерләгәндә, буржуазия идеологлары совет халыкларының үткән тарихын һәм хәзерге хәлен, төрле социалистик милләтләрнең иҗтимагый-политик фикер тарихын һәм культуралары үсешен бозып күрсәтүгә аеруча нык игътибар бирәләр.

В. Коларз, Р. Пайпс, Герхард фон Менде, Дәүләтшин, М. Мусабай, Т. Уяибек, А. Акиш кебек буржуазия ялчылары татар халкының тарихын һәм культурасын нәкъ әнә шулай бозып аңлаталар. Үзләренең күп санлы мәкалә һәм китапларында, XVI—XVIII йөзләрдәге татар тарихын язганда, буяуларны юри куертып җибәрәләр, татар буржуазиясен идеаллаштырып күрсәтәләр, аның барлык эш һәм гамәлләрен уңай яктан гына бәялиләр, фактларга каршы барып булса да, капитализм эпохасындагы татар милләте эчендәге сыйнфый аерымлыкларны инкарь итәргә маташалар. Әлеге «белгечләр» Татарстанда ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру турында аеруча күп ялалар, аны оятсыз рәвештә бозалар, шуннан аны яманлыйлар. Америка профессоры Р. Пайпс үзенең «Советлар Союзында мәгариф эше. 1917—1923 елларда коммунизм һәм милләтчелек» (1954 ел) исемле китабында Россия халыкларын большевизмга битараф карый торган соры масса төсендә сурәтли. Француз буржуаз галимнәре А. Беннигсен һәм Келькеженың «Россия мөселманнарының милли хәрәкәте. Татарстандагы солтангалиевчелек» дигән китаплары мәгълүм. Авторлар, бөтен көчләрен куеп, татарлар арасында революцион хәрәкәт зәгыйфь иде, алар социалистик революциядә катнашмадылар, дип исбатларга азапланалар. Чынында исә 1905—1907 елларда марксистик әдәбият татарлар арасында гаять киң таралган була. «Урал», «Азат», «Азат халык», «Фикер» кебек матбугат органнарында большевикларның мәкаләләре, марксистик хезмәтләрдән тәрҗемәләр күпләп басылган. Татарстанда революцион хәрәкәт милли азатлык хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә үскән. Шул җәһәттән Октябрьга кадәрге чорда татарлар арасындагы революция һәм милли-азатлык хәрәкәтләрен өйрәнү, татар милләтенең үсеш һәм сыйнфый аерымлану проблемаларын һәм андагы эшчеләр контингентын өйрәнү искиткеч әһәмиятле төс ала. РСДРП-ның Казан комитеты эшчәнлеге тарихчылар игътибарын үзенә аеруча нык җәлеп итәргә тиеш. Казан партия оешмасының эшчәнлеге тарихи әдәбиятта әле тиешенчә яктыртылмаган. Бу мәсьәләгә караган махсус хезмәтләр юк диярлек. Дөньядагы иң алдынгы иҗтимагый-политик фикер саналган һәм кешелек җәмгыятенең алга таба объектив үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән, әлеге җәмгыятьне үзгәртеп кору өчен барлыкка килгән марксистик-ленинчыл идеология, аның халык массалары аңына үтеп керүе тарих фәнендә беренче чиратта яктыртылырга һәм өйрәнелергә тиеш.

Татар культурасының демократик, алдынгы элементлары Идел һәм Урал буйларындагы башка халыкларның культуралары үсешенә дә уңай йогынты ясаган. Татар халкы үзе бөек рус һәм башка халыклар, шулай ук прогрессив дөнья культурасының бәрәкәтле йогынтысын татыган. Рухи байлыклар алмашуның гүзәл традицияләре, үзара йогынты һәм тәэсир нәтиҗәсендә алдынгы татар культурасының үсеше тирәнтен өйрәнелергә тиеш. Бу теманы өйрәнүнең никадәр актуаль булуын аңлатып торасы юк, дип уйлыйм. Бер нәрсәне истән чыгармыйк: татар халкының иҗтимагый-политик фикер үсеше һәм культурасына караган актуаль мәсьәләләр совет галимнәре тарафыннан никадәр күбрәк өйрәнелгән булса, буржуазия идеологларына татар халкының, Татарстан республикасының тарихын бозып күрсәтү өчен мөмкинлекләр шулкадәр азрак калачак. Бүгенге заманның һәм үткән тарихыбызның бер генә фактын да буржуаз идеологлар ихтыяҗына калдырмаска!

...Без татар халкының иҗтимагый-политик фикер үсеше һәм Татарстандагы культура революциясе тарихын өйрәнүгә караган кайбер мәсьәләләргә генә тукталдык. Шунысы куанычлы: иҗтимагый фәннәр өлкәсендә эшләүче галимнәребез олы юбилейларга буш кул белән килмәгәннәр икән. Бәйрәмне алар кызыклы, төпле монографияләр һәм коллектив хезмәтләр белән, шул ук вакытта зур, актуаль мәсьәләләргә җиң сызганып тотынган хәлдә — эш өстендә каршылыйлар.

**Сафа Сабиров**

# УЛ КӨННӘРДӘ

Гражданнар сугышы вакытында Идел хәрби флотилиясе өчен пароходлар коралландыручы, суднолар төзү остасы һәм хезмәт ветераны Ленин ордены кавалеры И. Н. Орловна багышлана.

АВТОР.

Инде төн уртасы җитеп килә, мин һаман йокыга китә алмый ятам. Күзгә йокы керми, башка берсеннән-берсе борчулы һәм эч пошыргыч уйлар килеп алҗыта.

Бу көннәрдә берни аңлар хәл юк, дөньяның асты-өскә килеп буталып бетте. Иделнең уң ягында — Казаннан чигенгән кызыл гаскәрләр; сул ярында — аклар, шәһәр белән Васильево арасында аларның бронепоездлары йөреп тора. Безнең затон ике ут арасында торып калды. Су өстендә каты сугыш бара. Төннәрен бигрәк шомлы була. Әнә хәзер дә, баш очында гына күк күкрәгәндәй, туплар шартлаудан тирә-юнь гөрселдәп тора, тәрәзәләр зыңгылдый, караңгы күкне телгәләп аҗаганнар уйный башлый.

Казан әле дошман кулында. Аклар, имеш, тиздән Идел аша чыгып, Нижний Новгородка юл тоталар, аннан туп-туры Мәскәүгә барып җитәргә җыеналар, ди. Тимер юл күперен алмакчы булып, дошман туктаусыз һөҗүм итә. Ләкин Кызыл флотилия күперне нык саклый, чакырылмаган кунакларның артсабагын укытып, бер-бер артлы дөмбәсләп тора.

Минем абый да шунда — «Дельфин» корабында хезмәт итә. Ә без затонда буксир пароходларны сугыш корабларына әйләндерәбез, броня белән ныгытабыз, туплар, пулеметлар белән коралландырабыз.

Тик шунысы начар, кемнәрдер күңелсез хәбәр тарата: безнең гаскәрләр чигенә, безне, аклар кулына төшермәс өчен, баржаларга төяп тылга озатачаклар.

Ул да түгел, ер-яңа хәбәр тарала: берниндм чигенү юк, безнең затон Кызыл флотилиянең ремонт базасы булачак. Шулай дип Ленин үзе фәрман биргән.

Бу сүздән эчкә җылы керә. Җиңнәрне ныграк сызганып тотынабыз. Пароход артыннан пароходны фронтка озата торабыз. Без китсәк, боларны кем эшләр, флотилиягә кем ярдәм итәр!..

Бүген көндез дә бер буксир пароход безнең затонга «Сережа» форт-баржасын алып керде. Аңар утырып комиссар Маркин үзе килгән.

Пароходы ике морҗалы. Мачта башында кызыл флаг җилферди. Баржаның иркен палубасында озын көпшәле туплар, пулеметлар, кораллы матрослар. Безнең эшчеләрдән кемдер бик хәйран калган хәлдә, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Простой баржа гына түгел, нәрсә йөзмә крепость икән бу... Моның бер генә тубы да көлеңне күккә очырыр...

Комиссар Маркин гадәтенчә житез хәрәкәтле, әмма никтер борчылган кыяфәтле иде.

— Әйе, туплар куәтле, болар белән дошманның кирәген бирергә була,— диде ул.— Ләкин, дуслар, шунысы җайсыз: тупларның күпчелеге без теләгәнчә күтәрелми, шунлыктан тау башына урнашкан дошман батареяларына каршы якын дистанциядән ут ачып булмый... Ышаныч сездә, иптәшләр. Әйдәгез, уйлашыйк-киңәшик.

Без ни әйтергә белми аптырап калдык, бер читтәрәк басып торган мастерга карадык. Иске белгечләр үз эшләренә катнашуны өнәп җиткермиләр, яңа властька теләр-теләми генә хезмәт итәләр. Ачыктан-ачык сиздермәсәләр дә, акларның килүен, иске тәртипләрнең кире кайтуын көтәләр. Безнең мастер да шундый адәм булса кирәк.

Комиссарның сүзләрен ишетүгә, ул:

— Юк, безнең шартларда бу мөмкин хәл түгел,— дип кылыч борыны өстендәге пенснэсе белән кайнашырга тотынды.— Безнең затонда тупларга өстәмә ныгытма куярлык материал да, белгечләр дә юк. Комиссар әфәнде, сезгә Нижний Новгородка барырга туры киләчәк.

Комиссар тиз генә чигенә торганнардан түгел икән. Ул мастерның сүзләрен игътибар белән тыңлаганнан соң: «Әйдәгез әле, цехларны, складларны карыйк»,— дип, мастерны да, эшчеләрне дә үзе белән ияртеп алып китте.

Менә без «Сережа» палубасында. Якыннан караганда туплары исәң-акылың китәрлек зур. Күпчелеге шундый юан, чынлап әгәр, колач җитмәслек. Һәр туп бүрәнәдән кисеп алынган бүкән төсле тәбәнәк тимер тумбага куелган. Әнә шул тумбаларны кимендә егерме сантиметрга биегәйтергә кирәк икән. Ягъни безнең кара исәп белән биш вершок чамасы була инде.

— Комиссар әфәнде, белгеч буларак, мин сезгә алдан әйтеп куям, безнең шартларда бу була торган эш түгел,— дип, мастер тагын яр буенда әйткән сүзен кабатлады.— Монда төгәл исәп кирәк, материал кирәк, мондый эшне буш энтузиазм белән генә эшләп булмый...

Бу минутта безнең бригадир Архипов палубага тизләнгән дә кулындагы метр белән туп тумбасының биеклеген һәм юанлыгын үлчәп маташа иде.

— Николай Григорьевич, минемчә, бер әмәл бар кебек,— диде ул, комиссарга карап.— Бу тумбаны биегәйтү өчен аның астына каты агачтан ясалган калын борыс куярга да палубага болтлар белән беркетергә кирәк. Башта берсен сынап карыйк. Әгәр барып чыкса, бүтәннәрен дә шулай итәрбез.

Комиссарның кырыс йөзе берьюлы яктырып китте:

— Иптәш Архипов, бу, һичшиксез, барып чыгарга тиеш. Егетләреңә әйт тә хәзер үк тотыныгыз. Үзегез беләсез, вакытның һәр минуты кадерле, алда кызу эш көтә. Берәүләр мастерскойга кайтып борыслар әзерли башласын, башкалары болтларны сүтә торырлар. Кирәк булса, әйтербез, безнең егетләр дә булышыр. Слесарьларга әйтегез, өйләренә кайтып вакыт үткәрмәсеннәр, матрослар белән бергә биздә генә ашарлар... Бөтен көчне куеп тырышырга кирәк, фронт бездән шуны таләп итә.

Һәм без тырыштык, ару-талуны белмичә көн буе эшләдек. Кич җитәрәк, кояш аргы яктагы Зөя таулары артына авышып барганда, без инде эшләрне тәмамлап, хәрби диңгезчеләр белән бергә, Иделгә чыгып тупларны сынап бетергән идек.

Инструментларны катерга төяп затонга кайтырга чыкканда, комиссар Маркин диңгезчеләр исеменнән рәхмәт әйтеп кулларыбызны кысты, һәм балаларча сөенеп:

— Булмый дигәннәр иде, булды бит! — диде.— Дуслар, без моннан туп-туры ялга китәбез. Болай булгач, белеп торыгыз, «Сережа» тупчылары дошманга күрмәгәнен күрсәтерләр әле...

Комиссар дөресен әйтә, безгә моннан һич тә китәргә ярамый. Әнә Иделдә каты сугыш төнне-төн буе дәвам итә, туплар өзлексез гөрселдәп тора. Димәк, иртәгә затонга яңа кораблар киләчәк. Без кучеп китсәк, аларны кем ремонтлар?..

Уйланып ята торгач, акрынлап күзләрем йомыла башлады, һәм мин нәрсә йокыга киткәнмен...

* * *

Иртәгесен нәкъ мин уйлаганча булды: мин эшкә барып кергәндә, затон уртасында кораллы «Ольга» пароходы якорьга туктап, ремонт көтеп тора иде инде. Җыелышып бетү белән безне катерга утыртып шунда алып киттеләр.

Идел белән Камада купец Стахеевның икмәк баржаларын тартып йөргән бу буксирны мин бик яхшы беләм. Затонга урнашканчы бер җәйне мин анда кочегар булып йөргән идем. Сугыш безнең якларга килеп җитәр алдыннан аны хәрби кораб иттеләр. Казанны һәм Зөя күперен акларга бирмәс өчен барган сугышларда катнашып, ул шактый ук какшаган, шуңа күрә тиздән башланачак яңа һөҗүмнәр алдыннан бераз «дәваланып алырга» затонга кергән иде.

«Ольга» командиры Иван Дойниковны да күреп беләбез. Хәер, ул атаклы диңгезчене флотилиядә белмәгән кеше дә юктыр. Корабның элекке командиры куркак бер адәм иде, дошман белән очрашмый, күбрәк оборонада ятарга ярата, бәрелеш вакытларында еш кына каушап кала иде. Комиссар Маркин аның урынына командир итеп Балтик диңгезчесе Дойниковны куйгач, «Ольга» әледән-әле хәтәр рейдларга чыга, караңгы төннәрдә кинәт һөҗүм итеп, дошманны өркетә башлады. Матрослар Дойниковны үз итеп өлгерделәр, аның белән утка-суга керергә әзер иделәр.

Команда палубага җыелып ял иткән сәгатьләрдә Дойников матур итеп җыр җырлаучы, үзе чыгарган такмакка тыпырдап биюче, көлдерә-көлдерә мәзәкләр сөйләүче ачык күңелле иптәш булып китә.

Безне дә ул якты чырай белән каршылады.

— Безнең бер тубыбыз никтер киреләнә,— диде ул, безне алгы палубага алып чыгып.— Корабка гаскәри туп куйгач, сыерга ияр салган кебек була икән. Күрәсезме, палубаны нишләтеп бетерде...

«Ольга»ның алгы палубасында коры җирдә ат тартып йөртә торган ике көпчәкле, лафетлы туп тора. Аткан саен лафеты белән артка кага-кага палубаны янчеп бетергән, берничә урында хәтта тишеп тә чыгарган иде.

Дойников палубаны янә бер тапкыр күздән кичергәннән соң, туп өчен уңайсызлангандай:

— Бүген төнгә тагын походка чыгасы бар бит,— диде.— Шуңарчы ничек тә ремонтлап бетерәсе иде.

Без моны үзебез дә яхшы аңлыйбыз. Озын-озак юанырга вакыт юк. Туп урнашкан платформаны аркылыга-буйга үлчәдек, болтлар әзерләп, палубаны табаклы тимер белән ямадык та куйдык. Тагын да ышанычлырак булсын өчен туп торган платформасын агач борыслар белән калынайттык. Иделгә чыгып, туплардан атып, ныгытмаларны сынап бетергәндә көн инде кичкә авышып бара иде.

Затонга кайтырга җыенган чакта, Архипов белән мине Дойников читкәрәк чакырып алды да:

— Иртәгә кадәр сез икегез корабта калып торыгыз. Безнең машинистларыбыз аз. Иртәгә Нижнийдан килеп җитәргә тиешләр — диде.

Һич тә уйламаганда без, затон кешеләре, хәрби диңгезчеләр булып әвереледек. Бүген төнлә походка чыгабыз.

«Ольга»ның командасында кемнәр генә юк: иске флотта хезмәт иткән, Октябрь көннәрендә патша сараен алган чын диңгезчеләр дә, гомерендә кораб күрмәгән гади солдатлар да, Идел пароходларында лоцман, рулевой яки кочегар булып эшләгән елгачылар да бар. Ләкин машинаны бик яхшы белүче кеше — механик юк, шунсыз кораб походка чыга алмый икән.

— Иптәшләр, көн буе эшләп арыгансыздыр,— диде Дойников.— Сез хәзер ашагыз-эчегез дә кубрикта бераз ял итеп алыгыз. Юлга чыгар алдыннан сезне уятырлар.

Кичке эңгер якынаеп килгән чак. Иркенләп ял итәргә вакыт юк. Тиз генә тамак ялгап алдык та кораб Морквашы култыгында торган арада машина бүлегенә төшеп, механизмнарны тикшереп чыктык, цилиндрларны эшләтеп карадык. Яуга чыкканда иң мөһиме — казанда парның мул булуы. Мин шундук утны көчәйтеп, казанда парны күтәрергә керештем. Болай бар да төзек, команда булу белән кузгалып китәргә әзер торабыз шикелле.

Шул чак Архипов миңа ачкыч һәм чүкеч алып рубкага менәргә кушты. Мин култык астына инструмент ящигы кыстырып рубкага килеп кергәндә, җирән мыеклы лоцман Ефим Рахманцев белән рулевой егет штурвал янында маташалар, ә Дойников үзе өстәлгә җәйгән Идел картасына карандаш белән ниндидер билгеләр ясап утыра иде. Ачык изүле зәңгәрсу фланель күлмәк, киң балаклы кара чалбар кигән. Кара бескозырькасының тасмасына алтын хәрефләр белән «Громовой» дип элек хезмәт иткән корабының исеме язылган. Пөхтә итеп төзәтелгән кыска мыегы аның йөзенә ачыклык биреп, яшәртеп тора иде.

— Карагыз әле, ни булды икән? — диде ул, эшеннән аерылып.— Штурвал никтер чыгымлый башлады... Әйбәт кенә эшләгән чакта, нәрсәседер ычкына да кинәт бушка әйләнә башлый, койрыкны бер якка да бормас була...

Штурвалның калай каплавычын ачып карадым. Борчылырлык берни дә юк. Бераз бушап калган гайкаларны ачкыч белән ныгытып, чылбыр оялярын яхшылап майлагач, штурвал тоткарсыз эшли дә башлады. Дойников көпчәкне әле уңга, әле сулга әйләндереп карагannан соң:

— Молодец, әйбәт булган бу,— дип мактап алды.

Түбәндә пар казанынnан, механизмнардан бүтән берни дә күрмисең. Ә югарыдан карaганда бөтен рейд күз алдында. Хәзер монда дистәгә якын кораб тупланган. Ленин фәрманы белән Балтикадан җибәрелгән үткен борынлы миноносецлар үзләре бер отряд булып түбәнге рейдта якорь салганнар. Алардан үрдәрәк икенче отряд: «Ваня», «Лев», «Олень» кораблары, йөзмә форт «Сережа» һәм тиз йөрешле разведка катерлары тезелеп киткән иде. Дойников безнә иллюминаторларны ныклап ябарга, морҗадан очкын чыкмасын, тышкы якка тычкан уты хәтле дә яктылык төшмәсен дип ныгытып кисәтеп куйды.

Төн карасы куера төшеп, елга өсте тынып калгач, якорьны күтәртергә, машинаны эшләтә башларга команда булды.

Түбәндә без икебез генә. Архипов машина бүлегендә, рупордан нинди приказ булса, шуны үтәргә әзер тора; мин гүләп торган пар казаны янында кайнашам. Ходта барган чакта пар бик күп китә, миңа бар көчемә тырышып эшләргә туры килә иде.

Баягынак, Моркваш рейдында торган вакытта ук әле, машина бүлегендә бик кызу иде. Хәзер, иллюминаторларны ябып куйгач, бигрәк тә бөркү булып китте. Пар казанынnан, цилиндрлардан аяусыз бөркелгән кызу сулышны кыса, тирләтә. Авыр тимер кисәү белән мичне болгатып алгач, башны краннан аккан суга чылатырга туры килә. Ахыр чиктә, инде һич түзәр хәл калмагач, топкага утын өстәдем дә чак кына хәл алырга дип палубага мендем.

Төнге салкынча һавада бик тиз җиңеләеп киттем. Караңгыга бераз күзләрем ияләшә төшкәч, күрәм: миноносецлар бер-бер артлы тезелеп, бездән алдарак елга уртасыннан баралар. Күп тә үтмәде, алар тау башларына урнашкан батареяларны тупка тота башладылар һәм, әлексез ата-ата, Казан пристаньнарына таба бик кызу төшеп киттеләр. Безнең отряд кораблары да дәррәү ут ачты. Тау башларында әле бер, әле икенче урында, төн карасын ярып, тубал чаклы ут чәчелә. Батареяларның көле күккә оча бугай.

Озак тамаша кылып торыр вакыт түгел. Хәл алуга йөгереп аска төштем, юан-юан утын түмәркәләрен мичкә тондырырга тотындым. Күрәм, машина бүлегендә Архипов та шабыр тиргә баткан, пиджагын салып җиңсез майкадан гына калган. Әмма үзе бирешми, рубкадан алынган һәр приказны шундук үтәп, машина белән идарә итеп бара.

Ниһаять, дошман тупчылары безне дә прицельгә элэктерделәр бугай, аларның снарядлары бик якында гына гөрселди башлады. Менә бер снаряд өстә каядыр төшеп, коточкыч каты шартлады һәм корабль, кире капланырга җыенгандай, бөтен корпусы белән чайкалып куйды. Икебез дә чак кына аяктан егылмый калдык.

Архипов кушуы буенча палубага чыксам, снаряд өстә шартлаган икән. Траптан йөгереп мостикка менсәм, ни күзем белән күрим: рубка яртылай җимерек, штурвал бер якка куптарып ташланган, төрлесе төрле якка ауган кешеләр хәрәкәтсез яталар; ярым караңгыда аларны танырлык та түгел иде.

Шул арада рубкага башкалар да менеп җитте. Лоцман белән койрыкчының үле гәүдәсен җимерек штурвал көпчәге арасыннан көчкә тартып чыгардык. Кораб командиры Дойников сул як ишек янында берниндн хәрәкәтсез йөзтүбән ята иде. Ике кеше ике ягыннан алып акрын гына күтәрә башлагач, ул аңына килде һәм ишетелер-ишетелмәс хәлсез тавыш белән:

— Тизрәк ут астыннан чыгарга тырышыгыз... Кешеләрне, корабны сакларга кирәк,— дип әйтә алды.

Штурвалсыз калган кораб бу минутта бер урында әйләнә, ә дошман тупчылары һаман ут яудыра: снарядлары якында гына төшеп шартлаган саен, су баганалары гөрселдәп күтәрелә иде. Безгә хәзер үк бу җәһәннәмнән котылырга кирәк, юкса эш хәрти. Каты яралы Дойников тагын шул сүзен кабатлады:

— Ярга таба тотыгыз... Тизрәк сайга ташланыгыз... Сайга...

Һәм шулай иттеләр дә: борыны белән Печищига таба борылган бер арада корабны бар куәтенә эшләтеп, ут астыннан алып чыктылар һәм сай җиргә утырттылар. Ниһаять, бер мәлгә котылдык бугай. Хәзер инде биек тау башыннан аткан дошман снарядлары безгә тими, югарыдан очып үтәләр дә елга уртасына төшеп шартлыйлар иде.

Әмма дошман безне күздән югалтмаган икән. Күп тә үтмәде, безнең өскә яр буеннан дошман пехотасы ташланды. Ярга якында гына сайга төртелеп хәрәкәтсез калган корабны ансат кына пленга алырга уйлап булса кирәк, һич тә сакланмыйча «ура» кычкыра-кычкыра киләләр һәм бу дәһшәтле ташкынга каршы торырлык берниндн көч юктыр шикелле иде.

Шул чак рубканың ачык ишек яңагына көч-хәл таянып Дойников аякка басты һәм кәтелмәгән куәтле тавыш белән:

— Кызыл матрослар, туганнар! Революция дошманнарына рәхимсез ут ачыгыз!..— дип кычкырды. Шундук комендорлар ике туптан да берьюлы атып җибәрделәр.

Яр буенда снаряд шартлаган урында төтен таралып бетәргә өлгермәде, инде безнең пулеметчылар дәррәү ут ачты, матрослар винтовкалардан ата, гранаталар тондыра башладылар... Таш кыя итәге белән елга арасындагы тар гына мәйданга килеп эләккән аклар пехотасы берничә минут эчендә кырып ташланды. Әле генә дөнья җимерердәй ябырылып килгән дошман өеренннән су читендә йөзләрчә үле гәүдәләр генә ятып калды һәм бик аз гынасы тау араларына кереп котыла алды...

Сугыш тәмам булгач, мостиктагы пулеметчыларның берсе әле һаман тынычлана алмыйча:

— Ярар, кирәкләрен алдылар бугай,— диде, кул сырты белән тирле маңгаен сертеп.— Хәер, шул кирәк ул ахмакларга... Бүтән вакытта коры җирдән хәрби корабка ташланмаска гыйбрәт булыр...

Бу вакытта инде таң аткан, Иделнең аргы ягында бөтен офыкны алсулатып кояш чыгып килә иде.

Озакламыйча, бронекатер «Олень» килеп җитеп, безне сай урыннан тартып чыгарды да, Паратскига таба алып китте. Ә безнең бүтән кораблар дошман кулындагы Югары Ослан белән Казанны әле һаман тупка тоталар иде. Алар нык тоталар булса кирәк, һавада туп тавышлары, күк күкрәгәндәй, гөрселдәп тора, пристань һәм бистәләр өстендә күк йөзен каплап, кара төтен күтәрелә, ялкын телләре уйный иде.

* * *

Казан өчен сугышлар көннән-көн кыза бара, Кызыл гаскәр һәм флотилия Казанда оялаган кара көчләрне өзлексез кысрыклый һәм чигенергә мәҗбүр итә. Казан өчен көрәш бөтен революция, бөтен яшь Совет иле язмышы өчен иң мөһим көрәш фронты булып әверелде.

Шундый киеренке көннәрнең берсендә, иртән иртүк эшкә барып керсәм, тетрәткеч хәбәр ишеттем:

— Ленинга атканнар...

— Ленин каты яраланган...

— Юлбашчы авыр хәлдә ята...

Затон халкы, судно командирлары безнең цехка җыелган. Йөзләр кырыс, иреннәр кысылган.

Соңгы айларда революция дошманнарының бик күп кара эшләр кылганын белә идек. Әмма бу тикле әшәке хыянәтне, бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы Ленинга кул күтәрүне һич тә башка сыйдырып булмый, мондый ерткычлыктан тамырларда кан суына, һәр намуслы кешенең күңелендә дошманга нәфрәт уяна. Митингта затон эшчеләре һәм хәрби дружина члennары исеменнән Ленинга телеграмма җибәрергә бердәм карар кабул ителә һәм тынып калган халык өстеннән кайнар сүзләр яңгырап үтә:

— ...Англия-Франция буржуаз залимнәренең куркакларча кылган кабахәт эшен, бөтен дөнья пролетариатының бөек остазы, сөекле юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинга хаиннарча атуын ишетеп без тирән ачу белдерәбез. Без барлык контрреволюционерларга иң каты һәм рәхимсез җәза бирелүен таләп итәбез. Ленин, Володарский һәм Урицкий каны, пролетариат эше өчен бик күп фронтларда түгелгән эшчеләр каны безне дошманнардан үч алырга чакыра. Курку белмәс сөекле юлбашчыбыз, без ихлас күңелдән сезнең кайгыгызны уртаклашабыз, тиздән савыгып аякка басуыгызны, дөнья буржуазиясен тетрәтеп бөек социализм эшен дәвам иттерүегезне телибез...

Халык ачуының чиге юк. Цехларга, судноларга таралышкач та, кешеләр, һич тынычлана алмыйча, әле анда, әле монда хыянәтче эсерларны яман сүзләр белән тиргиләр. Безнең бригадир Архиповны бөтен заводта иң юаш кеше дип йөртәләр иде. Хәзер аны танырлык та түгел, ачуы йөзенә бәреп чыккан.

— Аларның куштаннары безнең арабызда да бар бит,— дип, нәфрәтләнеп сүгенә ул.— Төрле коткы, шомлы хәбәр таратучылар да, станокларны төяп безне каядыр күчеп китәргә өндәүчеләр дә — бәрсы да шул сатлык җаннар...

Без бүген, иртән эшкә чыгу белән, баркаска төялеп, флотилия базасы урнашкан Зөя рейдына киттек һәм кичә тенге походта какшап кайткан корабларны ремонтларга керештек.

Флотилиядә митинглар бара. Николай Маркин, Лариса Рейснер әле бер, әле икенче корабта чыгыш ясыйлар, командаларны паникага бирелмәскә, дошманнарның явыз эшенә Казанны азат итү белән җавап кайтарырга өндиләр.

Корабларда моңарчы булмаган көчле әзерлек купты. Командалар туп, пулеметлар, механизмнар янында кайнашалар, Зөя станциясенә поезд белән килгән ящик-ящик снарядларны, ягулык һәм азыкны ташып корабларга төйиләр. Кайбер кораблар, базадан читкә чыгып, Идел эчендә туплар сыный; шартлау тавышлары, нәфрәт болыты күкрәгәндәй, бер гөрселдәп ала да, еракка-еракка китеп, бик озак тарала.

Ил өстенә төшкән авыр кайгыдан кешеләр ничектер үзгәреп китте. Шаяру-көлү юк, эленке-салынкы йөрү юк. Кешеләр үз-үзләрен аямыйча эшлиләр. Флотилия бер максатка төбәлгән. Ачулары ашып чыккан кызыл матрослар гел бер сүзне кабатлыйлар:

— Казан өчен яуга!..

— Даешь Казань!..

— Юлбашчының каны өчен явыз дошманның көлен күккә очырыйк!..

Шул максат белән флотилия, сафларга тезелеп, тагын походка кузгалды. Күп көрәшләрдә чыныккан революцион матрослар яшь Совет иленә, хезмәт халкының сөекле юлбашчысына кул күтәргән явыз дошманга каршы яуга чыгып киттеләр...

**Марсель Зарипов,**
**Гариф Ахунов**

# ТОРМЫШ КИТАБЫ



Кичтән үк балыкка барырга сөйләшеп куйган идек. Иртән торуга суык егерме градуска җиткән! Салкын боз өстендә дер калтырап, шыкыраеп утыруның ни кызыгы булыр икән? Бармабыздыр, ахрысы.

— Нинди бармаган ди ул! Кояш җылысында кем дә булдыра аны, сез менә суыкта тотып карагыз балыкны. Пенсионер дигәч тә май кояшы кыздырганны көтеп утырыйммы мин? Бүген бердәнбер буш көнем, иртәгә армиягә алынасы яшьләр белән әңгәмә үткәрәсем бар. Киттек!

Тихон Ильич, яшьләргә хас җитезлек белән, мич башыннан җылы киез итекләр сөйрәп төшерде, каяндыр сырган чалбарлар табып алып килде — һәм без, аның ихтыярына буйсынып, балык тотарга Иделгә китеп бардык.

Иртәнге бишләр тирәсе. Агачлар — зыкылы, суыктан туңган йолдызлар чекерәеп яна.

Курковлар йорты яр башында ук, аска ниндидер тирән бер чокыр эченнән төшәбез. Биредә аулак, җил кайдадыр йолдызлар янында ук сызгырынып йөри бугай. Чокыр бик текә, я кинәт шуып китәбез, я, туктала алмыйча йөгереп, Тихон Ильичка килеп бәреләбез.

— Чокыр түгел, җен бу,— дип тиргәнә Тихон Ильич,— җанымны суыра инде ул минем. Шуның аркасында ничә мәртәбәләр Тәтешне ташлап китәргә җыендым. Булмый. Бер егылып, бер торып йөрүнең үз рәхәте бар. Холыкны үзгәртә, тырыш һәм үҗәт булырга өйрәтә.

Тиешле урынга килеп җитәбез. Идел җәйге төсле шауламый, Идел боз астында. Текә яр читеннән башлап теге як болыннарга тикле боз өйләр тезелеп киткән. Шулар янында кара бүрекләр тырпаеп күренә. Без дә берәр бәке тишәбез. Тихон Ильич кармакларын рәтли, безгә алюмин чыбыктан ишеп ясаган чүмеч бирә, бәке өсте чыераган чакта боз элпәсен шуның белән җыеп аласы икән. Карт балыкчы безгә төрле киңәш бирә.



— Йоклап утырмагыз. Кышкы балык сүлпән ул. Җимне әкрен ашый, кармакны әлектереп ала да поса. Алабугамазар иләнсә бигрәк тә. Җим әзерләп өлгерә алмыйсың.

Дөресен әйткәндә, без — булдыксыз балыкчылар. Балык турында белгәнебез — тәмле итеп пешергән хуш исле балык шулпасы ашаудан ары узмый. Шулай да без бәке өстендә калкынып утыра бирәбез, берәр кызыл канат капмасмы дип көтәбез, капмаса да исебез китми, ник дисәң — без, балык тотудан бигрәк, Тихон Ильич белән бергә булырга дип килдек. Аның әтиебез кебек олы кеше булганы өчен түгел, кызыклы бай тормыш белән яшәгәне өчен генә дә түгел. Юк. Безне аның янына китергән сәбәп — ул Ленинны белгән кеше, Ленинга хат язып, хәсрәт-сагышын бушатучы, бүгенге һәм иртәгәге көнгә булган ышанычөметләрен әйтүче кешеләрнең берсе. Кокушкино крестьяннары Ленинга: «Сәламәтлегеңне сакла, син Россиядә бердәнбер кеше»,— дип язганнар, Әгерҗе тимер юлчылары усал ният белән эшләүчеләргә, ялкауларга каршы ничек көрәшкәннәрен язып җибәргәннәр. Кама буендагы бәләкәй генә калада — Чаллыда Советларның беренче губерна съезды үткәрелә, анда катнашучылар Ленинга язган хатларында Октябрьда яулап алганнарын ач-ялангач хәлендә дә дошманнарга бирмәскә ант итәләр...

1920 елның сентябрендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының учредительный съезды җыела. Съезд делегатлары Ильичка ант итәләр: урак белән чүкеч бөтен дөньяга баш булмый торып, без кулыбыздан коралны ташламабыз, берниндн мохтаҗлыклардан да курыкмыйча, Советлар Россиясенең пролетарийлары сафында иске дөньяны җиңгәнче барырбыз, диләр.

Без, революциядән соң туган кешеләр, Совет илендә яшәүче олы һәм кечә халыкларның тигез хокуклылыгына шул хәтле күнеккәнбез, моны гадәти бер нәрсә итеп карыйбыз.

Хәзер без үз язмышыбызны үзебез кайгыртабыз, республикабыз белән үзебез идарә итәбез, безнең үз Йортыбыз бар.

Безнең үз туган Йортыбыз булганга, үз кагыйдәләребезне, үз гадәт-йолаларыбызны саклап, тату бер гаиләдә яши башлаганыбызга быел нәкъ илле ел тула. Мәшәкатьләребез арта төште. Безгә яңа калалар салырга, иске авылларны яңартырга кирәк булды, Иген игәргә, бакчалар үстерергә, балаларыбызны белемле итәргә һәм кунаклар кабул итәргә кирәк булды. Һәм без аларның барысын чын хуҗаларча башкарабыз.

Һәм без моның өчен кемгә бурычлы икәнебезне беләбез. Барлык эшләребезнең юл башында Ленин тора.

1920 елны Татарстан республикасы — үз дәүләт идарәсе булган республика булырмы-юкмы дип, мәсьәлә кискен итеп куелган чакта, Владимир Ильич: «Булыр!» диде. Ленинча кыска һәм нык итеп әйтте.

Авыр заман бу, ил язмышы хәл ителгән заман. Казан губерна башкарма комитеты председателе Ходоровский партиянең IX съездына килгәч, делегацияләре белән Владимир Ильичка керүләрен искә ала. Алар Татарстанны республика итүнең гамәлгә ашмастай нәрсә икәнен исбат итәргә тырышалар. Дәлилләре нәрсә? Патша самодержавиесе тарафыннан гасырлар буена изелеп яшәгән халыкның үз Йорты белән идарә итә алырлык кадрлары юк. Бәләкәй Йорт түгел бит, бөтен бер республика.

Республика белән идарә итүнең авырлыгын, әйтерсең, Ленин белми! Ильич һәрбер халыкның иҗат көчләренә, мөмкинлекләренә беркем ышанмаганча ышана, социалистик революциясенең гаять зур социаль көчләр тудырачагын, һәрбер милләткә киң колачлы зур борычлар йөкләргә мөмкин икәнен аңлый. Россияне эксплуататорлардан тартып алганбыз икән, идарә итәргә дә өйрәнергә тиешбез, ди Ленин.

Владимир Ильич Ленин, гадәтенчә, башын кыңгыр салып, Татарстан делегациясен бик зур игътибар белән тыңлый, милләтләрне үз эчке эшләре белән идарә итүдән тыю — гади бер ялгышу гына түгел, политик хата булуын әйтә. Татарстан автономияле республикасын оештыру эше белән турыдан-туры үзе шөгыльләнә. Бер ишелерен шелтәли, ашыкмаучыларны ашыктыра. Һәм 1920 елның 27 маенда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында декрет кабул итә.

Без әнә шулай үз Йортыбыз белән яши башлыйбыз. Моңа хәзер 50 ел тула.

Моннан берничә ел элек Казанда басылып чыккан «Ленин һәм Татарстан» дигән китапта республикабыз хезмәт ияләренең бөек юлбашчыбызга язган йөзләрчә хаты тупланган. Вакыт ул елларның кайнарлыгын киметә алмады, хатлардагы уй-фикерләр чын күңелдән әйтелгәнгә күрә, әле дә безне дулкынландыралар. Тик шунысы бар: күңел күге яктырып киткән чакларда Ильичка иң изге тойгыларын язып җибәргән, планнары белән уртаклашкан кешеләр көннән-көн кими бара. Аларның байтагы акгвардиячеләргә каршы аяусыз сугышларда корбан булды, бер ишесен кулак пулясы алып китте, соңгы ветераннарны рәхимсез үлем чүпли бара. Ләкин алар үлми, алар безнең ярсулы темп белән барган бүгенге тормышыбызда, эшләгән эшләребездә яшиләр.

Без бәке өстенә иелеп утырган киң җилкәле, өлкән булса да, әле һаман нык һәм чыдам табигатьле Тихон Ильичка күз төшерәбез, аның ярты гасыр элек, крестьян җыены тарафыннан авыл Советы секретаре итеп елына егерме биш сум игана акчасына сайланып куелуын һәм унөч яшьлек үсмер малайның Ленинга хат язар өчен өстәл янында чүмәшеп утыруын күз алдына китерәбез. Сукыр лампа тети, тәрәзәдән кара күләгәләр йөгереп уза, каләм очыннан үсмернең урман чишмәсе кебек саф, әйләнәтирәдәге мөхит кебек зур, тынгысыз уйлары агыла:

«Кадерле Ленин!

Социализмның тизрәк төзелүен теләп сәлам җибәрәм. Мин, надан һәм диндар атаана кулында тәрбияләнеп үскән һәм хәзергесе көнне сука башы тотып, үзем һәм социалистик Россия өчен икмәк үстерүче 13 яшьлек малай, Сезгә хат язарга булдым, ягъни бөтендөнья социалистик революциясенең бөек юлбашчысы иптәш Ленин белән күңелемнән килешкәнемне әйтергә теләдем.

Кадерле Ленин!

Мин революция өчен файдасыз булган мондый хатлар язуны... хурлык саныйм, ник дисәң, андый хатлар Сезне бөек эшегездән аера. Әмма, беләсезме, мин, 13 яшьлек малай, Сезне үлеп яратучы, Сезгә хат язмыйча түзә алмадым.

Сезгә түбәнчелек белән хәбәр итәм, мин намуслы малай буларак культура-агарту түгәрәгендә, ревизия комиссиясендә эшлим, шул ук вакытта Авыл башкарма комитетында секретарь да булып торам.

Курков
Пролей Каши авылы,
Тәтеш өязе,
Казан губернасы».

Балык начар чиртә. Сәгать ярымнар вакыт узып, киез итекләр аркылы да суык үтә башлагач, беренче алабуга эләгә. Ул зәңгәр боз өстендә тыпырчынып, бәргәләнеп ята.

Тихон Ильич балыкка күз төшереп ала, туңмадыгызмы әле дип сорый, җылынып алырга куша.

Без бәкебез тирәсендә йөгереп йөрибез, тэрткәләшәбез, унбиш минутлар шулай мәш килгәч, салкын кимеп киткәндәй була. Карт көлә.

— Балык каптыру — шәп эш. Кышын бигрәк тә. Тәннәр язылып, каннар таралып китә. Бер атналык көч-гайрәт алып кайтасың. Тагын бераз утырыйк әле. Нәрсә, бер алабуга белән кайтмабыз бит?

Искитәрлек хәл!

Ленинга хат язганнан бирле ничәмә-ничә еллар үткән, ул ифрат зур тормыш юлы узган, шулай да әлеге хат аның күңелен яктыртып, җанын рәхәтләндереп тора. Ул чагында кәгазь битенә төшергән һәрбер сүз аның өчен сүз генә булып калмый, вәгъдә булып, ант булып әверелә, бер мәртәбә әйтелгәннән соң гомер буе күңел күген яктыртып яши.

Тихон Ильич шул ярты гасырлык тормышын, кештәләргә салгандай, җентекләп сөйләп чыга ала. Һәм без шул юл белән барып, аның бер үзенең генә түгел, бөтен халыкның, бөтен илнең биографиясен күрәбез.

Ленинга хат язганнан соң Тихон Ильич үзләренең авылында беренче комсомол ячейкасы секретаре була. Кулакларның аңа төбәлгән кыска мылтыгын җилкәсендә тойган хәлдә, икмәк төяп ач калаларга продотрядлар озата. Крестьяннарга җир өләшә.

Белеме аз, өч класслык земский мәктәп белеме генә, үзлегеннән укырга туры килә. Алай гына укып ерак китә алмаячагын аңлагач, рөхсәт алып, рабфакка керә. Укый да эшли, эшли дә укый, чөнки ул чакта уку пролетариат эшенең мөһим бер тармагы санала. 8 сәгать лекция, 3 сәгать лаборатор эш, тулай торакта 3 сәгать мөстәкыйль эш — шул рәвешчә урта мәктәп программасын өч елда үтеп чыга. Аннары — Мәскәү университеты, «Сельхозгиз»да редактор, сугыш...

Тихон Ильичның ул чакта инде ике улы була. Юркасына өч яшь, Мишкага — биш. Нишләтергә аларны, кая куярга? Аларны ул үзе белән Пролей Кашига алып кайта да сеңелләре Катя белән Полинага калдыра. Ә үзе — туп-туры Воронежга, ут өермәсенә барып керә. Фронт юллары буйлап Венага кадәр барып җитә, сугыштан соң тагын Иделгә әйләнеп кайта.

Балалар йортында, партия райкомында эшли, мәктәп директоры була, кайда җиңел, кайда рәхәт, шунда йөгерми, кайда кирәгрәк — шунда бара. Бер сүз белән әйткәндә, өзлексез хезмәт итә, чөнки «бөтенденья революциясе юлбашчысы белән килешкәнен» гомер буе күңел күгеннән үткәреп яши. Эшләгән саен аз эшләгән кебек тоела, күңеле зурракны өмет итә.

Тәтеш зур кала түгел, аны олысы да, кечесе дә белә — хәзер дә иң элек аңар киләләр. Мин бит пенсионер димәс, кулыннан килгәнне эшли бирер.

Җитмешне тутырып килү — уен эш түгел. Юк инде, булмый дип әйтсә дә үпкәләмәсләр иде. Кешеләргә кирәк булуын тоеп эшләүдән аның үзенә рәхәт.

Тихон Ильич — шәһәр сәүдәсендә кибетләр комиссиясе председателенең урынбасары, райкомның штаттан тыш даими пропагандисты, шәһәрдә Ленин өмәләрен оештыручы. Аның өчен эшнең олысы һәм кечкенәсе, җаваплысы һәм җавапсызы юк. Өстенә йөкләнгән теләсә кайсы эшне намус белән үти.

Көн инде сүнеп бара, боз өстендә кышкы шәфәкънең алсу нурлары уйный башлады, безнең бар тоткан балыгыбыз — борын башына бергәр алабуга. Әгәр шәбрәк балыкчылар очрамаса, безнең кышкы Иделдә балык тотуыбыз сагынып сөйләргә генә калыр иде.

Менә без җылы өйдә утырабыз. Тихон Ильич безне үзе үстергән алма белән сыйлый, балык шулпасы пешкән арада әңгәмә корып җибәрәбез. Дөресрәге, Тихон Ильич үзе генә сөйли, без бүлдермичә тыңлыйбыз. Аның сүзләре ничектер түгәрәкләнеп, йомры булып чыгалар, әйтелү белән онытылмыйлар, аларга аның күп еллык тәҗрибәсе салынган. Сүзен ул безнең өчен генә дә сөйләми кебек, уй-фикерләр

кемгәдер ышанып тапшыра төсле. «Кемгәдер» дигәне безнең белән бер өстәл янында утырмый, ләкин ул барыбер бар, ул безнең күңелләрдә яши.

— Китабым белән азапланам. Хәтерегездәме, Ольга Берггольц китабында бәләкәй генә кыз көндез йолдызларны күрер өчен кое төбенә карый. Мин дә дәфтәр битенә иелеп утырам. Ильичка язган хатымнан башлап, менә бүгенге балыкка баруыбызга тикле вакыт эчендә үткән гомеремә төбәлеп карыйм.

Мин, хәзер барыгызга да билгеле, Ленинга хат язган кеше бит. Ә хәзер минем үземә язалар. Казагыстаннан, Украинадан, Камчаткадан язалар, Ленин музее ачабыз, диләр, үзем турында сөйләвемне үтенәләр. Биографиямне язып җибәреп кенә котыласым килми, уй-фикерләремне бүлешәсем килә. Кем дә кем бүгенгесе көнне безнең җирдә яши, хезмәт итә, сөенә һәм ярата белә, алар Ленинның варислары, Ленин башлаган эшне дәвам иттерүчеләр... Кешеләр шуңа үз акыллары белән барып җитсеннәр дип уйлыйм.

Беләсезме, бик авыр языла. Элегрәк, үзебезнең район газетасын чыгарганда, бер төн эчендә дүртәр полосаны наборга бирә торган идем. Хәзер күпме генә язам — алай да ошамый. Җаваплылык хисе бик зур. Минем өчен бу беренче һәм иң төп китап. Ленин безнең өчен кем иде — менә шуны ачарга телим. Минем өчен ул — кояш, якты көн, Идел... Кемнәр аның белән бер дәверда яшәгән, кемнәр хәзер дә яши һәм эшләгән эшенә сөенә, бездән соң кемнәр яшәр — барыбыз өчен әйтәсем килә. Сизәсезме, өнә кая таба китте уйлар?!

Иртәгесен ул безне озатып куйды. Без самолетка ашыгабыз, аның армиягә алынасы яшьләр белән очрашасы бар. Гади генә саубуллаштык. «Онытмагыз, хат языгыз»,— диде.

Башка сүз әйтмәде. Без дә артыгын әйтмәдек, аның китабы, гомер эчендә язган беренче китабы әйбәт булсын иде дип күңелебездән уйлап бардык.

Кешеләргә бик тә кирәк китап ул.

Самат Шакир

# ОНЫТЫЛМАС ХАТИРӘ



Мәскәү. Кызыл мәйдан. Ленин Мавзолее.

Планетаның ерак материкларыннан, Советлар Союзының төрле почмакларыннан туристлар һәм кунаклар пролетариатның бөек юлбашчысы В. И. Ленинны күрү өчен бирегә килгәннәр. Алар барысы да, Мавзолейга караган хәлдә, әкрен генә алга атлыйлар. Күбесе үз телендә Ленинны хөрмәт белән искә ала. Кызыл мәйданда басып торучы бу сафта кемнәр генә юк: кубалылар, французлар, гарәпләр... Менә алгы рәттә грузиннар, үзбәкләр, төркмәннәр. Алардан ерак түгел генә олы яшьтәге бер кеше үзенең тормыш иптәше белән янәшә басып тора. Аларга бу урыннар күптәннән таныш. В. И. Ленинны соңгы юлга озаткан вакытта да алар бу изге җирдә булдылар.

Бу ике кеше — гражданнар сугышы һәм хезмәт фронты ветераннары Габдрахман Вәлитов белән Кояш Вәлитова иде.

Халык һаман Мавзолейга якынлашты.

Менә Кремль сәгате уникене сукты. Сакчылар җитез генә урыннарын алмаштылар. Вьетнам Демократик Республикасыннан килгән бер төркем кунакларның тарих музее ягыннан килүе күренде. Алар Ленинга чәчәкләр куйдылар.

Кешеләр әкрен генә атлап Мавзолей эченә керәләр. Менә даһи Ленин. Күңелдә Ленинга булган рәхмәт хисләре ташый. Ленинны юксыну кешеләрнең йөзенә чыккан. Алар Ленин идеяләренә турылыклы булырга ант итеп әкрен генә атлыйлар... Габдрахман аганың да, Кояш апаның да күзләре яшьләнде.

Квартирага кайтканнан соң, Габдрахман ага түр стенага куелган фоторәсемгә карап уйга калды. Бу фоторәсем моннан илле ел элек төшереп алынган иде. Анда Владимир Ильич Ленин да бар. Җанлы тарих Габдрахман аганың күз алдында гәүдәләнде. Ул башыннан үткәннәрне хәтерләде...

Габдрахман Казан артында — татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай туган якта туып-үсә. Өшкәтә дип аталган бу авыл Кушлавычтан ерак түгел. Башта үз авылларында укыган Габдрахманны, берничә елдан соң, Казанга алып барып «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бирәләр.



*Габдрахман ага Вәлитов.*

1913 елның язында, татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай үлгәч, аны соңгы юлга озата баручылар арасында Габдрахман да була. Тукайның үлүенә бер ел тулу көннәрендә «Мөхәммәдия» шәкертләре шагыйрьне искә алу кичәсе үткәрәләр. Бу эштә башлап йөрүче ике шәкерт мәдрәсәдән чыгарыла. Аларның берсе — Габдрахман. Ул халыкка хезмәт итүне үзенә төп максат итеп куя һәм Югары Курса авылында укытучы булып эшли башлый. Бу вакытта авыллардагы типсә тимер өзәрлек таза ирләрне беренче бөтендөнья сугышына — ут эченә куалар. 1915 елда Габдрахман да солдатка алына һәм фронтка җибәрелә. Монда ул окопта большевик-агитаторларның ялкынлы речьләрен тыңлый, Ленин турында ишетә...

Февраль революциясе көннәрендә Габдрахман Вәлитов «бетсен патша!» дип халык ягына чыгучыларның берсе була, митингларда сугышка каршы чыгышлар ясый. Көннәрдән бер көнне В. И. Ленинның «Социал-демократлар нәрсә тели?» дигән брошюрасы аның кулына төшә. Габдрахман әнә шул брошюраны төннәр буе укый. Учредительное собраниегә сайлаулар вакытында большевиклар исемлеген үткәрү өчен җиң сызганып аңлату эшләре алып бара.

Октябрь революциясе көннәрен Габдрахман Вәлитов Сембер шәһәрендә госпитальдә каршылый. Империалистик сугышта алган яралар аның сәламәтлеген какшаталар. Госпитальдә дәваланучы солдатлар Октябрь революциясенең житәкчесе В. И. Ленинның шушы шәһәрдә туып, балалык елларын гимназиядә укып үткәрүе турында искә алалар. Габдрахман да Ленин турында уйлый. Ул аның газеталарда басылып чыккан мәкаләләрен игътибар белән, кабат-кабат укып бара.

Габдрахман Вәлитовны, госпитальдән чыккач, 95 нче запасной батальонга җибәрәләр. Аннан ул 1917 елның ноябрь ахырында гарнизон конференциясенә делегат була. Делегатлар аны хәрби комитетка член итеп сайлыйлар.

Габдрахман 1918 елның мартында армиядән демобилизацияләнә һәм укытучылар әзерли торган курска укырга керә. Менә шунда укып йөргәндә Кояш Җаббарова дигән кыз белән таныша. Октябрь революциясен зур шатлык белән каршы алган, властьның эшче-крестьяннар кулына күчүен хуплап газеталарга мәкаләләр язган бу шахтер кызы Габдрахманга ошый һәм алар тормыш корып җибәрәләр. Кояш Җаббарова революция башыннан ук, большевиклар тапшыруы буенча, хатын-кызлар арасында аңлату эшләре алып бара, аларны укырга-язарга өйрәтүдә армый-талмый эшли, балалар бакчалары ачуда актив катнаша, Казанны ак чехлар алганнан соң мобилизация үткәрә башлагач, аклар тырнагына ирексездән эләккән солдатларга һәм бер офицерга кызыллар ягына чыгу өчен ярдәм итә. Кояш Җаббарова 1919—20 елларда Татар запасной батальонында хезмәт итә.

1918 елның салкын көзе. Бертуктаусыз диярлек яңгыр ява. Яңа гына төзелгән Совет республикасын саклау өчен Кызыл Армия сафына эшче-крестьян балалары үзләре теләп керәләр. Алар арасында 24 яшьлек Габдрахман да бар. Аңа кызылармеецлар арасында аң-белем тарату, политик эш алып бару тапшырыла. Фронтта булган, дары исе иснәгән Вәлитов кызыл сугышчыларга Совет дәүләтенең эчке һәм тышкы политикасы, дошманнарга каршы көрәш турында лекцияләр укый, политик түгәрәкләр оештыра. Кызыл Армиягә килгәндә укый-яза белмәгән яшьләр әкренләп хәреф таный, кайберләре газета хәбәрләрен укый, семьяларына хатлар яза башлый. Моның өчен алар Вәлитовка рәхмәтләр әйтәләр, аңа хөрмәт белән карыйлар.

Бер ел да үтми, Вәлитовны армия Политбүлеге Мәскәүгә Политбүлек инструкторлары әзерләү курсына җибәрә.

Илебезнең башкаласы Мәскәү Габдрахманны җылы каршылый. Ләкин бу вакыт — илдә гражданнар сугышының иң кискен чоры. Партия тарафыннан: «Бөтен көч фронтка! Бөтен көч яшь Совет республикасын коткару өчен!» дигән лозунг куела. Газеталарда В. И. Ленинның бу турыда хаты басылып чыга. Ленинның бу хаты укып тикшерелгәннән соң, курсантлар үзләре теләп фронтка китәргә дип карар кабул итәләр.

Курсның соңгы йомгаклау конференциясенә бөек юлбашчы В. И. Ленин һәм Н. К. Крупскаяның киләчәге турында хәбәр тарала. Зарыгып көткән көн — 1919 елның 28 октябре килеп җитә. Көз булса да, кояшлы көн була ул. Агачлар әле яфрак коеп бетермәгәннәр, алар әкрен генә искән җилдә кыштырдыйлар, үзара нәрсәдер сөйләшәләр кебек. Курсантларның шатлыгы йөзләренә чыккан, алар бер-берсе белән елмаеп һәм шатланып сөйләшәләр.

Мәгариф Халык Комиссариатының съездлар йорты янына бер җиңел машина килеп туктый. Машинадан В. И. Ленин белән Н. К. Крупская төшә. Алар, укытучылар һәм курсантлар белән исәнләшкәннән соң, баскыч буйлап күтәреләләр. Курсантлар даһи юлбашчының гадилегенә сокланалар, сакчыларсыз йөрүенә гаҗәпләнәләр.

Съездлар йортының залы халык белән шыгрым тулы. Барысының да йөзе шат һәм көләч.

Менә залның ишеге киң итеп ачыла, Ленин белән Крупская күренә. Халык дәррәү кул чаба башлый. Сәхнәгә зал аша узарга кирәк. Ленин һәм Крупская алга атлыйлар. Йөзләрчә күзләр аларга төбәлә, көчле алкышлар дәвам итә.

Нык адымнар белән сәхнәгә чыгып баскан Ленинны күргәч, залдагыларның сулыш алган тавышлары да ишетелмәс булды. Бөек юлбашчы халыкара һәм фронттагы хәлләр турында, Совет властеның ныгып килүе, революция дошманнарына каршы көрәшү өчен барлык көчләрне һәм средстволарны мобилизацияләү турында сөйли.

Сөйләп бетергәч, ул курсантларның сорауларына җаваплар бирә. Аларның үтенече буенча, бергәләп фоторәсемгә төшәргә ризалаша. Рәсемгә төшкәндә һәркем бөек юлбашчы янынарак утырырга тырыша. Габдрахманның бәхете бар икән, ул төркемнең уртасына — Н. К. Крупская янына туры килә.



*1919 елда В. И. Ленин һәм Н. К. Крупская белән бергә төшкән рәсем. Н. К. Крупская янында басып торучылардан уңнан икенчесе — Габдрахман ага Вәлитов.*

...Менә шул очрашу Габдрахман аганың күңелендә мәңге онытылмас булып калды. В. И. Ленинның якты образы аның күз алдыннан һич китми. Әйе, нәкъ менә шушы очрашудан соң, бөек юлбашчының речe белән рухланып, Габдрахман Вәлитов Коммунистлар партиясенә керде.

Курслар тәмам булганнан соң, курсантларны Республика Хәрби Советының политик идарәсенә чакырдылар. Политик идарә начальнигы А. С. Бубнов төрле милләт вәкилләрен үзе кабул итте. Бубнов аларга фронттагы хәлләр, авыллардагы сыйнфый көрәшнең кискенләшә баруы, Кызыл Армияне ныгыту, кызыл сугышчыларның политик аңын күтәрү турында сөйләде. Бу эшне аерата милли бүлекләрдә бик нык җанландырырга кирәклеген әйтте. Соңыннан курсантларны, җаваплы эшләргә билгеләп, төрле урыннарга җибәрделәр.

Габдрахман Вәлитов Республика Хәрби Советы политик идарәсенең Көнчыгыш бүлеге янындагы Мөселман хәрби коллегиясенә билгеләнде. Бу коллегиянең җитәкчеләре Шамил Усманов, Нәбиулла Вахитов һәм башкалар иде. Габдрахман Вәлитов коллегиянең политик инструкторы булып эшкә кереште. Бу елларда Мөселман комиссариаты янында Гыйльми коллегия төзелеп, аның белән җитәкчелек итү атаклы галим, төрек коммунисты Мостафа Собхига тапшырылган иде. Габдрахман ага, Гыйльми коллегиянең секретаре буларак, шактый вакытлар аның белән бергә эшләде, тел һәм әдәбият укыту программалары, дәреслекләр һәм методик кулланмалар төзүгә катнашты.

1920 елның язында Габдрахман Вәлитов Хәрби коллегия каршындагы Кызыл Армия өчен агитаторлар һәм пропагандистлар хәзерләү курсының уку бүлеге начальнигы итеп билгеләнде.

1921 елда, Идел буенда ачлык башлангач, ул, районнардан китерелгән балаларны җыеп, поездга утыртып, Советлар Россиясенең иген уңган өлкәләренә җибәрү эшен оештырды. Үзәк эвакуация пункты Казанның иң зур һәм иң матур биналарының берсенә — Щетинкин номерларына урнашкан иде.

Габдрахман ага бер үк вакытта Мәгариф Халык Комиссариатында да актив эш алып барды. Ул методика өлкәсендә гыйльми хезмәтләр язды, «Мәгариф» журналының редколлегия члены итеп сайланды.

1922 елның язы. Май аеның җылы, матур көннәре. Яшь Совет республикасы үсә бара, көннән-көн ныгый. Менә шундый көннәрнең берсендә партиянең Татарстан Өлкә Комитеты Габдрахман һәм Кояш Вәлитоваларны Мәскәүгә — Крупская исемендәге коммунистик тәрбия Академиясенә укырга җибәрде. Берничә ай рабфакта укыганнан соң, Габдрахман мәктәп факультетының беренче курсына, Кояш исә мәктәпкәчә яшьтәгеләр факультетына керделәр.

Мәскәүдә укыган вакытларда Габдрахман Вәлитов партия һәм хөкүмәт учреждениеләрендә эшләде.

В. И. Ленин үлгәч, 1924 елның 26 январенда, төнге сәгать икедә дүрт йөз кешелек коллективны ул Ленин белән соңгы мәртәбә саубуллашу өчен Колонналы залга алып килде. Габдрахманның да, аның белән килгән эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең дә күзләрендә яшь бөртекләре иде. Пролетариатның бөек юлбашчысы В. И. Ленин белән саубуллашу Габдрахман өчен аерата авыр булды. Чөнки ул моннан дүрт ел элек кенә Ленинны күргән, аның ягымлы тавышын ишеткән иде бит.

1926 елның апрелендә Габдрахман да, Кояш та Академияне уңышлы тәмамладылар. Вәлитов Мәскәү өлкәсе Мәгариф бүлегендә милли мәктәпләргә җитәкчелек һәм ярдәм итү буенча инспектор-методист булып эшли башлады. Ул Мәскәү өлкәсендә һәм Мәскәүнең үзендә яшәүче татар эшчеләренең балаларын укыту өчен мәктәпләр ачу, аларның аң-белемен күтәрү эшенә җиң сызганып кереште. Кояш Вәлитова да иң тырыш, иң актив хезмәткәрләрнең берсе иде.

1927—1928 елларда, яңалифкә күчү хәрәкәте башлангач, Габдрахман Вәлитов Мәскәү өлкәсенең яңалиф комитеты члены итеп билгеләнде. 1928 елда яңалиф җәмгыятенең РСФСР күләмендә үткәрелгән конференциясендә Вәлитов тикшерү комиссиясе председателе итеп сайланды һәм өлкәләрдәге яңалиф комитетларының эшләрен тикшерү һәм ярдәм итү өчен җибәрелде. Ул бу елларда яңалифнең кирәклеге турында мәкаләләр язып чыкты, дәреслекләр һәм методик кулланмалар төзеде.

1929 елның апрелендә Габдрахман Вәлитов, партия Үзәк Комитетының командировкасы буенча, Урта Идел крае мәгариф бүлегендә инспектор-методист булып эшли башлады.

1930—1936 елларда ул — партия Үзәк Комитетының оештыру һәм пропаганда бүлекләрендә штаттан тыш сотрудник. Ул Үзәк Комитетка һәм СССР Верховный Советына Көнчыгыш халык вәкилләреннән — казакъ, кыргыз, үзбәк, төркмән, әзербайҗан, каракалпак, татар, башкортлардан килә торган күп кенә гаризаларны, хатларны рус теленә тәрҗемә итә иде. Шул ук вакытта Габдрахман Вәлитов Муса Җәлил тарафыннан редакцияләнә торган «Кечкенә иптәшләр» журналы редколлегиясе эшенә дә актив катнашты.

Яңа күтәрелеп килә торган республикаларның культура һәм фән кадрларын үстерү өчен 1936 елның октябрендә Партия Үзәк Комитеты Вәлитовны Кыргызстанга җибәрде. Анда ул, кыргыз мәктәпләренең үсеше турында диссертация яклап, педагогия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алды һәм, тел-әдәбият институтының директоры булганы хәлендә, бер үк вакытта педагогия институтында лекцияләр укыды, 1939 елның августыннан башлап институтның психология һәм педагогика кафедрасы мөдире булып эшләде.

1949 елның августында, Педагогия фәннәре Академиясе янында милли мәктәпләр институты төзелгәч, Габдрахман Вәлитовны Мәскәүгә чакырып алдылар һәм ул анда гыйльми секретарь булып эшкә кереште.

Партиябез һәм хөкүмәтебез Габдрахман аганың хезмәтләренә зур бәя бирде, аны орден һәм медальләр белән бүләкләде. Ул Кыргызстан ССРның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем алды.

Үткән елның декабрендә Габдрахман агага 75 яшь, ә коммунистлар партиясе сафына керүенә илле ел тулды.

Хәзер Габдрахман ага персональ пенсионер. Шулай булуга карамастан, ул һаман сафта, һич тынгылык белми, бик күп җәмгать эшләренә катнаша.

# ИЛЬИЧ ҮРНӘГЕНДӘ

**В. И. Ленин-Ульянов исемендәге Казан дәүләт университеты — Владимир Ильич укыган бердәнбер югары уку йорты. Әйдә, хөрмәтле укучы, карашыбызны шул университетның төп бинасына юнәлтик. Әнә алдынгы карашлы студентларның революцион чыгышларына шаһит булган ап-ак колонналар. Алар яныннан үтеп, киң ишекне ачып эчкә кергәч, уң як коридорга борыласың һәм икенче катка күтәреләсең. Анда — Актлар залы. Узып баручылар монда адымнарын акрынайталар. Көн саен, сәгать саен бирегә берәзлексез килеп торучылар зур мемориаль тактага алтын хәрефләр белән язылган түбәндәге сүзләрне укыйлар.**

**— Монда 1887 елның 4 (16) декабрендә Владимир Ильич Ульянов-Ленин студентларның революцион чыгышында актив катнашты...**

Яшь Ульянов университетның ишеген соңгы тапкыр ачып кергән көннән безне сиксән ике елдан артык вакыт аерып тора. Ләкин Владимир Ильичның тере образы, аның эшләре, уйлары һәм хыяллары университет укытучылары һәм студентлары коллективының тормышында, эшчәнлегендә һаман да аерылгысыз юлдаш булып кала. Кайсы гына аудиториягә яки лабораториягә кермә, син анда һәркемнең үз эшендә Ильичка охшарга тырышканлыгын тоясың.

Күптән түгел миңа университетның фәнни эшләр буенча проректоры профессор Шәүкәт Хәбибуллин белән очрашырга туры килде. Әңгәмә вакытында сүз уңаенда мин аңа **«Университетта яшьләрне Ленин традицияләрендә тәрбияләү эше ничек куелган!»,**— дигән сорау белән мөрәҗәгать иттем. Аның фикерләрен мин журнал укучылар белән дә уртаклашмакчы булам.

— Ленин традицияләрендә тәрбияләү системасы,— дип башлады профессор үзенең сүзен,— Владимир Ильичның үлемсез образы белән бәйләнешле күп кенә чаралар комплексын тәшкил итә. Менә конкрет фактлар. Университетның беренче курсына ел саен йөзәрләгән кызлар һәм егетләр укырга килә. Бу яшьләрнең биредәге тормышы аларны студент булулары белән тәбрикләүдән башлана. Ә ул церемония яшь Ульяновның университет бинасы каршындагы һәйкәле янында уздырыла. Бу көнне алар Владимир Ильич васыять иткәнчә яшәргә, укырга һәм көрәшергә ант итәләр. Һәм бу ант соңыннан университетны тәмамлап чыгучыларның тормыш девизы булып әверелә.

Университетка яңа кабул ителгән студентларның беренче дәресләре дә үзенчәлекле уза. Ул дәресләр кайчандыр Ильич, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «Россия хокуксызлыгы» тарихы курсларын тыңлаган бүлмәдә — В. И. Ленинның музей-бүлмәсендә уздырыла. Университетның КПСС тарихы кафедрасы укытучылары студентларны Владимир Ильичның Казандагы тормышы һәм эшчәнлеге, узган гасырның 80 нче елларында яшьләрнең революцион хәрәкәте белән якыннан таныштыралар. Шул ук көнне юридик факультетның беренче курс студентлары В. И. Ленинның беренче сөрген урыны булган Кокушкинога баралар. Анда аларның һәркайсы юристлар аллеясына яшь агач утырта, ә безнең биологлар шул паркка шефлык итәләр.

Шулай итеп, һәр студент беренче көннән үк үзен бөек юлбашчыбыз исемен йөртүче университет коллективы члены һәм Ильич токымының бер вәкиле итеп тоя.

Без һәр елның 4 декабрендә В. И. Ленинның беренче революцион чыгышын билгеләп үтүне традициягә керттек. Студентларның революцион сходкасы уздырылган

Актлар залында 1967 елны без, мәсәлән, яшьләрнең республика митингысын үткәрдек. Анда завод һәм фабрикалардан, колхоз һәм совхозлардан килгән вәкилләр, шулай ук Совет Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, студентлар һәм укучылар катнашты. Алар Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу көнен лаеклы каршыларга чакырып, республикабызның барлык яшьләренә мөрәҗәгать кабул иттеләр.

**— Шәүкәт Таипович, ул мөрәҗәгать Татарстанның ерактагы районнарына ничек җиткерелде?**

— Володя Ульянов һәйкәле янында уздырылган митингтан соң, чаңгычылар эстафетасына старт бирелде. Эстафетада катнашкан йөзләрчә кызлар һәм егетләр үзләре кабул иткән әлеге мөрәҗәгатьне районнардагы башлангыч комсомол оешмаларына кулга-кул бирә-бирә тапшырдылар.

**— Университетта Ленин мирасын өйрәнүнең ничегрәк алып барылуы турында берничә сүз әйтә алмассызмы?**

— Башта миңа Сормово эшчесе П. А. Золомовның 1924 елның гыйнварында Надежда Константиновна Крупскаяга язган хатын искә төшереп үтәргә рөхсәт итегез. Анда менә мондый юллар бар: «Ильич идеяләре эшчеләр һәм хезмәтчел крестьяннарның киң массалары аңына күбрәк кергән саен, Ленин шәхесенә карата булган ихтирам да арттканнан-арта барыр һәм безнең көчебез тагын да ныгыр... Иптәш Ленин ул безнең үзебезнең бер өлешебез, ул безнең белән органик рәвештә бәйләнгән, аның хезмәтләре һәм шәхесе белән никадәр күбрәк танышсак, бу бәйләнеш тә шулкадәр ныгыр». Сормово эшчесенең сүзләрен куәтләп, шуны әйтәсе килә: юлбашчының иҗат мирасын, иҗат лабораториясен өйрәнү, җәмгыять тормышындагы һәм политик агымдагы вакыйгаларга, күренешләргә дөрес бәя бирә белү — зур әһәмияткә ия булган бурычларның берсе.

Бу юнәлештә эшләүнең төрле формалары, төрле ысуллары бар. Ләкин аларның төп асылы бернәрсәгә — һәрбер студентны Ленин идеяләренә, революцион традицияләргә тугрылыклы булырга тәрбияләүгә кайтып кала. Менә шуңа күрә дә безнең университетта Ленин зачетлары тапшыру кебек яңа форманың тууы һич тә очраклы хәл түгел. Икенче сүзләр белән әйткәндә, бездә һәр студент үзенең укуы һәм эше турында коллектив алдында отчет бирә. Аның эшчәнлеге В. И. Ленин тарафыннан яшьләр алдына куелган таләпләргә җавап бирерлекме-юкмы — коллектив үз нәүбәтендә әнә шуны бәяли. Бу чараны уздырганда студентның профессия сайлавына, Ленин идеяләре өчен көрәш фронтының ышанычлы солдаты булу юлында нәрсәләр эшләвенә аеруча зур игътибар бирелә. Студентның иҗтимагый фәннәрне өйрәнүгә карата булган мөнәсәбәте Ленин зачетларының үзәгендә тора.

Университетта иҗтимагый дисциплиналар буенча семинарлар уздыруга зур әһәмият бирелә. Үтелә торган материал, кагыйдә буларак, университет традицияләре һәм аның партия, комсомол оешмалары тарихы белән бәйләп алып барыла. Механика-математика факультетының беренче курсында, мәсәлән, «Милли мәсьәлә буенча Ленин программасы һәм аның тарихи әһәмияте», «Ленин революцион ситуация турында», «Октябрь революциясенең халыкара әһәмияте» һ. б. темаларга барлыгы 25 доклад-реферат тыңланды.

Владимир Ильич Ленин хезмәтләрен тирәнтен өйрәнүдә философия, политэкономия, тарих һәм фәнни коммунизм проблемалары буенча комсомол комитеты һәм иҗтимагый фәннәр кафедрасы тарафыннан уздырыла торган конкурслар зур роль уйный. Шунсы характерлы, студентларның фәнни хезмәтләрендә Ленин тематикасы өстенлек итә. 1968 елда уздырылган шундый конкурсларда 1800 кеше катнашты. Йомгаклау конференцияләрендә 900 дән артык доклад тыңланды. Студентларның 15 хезмәте Мәскәүдә үткәрелгән икенче турда лауреат исеменә лаек булды, ә университетның соңгы курсында укучы студентлардан Г. Смирнова һәм В. Скворцов Бөтенсоюз конкурсының өченче турында беренче урынны яулап алдылар.

Бу чараларның бөтенесе дә иҗтимагый фәннәр буенча өлгерешне күтәрүгә һәм студентларда Ленин тарафыннан эшләнгән революцион теорияне иҗади үзләштерүгә, аларда марксистик-ленинчыл аңлылык тәрбияләүгә ярдәм итә.

**— Шәүкәт Таипович, бүгенге көндә университет студентларының фәнни җәмгыятьләр Советы нинди эшләр белән шөгыльләнә! Шул хакта тукталып үтсәгез иде.**

— Студентларның фәнни җәмгыятьләр Советы соңгы вакытта үзенең бөтен көчен

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көнен каршылауга әзерлеккә юнәлдерде. Шушы елның апрель аенда без, Ленинград университеты белән берлектә, студентларның һәм аспирантларның иҗтимагый фәннәр буенча фәнни конференцияләрен үткәрдек. Юридик факультет, мәсәлән, «В. И. Ленин һәм Совет дәүләте һәм хокукы» дигән темага юбилей конференциясе әзерләде. Анда Ленинград, Вильнюс, Томск, Рига һәм Ташкент университетларының студентлар фәнни җәмгыятьләр советлары члennары катнашты.

Әмма студентлар фәнни җәмгыятьләренең эшчәнлеге юбилей конференцияләренә әзерлек эше белән генә чикләнми. Алар республикабыз мәктәпләренә шефлык итүгә дә зур игътибар бирәләр. Фәнни җәмгыятьләр Советы членнары олимпиадалар үткәрү буенча төзелгән жюрилар составына кертелделәр, алар мәктәпләрдә төрле түгәрәкләр белән җитәкчелек итәләр, читтән торып укучы яшь математикларга даими ярдәм күрсәтәләр, авыл районнарындагы мәктәп балалары өчен әзерлек курслары оештыралар.

**— Университетта Ленин хезмәтләрен пропагандалау ничегрәк куелган!**

— Безнең университет каршында иҗтимагый профессияләр факультеты эшли. Анда халыкара хәлләр буенча лекторлар, атеистлар, техник белемнәр тарату буенча пропагандистлар һәм әдәбият белгечләре хәзерләнә. Биредә «Ленин мирасын өйрәнүчеләр» мәктәбе аерым урын алып тора. Анда укуларны, өлкән укытучы Йолдыз Бурнашева җитәкчелегендә, КПСС тарихы кафедрасы оештыра. Ленин мирасын өйрәнүчеләр хәзерге көндә «В. И. Ленин тормышында һәм эшчәнлегендә Идел чоры» дигән комплекслы проблема өстендә эшлиләр. Укулар ике еллык программа нигезендә алып барыла. Лекцияләрне тарих фәннәре докторлары Рәфикъ Нәфиков, Аркадий Шофман һ. б. лар укый.

Өйрәнелгән материаллар нигезендә студентлар В. И. Ленин эшчәнлегенең Казан һәм бүтән чорлары буенча үзлекләреннән лекцияләр әзерлиләр. «Владимир Ильич турында үзең нәрсә беләсең, аны син башкаларга да җиткер!» — юлбашчының бай мирасын өйрәнүчеләрнең төп девизы әнә шул.

Ленин тематикасы буенча эшләүче студент-лекторлар тарафыннан узган елда колхозларда, совхозларда, предприятиеләрдә һәм мәктәпләрдә 800 дән артык лекция укылды, В. И. Ленинның музей-бүлмәсендә эшчеләр, колхозчылар, укучылар, Совет Армиясендә хезмәт итүчеләр һәм студентлар белән 2600 әңгәмә уздырылды.

Университет еш кына теге яки бу урында лекторлар группаларының коллектив чыгышларын оештыра. Ленин мирасын өйрәнүче студентлардан Николай Степанов, Любовь Фиш, Евгения Доронцева, Зоя Алексеева һәм башка бик күпләрнең исемнәре Казаннан читтә яшәүчеләргә дә якыннан таныш.

Университет комсомол комитетының шефлык секторы һәм Ленин бүлмәсе Советының эше дә игътибарга лаеклы. Алар илебезнең төрле почмаклары белән элемтәдә торалар, иң-иң ерак урыннарда Ленин бүлмәләре һәм музейлар оештыру, лекцияләр һәм докладлар әзерләү, әңгәмәләр уздыру буенча анда яшәүчеләргә практик ярдәм күрсәтәләр. Соңгы вакытта университетның Владимир Ильич исемен йөртүче яки Ленин ордены белән бүләкләнгән предприятиеләр һәм колхозлар белән элемтәсе тагын да ныгый төште. Студентлар заводларның, колхозларның һәм алардагы комсомол оешмаларының тарихын язуда, хезмәт даны бүлмәләрен бизәүдә якыннан торып катнашалар.

**— Идея-тәрбия эшләрен алып баруда университет коллективы төп нигез итеп нәрсәне күздә тота!**

— Безнең совет җәмгыятенең табигатендә яшьләрнең идея-политик аңын гарипләндерү өчен бернинди объектив җирлек юк. Яшьләр арасында идея-политик эш алып баруның тагын да камилләшкән ысулларын эзләп табу юлында бездә күп кенә чаралар үткәрелде һәм үткәрелә. Тәрбия эшен тиешле югарылыкка күтәрү өчен кирәкле ул чараларның төп звеносын эзләп таптык шикелле. Университетта Ленин традицияләрен торган саен тирәнрәк үзләштерү һәм ныгыту — минемчә, төп звено әнә шул. Яшьләрне Владимир Ильич Ленин образы үрнәгендә, совет патриотизмы принципларында һәм буржуаз идеология белән килешмәүчәнлек рухында тәрбияләү безгә аңлы һәм киң колачлы белгечләр әзерләү эшен тиешле югарылыкка күтәрүдә төп корал булып хезмәт итә.

**Әңгәмәне АЛЬБЕРТ МӨСЛИМОВ язып алды.**

**Светлана Червонная,**
СССР художество Академиясе каршындагы сәнгать теориясе һәм тарихы институтының өлкән фәнни сотруднигы.

# КУАНЫЧЛЫ КҮРЕНЕШ

*Татарстан рәссамнары «Зур Идел» күргәзмәсендә*

**1969** ел ахырларында Владимир Ильич Ленинның туган шәһәре Ульяновскида Идел буе рәссамнарының өченче зональ күргәзмәсе ачылды. Ул «Зур Идел» дип атала. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган бу күргәзмә һәм күләме белән, һәм эчтәлеге белән әлегә кадәр үткәрелеп килгән күргәзмәләрдән аерылып тора. Иҗат коллективлары аңа аеруча җаваплылык белән әзерләнгәннәр. Сәнгать осталары Идел буе халыкларының революцион тарихын бөтен катлаулылыгы белән, сәнгатьчә тирәнлек белән ачарга омтылалар. Күргәзмәдә В. И. Ленин образы, аның характеры җанлы үсеш процессында бирелгән. В. И. Ленинның ихтыяр ныклыгын, рухи көчен, даһи булып җитлегүен күргәзмәгә куелган әсәрләрдән шактый ачык күзалларга мөмкин. «Зур Идел» күргәзмәсендәге әсәрләрдә, бер яктан, В. И. Ленинның тормышы һәм революцион эшчәнлеге чагылдырылган булса, икенчедән, рәссамнарның заман темасына йөз тотулары, ленинизм идеяләренең тормышка ашырылуын сурәтләргә омтылулары яхшы сизелә.

«Зур Идел» күргәзмәсендә Идел буе зонасына кергән үндүрт иҗат коллективы катнашты. Шуларның бишесе Идел буендагы автономияле республикаларның милли культураларын тәшкил итә. Бу автономияле республикаларның рәссамнары сәнгатьтә үз туган җирләренең кабатланмас образын үзенчәлекле буяуларда чагылдыралар. Аларның милли колориты күргәзмәнең гомуми яңгырашын тагын да тулыландыра, баета төшә. Рус совет реалистик сәнгатенең иң көчле традицияләрен Горький, Волгоград, Ульяновск, Ярославль, Кострома, Калинин, Куйбышев, Астрахань, Саратов рәссамнары — тематик картина, пейзаж, скульптура, графика осталары үстерәләр.

Мари АССР рәссамнары тамашачыларны формасы белән нәфис булган кызыклы графика, агачка кисеп эшләнгән декоратив бизәкләр, югары культуралы пейзаж рәсемнәре белән шатландырды. Чувашстанның яшь рәссамнары күргәзмәгә шактый җитди, зур масштаблы тарихи һәм жанр картиналары алып килгәннәр. Аларның халык тормышындагы әһәмиятле темаларга шулай кыю тотынулары бик куанычлы күренеш. Удмурт рәсем сәнгатендә революция һәм хезмәт темасы күп кырлы яктыртылган, бик үзенчәлекле психологик портретлар бар. Аларның иң яхшы картиналарына чор, заман тойгысы, эчке эмоциональ киеренкелек, күтәренке романтика хас. Калмык автономияле республикасының иҗат коллективы — Идел буендагы иң яшь һәм иң кечкенә коллектив. Шулай булуга да карамастан, бик үзенчәлекле декоратив сәнгатьләре, кыю фантазия һәм пөхтәлек белән халык авыз иҗатына таянып эшләнгән картиналары бу коллективның көчен ачык күрсәтә.

Зональ күргәзмә комиссиясе, «Зур Идел»гә әзерлек чорында ике меңнән артык хезмәт белән танышып, шулардан сигез йөзләбен халыкка күрсәтергә сайлап алды. Югары зәвык һәм зур принципиальлек, таләпчәнлек сорый торган бу бик катлаулы һәм «четерекле» эштә рәссамнарның иҗади эзләнүләренә игътибарлы булу да кирәк иде, әлбәттә: Идел буеның социалистик сәнгатендә булган чиксез байлыкның иң яхшы дигәнен генә сайлап алырга, һәр республика һәм өлкәне иң үзенчәлекле ягыннан күрсәтергә, шул ук вакытта күргәзмәнең тулаем гармоник бөтенлегенә дә ирешергә, аның социалистик реализм принципларына нигезләнгән идея юнәлешен дә ачыкларга кирәклек таләбе иде бу.

«Зур Идел» күргәзмәсендә Татарстан рәссамнарының әсәрләре күренекле урын тота. Кырык дүрт авторның сиксән ике әсәре, ягъни күргәзмәгә куелган хезмәтләрнең уннан бере — менә татар рәссамнарының күргәзмәдәге өлеше. Үткән күргәзмәләр белән чагыштырганда, бу — җитди уңыш.

Татар рәссамнарының шундый зур күргәзмәгә массовый төстә катнашулары бик куанычлы күренеш. Күп кенә авторлар мондый зур сәнгать смотрында беренче мәртәбә катнашалар. Яшьләрнең күргәзмәдән күргәзмәгә арта баруына да куанмый мөмкин түгел. Әле утыз яшькә дә җитмәгән рәссамнарның күпчелеге соңгы елларда Казанда яхшы традициягә әйләнгән республика яшьләре күргәзмәләрендә чыныгып үстеләр.

Иҗади бурычларның җитдилеге, фикер тирәнлеге, халык тормышы белән тыгыз элемтә тойгысы, югары сәнгать осталыгына омтылу — Совет Татарстаны рәссамнарының яхшы әсәрләренә хас сыйфатлар.

Күргәзмәнең үзәгендә Харис Якуповның «Пролог» исемле картинасы булды, дисәк, һич тә арттырып әйтү булмас. Бүгенге совет рәсем сәнгатендә В. И. Ленинның яшьлегенә, революцион эшчәнлегенең башлангыч чорына багышланган шундый көчле гражданлык пафосы, ачык публицистика, шундый югары осталык белән хәл ителгән башка берәр әсәрне әле атап күрсәтүе дә кыен. Сәнгать чаралары дисеңме, композицион төзелеше дисеңме: төрле төсләргә күмәкләрнең тәэсирле ритмы, студентларның зәңгәр мундирлары, тесләрнең киеренкелеге, яныл-уйнаклап торулары рәсемне гаҗәеп дулкынландыргыч итә. Казан университетындагы 1887 елгы революцион сходка безнең күз алдына җанланып килеп баса. Студентларның характерлары бик нечкә тотып алынган, индивидуаль тойгылар төсмере — ачу, протест, эшчәнлеккә сусау, яшьлекнең саф ашкынуы күңелләрне тетрәндерә. Бунт күтәрүчеләрнең күз карашларында зур киеренкелек чагыла, алар самодержавие власте вәкилләренә куркусыз карап торалар, ә караңгы көчләр сафы арасында аптырау, югалып калу галәмәтләре үскәннәнүсә бара. Иске режим тәртипләренә протест йөзеннән, иң беренчеләрдән булып ректорга үзенең студент билетын тапшыручы яшь Володя Ульянов образында рухи көч, ныклык, көрәштә килешмәүчәнлек тупланган.

Ульяновлар гаиләсе өчен бик авыр булган шул ук 1887 ел вакыйгаларын Лотфулла Фәттахов исә бөтенләй башка эмоциональ чишелештә бирә. Аның «Уйлар [Володя Ульянов Иделдә]» исемле картинасы тыныч лирик жанрда хәл ителгән. Художник яшь Ленинны Идел пристанендә, кемештәй елга пейзажы, зәңгәр һәм алсу яктылык белән өретелгән биек күк фонында сурәтли. Володя гади татар карты белән янәшә утыра. Бер-берләренә һич тә охшамаган, төрле караштагы бу ике кеше Идел ярында очраклы очрашканнар. Ләкин аларның уйлары бер юнәлештән ага кебек, күңелләренең рухи якынлыгы үскәннән-үсә бара төсле тоела. Карт белән егетнең күңелләрендәге бу авазадашлык тойгысы һәр икесенең дә бердәм уйчанлыгыннан да, бер позада булулары һәм силуэтларының «авазадашлыгыннан» да киләдер, мөгаен. Унҗиде яшьлек Володя Ульяновның Сембердән Казанга килү чорында чынлыкта булган шушы кечкенә эпизод аркылы Л. Фәттахов В. И. Ленинның татар халкы белән тамырлары яшьлек елларына ук барып тоташа торган рухи бәйләнешен татар рәсем сәнгатендә ышандырырлык итеп күрсәтә алган.

Ленин темасы татар рәссамнарының зур тарихи полотноларында гына чагылып калмый. Менә С. О. Лывинның «В. И. Ленин Кокушкинода беренче сөргендә булган җирләр» исемле лирик пейзажлар сериясе. Беренче сөрген. Эчпошыргыч озак үтә торган айлар-көннәр. Яшь Ленин табигатьтән юаныч таба. Ә табигатьне художник әле ягымлы, әле кырыс, әле тынгысыз итеп сурәтли белгән. «Үшнә аръягында» исемле



С, Лывин. «Кокушкино».

картина табигатьнең драматик халәтен тасвирлый: шомлы караңгы күк йөзе, кәрәлыр-га өлгергән җир өстендә март аеның соңгы кар таплары, йөнтәс бүрек төсле карга ояларыннан сыгыла төшкән шәрә ботаклы агачлар, ниндидер эчке сагыш һәм яшерен борчудан җиргә сеңгән ярлы авыл өйләре... Бу сериядәге икенче картина «Кокушкино» дип атала. Биредә ягымлы-нәфис, көмешсу-яшькелт апрель ае сурәтләнә: яшь каенлыктан яктылык бөркелә, авыл йортларының юылган тәрәзәләре дә күңеллерәк тоелалар, язгы юлда арбалар күренә. Шушы яз белән бергә күңелдә үзеннән-үзе ниндидер олы өмет уяна. Ә инде «Черемышев болыннары» исемле картинадагы май яшеллегенә төренгән яшьлек көче, тыелгысыз шатлык сине бөтенләй әсир итә.

Революциядән соңгы татар авылының беренче еллары В. И. Кудельюкинның «М. И. Калинин Татарстан крестьяннарында кунакта» дигән картинасында бик матур чагылыш тапкан. Рәссам очрашуны бик җылы итеп күрсәтә алган: бәйрәмчә чиста, якты авыл өе, «бөтен Рәсәй старостасы» Михаил Иванович Калинин өстәл янында крестьяннар белән тәмләп сөйләшеп утыра. Үзләренә киңәш белән дә, эш белән дә күп ярдәм күрсәткән кунакны татарлар яратып, үз итеп тыңлыйлар. Калинин белән алар арасында табигый берлек сизелә.

Исмәгыйль Хәлилуллов та үзенең «Җир хуҗалары» исемле картинасын октябрьдән соңгы крестьяннар тормышына багышлаган. Ләкин ул аны башка рухта — драматик эчеренкелек һәм психологик үткенлек белән чишкән. Болытлы һава һәм язгы басу тонык-яшькелт һәм көлсу-соры төсләрдә бирелгән булса, крестьян хезмәтен символлаштыручы сабан төрәне кызыл төстә. Сабан янында өч ир-ат, өч буын вәкиле: бабай,

хәрби гимнастеркалы яшь сабанчы һәм ябык йөзле чандыр яшүсмер. Әле балалыктан чыгып җитмәгән яшүсмернең зур күзләрендә өлкәннәрчә җитдилек чагыла, ул үзе әтисеннән калган шинельгә баш-аягы белән чумган, башында — кызыл йолдызлы буденовка, сирень төсендәге күлмәге иртәнге яктылыкта әллә каян күренеп тора. Рәссам бу өч кешенең язмышлары уртаклыгына басым ясый, аларда халыкның яңа юл белән барырга катгый карар кылган, Ватаны өчен, җире өчен җаваплылык тойган, көрәштә авыр сынауларга да әзер торган нык рухлы вәкилләрне күрә. Автор бу картинаны утызынчы еллар башы — колхозлашу чоры дип уйлап иҗат иткән булса да, биредә егерменче еллар рухы, беренче коммуналарга хас тынгысыз романтика күбрәк сизелә. Кыскасы, биредә тарихи төгәллек юк. Картина халык язмышы турында, революцион традицияләрнең буыннан буынга күчүен гомумиләштереп, символик характерда уйлану формасында иҗат ителгән.

Совет Татарстанының бүгенге көне күргәзмәдә индустриаль пейзажларда, республиканың нефть һәм химия промышленностена багышланган картиналарда чагыла. Н. Д. Кузнецовның «Кара алтын» һәм «Татарстанның индустриаль пейзажы» картиналары, Мәхмүт Усмановның «Түбән Кама химстрое» картинасы әнә шундыйлардан. Аларда бөек төзелешләр, энергияле хезмәт ритмы, күз алдында өзлексез туып тора торган могҗизалар тасвирлана.

Бүгенге тыныч, якты тормыш күренеше Б. И. Майоровның «Аларның улы» исемле картинасында матур чагылыш тапкан. Е. В. Зуевның «Балалар бакчасы» дигән картинасы декоративлыкның яңа сыйфатларын, заман тойгысының үткенлеген раслап тора. Рәсемдә шәһәрнең кояшлы яңа районы ачык балкон ишеге аша, ялт итеп торган тәрәзәләр аша күренә. Бүлмә идәненә кызыл келәм җәелгән, заманча матур интерьер бирелгән. Идәндә алсу күлмәкле курчак утыра. Зәвыклы мебель, чәчәкләр... Болар барысы да күтәренке рухта, шатлык тойгысы белән сурәтләнгәннәр. Яшь художник Эрот Зариповның «Якташ кызлар» исемле картинасы җылы һәм чиста буяуларның матур гаммасыннан тора. Авыл тормышын, андагы поэзияне художник такт белеп, зәвык белән күрсәтүгә ирешкән. Яшь рәссамның таланты киләчәктә тагын да ачыла төшәр дип ышанабыз, шунлыктан аны тышкы эффектлар белән мавыгудан, арзанлы модага иярүдән кисәтәсе, саклыйсы килә.

А. Л. Прокопьевның лирик Идел пейзажлары, республиканың өлкән рәссамнарыннан берсе Н. М. Сокольскийның «Көзге Казанка»сы турында да яхшыдан башка сүз әйтеп булмый. Тагын бер куанычлы хәл: казанлылар «үз» темалары белән генә чикләнеп калмыйлар. Н. Д. Кузнецовның «Мәскәүнең яңа силуэтлары» дигән пейзажлар триптихын карагач, Советлар Союзы башкаласының бүгенге поэтик матурлыгын шулай тирән һәм оста итеп Мәскәү художникларының да күбесе ясый алмас иде, диярга генә кала. Бу мисал Совет Россиясе белән Татарстан нәфис сәнгать культурасы арасындагы якынлык тойгысын тагын да көчәйтә, күп милләтле совет сәнгатендәге төрле



Б. Майоров. «Аларның улы».

юнәлешләрнең бер-берсенә йогынты ясауларына һәм якынаюларына ачык дәлил була ала.

Татар скульпторларының хезмәтләре күргәзмәдә чагыштырмача аз иде. Әмма булган кадәресе үзенчәлекле характерлары, декоративлыгы, кызыклы пластик формалары белән истә калды. Васил Маликовның көмеш сыман якты мәрмәрдән эшләнгән «Хәтерлимсең, иптәш...» һәм «Һади Такташ» әсәрләре лиризмга искиткеч бай булуы, образларның эмоциональ сәнгатьчәнлеге белән җәлеп итә. Скульпторның ташны пластик эшкәртүдә югары культурага ия булуы күренеп тора. Нәүфәл Адылов математик Якушев портретын караңгы тондагы агачтан кисеп эшләгән. Бу әсәрнең монументальлеге, формасының җыйнаклыгы кеше фикеренең киеренкелеген күрсәтүдә зур уңыш булып тора. Скульптор Рада Нигъмәтуллина агач белән әле беренче мәртәбә эш итә. Аның юмор белән бирелгән шаян малае — «Уеннан уймак» һәм аналарча иркәлек, ягымлылык салынган «Бишек җыры», һичшиксез, уңышлы әсәрләр.

Татарстанның хәзерге графикасы да күргәзмәдә бик яхшы бәя алды. Бигрәк тә Ситдыйков, Язынин, Хаҗиәхметов, Карамышевларның хезмәтләре отышлы иде.

Эмиль Ситдыйков, үзенең «Кызыл Байрак кешеләре» дигән линогравюралары сериясен дәвам итеп, замандашларыбызның яңа образларын тудырган. Аның геройлары үз көчләренә ышанучы, күңелләре белән матур кешеләр. Бу сериядән иң уңышлы эшләрнең берсе — «Бабай» исемлесе. Художник татар крестьянының милли характерын әйбәт тотып алган. Совет кешесенең горурлыгын, картларга хас акыл һәм тәҗрибәне оста гәүдәләндергән ул. Стильләштерүдә һәм гротескта зур осталык, җанлы юмор, фольклор дөньясына теп керә белүе белән Тавил Хаҗиәхметов татар халык әкиятләрен бик матур иллюстрацияләгән.

Тукайның үлемсез шигърияте, аерым алганда «Су анасы» әкияте, Валентин Карамышевны матур акварель рәсемнәр иҗат итәргә илһамландырган. Әле моңа кадәр бу шигъри әкият графикада болай тулы итеп чагылдырылмый иде. Карамышевның су анасы ниндидер кешеләргә ят сагышлы, күңелне кузгатырлык кайгылы, аның чәч




Т. Хаҗиәхметов. «Халык әйтсә — хак әйтер» дигән шаян мәзәкләргә эшләнгән гравюралар сериясенең бер бите.

чәчләре, үпкәләгән кыяфәттәге йөзе тамашачыга көчле тәэсир итә. Авторның пейзаж мотивлары — бер якка сәрлеккән урманы, әйтерсең, алтын таракны урлаган малайны су анасы белән бергә куа бара, басмада чәчен тарап утыручы су анасының аяк очында җиңел зур чәчәкләр янып ята, су анасы тәрәзә янына килгәч, тәрәзәдән айлы салкын зәңгәр төн дә шомлы күренә — болар бары да әкияттәге образларны сәнгатьчә сурәтләүдә актив катнашучы элементлар.

Иван Язынин С. Злобинның «Степан Разин» романына иллюстрацияләр ясаган. Китап өчен генә дип эшләнгән бу рәсемнәр «Өч гасыр аша» исемле мөстәкыйль серия булып җитлеккәннәр. Язынин моннан өч гасыр элек Степан Разин җитәкчелегендә азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән Идел буе халыкларының идеаллары бүгенге татар совет халкына да рухи якын икәнлекне үзенчә ачып бирә алган. Әлеге сериядән бигрәк тә «Идел өстендә» һәм «Тәре һәм зынҗырлар белән» дигән рәсемнәр көчле тәэсир калдыра. Аларның беренчесендә атаман Разин биек кыяга басып, бөтен Идел өстен баһадирларча сызгырып яңгырата. Йокыга талган иске дөньяны сискәндереп, халыкны хак эш өчен көрәшкә чакырып сызгыра ул. Икенче рәсемдә зур агач тәрәгә чылбырлар белән богаулап куелган атаманны җәза мәйданына илтәләр. Разин арбада ачык ак күлмәктән басып тора, әйтерсең, ул аксыл томанда беленер-беленмәс күренгән чиркәүләр, храмнар өстеннән, Мәскәү өстеннән йөзеп бара. Разин һаман да бөек, һаман да көчле рухлы, богауланган булса да, башы күкрәгенә салынып төшсә дә, ул һаман да буйсынмаган, ул һаман да Идел өстен яңгыратып аваз салырдай мәгърур атаман булып кала.

Татарстан рәссамнары «Зур Идел» күргәзмәсенә, башка өлкә һәм республикалардан аермалы буларак, театр декорациясе (Әнәс Тумашевның Сәхиб Җамал пьесасы «Фатыйма Сабри» спектакленә эскизлары), монументаль-декоратив сәнгать (Е. В. Киселеваның витраж эскизы), плакат (Рөстәм Килдибеков, Илдар Әхмәдиев һәм башкаларның эшләре) һәм «Чаян»ның сатирик графикасы кебек жанрлар белән дә катнаштылар.

«Чаян» рәссамнарының хезмәтләре күптән түгел Мәскәүдә үткәрелгән «Сатира тынычлык өчен көрәштә» исемле халыкара күргәзмәдә дә уңыш казанган иде инде. Бирәдә дә алар югары бәя алдылар. Бигрәк тә Л. Ельковичның «Беренче мәртәбә Куклукс — класста», И. Әхмәдиевның «Күрәсең, син яхшы гаиләдән» әсәрләре һәм күргәзмәнең иң яшь авторы Ю. Денисовның «Самогоныңны яхшыртмасаң, аппаратыңны конфисковать итәм» исемле рәсеме яратып кабул ителделәр.

Совет Татарстаны рәссамнарына В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган күргәзмәгә катнашу хокукы республика исеменнән, татар халкы исеменнән бирелгән иде. Аларның хезмәте үз халкына лаеклы булып чыкты, күңелләрне шатландырды. «Зур Идел» күргәзмәсендә татар рәсем сәнгате Совет Татарстанының бүгенге олы мәдәниятендәге, бай тормышындагы куанычлы күренеш булып гәүдәләнде.

# *ЗУР БӘЙРӘМГӘ ЯҢА КИТАПЛАР*

## БЕЗНЕҢ ЛЕНИНИАНА

*Халык бәхете өчен армый-талмый көрәшкән сөекле юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинга барлык совет халкының, бөтен дөнья хезмәт ияләренең хөрмәте һәм мәхәббәте чиксез зур. Аның бөек исеме, үлмәс истәлеге Жир шарындагы барлык намуслы кешеләрнең күңел түрендә. Халыкның иң кирәкле, иң кешелекле сыйфатларын үзендә туплаган даһи юлбашчыбызның якты образы миллионнар өчен җылылык һәм көч чыганагы, илһам һәм дәрт чишмәсе булып тора.*

*Юлбашчыга булган тирән хөрмәт һәм чикләнмәгән мәхәббәт хисләрен халык үзенең иҗатында гәүдәләндергән. Элек-электән Жир шарының бөтен почмакларында Ленинга багышланган шигырь-поэмалар, повесть-хикәяләр, сәхнә әсәрләре языла килгән, истәлекләр һәм мәкаләләр басылып чыга торган. Шулай төрле илләрдә, төрле телләрдә гаять зур әдәби байлык тупланган.*

*Хәзер татар укучылары шул байлыкның шактый өлеше белән үз ана телебездә таныша алалар.*

**Безнең Ильич. Казан. 1966 ел.**
***Төзүчесе* М. ГАЙНУЛЛИН**




**Республикам минем, Татарстан,**
**Ленин сине танга караткан...**

Бу шигъри юлларга тирән мәгънә салынган. Әйе, шагыйрь Сибгат Хәким хаклы: Ленин һәм Татарстан, Ленин һәм татар халкы бер-берсеннән аерылгысыз.

В. И. Ленин үзенең сабыйлык һәм балалык елларын Казан тирәсендәге матур табигать кочагында уздыра. Ул — безнең бөек якташыбыз. В. И. Ленин безнең Казан университетында укый, шунда революция юлындагы беренче адымын атлый. Аның яшьлеге, революцион эшчәнлеге Казан белән бәйләнгән. Үзенең ярты гасырлык бәйрәмен каршыларга җыенган Татарстан республикасы В. И. Ленинның турыдан-туры катнашы белән, аның житәкчелегендә төзелде. Республиканың экономикасын торгызуда булсын, татар халкының милли культурасын үстерүдә булсын, ул якыннан булышып, ярдәмләшеп торды.

Шуңа күрә татар халкының юлбашчыга булган ихтирам хисе дә аеруча зур, үтә эчкерсез һәм самими иде. Татарстан жирлегендә иҗат ителгән әдәбият-сәнгать әсәрләрендә аның образы иң хөрмәтле урынны алып тора.

Татарстан китап нәшрияты басып чыгарган «Безнең Ильич» исемле җыентыкка татар әдипләренең, журналистларының һәм күренекле җәмәгать эшлеклеләренең юлбашчыга багышланган әсәрләреннән бер өлеше тупланган. Ленин идеяләренең үлемсезлегенә дан җырлаган ул әсәрләр укучыларыбызны Ленинча яшәргә һәм эшләргә рухландыралар.

**Һәркемнең күңелендә. Казан. 1967 ел.**
*Төзүчесе* **З. НУРИ**

«Һәркемнең күңелендә» — татарча лениниананың икенче томы. Бу том күп милләтле совет әдәбияты җәүһәрләреннән — СССР язучыларының бөек Ленинга багышланган, аның тормышыннан, эшчәнлегеннән аерым вакыйгаларны һәм эпизодларны чагылдырган әсәрләреннән төзелгән.

Жыентык В. Маяковскийның «Владимир Ильич Ленин» исемле мәшһүр поэмасыннан өзек белән ачыла. Алга таба С. Есенин, К. Федин, М. Зощенко, С. Маршак, А. Сурков, Р. Гамзатов, М. Шагинян, Н. Тихонов кебек күренекле әдипләрнең, шулай ук башка рус язучыларының һәм украин, белорус,




казакъ, үзбәк, әзербәйҗан, грузин, әрмән, эстон, башкорт, чуваш, калмык, балкар, мари әдәбиятлары вәкилләренең Ленин хакындагы әсәрләре белән очрашабыз. Укучылар Владимир Ильичның якыннарыннан һәм көрәштәшләреннән А. И. Ульянова-Елизарова, В. Д. Бонч-Бруевич, К. Е. Ворошиловларның истәлекләрен дә яратып каршы алганнардыр дип ышанырга була.

СССР халыклары әдәбиятының Ленинга багышланган иң яхшы үрнәкләрен тәрҗемә итү эшенә нигездә тәҗрибәле кешеләр тартылган. Шигъри әсәрләрнең күбесен З. Нури, Н. Арсланов, М. Садрилар тәрҗемә иткән, проза әсәрләрен тәрҗемәләүдә Х. Сарьян, С. Сабиров, Р. Сабиров, С. Ибраһимова, Н. Гобәйдуллиннар катнашкан. Аларның эше хуплауга һәм мактауга лаек.

**Ленинның якты юлыннан. Казан. 1968 ел.**
*Төзүчесе* **З. НУРИ**

Алда әйтелгәнчә, Ленин идеяләренең әһәмияте, Ленин тәгълиматының кыйммәте бер безнең ил белән генә чикләнми, ул бөтен дөнья хезмәт ияләренең сөекле юлбашчысы. Пролетар юлбашчысын олылаган җырлар, легендалар Җир шарының бөтен почмакларында, дөньяның бөтен телләрендә иҗат ителә.

Ленинианаың өченче китабы дөнья халыклары әдәбиятының Ленин темасына язылган әсәрләреннән тупланган. Дөрес, анда совет язучыларына да (М. Горький, Н. Асеев, С. Щипачев, А. Твардовский, С. Хәким, Н. Вирта, С. Антонов һ. б.) шактый урын бирелгән. Шулай да күпчелеге




чит илләрнекеләр. Аларның Назыйм Хикмәт, Ж. Жерманетто, И. Бехер, Джон Рид, Петрос Антеос кебекләре белән татар укучылары электән таныш. 20 ләп илнең (Америка, Англия, Аргентина, Австралия, Бирма, Венгрия, Греция, Иран, Испания, Италия, КНДР, Куба, Норвегия, Польша, Румыния, Франция, Швеция, Чили, Япония, Һиндстан) калган әдипләре белән укучы, ихтимал, беренче тапкыр шушы китапта очрашадыр.

**Исеме халык телендә. Казан. 1970 ел.**
*Төзүчесе* **И. НАДИРОВ**

Күп милләтле Россиядә пролетариат башлаган бөек азатлык хәрәкәте Октябрь




революциясенең җиңүе белән тәмамланды. Революция халыклар иҗатында гасырлар буе якты нур булып балкый торган азатлык һәм бәхет хыялын тормышка ашырды. Халыклар яңа чынбарлык тәэсирендә үзләренең тормышка ашкан өметләре, табылган бәхетләре һәм шатлыклары турында җыр башладылар. Төрле телләрдә, төрле төбәкләрдә иҗат ителә башлаган яңа фольклор китабының иң беренче битенә алтын хәрефләр белән Ленин исеме язылды.

Татарча ленинчананың бәйрәм алдыннан чыккан чираттагы томы СССР халыклары фольклорына багышланган. Җыентык филология фәннәре кандидаты И. Надировның «Халыклар шигъриятендә Ленин образы» исемле кереш сүзе белән ачыла. Соңыннан киң илебезнең төрле почмакларында яши торган халыкларның юлбашчыга багышланган әсәрләреннән үрнәкләр: әкиятләр, сөйләкләр, җырлар, поэмалар, легендалар китерелә.

Халыклар хәтерендә Ленин образы бөек юлбашчы, даһи фикер иясе булып кына түгел, акыллы һәм гади, тыйнак һәм ягымлы кеше буларак та саклана, ди И. Надиров. Бу образда халыклар безнең чорның иң күркәм уңай героен, идеаль героен күрәләр. Ленин образы СССР халыклары поэзиясенең иң күркәм казанышларыннан берсе.

**Гасырлар кешесе. Казан. 1970.**
*Төзүчесе* **М. САДРИ**




Озакламый китап кибетләренә татарча ленинчананың бишенче томы да чыгып житәр. «Гасырлар кешесе» исемле ул китапта совет язучыларының В. И. Ленинга багышланган иң яхшы пьесалары һәм киносценарийлары тупланган. Юлбашчы тормышының төрле этапларын, Ленин идеяләренең тантанасын һәм ленинизмның җиңелмәс көчен күрсәткән драма әсәрләре әдәбият сөючеләр өчен зур бүләк булыр.



*ТАТАРСТАННЫҢ ЕЛЛЫГЫНА*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ РЕВОЛЮЦИОН ҖЫРЛАРЫ

Җыр элек-электән революциячеләрнең турылыклы юлдашы булып килгән. Халык массаларын көрәшкә күтәргән ялкынлы җыр җәмгыятьнең сәяси тормышында мөһим урын тоткан.

Татар хезмәт ияләре арасына революцион җырлар башлап 1905—1907 елгы вакыйгалар белән килеп керә. Татар теленә тәрҗемә ителгән революцион җырлардан «Марсельеза», «Варшавянка», «Матәм маршы» кебекләре аеруча популяр саналган. Ул вакыттагы газета-журналларда бу хакта еш языла.

«Алабуга шәһәре татарлары,— дип яза «Казан мөхбире» газетасы үзенең 1905 елгы 2 ноябрь санында,— руслар белән бергә, кызыл байраклар тотып, урамнарга чыктылар, «Марсельеза» җырладылар». Менә «Азат» газетасының 1906 елгы 4 май санында басылган бер хәбәр: «Манифестантлар Державин бакчасында «Марсельеза» җырладылар. Күпләр кулга алынды» [1]. Алдынгы матбугат моның белән генә чикләнми, революцион эчтәлекле җырларны пропагандалау эшенә дә якыннан катнаша. Оренбургта чыга торган большевистик «Урал» газетасы, мәсәлән, үзенең 1907 елгы 12 январь санында көчле революцион рух белән сугарылган «Тәрмәдән» исемле бер җыр урнаштыра һәм аны халык арасында киң таралган «Мәкәрҗә» көенә башкарырга тәкъдим итә [2]. Хезмәт ияләрен революцион көрәшкә күтәрүдә «Марсельеза»ны башлап тәрҗемә иткән күренекле татар шагыйре Сәгыйт Рәмиевның ролен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Аның «Варяг», «Стенька Разин» кебек рус көйләренә җырлана торган «Сызла, күңелем», «Бетте баш, кипте яшь» җырлары да халык арасында бик популяр була» [3].

1905 елгы революциядә, рус һәм татар эшчеләре белән бергә, мәдрәсә шәкертләре дә актив катнаша. Революцион вакыйгалар эчендә кайнаган шәкертләр байтак яңа җырлар иҗат итәләр. Соңыннан аларның кайберләре халыкның түбән катламнары тарафыннан күтәрелеп алына, шулай алар илнең татарлар яшәгән бөтен почмакларына таралалар. «Беренче сада», «Икенче сада», «Өченче сада» һәм Г. Тукай сүзләренә

---

[1] Цитата «Вопросы татарской музыки» (Казан. 1967 ел. 195 бит) исемле җыентыктан алынды.

[2] Шунда ук, 194 бит.

[3] Ш. Рахманкулов. Татарда музыка культурасы. «Совет әдәбияты» журналы. 1945 ел. 6 сан.

**жырлана торган «Шәкертләр жыры» кебек жырлар, мәсәлән, шундый бәхетле язмышка очрыйлар.**

**Беренче революцион татар көйләре асылда рус пролетар жырлары йогынтысында туа. Әмма аларның текстларында профессиональ татар поэзиясенең һәм халык авыз иҗаты әсәрләреннән бәетләрнең көчле йогынтысы сизелә. Шәкертләр иҗат иткән ул жырларның эчтәлеге төрлесенеке төрлечә. Бер ишеләрендә шәкертләрнең авыр язмышыннан зарлану ноталары өстенлек итсә, икенчеләрендә, көрәшкә чакырып, набат авазлары яңгырый. Соңгыларының текстлары да яшәп килгән стройга каршы көрәшкә күтәрелергә өндәгән ялкынлы сүзләр белән тулы. «Шәкертләр жыры»нда, мәсәлән, «Алга, алга! Алга табан, алга дуслар, басыйк табан» кебек чакырулардан соң патша строен, иске җәмгыятьне фаш иткән юллар килә: «Моңгар чаклы җәһел безне артка тарткан да алдаган». «Беренче сада»да исә бу чакыру тагын да ялкынлырак һәм конкретрак төс ала:**

**Кояш чыкты, нур балыкты,**
**Тәрәзәдән өйгә аркылды.**
**Ятма йоклап, уян, шәкерт,**
**Файдаланыр вакыт җитте!**

**Революцион татар жырларының төп чыганагы — татар һәм рус халыкларының шәһәр жыр фольклоры. Ачыграк аңлашылсын өчен, революцион жырларны өч төркемгә бүлеп тикшерергә мөмкин булыр иде. Беренче төркемгә электән яшәп килгән популяр шәһәр жырларының көйләрен үзгәрешсез-нисез үзләштергән революцион жырлар керә. Югарыда исемнәре телгә алынган жырлардан «Өченче сада», мәсәлән, «Сәлим бабай», ә «Төрмәдән» «Мәкәрҗә» көенә башкарылган. (Бүгенге көндә аларның беренчесенә Г. Тукай язган сүзләр белән «Туган тел» жырлана, икенчесе «Яз да була» исеме белән мәгълүм.) Әйтелгәнчә, әлеге төркемгә кергән жырларда яңа сүзләрнең иске көй белән кушылып китүе музыкада берникди үзгәрешкә китерми диярлек. Шул ук хәл революцион рус жырларында да очрый икән. Музыка белгече А. Сохор аны түбәндәгечә аңлата: «...Яңа сүзләр белән бер үк вакытта яңа көй дә иҗат итү гел генә мөмкин булмаган... шуңлыктан, бик үк туры килеп бетмәсә дә, электән билгеле көйләрне яңа сүзләргә яраклаштырырга туры килгән. Ахыр килеп, тизрәк һәм ныграк тарату нияте белән (шулай ук конспирация максатларыннан чыгып...) дә яңа революцион текстлар аңлы рәвештә электән мәгълүм популяр көйләргә яраклаштырылган»[1]. Бу сүзләрне тулысы белән югарыда иске алынган татар жырларына карата да кулланып була.**

**Икенче төркемгә иске, әзер көйне күпмедер күләмдә үзгәртеп кабул иткән революцион жырлар керә. «Шәкертләр жыры» һәм «Икенче сада», мәсәлән, шундыйлар. Беренчесе «Как в Москве-городке» дигән студентлар жырына таянып чыгарылса, икенчесе «Хасбулат батыр» дигән рус жырына нигезләнгән. Иске жырларны кабул иткәндә, аларның сүзләре генә үзгәреп калмаган, хәтта мелодияләре дә үзгәреш кичергән. Һәм бу үзгәреш аларның төрлесендә төрле күләмдә чагыла. «Икенче сада» жырында, мәсәлән, татар көенә чит, ят интонацияләр, бигрәк тә кереш тон куллану белән бәйле интонация, үзгәртелгән. Бу — аларны үзара чагыштырып караганда да күренә:**





[1] А. Сохор. Русская советская песня. Рус телендә. 1959 ел. 46 бит.


«Шәкертләр җыры»нда музыканы үзгәртү исә көйнең бөтен характерын үзгәртә: элекке шат күңелле көй чакыру характерындагы җырга әйләнә. Җырның тавышларга бүленмәве, такт алдының булмавы, өч чирек үлчәүле булуына да карамастан, аңа тегәллек, марш характеры бирә.




Ниһаять, соңгы өченче төркемгә «Беренче сада» тибындагы яңа, оригинал җырларны кертергә мөмкин. Узган йөзнең 90 елларында иҗат ителгән бу җыр 1905—1907 елларда аеруча зур популярлык казана.



Әгәр җырның лад төзелешендә аңа милли төс бирә торган авазлар зур роль уйнаса, мелодик төзелештә рус җырларының йогынтысы сизелә: ул, әйтерсең лә, революцион гимннарның («Интернационал», «Кем һәммәне туйдыра», «Котырыгыз, тираннар» һ. б. ш.) көрәшкә чакыручан ялкынлы рухы белән сугарылган. Әлеге көйдәге соңгы кадансның «Славное море, священный Байкал» исемле мәгълүм Себер җырындагы беренче фразаның тәмамланышы белән тәңгәл килүе дә кызыклы:




Бөек Октябрь революциясеннән соң көрәш һәм протест җырлары митинг һәм демонстрацияләрдә генә түгел, театр сәхнәләреннән дә яңгырый башлый. Татар совет театры репертуарында, классик әсәрләр белән беррәттән, революция вакыйгаларына багышланган яңа пьесалар да мактаулы урын ала.

Халыкның аң һәм культура дәрәҗәсе үскән саен, революцион рус җырларының элекке тәрҗемәләре укучыны канәгатьләндерә алмый башлый. Татар шагыйрьләре ул җырларның яңа тәрҗемәләрен эшлиләр. Сембердә чыга торган «Таң» газетасы, мәсәлән, үзенең 1919 елгы 23 август санында, «Курыкмый алга!» исеме белән, «Смело, товарищи, в ногу» җырының Ф. Бурнаш тарафыннан тәрҗемә ителгән яңа вариантын урнаштыра [1]. Бу вариант халык арасында зур теләктәшлек таба, чөнки ул чорның ру-

---

[1] Х. Госман. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан университеты нәшрияты. 1960 ел. 133 бит.

хына бик туры килә. Халыкара коммунистик хәрәкәтнең бөек гимны «Интернационал» элек татар теленә күчерелмәгән була. Х. Госманның язуына караганда, революциядән соң аның берьюлы ике тәрҗемәсе эшләнә: беренче тәрҗемә 1919 елда Сәгыйт Сүнчәләй тарафыннан «Бәйнәлмилəл» исеме белән «Эшче» газетасында чыгарыла, икенче тәрҗемә «Акъегет» имзасы белән «Кызыл Армия» газетасының 1920 елгы 1 май санында басыла. «Бу икенең,— ди Х. Госман,— Сәгыйт Сүнчәләй эшләгәне киң таралды һәм, яңа тәрҗемә ясалганчы, озак еллар халык телендә яшәде»[1].

Әмма торган саен бер нәрсә ачыклана барды: яңа дәвернең рухына тәңгәл килердәй оригинал милли җырлар кирәк иде. Дәвернең бу ихтыяҗын башлап әдәбият, бигрәк тә поэзия канәгатьләндерергә омтылды. Бу чорда дистәләгән газеталар чыга, аларның һәрберсендә диярлек шигырьләр басылып бара. Аларны иҗат итүгә, танылган әдипләр белән бергә, революцион рухлы яшьләр дә катнаша. Әмма ул шигырьләрнең күбесе көйгә салынмый кала. Танылган музыкантларның байтагы (З. Яруллин, С. Габәши, Ф. Латыйпов һ. б.), революцион җырларны башкаручылар һәм пропагандалаучылар буларак, революциягә эшенә зур ярдәм күрсәтсәләр дә, яңа җырлар иҗат итмиләр диярлек. Әмма җырга сусау шул кадәр көчле була, күп кенә кызылармеецлар ул чактагы газета битләрендә халык көен революция эшенә җигәргә чакырып чыгалар. Төркстан армиясе каршындагы мөселман труппасы музыканты Х. Насыйров, мәсәлән, «Кызыл Армия» газетасының 1919 елгы 16 июнь санында шундый чакыру белән чыга: «Иптәшләр, музыкантлар, сез артык сизгер йөрәгегез белән бирелеп уйнаган музыкаларыгыздан, җыр вә такмакларыгыздан эшче вә игенче халык өчен җанын-тәнен корбан кылырга риза булган кызыл гаскәрләр арасына барыгыз! Талантлы музыкантлар, армияләргә язылыгыз!»[2]. Вакыт-вакыт алар, теге яки бу халык көенә яңа сүзләр язуларын үтенеп, шагыйрьләргә мөрәҗәгать итәләр. Гариф Гомәр «Кызыл яулардан бер иптәшнең, кызыл яулар өчен берәр нәрсә яз әле, дип әйтүе буенча» «Галиябану» көенә үзенең «Кызыл әләм, Кызыл йолдыз» исемле җыр язуын сөйли[3]. Яңа җырларга сусаган татар кызылармеецлары үзләре дә көй иҗат итәләр. Монда гаҗәпләнерлек берни дә юк, ул чакта массовый җыр иң күп яңгыраган урын нәкъ менә Кызыл Армия була.

Бу еллардагы рус җырларының ролен аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Гражданнар сугышында катнашкан татар солдатлары аларны яратып башкарган. Аларның күбесе татарча да җырланган (мәсәлән, «Совет власте өчен», «Без тимерчеләр» һ. б.). Шуңа күрә күп кенә татар җырларының текстлары да революцион рус поэзиясенең турыдан-туры йогынтысы тәэсирендә иҗат ителә. Аларда бер үк образлар, бер үк тематика гәүдәләнә: көрәш матурлыгы («Ком бураны»), Кызыл Армиягә («Батыр яшьләр»), яңа Ватанга («Яшәсен, яшәсен!») дан җырлау, дошманнан мәсхәрәле көлү («Илләр азат, күрәмсең») һ. б.

Эшчеләр, демократик карашлы интеллигенция һәм яшьләр арасында киң таралган кыска шәһәр көйләре гражданнар сугышы җырлары өчен төп мелодия чыганагы булып торган. Яңа текстлар белән алмашыну аркасында, интонацион яктан әллә ни үзгәреш кичермәсәләр дә, ул җырларның көйләре ачык яңгырашлы марш ритмын ала (шәһәр җырларының төгәл метрикалы булуы моңа ярдәм генә иткән). Әнә шулай элек лирик сүзләр белән башкарылып йөрелгән «Сандугач-күгәрчен» көеннән гражданнар сугышы елларында «Илләр азат, күрәмсең», ә «Күбәләгем»нән «Батыр яшьләр» исемле яңа җыр туа... Кайбер җырларның текстларына бераз үзгәрешләр кертелсә дә, исемнәре элеккечә, искечә кала. Мәсәлән, «Ком бураны», «Сәфәр» һ. б.

Бу еллардагы татар солдатлары арасында иң зур дан казанган җырларның берсе — «Бөтсен патша, янсын тәхет». Көйнең тарихы күптәннән килә. Рус-япон сугышы һәм Беренче бөтендөнья сугышы елларында ул «Окоп көе» исеме белән йөргән. Моңзар белән тулы солдат җырыннан сугышчан маршка әйләнгәндә, аңдагы:

Солдатский ремень белән
Будылар билләремне, шул,


---

[1] Шунда ук, 134 бит.
[2] Шунда ук, 117 бит.
[3] Шунда ук, 136 бит.

Йөгереп китәрдәй булам,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә
Туган үскән илләргә —

кебек сыкрау тулы сүзләр иске стройны җимереп ташларга (Бетсен патша, янсын тәхет, безгә патша кирәкми!), күп каннар бәрабәренә яуланган ирекле, азат тормышны сакларга чакырган юллар белән (Кулдан корал ташламабыз, сыйнфый дошман бетмичә!) алмашынып кына калмый. Җырның рухы ук үзгәрә. Бу хәлнең төп сәбәбе — әлеге көйнең функциясе үзгәрүдә: тар окоп җырыннан ул поход җырына әйләнә. Бу исә үз чиратында аның башкару характерын да үзгәртә: салмак, сузынкы мелодика кыю, тәвәккәл яңгыраш ала, чөнки катлаулы, бормалы ритмика марш характерындагы төгәл ритм белән алмашына, үлчәүнең үзгәрүе дә нәкъ шуңа ярдәм итә.

Гражданнар сугышы чорында гаять популяр булган тагын бер җыр сакланып калган. Сүз «Яшәсен, яшәсен!» исемле җыр турында бара. Заманында А. В. Затаевич, мәсәлән, аны казакъ җырчысыннан язып алган [1]. Әлеге революцион җырның ике варианты булуы билгеле. Түбәндәге беренче вариантны бу юлларның авторы гражданнар сугышында катнашкан кешедән язып алды [2]:




Башка төрле сүзләргә җырланган «Марш элгәре» исемле икенче варианты И. Мироновның 1926 елда Мәскәүдә басылган «Кыскача төп музыка нәзариясе» исемле китабында китерелә. Әлеге ике вариантны үзара чагыштырып карау нәтиҗәсендә аның элгәреге төп варианты нинди үзгәрешләргә дучар булуын ачыкларга мөмкин. Марш характерындагы ритм, соңгы фразаларның кабатлануы һәм җырдагы башка сыйфатлар борынгы халык иҗатына героик яңгыраш биргәннәр. Җырның икенче вариантында бу йогынты тагын да ныграк сизелә.

Шулай итеп, революцион татар җырларында пролетар интернационализм идеяләре ачык чагыла һәм бу күренешнең әһәмияте бер ул чор белән генә чикләнми. Гражданнар сугышы җырлары асылда беренче совет җырлары булдылар. Яңа тематика (көрәш героикасы, совет республикасын данлау), яңа жанрның барлыкка килүе (сугышчан поход җырлары), халыкчан интонацияләрне яңача аңлату — шушы барлык новаторларча сыйфатлар татар җыр сәнгатенең алга таба формалашуында зур роль уйнадылар.

Земфира СӘЙДӘШЕВА

---

[1] М. Ахметова. Песня и современность. Рус телендә. Алма-Ата. 1968 ел. 95 бит.
[2] Бу вариантның тексты И. Надиров чыгарган «Татар халык җырлары» исемле җыентыкта китерелә.

# БЕЗНЕҢ САФКА



Соңгы елларда татар әдәбиятына белемле, культуралы һәм иҗтимагый-фәнни өлкәдә иҗади эшләүче яшь язучылар килде. Шуларның берсе — Миркасыйм Госманов. Аналитик фикерләү сәләте, үткен һәм зирәк сүзе белән ул иҗтимагый һәм әдәби вакыйгаларны тирәннән аңларга, аларның тарихи үткәннәрен ачыкларга омтыла. М. Госманов хикәяләр язып бастыра, тәрҗемә белән шөгыльләнә. Аның публицистик мәкаләләре, фәнни хезмәтләре һәм рецензияләре Казан, Мәскәү матбугатында басылды һәм бүген дә басыла килә.

М. Госмановның әдәби тәрҗемәләре теленең сафлыгы һәм нәфислеге белән аерылып тора. Ч. Айтматовның турыдан-туры кыргыз теленнән тәрҗемә ителгән «Җәмилә» әсәре — моңа бик ачык дәлил. Тәрҗемә чын татар әсәре кебек укыла.

Сүз уңаеннан М. Госмановның берничә төрки тел белүен һәм иран-гарәп телләре белән дә таныш булуын әйтеп үтәргә кирәк. Бу нәрсә әдәби мираска мөрәҗәгать иткәндә бик зарур.

М. Госмановның әдәби-тәнкыйть мәкаләләрендә объектив фәнни анализ үткен полемика белән аралаша, аларда ул кызыклы актуаль проблемалар күтәреп чыга. Аның бигрәк тә татар культурасы һәм әдәбияты вәкилләре турында язган мәкаләләрен атап үтәргә кирәк. Аларда М. Госманов, яңадан-яңа документларны әдәби-гыйльми хәрәкәткә кертеп, бу өлкәдә чирәм күтәрүне дәвам итә. Аның эшләре тирән тарихилык белән сугарылганнар, аларга документаль төгәллек хас.

М. Госмановның бүгенге татар совет әдәбияты процессына керткән хезмәте бар иде.

Мин М. Госмановны СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәм.

ХАТИП ГОСМАН



Вакыйф Нуруллинны мин 1962 елдан бирле беләм. Аның газета-журналларда басылган беренче хикәяләре үк, минем игътибарымны җәлеп итеп, укучы буларак, күңелемдә кызыксыну тудырганнар иде. Минем ул яшь авторның, мөмкин кадәр тизрәк тиешле тәҗрибә туплап, үсеп, канатланып китүен күрәсем килгән иде.

Ләкин безнең заманда прозаиклар алай бик тиз җитлекмиләр шул! «Шинельсез солдатлар» исемле беренче повестен язып, бастырып чыгару өчен В. Нуруллинга алты ел вакыт кирәк булды. Яшь прозаик үзенең бу повесте белән укучылар каршына инде җитлеккән автор, лирик юнәлешле реалист буларак килеп басты.

1968 елда әдәби тәнкыйть һәм укучылар җәмәгатьчелегенең игътибарын җәлеп иткән бу повесть авторының уңышы, минемчә, шунда, анда ул үзенең чын кешелеклелеген һәм кешегә мәхәббәтен күрсәткән. Монысы мәсьәләнең фәлсәфи ягы. Әсәрнең әдәби эшләнеше ягына килгәндә исә, минем ышануымча, Нуруллин сугыш елларындагы яшь кешеләрнең тулы канлы образын тудырган. Автор әсәренең төп образын

шул кадәр ягымлы итеп сурәтләгән ки, укучы аның язмышына һич тә битараф кала алмый. Күңелне сафландыра, яхшы уй-хисләр уята торган әсәр язган автор.

Вакыйф Нуруллинның әйбәт тәрҗемәче һәм әдәби эшкәртүче булуын да әйтеп китәргә кирәк. Ул отставкадагы генерал-майор Фатих Булатовның «Генерал язмалары» исемле истәлекләрен әдәби эшкәртте һәм Сәгыйт Таҗетдиновның «Үлемнән яшәүгә» исемле документаль повестен татарчага тәрҗемә итте.

Бу ел В. Нуруллинның тагын бер китабы — «Төкле аягың белән» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыкты.

АТИЛЛА РАСИХ



Әгәр дә Фаил авылда, әтисез гаиләдә түгел, ә шәһәрдә, яхшырак шартларда үскән булса, әдәби мәйданга иртәрәк килгән булыр иде. Җидееллык мәктәптән соң хезмәт дөньясы мәктәбендә (һәм әле дә шунда) яшәгән егетне бүген инде без, байтак сынаулардан соң, язучылар сафына чакырабыз.

Безнең сафка ул «әдәбичәнлек»тән — литературщинадан түгел, тормышның-хезмәтнең үзеннән килә. Әйтми калмаслык шигъри хис-фикерләре бар хәлдә килә. Ничек итеп әйтергә кирәклеген тормыш инде шактый әйбәт өйрәткән аңа. Матбугатыбыздагы шигырьләре, аз сүзле, ләкин киң мәгънәле шигырьләре шуны раслыйлар. «Туган-үскән нигез ташларына» дигән шигыре — әчтәлегенең киңлеге, тирәнлеге белән Дәрдмәнднең «Кораб»ы янына куярлык шигырь.

«Алтын эзләүчеләр»енең төп фикере — «алтын тапты да шунда ук үзен югалтты» рәвешендә дидактик фикер генә кебек. Ләкин шул ялангач фикерне, сурәтләүләр аша әйтә белүе белән, кат-кат укырлык әсәр хәленә китерә. Халыкның шигъри телендәге гади, табигый гүзәл үзенчәлекләрне иҗади рәвештә куллана белә. Традицион шигырьнең потенциаль мөмкинлекләрен киңәйтү-үстерү үрнәкләрен дә бирә бу тыйнак шагыйрь.

Модернизмның ритмсыз «ритмика»сы, шигъри уенчыклары кызыктырмый аны. Фаилдә Әхмәт Фәйзинең яхшы йогынтысы ачык сизелә.

Фаилнең хикәяләрендә дә реаль тормышны яхшы белүе, лирик тел белән сөйли, сурәтли алуы сокландыра.

Фаил Шәфигуллин иҗаты белән дә, кешелек сыйфаты белән дә Союзга алынырга лаеклыларның берсе булып тора.

ХӘСӘН ТУФАН



Кыям Миңлебаев — тәрҗемә өлкәсендә күп эшләгән иптәш. Рус әдәбиятын тәрҗемә итүдә аның зур хезмәтләре бар. Шулар арасыннан игътибарга аеруча лаеклы хезмәтләре итеп Лев Толстойдан «Балачак», «Үсмерчак», «Егетчак», В. Шишковтан «Хәсрәт дәрьясы», В. Катаевтан «Ялгыз җилкән» дигән тәрҗемәләрен күрсәтергә мөмкин. Болардан тыш П. Цвирка, Т. Семушкин, Н. Носов әсәрләренең тәрҗемәләрен дә күрсәтеп үтәргә була.

Кыям Миңлебаев — иҗади тәрҗемәче, Ул рус әсәрләрен, әчтәлегенә һәм стиленә зарар китермичә, саф татарча итәр өчен эзләнеп, уйланып эшләргә тырыша. Бу җәһәттән мин аның «Хәсрәт дәрьясы» дигән тәрҗемәсен күрсәтер идем. Рухы, теле белән гаять русча һәм шул сәбәпле тәрҗемә өчен гаять авыр булган бу әсәрне Миңлебаев татар укучыларына җиңел барып җитәрлек итеп, шактый оста эшләп чыккан. Бу бик зур һәм бик авыр эш.

Кыскасы, мин Кыям иптәш Миңлебаевны танылган җитди тәрҗемәче буларак, безнең Язучылар союзына член итеп алырга тәкъдим итәм.

ӘМИРХАН ЕНИКИ

**Радик Фәизов**

# СОҢГЫ БАТЫР

хикәя



Сабантуй, сабантуй!

Андагы халык дингезен, йөгерешчеләрнең житезлеген, биючеләрнең осталыгын тасвирлап тормыйм. Андагы галәмәтнең сөйләп тә, язып та очына чыгарлык түгел. Алары үзегезнең авылда да бардыр. Тик минә сезгә безнең авыл батырларын күрсәтәсе килә.

Шулай итеп, мәйдан уртасында көрәш китте. Инде данлыклы көрәшчеләр Шашы Гали белән Күшәр Вәли дә егылдылар. Бәрәскә Хисмә тә үзенең пәһлеван буйлы гәүдәсе белән җиргә сузылып, мәйдан кинлеген үлчәде. Уртада күрше бригада егете Сәлмән белән безнең авыл тимерчесе Кәрам гына басып калдылар. Хәзер алар да алыша. Хәзер колхоз батыры булып кем калганны күрәбез.

Иллә таза да икән соң бу Сәлмән! Күпме батырларны чөеп ташлады бит. Ул кунадай җилкәләрен, калку күкрәген күрсәң аның. Алып батырныкыдай сынын күрсәң. Егет түгел, арслан бу. Анысы, безнең Кәрам да салам сыйрак түгел. Төптән юан чыгып үскән яшь имән кебек нык. Беләкләре дә имән тамырлары кебек юан.

Менә шушы ике батыр, күптән күрешмәгән җан дуслардай, берберсен чытырдатып кысып алдылар. Халык аларга куәт биреп, киңәш биреп торды.

— Сынатма, Сәлмән!

— Биленнән ал, Кәрам, биленнән!

— Аяк чалмасын, Сәлмән, аны кара...

— Күтәреп сал, Кәрам, күтәреп!

Әмма Кәрам яклылар отылды. Озак тарткалаша торгач, Сәлмән тимерчене шундый итеп китереп салды, мәйдан уртасындагы җир иңеп кергәндәй булды.

Хәзер Сәлмән, әкияттәге баһадирдай, мәйдан уртасында берүзе басып калды. Менә ул кулын күтәреп тынлык сорады. Әллә шаяртып, әллә көче белән масаясы килепме, сорап куйды:

— Тагын көч сынашырга теләүчеләр юкмы?

Халык тынып калды. Мәйдан кырыена чүгәләгән көрәшчеләр берберсенә карашып алдылар. Ләкин мондый батырга каршы күтәрелүче табылмады. Шунда кинәт халык арасыннан бер тавыш ишетелде.

— Бар, бар! Нишләп булмасын...

Бу тавышның иясе уртага чыккач, халык шаулатып көлеп җибәрде. Бәләкәй генә гәүдәле, йөзе җыерчыкланып беткән, яше алтмыштан узган Сәләхи бабай иде бу. Бабайның авыл даны өчен җанын фида кылырга әзер торган кеше икәнен барысы да беләләр иде. Халык борчыла калды. «Имгәнергә йөрисең, бабай!», «Көрәштермәскә!» дигән сүзләр ишетелде. Сәлмән үзе дә мондый карт белән алышуны түбәнсенде.

— Булмас, Сәләхи абзый, тотынма. Сөякләрең таралыр,— диде.

Әмма картның бирешер исәбе юк иде.

— Ашыкма әле, егет. Кем сөяге таралганын хәзер күрербез,— диде ул. Һәм батырның каршысына ук килеп басты. Кәкре бармагын югары күтәреп, халыкка мөрәҗәгать итте:

— Элгәре минем әйтер сүзем бар әле, җәмәгать,— диде ул. Һәм түбәтәен егетләрчә кыңгыр салды. Сәлмәнгә карап, хәйләкәр тәстә күз кысып алды.— Язгы чәчү вакытында басуга чыктым мин. Күрәм, орлык ташырга, капчык күтәрергә кеше җитешми. Чәчүчеләргә булышып арыгач, ызан буена хәл алырга утырдым. Ишетәм, еракта күк күкрәгәндәй бер гөрелдәү килә. Ызандагы агач төбенә карасам, күзләремә ышанмадым, җәмәгать. Уттай эш көнендә, типсә тимер өзәрлек бер егет йоклап ята иде анда, җәмәгать! Менәтерә...— диде бабай һәм Сәлмәнгә тагын бик мәгънәле итеп күз кысты. Ә тегесе чөгендер кебек булган, кемнәндер шүрләгәндәй як-ягына карана иде.

— Экият сөйләмә, бабай. Урыны бу түгел,— диде ул һәм сөлгесен картның биленә салмак булды. Әмма бабай читкә тайпылды. Кесәсеннән ниндидер кәгазь кисәге алды.

— Бәйрәм алдыннан гына бухгалтер Мәхмүт катына кердем әле мин,— дип дәвам итте ул, халыкка карап.— Анысын-монысын чутладык. Быелгы елда мин, алтмыш яшәрлек карт, җыйнамасы йөз хезмәт көне эшләгәнмен. Ә менә безнең колхозның бер баһадир егете артык өшәнеп киткән димме. Ел башыннан мин эшләгәннең яртысына да куәте җитмәгән, бичараның. Менәтерә...— диде ул һәм тагын нәрсәдер өстәмәкче булды. Ләкин мәйдан халкы аны тыңламый иде инде. Халык гөж килә, баягыдан да битәр шаулатып көлә иде. Сәләхи бабай күзләре белән әле генә каршында басып торган Сәлмәнне эзләде. Әмма Сәлмәннән җилләр искән, ул мәйдан уртасыннан чыгып качкан иде инде.

## ЮБИЛЕЙГА БАГЫШЛАП

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, В. И. Ленинның 100 еллык юбилеена багышлап, Николай Погодинның «Третья патетическая» пьесасын февраль аенда «Баһадирләр» дигән исем белән татар тамашачыларына күрсәтә башлады. Русчадан язучы Гариф Ахунов тәрҗемә иткән ул әсәрне безнең татар сәхнәсенә Мәскәүдәге Кече академия театры режиссеры, РСФСРның атказанган артисты **Михаил Новохижин** куйды. Художнигы — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты **Әнәс Тумашев.** Композиторы — **Владимир Березин.** В. И. Ленин ролен ТАССРның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты **Шәүкәт Биктимиров,** Мария Ильинична Ульянова ролен ТАССРның халык артисткалары **Вера Минкина** һәм **Асия Галиевалар** башкара.



*Рәсемдә: Шәүкәт Биктимиров В. И. Ленин ролендә.*

## ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ КОНФЕРЕНЦИЯ

Шушы елның февраль аенда республикабызның башкаласы Казан шәһәрендә, Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап, студентларның Бөтенсоюз интернациональ фәнни конференциясе үткәрелде. «В. И. Ленин — бөтендөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы һәм остазы» дигән тема буенча Казан дәүләт университетының актлар залында үткәрелгән ул конференциягә, Европа, Азия, Латин Америкасы һәм Африка илләреннән (барлыгы кырык илдән) килеп, Советлар Союзының үндүрт шәһәрендәге уку йортларында белем алучы аспирантлар һәм студентлар катнашты. Өч көн дәвам иткән шул интернациональ конференциянең пленар һәм секция утырышларында йөзгә якын доклад тыңланды. Докладларның күбесе төрле илләрнең иҗтимагый үсешендә В. И. Ленин идеяләренең йогынтысын күрсәтүгә багышланган иде. Конференциядә тыңланган докладларда фәнни коммунизм мәсьәләләренә дә шактый зур урын бирелде. Бу аңлашыла да, чөнки конференциядә катнашучыларның күбесе — соңгы елларда гына мөстәкыйльлеккә ирешеп үсә башлаган дәүләтләрнең вәкилләре. Ә аларга үз илләренең киләчәктә нинди юл белән үсүе турында уйлану — бик табигый хәл.

Конференция дәвамында Ленин идеяләренең көннән көн күбрәк тарала баруы тагын бер тапкыр ышандыргыч дәлилләр белән расланды. «Чад республикасында В. И. Ленин турында нәрсә беләләр?» дигән докладта, мәсәлән: «Илебезнең ерак джунглиларында урнашкан поселокларда да В. И. Ленин хезмәтләре язылган китап һәм брошюраларны таба алуыгызга мин ышанам,— диелде.

Конференциягә килгән чит ил студентлары В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты аспиранты М. Хәйруллинаның социологик эзләнүләргә нигезләнеп язылган «В. И. Ленин хатын-кызларның тигез хокуклылыгы һәм коммунизм төзү чорында аларның социаль активлыгының үсүе турында» дигән докладын да зур кызыксыну белән тыңладылар.

Конференция көннәрендә кунаклар Казанның В. И. Ленин исеме белән бәйле урыннарында булдылар, компрессорлар заводы, С. М. Киров исемендәге синтетик каучук һәм В. В. Куйбышев исемендәге химия заводлары эшчеләре белән очраштылар.

Конференциядә чит иллән килгән укучылар эшләре буенча Бөтенсоюз советы председателе урынбасары Н. Софинский, КПСС Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм институты директоры урынбасары Д. Кукин иптәшләр дә катнашты.

* * *

Казан һәм Ленинград университетларының юридик факультетлары В. И. Ленин исеме белән бик тыгыз бәйләнгән. Зама-

нында В. И. Ленин шул университетларның юридик факультетларында укыган. Менә шуны истә тотып һәм КПСС Үзәк Комитетының «Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга хәзерлек турында»гы карарын тормышка ашыру йөзеннән, әлеге ике факультет галимнәре бергәләп фәнни конференция үткәрделәр. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында үткәрелгән ул конференция ленинизмның иң әһәмиятле тармакларыннан берсе — социалистик дәүләт һәм хокук турында Ленин теориясе һәм социализм төзү практикасында аның гәүдәләнеше дигән темага багышланган иде. Казан һәм Ленинград университетлары галимнәреннән тыш, конференциядә Мәскәү, Харьков һәм Советлар Союзының башка күп кенә шәһәрләреннән килгән юрист-галимнәрнең кырыктан артык доклады һәм информациясе тыңланды, В. И. Ленинның дәүләт һәм хокук турындагы теоретик мирасының актуаль проблемалары каралды.

Конференциядә Казан галимнәреннән университет профессоры Р. И. Нәфиковның «В. И. Ленин Казан дәүләт университетында» дигән чыгышы, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе, доцент С. Г. Батыевның «В. И. Ленин һәм Татарстан Совет Автономиясе» дигән һәм башка чыгышлар тыңлады.

* * *

Шушы елның 16—17 январенда Казандагы А. М. Горький музеенда В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган фәнни конференция үткәрелде. Анда филология фәннәре докторы Б. А. Бяликның «Ленин һәм Горький», филология фәннәре кандидаты С. С. Зиминның «Ленин һәм Горький» исемле җыентыкның өченче басмасындагы яңа материаллар», филология фәннәре докторы М. Х. Гайнуллинның «Татар әдәбиятында В. И. Ленин образы», Казандагы Горький музееның фәнни хезмәткәре В. З. Дәүләтшинаның «Сибгат Хәким поэзиясендә В. И. Ленин образы», композитор Җәүдәт Фәйзинең «Татар музыкасында Ленин» дигән темага докладлары һәм Мәскәүдәге А. М. Горький музее директоры М. Б. Козьминның В. И. Ленинның 100 еллыгына әзерлек буенча музейда алып барыла торган эшләр турындагы чыгышы тыңланды.

## КИНОЛЕНИНИАНА

СССР Министрлар Советы каршындагы кинематография комитеты карары буенча, «Ленин идеяләре яши һәм җиңә» дигән девиз белән, В. И. Ленинның 100 еллыгына багышлап, 1970 елның гыйнвареннан апрель аена кадәр республикабызда тематик кинолар күрсәтү үткәрелде. Татарстан кинопрокат коллективы бу зур кино бәйрәменә нәфис, документаль һәм фәнни-популяр фильмнардан торган бай һәм күп төрле репертуар әзерләгән иде.

Соңгы вакытта совет кинематографистлары В. И. Ленинның тормышын һәм революцион эшчәнлеген чагылдыруга багышланган «Дөнья өстендә байрак», «Без Ильич белән бардык», «Аның исеме үлемсез», «Ленин белән бер минут» исемле яңа ленталар әзерләгәннәр һәм ул фильмнар экраннарда зур уңыш белән барды.

1969 елда Казан кинохроника студиясе дә кинолениннанага үзеннән өлеш кертте: «Ленин Казанда» исемле документаль фильм эшләде һәм республикабыз авылларында әле дә яратып карала торган «Алтынчы июль» исемле нәфис фильмны татарчага тәрҗемә итте.

## МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР ТУРЫНДА

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты бюросы Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләрен бирү вакытларын үзгәртү һәм премияләр комитетының составын раслау мәсьәләсен карады.

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуны һәм ТАССРның 50 еллыгын бәйрәм итү уңае белән, 1969—1970 еллар өчен Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләрен бирү 1970 елның июненә күчерелде. Премияләр комитетына хезмәтләрне тәкъдим итү срогы 1970 елның 1 маена кадәр билгеләнде.

Бюрода Муса Җәлил исемендәге премияләр комитеты да расланды. Аның составына түбәндәге иптәшләр кертелде: И. К. Хәйруллин — ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре (комитет председателе); Ю. З. Әминов — ТАССР Культура министры урынбасары (комитет председателе урынбасары); Л. С. Сәләхетдинова — ВЛКСМ өлкә комитетының культура-масса эшләре секторы мөдире (комитет секретаре) һәм башкалар.

## БЕЗНЕҢ ЮБИЛЯРЛАР

Язучы һәм РСФСРның һәм Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты Габдулла Шамуковка 60 яшь тулу уңае белән шушы елның 2 февралендә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында юбилей кичәсе үткәрелде. Г. Шамуковның тормышы һәм иҗат юлы турындагы докладтан соң (докладны Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре Дания Гыймранова ясады) юбиляр адресына килгән котлау сүзләре укылды, кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Татарстан язучылар союзы һәм «Казан утлары» журналы редакциясе Г. Шамуковка менә шушындый котлау сүзләре язылган адрес тапшырдылар:

*«Язучы, тәрҗемәче, күренекле артист дустыбыз, каләмдәшебез, Габдулла Шамуков!*

*Сәхнәдә Сез иҗат иткән берсеннән-берсе кызыклы, чын тормыштагы кебек җанлы образларга караганда, Сез язган үткен фикерле тапкыр мәсәлләрне укып, күңелле елмайганда, әллә ничек, 60 яшькә җиткәнсездер дип уйлаган да юк иде. Гаҗәп, 60 яшь дигәнең кайберәүләргә шулай сиздермичә генә килә бит ул. Әдәбият, сәнгать, театр өлкәсендә тынгысыз, иҗат эшчәнлегегезгә дә 40 ел тулган. Халкыбыз өчен*

*эшләгән эшләрегез шулкадәр күп, сәнгатебез, культурабыз үсешенә керткән өлешегез шулкадәр зур, Сез безгә күп кенә үткен, тирән фикерле мәсәлләр, драма әсәрләре, балалар өчен пьесалар, Шекспир, Шиллер, Пушкин, Грибоедов, Эсхил әсәрләрен тәрҗемә иткән тәҗрибәле тәрҗемәче, әдәбият һәм тарихка кагылышлы кызыклы мәкаләләр язучы әдип буларак та, «Хуҗа Насретдин», «Мулланур Вахитов», «Тукай», «Җилкәнсезләр», «Зифа», «Ревизор», «Ике хуҗаның хезмәтчесе» һ. б. бик күп спектакльләрдә онтылмас образлар иҗат иткән талантлы артистыбыз буларак та якын һәм кадерле. Ә инде татар театры сәхнәсендә беренче булып Владимир Ильич Ленин образын тудыручы артист буларак, без Сезнең сәхнә осталыгыгызга чын күңелдән сокланабыз, Сезнең белән горурланабыз. Шулай ук сәхнәдә Сез иҗат иткән бөек шагыйребез Габдулла Тукай, халкыбызның мәңге үлмәс Хуҗа Насретдин образлары Сезнең талантыгызның күп кырлы булуын раслап, безнең күңелләрдә саклана. Сезнең әле иҗатыгызның гөрләп торган чагы, Сез әле театр сөюче тамашачыларыбызны үзегез иҗат иткән замандашларыбызның матур образларын гәүдәләндереп куандырырсыз, әдәбият сөючеләребезгә яңадан-яңа әсәрләр бүләк итәрсез. Каләмегезнең карасы кипмәсен, йөрәгегезнең ялкыны сүрелмәсен, сәхнәдә канатланып очып йөргәндәй җиңел хәрәкәтләрегез бер кайчан да сүлпәнәймәсен!*

*Олы юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз, Сезгә нык сәламәтлек, бәхет, шатлык, иҗат уңышлары телибез».*

Котлаулардан соң юбиляр төп рольләрне башкарган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде: Габдулла Шамуков Н. Погодинның «Мылтыклы кеше»сендәге Ленин образын һәм Н. Исәнбәтнең «Зифа»сындагы Илдерхан рольләрен уйнап күрсәтте.

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән **Габдулла Рухулла улы Шамуков Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Күренекле композиторыбыз Җәүдәт Фәйзигә шушы елның январь аенда 60 яшь тулды. Шул уңай белән Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында композиторның юбилей кичәсе үткәрелде. Анда республикабызның партия, совет, профсоюз, комсомол һәм иҗат оешмалары вәкилләре, тугандаш республикалардан һәм өлкәләрдән килгән кунаклар, эшчеләр һәм студентлар катнашты.

КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм ТАССР Министрлар Советы исеменнән юбилярны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев котлады. Аннары Җәүдәт Фәйзигә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тапшырылды.

Юбилярны республикабыздагы иҗат оешмалары вәкилләре, тугандаш республикалардан һәм өлкәләрдән килгән кунаклар да кайнар котладылар.

Соңыннан республикабыз сәнгать осталары Җәүдәт Фәйзи әсәрләрен башкардылар һәм «Башмагым» музыкаль комедиясеннән өзекләр уйнап күрсәттеләр. Театр фойесында юбилярның музыка сәнгатендәге эшчәнлеген гәүдәләндергән күргәзмә дә оештырылган иде.

* * *

Февраль аенда күренекле әдәбиятчы, филология фәннәре кандидаты Хәсән Хәйригә 60 яшь тулды. Шул уңай белән СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында 6 февральдә тантаналы утырыш үткәрелде. Утырышта филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин юбилярның тормышы һәм иҗаты турында доклад ясады, юбиляр адресына килгән котлаулар укылды.

ТАССР Верховный Советы Президиумының 4 февральдә игълан ителгән Указы нигезендә, татар совет филологиясен үстерүдәге хезмәтләре өчен СССР фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты әдәбият секторы мөдире **Хәсән Фәхретдин улы Хәйруллинга Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

## «ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ»НӘ 50 ЕЛ

Республикабыз яшьләренең якын дусты, киңәшчесе булган «Татарстан яшьләре» газетасы чыга башлауга шушы елның январенда 50 ел тулды. Шул уңай белән 23 январьда Актерлар йортында газетаның юбилей кичәсе үткәрелде. «Татарстан яшьләре»нең 50 еллык тарихы турында газетаның җаваплы редакторы Салих Гарипов доклад ясады. Аннары газета адресына килгән күп санлы котлау адреслары укылды, бүләкләр тапшырылды. Соңыннан Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары көче белән газетаның 50 еллыгына багышланган бик әйбәт концерт бирелде.

Яшьләрне коммунистик тәрбияләүдә актив катнашуы өчен һәм чыга башлавына 50 ел тулу уңае белән, «Татарстан яшьләре» газетасы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының, ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм Татарстан мәгариф министрлыгының **Почет грамоталары** белән бүләкләнде.

Газетага илле яшь тулу уңае белән һәм яшьләрне коммунистик тәрбияләүдә нәтиҗәле эш башкарганнары өчен «Татарстан яшьләре»нең җаваплы редакторы Салих Гарипов, хатлар бүлеге мөдире Суфия Әхметова һәм редакция машинисткасы Вәсимә Ишалина Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының **Почет грамотасы** белән; художник Әнәс Әмирханов, корректоры Мәүлүдә Гыйззәтуллина, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Җәүдәт Кәлимуллин, әдәби хезмәткәр Шамил Маннапов һәм җаваплы секретарь Әмин Раков КПСС өлкә комитетының һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** белән бүләкләнделәр.

Үзләренең әсәрләре, мәкаләләре белән «Татарстан яшьләре»ндә озак еллар буена катнашып килгән язучыларыбыздан **Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Зәки Нури, Ләбибә Ихсанова, Габдрахман Минский, Нәби Дәүли һәм Самат Шакирны газета редакциясе үзенең Почет грамотасы белән бүләкләде.**

## БАШКОРТ ТЕАТРЫ ЮБИЛЕЕ

Быел Уфадагы башкорт театрының эшли башлавына 50 ел тулды. Шул уңай белән 6 февральдә театр бинасында тантаналы юбилей кичәсе үткәрелде.

Ул кичәдә Татарстаннан Г. Камал исемендәге татар академия театры директоры, Татарстанның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншина, драматург Хәй Вахит, сәнгать белгечләре Хәсән Гобәйдуллин һәм Роза Усманова иптәшләр катнашты. Р. Җиһаншина татар артистлары исеменнән дуслар театрына котлау адресы һәм истәлекле бүләк тапшырды.

## КҮРГӘЗМӘ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

В. И. Ленинның 100 еллыгына багышлап, Татарстанның сынлы сәнгать музеенда художество һәм сәнгать училищелары укучылары иҗат иткән әсәрләрнең Бөтенроссия күргәзмәсе үткәрелде. Ул күргәзмәгә Россия федерациясе өлкәләреннән һәм автономияле республикаларыннан 22 училище үзләренең иң яхшы рәссамнарының әсәрләрен алып килгәннәр иде. Илебезнең иң өлкән художество училищеларының берсе булган Казан художество училищесы (ул Россиядә Ленинградтан кала икенче булып ачылган) укучыларының күргәзмәгә 32 хезмәте куелды. Казан тамашачылары яшь рәссамнарның 500 хезмәтен чагылдырган ул күргәзмәне яратып карадылар.

## ТАБЫШМАКЛАР КИЧӘСЕ

6 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында табышмаклар кичәсе булды. Филология фәннәре кандидаты Хуҗи Мәхмүтов башта кичәгә җыелган халыкка табышмакларның тарихы турында кыска, әмма тирән эчтәлекле лекция укыды. Аннары «Яшь ленинчы», «Азат хатын», «Татарстан яшьләре» һәм «Казан утлары» редакцияләре хезмәткәрләре Р. Мингалимов, Т. Камалиев, М. Маликова, Ш. Маннапов һәм В. Нуруллин иптәшләр составында жюри сайланып, табышмакларга җавап табу конкурсы башланды. Конкурс нәтиҗәсендә С. Мөхәммәтшина (студентка), Р. Хәнәфиева (конструктор), И. Мортазин (экономия фәннәре кандидаты), Х. Гатина, Ф. Зыятдинов (фәнни хезмәткәрләр), С. Ибраһимова (эшче), Х. Монасыйпов (инженер) һәм Ф. Батуллин иптәшләр җиңүче дип табылды һәм аларның барысына да кыйммәтле бүләкләр бирелде. «Казан утлары» редакциясенең бүләкләре (татар түбәтәйләре) И. Мортазин һәм Х. Монасыйпов иптәшләргә бирелде.

## ИҖАДИ ЯШЬЛӘР БЕРЛӘШМӘСЕ

Узган елның декабрь аенда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты каршында «Иҗади яшьләр берләшмәсе» оештырылды. Берләшмә биш секциядән тора. Яшь язучылар — әдәбият секциясен (председателе Гәрәй Рәхим), яшь композиторлар, башкаручылар — музыкаль секцияне (председателе Рафаэль Билялов), яшь рәссамнар — художество секциясен (председателе Илдар Әхмәдиев), яшь актерлар һәм башкаручылар — театраль секцияне (председателе Юрий Федотов) тәшкил итәләр. ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты бюросы берләшмәнең председателе итеп язучы Роберт Батуллинны раслады.

Бу яңа берләшмә сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗат итүче яшьләрнең яңа әсәрләрен пропагандалау, республикабыз клубларында, культура сарайларында, предприятиеләрдә, завод-фабрикаларда һәм колхоз-совхозларда хезмәт ияләре белән иҗади очрашулар, сәнгать кичәләре оештыру, комсомолның удар төзелешләрендә, шәһәрләрдә һәм районнарда булып, хезмәт кешеләре турында яңа әсәрләр иҗат итү, сәнгать конкурслары, күргәзмәләр уздыру, яшь иҗатчыларның ялын һәм хезмәтен тагын да уңайлырак итеп оештыру максатыннан чыгып төзелде.

Берләшмәнең узган елның декабрь аенда булып үткән оештыру кичәсе үк чын мәгънәсендә яшьләрнең сәнгать бәйрәменә әверелеп китте. Казанның Актерлар йортына яшь язучылар, композиторлар, рәссамнар, актерлар, башкаручылар, журналистлар, студентлар һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре җыелган иде.

Январь аенда берләшмәнең икенче кичәсе үткәрелде. Татарстанның яшь әдипләре белән яшь актерлары оештырган ул кичәдә яшь әдипләрдән һәм актерлардан төзелгән ике команда узара тапкырлык ярышы үткәделәр. Бу кичәгә олы әдипләребез Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур, Әхмәт Исхак, Фатих Хөсни һәм шулай ук олы буын актерлар да килгән иде.

23 февральдә иҗади берләшмәнең әдәбият секциясе яшь шагыйрьләрнең иҗат кичәсен үткәрде. Актерлар йортында уздырылган ул кичәдә шагыйрьләрдән Р. Гатауллин, Г. Рәхим, Р. Мингалимов Ленинга, партиягә, илгә һәм комсомолга багышланган шигырьләрен укыдылар.

*Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ